АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени Г.ИБРАГИМОВА

Габдулла Тукай
Сочинения

Академическое издание
В шести томах

Том 1

Поэтические произведения
(1904 –1908)

Казань
Татарское книжное издательство
2011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г.ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Габдулла Тукай
Әсәрләр

Академик басма
Алты томда

1 том

Шигъри әсәрләр
(1904 –1908)

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2011

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Т72

Редколлегия :

К.М.Миңнуллин (җитәкче), Т.Н.Галиуллин, Д.Ф.Заһидуллина,
Х.Й.Миңнегулов, Р.Ф.Рахмани, З.З.Рәмиев, Р.Г.Фәйзуллин,
Н.Ш.Хисамов, Д.С.Шакиров

Төзүчеләр, текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны
әзерләүчеләр :

Р.М.Кадыйров, З.Г.Мөхәммәтшин

Фәнни мөхәррире

Зөфәр Рәмиев

Тукай, Г.М.

Әсәрләр : 6 томда / Габдулла Тукай. – академик басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.

ISBN 978-5-298-02041-1

1 т. : шигъри әсәрләр (1904–1908) / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл. Р.М.Кадыйров, З.Г.Мөхәммәтшин ; кереш сүз авт. Н.Ш.Хисамов, З.З.Рәмиев. – 2011. – 407 б.

ISBN 978-5-298-02042-8

Әлеге томда татар әдәбияты классигы Габдулла Тукайның 1904–1908 елларда иҗат ителгән шигырьләре, балладалары, поэмалары, балалар шигырьләре хронологик тәртиптә туплап бирелде. Шулай ук Тукайныкы булуы ихтимал әсәрләр дә урын алды.

Китап Тукай иҗаты белән кызыксынган киң катлау укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

УДК 821.512.145-1

ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-02042-8 (1 т.)

ISBN 978-5-298-02041-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2011

© Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011

## Редколлегиядән

Габдулла Тукай әсәрләренең 6 томлы тулы академик басмасы беренче мәртәбә әзерләнә. Аның 1 нче һәм 2 нче томнарында шагыйрьнең мәгълүм булган барлык шигъри әсәрләре урнаштырылып, калган томнарында прозасы, публицистикасы, сатирик мәкаләләре, фельетоннары, әдәби тәнкыйте, балалар өчен язылган әсәрләре, очерклары, кульъязмалары һәм хатлары урын алачак. Томнарда текстлар хронологик тәртип буенча урнаштырыла, даталар иске стильдә күрсәтелә. Тукайның кульъязмалары бик аз сакланганлыктан, әсәрләр газеталарда һәм журналларда чыгу яисә китап-җыентык рәвешендә дөнья күрү вакытына карап куела.

Бу басмада Тукайның авторлыгы әле тулысынча расланмаган, ул язуы ихтимал булган яисә аныкы дип гөман ителә торган әсәрләр аерым бүлек итеп бирелә. Гарәп язуындагы Тукай әсәрләренең тел-стиль үзенчәлекләрен кириллицада төгәл бирү мөмкин түгел, шулай да аеруча характерлылары төп нөсхәдәгечә саклана. Тыныш билгеләре, гомумән алганда, бүгенге кагыйдәләр таләп иткәнчә кулланылды (шигъри әсәрләрдә интонация таләбе дә искә алынды).

Томнардагы һәр текстка искәрмә һәм аңлатмалар бар. Анда әсәрнең иҗат ителү һәм шагыйрь үзе исән чакта басылу тарихы, имзалары, текст үзгәрешләре, замандашлары, баштарләре тарафыннан бәяләмәләр турында мәгълүматлар китерелә, текстларда чагылыш тапкан тарихи вакыйгалар, телгә алынган реаль шәхесләр хакында да кыскача гына белешмә бирелә.

Текстларда очрый торган гарәп-фарсы алынмаларының сүзлекчәсе бернинди ишарәсез, Тукайның үз искәрмәләре һәм төзүчеләрнең кайбер шигъри юлларга аңлатмалары йолдызчык (*) белән күрсәтелә. Текстлардагы аерым сүзләр, гыйбарәләр, ялгызлык исемнәре янындагы саннар том ахырында аларның һәрберсенә дә искәрмә һәм аңлатма язылганлыгын искәртә.

Тукай әсәрләрендә очрый торган ялгызлык атамалары исемлеге соңгы томда урнаштырылачак.

## Тукай: бөеклеге һәм фаҗигасе

Тукай – XX йөздә татар шигърияте яңарышын иң югары кимәлдә гәүдәләндергән сәнгатькәр. Шигъриятебез үсешенә ул ясаган этәргеч һәм йогынты шундый тирән булды ки, татар поэзиясе бүген дә шушы маяның тиңсез колачын үзләштерү һәм үстерү дәрте белән яши. Татар шигыре яшәешендә Тукайдан соң аның казанышларыннан үсеп чыккан буыннарның берничә пассионар1 кабынышы булып алды. Такташлы, Җәлилле буыннардан соң «алтмышынчылар» буыны шушындый кабынышларга туры килә.

Шигърият белеме инде күптән Тукайны дөньяның иң бөек шагыйрьләре сафында күрә. Без аны хаклы рәвештә дөнья шагыйре итеп саныйбыз. Төрки халыклар өчен ул – аларның үз шагыйре, үз язма мәдәнияте. Электән килгән төрки халыклар шигъриятенә аның йогынтысы органик һәм бәрәкәтле булды. Үзбәк, төрекмән, уйгур, хәтта таҗик әдипләре дә рус һәм Европа шагыйрьләрен Тукай аша үзләштерүләрен яздылар.

Тукай – төрки шигъриятә гарузның XX гасырдагы соңгы шагыйре. Бу шигърият тарихында эпохаль пассионар кабынышлар 4–5 гасырга бер күзәтелә. XI гасырда – Йосыф Баласагунлы, XV гасырда – Нәваи, XX гасырда – Тукай. Ул бөтен төрки шигъриятнең 1000 еллык үсешенә йомгак ясый.

Шигърияттән, публицистика һәм чәчмәдән торган бу иҗатның үсешен концептуаль-мәгънәви яктан күзәтеп чыксак, сүзне аның публицистикасыннан башларга тиешбез. Чөнки шигъриятендәге тирән мәгънәләрне төшенүгә төгәл ачкычны аның публицистикасы бирә.

Тукай – милли уяныш җырчысы булып мәйданга чыккан шагыйрь. Ул – иҗтимагый-мәдәни офыкка даһиларча киң караш ташлап, татарның тарихта нәрсәләр югалтканын һәм нинди хәлдә калганын гаҗәеп төгәл күргән иҗатчы. Аның 1906 елда Уральск шәһәрендә чыга торган «Фикер» газетасында бастырган «Хиссияте миллия» исемле програм

мәкаләсе яшь зыялыларның манифесты булып яңгырый. Шагыйрь артталыкның сәбәбен һәм бу хәлдән чыгу юлларын гаять төгәл күрә, универсаль фактор итеп укуны саный. Ул үзенең әлеге публицистик мәкаләсендә чоры өчен үткен һәм хәзерге заман өчен дә актуаль вә татарның милли табигатен чагылдырган афористик формулалар эшли:

«Укымак – фикерләрне җирдән күккә җибәрмәк. Укымак – үз янында булып торган нәрсәләрдән бигрәк, фикерләрне булачакларга сузмак. Укымак – үткәннәрдән кичеп, киләчәкләр – истикъбальләр тугърысында пәйгамбәрлек итмәк...»;

«“Укымак” ләфзы астында моның кеби хисапсыз мәгънәләр чыкса да, барчасы үз халкымызга хезмәт итмәк, дигән сүзгә кайтадыр...».

Укуның, белем алуның асыл мәгънәсен, ягъни иҗтимагый әһәмиятен Тукай тирән төшенеп яза: «Бу... безнең азат булуымызга вә бюрократия золымыннан, башка милләтләр илә берлектә, безнең дә котылуымызга иң беренче вә иң тугъры юлдыр».

Әлеге өзекләр – шагыйрь иҗатының гаҗәеп бөтенлеген күрергә ярдәм итә торган ачкыч та. Шагыйрь, татарның милли уянышы, азатлыгы, күтәрелеше хакында хөкем йөрткәндә, «башка милләтләр илә» эш итүне күздә тота. Ул – иҗатының буеннан-буена эзлекле интернационалист. Әлеге мәкаләдә күзгә чалынып үткән «җирдән күккә җибәрмәк», «пәйгамбәрлек итмәк», «үз халкымызга хезмәт итмәк» мотивлары алга таба Тукай иҗатында зур-зур идея һәм тематик юнәлешләр булып үстерелә: «Әйдә халыкка хезмәткә» («Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр»), «Сөйләргә башладым хакны» («Пәйгамбәр») һ.б.

Табигый ки, Тукай милләт алгарышын әдәбиятка бәйли. Ориентир буларак, аның күз алдында рус әдәбиятының XIX һәм XX йөз башы казанышлары тора. «Безнең милләт тә, башка милләтләрдәге кеби, хамисез, мәлҗәэсез, фәкыйрь вә эшче халыкның файдаларына тырышучы, биш фәкыйрьне бер бай этенә алмаштырыр вакытлар үткәнлеген аңлаучы вә аңлатучы егетләргә мохтаҗ. Безнең милләт тә Пушкиннәргә, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ. Кыскасы гына, безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккъыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссәмнәргә, ...яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә, вә гайреләргә мохтаҗ», – ди ул.

Тукай иҗаты, шәхесе һәм чоры татар әдәбият фәнендә, иҗтимагый, фәлсәфи фикер тарихында тирән һәм төрле яклап яктыртылган. Бу феноменның контур сызыклары шактый төгәл һәм тулы билгеләнгән. Чөнки шушы бәрәкәтле теманы һәм затлы, алай гына да түгел, изге бурычны үз өсләренә үтә җитди һәм талантлы галимнәр алган. Җамал Вәлидидән башлап, Хатип Госман, Гали Халит, Якуб Агишев, Ибраһим Нуруллин, Рәфыйк Нәфигов, Рөстәм Башкуров кебек күренекле тикшеренүче-галимнәр шагыйрь иҗатының мәгънәви эчтәлеген, сәнгатьчә гүзәллеген, фикри колачын ачуга бөтен гомерләрен багышладылар. Бу исемлек янына Резеда Ганиева, Наип Лаисов кебек әдәбият белгечләрен өстәргә кирәк. Алар Тукай шигъриятенең ике мөһим өлкәсе – сатирасы һәм лирикасы турында махсус хезмәтләр яздылар.

Кыскасы, татар, киңрәк – совет әдәбият фәнендә, хәзер исә Россия әдәби фикер дөньясында «Тукай нинди шагыйрь ул?» дигән сорауны куюның кирәге юк, чөнки әсәрләренең тәрҗемәсе, галимнәрнең хезмәтләре һәм халыкның күңелендә саклануы аның бөек һәм даһи сәнгатькәр икәнен инде күптән раслады.

Әмма, бөек сәнгатькәр буларак, аның иҗат серләре чиксез, чөнки ул үз чорыннан күпкә өстен торып иҗат иткән, заманга, иҗтимагый гамәлләргә, әхлакка киләчәктән торып бәя биргән. («Ваксынмыйм» дигән шигырен генә искә төшерик.)

Шунлыктан Тукай феноменын кайта-кайта фикердән кичерүгә, иҗатының төрле һәм яңадан-яңа якларын тикшерүгә булган ихтыяҗ бервакытта да туктамаячак. «Аның бөеклеге нәрсәдә?» дигән сорауны һәр чор яңартачак һәм шуңа җавап эзләячәк.

Тукай бөек иҗади мирас калдырган, һәм шуның үзәгендә, һичшиксез, иң зур, мөһим урынны шигърият били. Ил һәм дөнья мәдәниятендә ул бөек шагыйрь буларак тәкъдир ителә. Шунлыктан иҗатының киң һәм иң тирән өйрәнелгән өлкәсе дә – шигърият. Әмма бу өлкәдәге карашларны тагын да конкретлаштыру һәм тирәнәйтү өчен, мотлак, публицистикасына, чәчмәсенә, аеруча хатларына мөрәҗәгать итәргә кирәк.

«Китмибез!» шигыренең азаккы юлларындагы иҗтимагый иман формуласын гына алыйк:

Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт – хөр Русия!
Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе русияһ!

Бу аның – Россия Дәүләт Думасындагы Пуришкевич кебек карагруһчы депутатларның татар халкы адресына ташланган провокацион репликасына җавабы. Хәлбуки ул бәхәс кайнарлыгы белән генә яңгыраган аваз түгел. Ул – татар халкының, аның алдынгы зыялы көчләренең иманы. Бу юллар хәзер дә актуаль яңгырый.

Тукайга килгәндә исә, әлеге патриотик, гали яңгырашлы юллар аның Россия шагыйре дә, Россиянең чын ватандар улы да булуын күрсәтә. Һәм бу караш аңарда һич тә «аның дипломатлыгыннан һәм сәяси эшлекле» (С.Рәмиевкә язган хатын искә төшерик) булуыннан гына килгән конъюнктур бизәкләр түгел, бәлки шагыйрьнең тирән иманыннан туган юллар. Моның шулай икәнлеген без аның матбугаттагы беренче чыгышларыннан ук күрәбез. Япон сугышы һәм аның аяныч нәтиҗәләре турындагы «Мөхәрәбә вә Государственная Дума» исемле мәкаләсе «Әлгасрелҗәдид» журналында 1906 елда басылган. Егерме яшьлек шушы публицистның югары дәрәҗәдәге сәяси аеклыгы һәм икътисади фикерләвенең җитлеккән булуы таң калдыра. Әмма хикмәт анда гына түгел, җавапсыз сәясәтче һәм комсыз байларның Россиягә, рус халкына китергән зур зыяннары өчен ул ихлас күңеленнән көенә: «...алтынга коенган һәм күмелгән бу вәхшиләр 100 миллионлык бөек Русияне, алдап, ...Япония белән сугыштыра алдылар. ...Хәзер һәр җирдә: авылларда, шәһәрләрдә кулсызларга, аяксызларга, мәңге зәгыйфь булып калганнарга очрау бик җиңелдер», – дип сыкрана ул. Шагыйрь шул рәвешле Россия ватандашы булып, Кеше булып хөкем йөртә. Шуннан аның «Пушкинә» дигән шигырендәге шушы юлларның тирән мәгънәсе аңлашыла төшә:

Мәрамем-матлабым анчак сәнең мәнзум вә мәнсүрең;
Бәнем шәэнемме тәфтиш мәзһәбеңне, дине мәнсүбең?

Хәзерге әдәби телдә

Бар теләк-максатым минем – тезмәң, чәчмәләрең синең;
Минем эшмени тикшерү – карашың синең һәм динең?

Шагыйрь интернационализм белән органик рәвештә сугарылган киң карашлы, зыялы гражданин булып күз алдына баса.

Аның асыл карашлары һәм югары заты публицистикасында һәм хатларында гәүдәләнә. «Мич башы кыйссасы» дигән язмасында бер авылдагы рус агае белән әңгәмәсе китерелә. Шунда ул рус агаена Россиядә руслар белән татарлар арасындагы бердәмлекнең ил куәте өчен ничаклы мөһимлеге турында сөйли: «Без – руслар белән татарлар – һәрвакыттагы кеби, тату гына, честный гына алыш-биреш итеп тора алабыз».

Гомеренең азагына ул, рус-татар мөнәсәбәтләре тарихын даһиларча гомумиләштереп, туган халкы һәм руслар өчен гасырларга исәпләнгән гамәл өлгесен болай формалаштыра:

Рус җирендә без әсәрле, эзле без,
Тарихында бер дә тапсыз көзге без.
Рус белән тормыш кичердек сайрашып,
Тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып...

Һич бетәрме тарихи бу бергәлек? –
Без туган бер җепкә бергә теркәлеп...
Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? –
Хаккыбыз уртак ватанда шактый ук!

(«Олуг юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре»)

Татар халкының тапсыз намусы һәм милли хокуклары мәсьәләсе биредә кистереп әйтелгән. Бу фикер, мотивлар татар халкы һәм Татарстан өчен бүген дә үткен, актуаль яңгырый.

Шагыйрьнең сугышка мөнәсәбәте дигәндә, ул – гомумән сугышка каршы, пацифист рухлы зат. Менә аның «Кышка бер сүз» шигыре:

Тиз югал, и кыш бабай, син ал да тиз кач карт башың,
Барыбер, күрсәң, качарсың, язны – гөлләр патшасын!

Бер дә юк ул патшаның мылтык-кылыч, алмаслары,
Һәр ягында аллы-гөлле күбәләктән гаскәре.

Сурәттәге камил нәфислекне инде әйткән дә юк, шагыйрьнең тынычлык, коралсыз яшәү хыялы чагыла бу шигырьдә. Татар шигъриятендәге бу мотив Кол Галидән үк килә.

Тукайның дөньяга карашы хатларында аеруча тулы ачыла. Әдәби барышка ул үзенең шигъри иҗаты белән генә түгел, хатлары аша да актив йогынты ясаган. Аның замандашлары, каләмдәшләре белән язышуыннан шигъри иҗат, рус шигърияте, дөнья әдәбияты турындагы төшенчәләре, мәгълүматы ничаклы тирән һәм төгәл булуына сокланасың. Компетентлы сәнгатькәр буларак, шагыйрьнең рус шигъриятендәге күренешләргә үз карашы бар. Мәсәлән, С.Сүнчәләйгә язган бер хатында ул: «Никитиннең фитри (тумыштан бирелгән. – Н.Х.) таланты, минемчә, Пушкиннән ким түгел. Фәкать ул тәртипле образование алып, гакылын вә рухын кирәгенчә тәрбия итә алмаган. Бу – шактый кирәкле фактор», – ди (1911 ел, 4 март).

Яки Сүнчәләйгә язган икенче бер хатында мондый фикерләрне укыйбыз: «С.Р.нең (Сәгыйть Рәмиевнең. – Н.Х.) вәзеннәр тугърысында артык лаф сугуына исегез китмәсен. Әле без татарларда теория словесности вә шигырьләр өчен хорей, дактиль-фәләннәр

ясалмаган чакта, вәзен вә гармонияләр төрлечә булса да зарар юк, фәкать мәгънә кирәк, гүзәл ифадә кирәк... Тургеневнең көйсез язылган «Отцы и дети» әсәре прозамыни? Анда вәзен рамкалары бер дә юк. Ә между прочим – поэзия!» (1911 ел, 1 гыйнвар). Русның хәзерге әдәбият галимнәренә ятыша торган фикерләр бу. Менә шагыйрьнең дөнья әдәбиятын тәрҗемә итүгә кагылышлы тагын бер киңәше. Ул Сәгыйть Сүнчәләйгә болай яза: «“Шильон мәхбүсе”нә, минемчә, иртәрәк, көчегезнең микъдарын үлчәмичәрәк тотынганга охшыйсыз. Әүвәлдә 4–5 сәтырлык (юллык. – Н.Х.) шигырьләрне асыл шагыйреннән калышмаслык дәрәҗәдә, гүзәл вә нәфис чыгарырга тырышырга кирәк иде. Менә Сәгыйть Рәмиев – Пушкин «Пәйгамбәр»ен, мин фәкыйрь дә Лермонтов «Пәйгамбәр»ен тәрҗемә иттек. Безнең икебезнеке дә шактый шома чыктылар. Шулай да без әле олугъ поэмаларга тотынырга батырчылык итә алмыйбыз» (1910 ел, 4 декабрь). Ниһаять, Байронның «Шильон мәхбүсе» тәрҗемә ителеп бетә. Тукай аңа хатында: «“Шильон мәхбүсе”н «Гасыр» (нәшрият. – Н.Х.) дөньяга чыгарса, сезне беренче муэффәкыятегез (уңышыгыз. – Н.Х.) белән тәбрик итәчәкмен», – дип яза (1911 ел, 22 гыйнвар). Соңрак поэманың тәрҗемә басмасына Тукай кереш сүз яза һәм бу казанышны хуплап чыга: «Менә шушы бөтен дөньяга «байронизм» мәзһәбен (юнәлешен. – Н.Х.) тудырган... бөек, югары вә гүзәл бер хисне руи зәмингә (җир йөзенә. – Н.Х.) агызып җибәргән кешенең кулга алырлык берәр әсәре безнең татар теленә күчерелгәне бар идеме? – Әлбәттә, юк иде. Инде бу бурычны Сәгыйть әфәнде үтәде».

Озакламый Тукай үзе дә дөньякүләм әдәби факторга әйләнә. ХХ йөзнең бөек әдибе Максим Горький үзенең С.Н.Сергеев-Ценскийга язган хатында бу дөньяның сүз сәнгатькәренә һәрвакыт рәхимсез караганлыгына дәлил итеп, Тукайның « Өзелгән өмид» шигыреннән «Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы» дигән юлны китерә. «“Вәгазьчеләр сәнгатькәрләрне бугазыннан ала”, – дип зарланасызмы? Кадерле С.Н., бу бит һәрвакыт шулай булган. Бу дөнья сәнгатькәрләр өчен түгел, аларга анда һәрчак кысан һәм җайсыз булган – шуның саен аларның роле хөрмәтлерәк һәм каһарманрак та. Бер Казан татары – шагыйрь… чахоткадан үлгәндә: «Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы», – дип, бик яхшы әйткән».

Тукай, – асылда, милли шагыйрь булганга, интернационалист шагыйрь. Югарыда китерелгән рус-татар мөнәсәбәтләренә кагылышлы уй-фикерләре үзәгендә дә татар халкы яшәеше өчен җайлы иҗтимагый шартлар гаме ята. Ул шартларны шагыйрь рус халкы белән тату бердәмлектә күрә.

ХХ йөз башының милли уяну дәвере шагыйрьләренең һәммәсенә дә татар милләтенең алгарышы өчен яну һәм иҗтиһат кылу хас. Дәрдемәндтә, Сәгыйть Рәмиевтә, Мәҗит Гафурида, Нәҗип Думавида шушы гамь, шушы иман иҗат этәргече булып тора. Әммә әлеге хисне үзендә төрле яклап һәм иң тулы гәүдәләндергән шагыйрь, – әлбәттә, Тукай. Аның йөрәге халыкның иң зур күпчелеген тәшкил иткән хезмәт иясе өчен әрни.

– Иң сөекле эшче әүладым быел ач калды, – дип,
Изге, шәфкатьле анабыз – мәрхәмәтле җир җылый.

(«Көзге җилләр»)

Яки:

Ул хәзер туктар сиңа, и ач авыл, мохтаҗ авыл!
Җимрек өй каршында ич оҗмах кеби кәйфиясе.

Җаннарым, күз нурларым, сез, бу мәһабәтне күреп,
Җан ачып: «во какъ!» дисез, мәзлум мужиклар семьясе.

(«Сайфия»)

Татар халкының, милләт алгарышының барлык мөһим мәсьәләләре шагыйрьнең кайгырту үзәгендә. Татар милли әдәби теленең үсеш юлларын ул хәзерге тел гыйлеменә хас югарылыкта аңлый. Аның «Туган тел» дигән изге гимнын әйтмим дә, хатларында бу хактагы хөкемнәре дә гыйльми төгәллеге белән шаккатыра. Сәгыйть Сүнчәләйгә язган бер хатында: «...Сезнең шигырьләрегездә мин провинциальный һәм төп халык телендә булмаган сүзләр табам. Аларны катыштырмасагыз икән... Мин Казанны тәхте пай (башкала. – Н.Х.) һәм Казан арты татарларын шушы көнгә кадәр милләтен югалтмаган вә киләчәктә дә югалтмаячак төп халык дип саныйм. Милли әдәбиятымыз фәкать шулар телендә, шулар рухында гына булуын телим (1910 ел, 9 ноябрь).

Тукайның хатлары ул яшәгән мохитне күзалларга, шагыйрьнең газаплы кичерешләрен аңларга һәм гаять көчле шигырьләренең мәгънәсенә төшенергә ярдәм итә. Аның С.Сүнчәләйгә язган бер хатында шушындый юллар бар: «Сине мин һәр тугърыда садәдил (эчкерсез. – Н.Х.) кеше таптым. Мин үзем дә Казанга килмәс борын «Гаяз Исхаков ашый-эчәме икән?» дигән кызык бер шөбһәле фикердә идем. Ләкин Казанга килгәч, бөтен милләтчеләрне күреп, хәлләрен аңладым. Мәгатәэссеф (кызганыч ки. – Н.Х.), алар минем колагыма «Синең шигырьләр халыкка үтә; фәлән хакка гына саткансың икән, без фәләнне биргән булыр идек» кеби ач күзле сүзләре илә мине мыскыллый башладылар. «Киләчәкне тәэмин итәргә кирәк-фәлән», – дип лыгырдадылар. Миңа, һәрвакыт милләт вә миллият фикере белән рухланып, илһамланып торган шагыйрьгә, табигый, ул сүзләр тәхкыйрь (хурлыклы. – Н.Х.) иде. Мин ни эшлим аларның киләчәкләре белән? Минем һәр минутым бөтен дөнья бәһасенә тора. Миңа хәзерге вакыт кадерле... Ләкин алар миңа тынычлык бирмәделәр: «Син бу язганыңны безгә бир, фәлән нашир сиңа аз биргән, ул вөҗдансыз!» – диделәр. Менә шулар мине ваксыттылар, изделәр». Менә кайдан килә, менә кайдан чыга аның «Ваксынмыйм» дигән бөек шигыре!

Син үзеңчә изге эш эшлим дигәндә халкыңа,
Әллә нинди былчырак баулар салалар гакълыңа:

– Бу заман шундый заман, – дип, – бу вакыт мондый вакыт,
Син үзеңне дөньяда безнеңчә йөрт, безнеңчә тот.

Мин сыялмыйм андый шартлар, фани дөнья вакътына,
Башны бөксәм – зур җинаятьтер олугъ җан хаккына.

Ашкынамын мин әбәд бетмәс урынга, мәңгегә,
Мәңгелеккә – мәңге рухлы, мәңге нурлы ямьлегә!

* * *

XX йөз башындагы әдәби процессның тизләтелгән үсешендә аның бер чагылышы һәм шарты итеп Көнчыгыш-Көнбатыш синтезын санийлар. Бу күренеш шул чор

шигъриятенең барлык күренекле вәкилләрендә, иң беренче нәүбәттә Тукайда, Дәрдемәндтә һәм С.Рәмиевтә күзәтелә.

Әмма синтез ике нигезнең дә бертигез булуы дигән сүз түгел. Бу процесста Шәрекътән килә торган традиция төп нигезне, үзәк чишмәне тәшкил итә. Күпгасырлык татар классик шигърияте дә шул ук мәдәни төргә, шул ук культура даирәсенә керә.

Тукайның тулысынча диярлек гарузга нигезләнгән шигърияте һәм ритмик сурәт, һәм шигъри фикерләүнең идея-фәлсәфи конструкциясе, һәм сурәтле-бизәкле гәүдәләнеше җәһәтеннән, асылда, Шәрекъ шигъри күренеше булып тора. Шәрекь шигъриятенең исә әйдәүче үзәк сыйфаты – традиционлык. XX йөз башы татар шигъриятенең шушы бөек вәкиле әлеге традицион җирлектә һәм система эчендә даһиларга хас новаторлык чалымнары ясый. Ул, традицион шәркый сурәтләрне сыналган һәм гадәти контекстта куллану белән бергә, бөтенләй көтелмәгән, кайвакыт хәтта сәер тоелырлык мәгънәви бәйләнешларга алып керә, үтә тәвәккәл сурәт хәрәкәте һәм борылышларын бирә.

Гасырлар дәвамында тотрыклы традицияләр өстенлек иткән шигъри системада сурәтләр саны бик күп булмый. Әмма бөек шагыйрьләр шул сурәтләрне виртуоз дәрәҗәсендә оста уйнаталар. Тукай шигъриятендә дә Шәрекътән килгән сурәтләр хисапсыз түгел. Аларның иң күбесе мөселман Көнчыгышының дөньяга карашын, яшәүгә, әхлакка мөнәсәбәтен билгеләгән ислам дине төшенчәләреннән тора. Иң беренче урында, әлбәттә, илаһиятне гәүдәләндергән төшенчәләр: «Алла», «Коръән» төшенчәләре кулланыла. Аннары фәрештәләр, пәйгамбәрләр килә. Тормышның кызу казанында кайнаган, иҗтимагый һәм фикер көрәшенең үзәгендә хәрәкәт иткән шагыйрь өчен, XX йөз башының трагик коллизияләрен йөрәге аша уздырганда, дини әдәбиятның негатив символлары – Иблис һәм шайтан сурәтләре калкып чыга. Алар, үзләренең табигый контекстында кулланылу белән бергә, бөтенләй көтелмәгән, парадоксаль контекст та хасил итәләр. Менә Тукай лирикасының җитлегеп кристаллашкан дәвереннән бер үрнәк:

Туйса Иблис тормышыннан, яд итә оҗмахларын, –
Яд итәм, бизсәм үземнән, мин сабыйлык чакларын.

И күңелнең шаулап аккан чишмәдән сафрак чагы!
И гомернең нурланып үскән яшел яфрак чагы!..

Чәчмәгән җир кук – күңелнең һәр гүзәлгә бушлыгы,
Тик кояшны һәм табигатьне сөюдән хушлыгы!

Монда нәрсә нәрсәгә каршы куела? Тормыш авырлыклары, борчулар һәм гөнаһ баскан лирик каһарман шәхесе ваемсыз, саф балачагына. Шуңа параллель итеп, шагыйрь гөнаһ һәм вәсвәсә гәүдәләнеше булган Иблисне ала. Дөресрәге, шагыйрьнең, лирик каһарманның халәте шушы модель, шушы сурәт нигезендә ачыла. Моны XX йөз башы шагыйре генә эшли ала. Урта гасыр булса, дин һәм гавам аңында каһәрләнеп килгән бу зат белән үзен тиңләштергән өчен, шагыйрьне кичермәсләр иде. Бу төшенчәләрне янәшә алуның җирлеген Тукай гуманизмыннан эзләргә кирәк. Ул әлеге затта үзенең шул чордагы халәтенә хас фаҗига, трагизм күрә. Үз-үзеннән тую, бизү мизгелләре аны саф балачагыннан, үткәннәреннән якты хатирә эзләп юанууга этәрә. Баланың дөньяга мөнәсәбәтендәге сафлыкка, яктылыкка, шуны гәүдәләндергән сурәтләрнең нәфислегенә

генә карагыз! Һәм шул халәтне фәлсәфи төшенү дә, шуның фәлсәфи сурәте дә нинди тирән!

Тукайның бала сурәтен күзаллавы, лирикасында бала һәм балачакның яктыртылуы – үзе бер зур тикшеренү темасы. Сез шигырьләрнең исемнәренә генә карагыз: «Бала оҗмахта», «Сагынып вакытлар» һ.б.

Сабый төшенчәсен фикердән кичергәндә, Тукай кешелекнең иң бөек гуманистлары, нәфислектә иң камил сәнгатькәрләр югарылыгында эш итә.

Сабыйга эндәшеп язган «Таян Аллага» шигырендәге шушы юллардан да өстен камиллек булырга мөмкинме икән?!

Пакь җаның һәм пакь тәнең – барлык вөҗүдең пакь синең;
Син – фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!

Әдәбиятка ислам аша кергән төшенчәләр шагыйрьнең мәхәббәт лирикасында киң урын ала. Мәсәлән, гашыйк кешенең сөеклесе каршындагы халәтен ул намазга оеган гыйбадәтче рәвешендә сынландыра. Әйтик, әле генә уен-көлке сөйләп утырган гашыйк каршына җанашы керә, һәм егет шундук җитдиләнә, үзгәрә:

Нишләсен, җанаш хозурында аңар лязем намаз;
Бер азан әйткәч, колак каккач, мөселман уйнамас.
(«Гашыйк»)

Тукайның мәхәббәт шигырьләрендә сөеклесенең сурәте иң изге биеклеккә күтәрелә. Чагыштырулар да дини тәкъвәлек күзлегеннән гафу ителгесез күренгән тәвәккәлләр. Шагыйрьнең бу өлкәдә кыюлыгы шул дәрәҗәгә барып җитә ки, ул Коръәндәге «ля шәркыя, ля гарбия» (Шәрекътә дә, Гаребтә дә юк) гыйбарәсен сөеклесенә мәдхия дип шәрехли:

Күргәнең бармы әле Коръәндәге мәдхияңи?
Ул синең васфеңдә: «ля шәркыйя, ля гарбия», – ди!

Мәхәббәт, – гомумән, Тукай өчен илаһи хис. Ул аның чыганакларын, урынын гел күктән эзли. Шагыйрьнең лирик сурәтләре, чагыштыру һәм метафораларының илаһи төшенчәләр даирәсеннән алынуы әлеге хискә әнә шул карашыннан килеп чыга. Аның яшьлек шигырьләре арасында «Дәрдемәнд дәгелмием?» дигән камил бер әсәре бар. Анда мондый юлларны укыйбыз:

Тәңре гыйшкында шәһадәт итсәләр дәр Гәрбәла,
Бән шәһидем дәр мәхәббәт, дәр бәлаем, нәйләем.

Хәзерге әдәби телдә

Әгәр Гәрбәладә Тәңре гыйшкында шәһит булсалар,
Мин мәхәббәт-бәла юлында шәһитмен, ни эшлим?

Гәрбәла – Гыйрактагы бер шәһәр. Анда өммәвиләр кулыннан хәзрәте Галинең улы – Мөхәммәт пәйгамбәрнең оныгы Хөсәен һәлак була. Шигыйлар анда хаҗга йөри. Тукай мәхәббәт юлында корбанга әзерлеген менә шушы шәһитләр язмышына һәм ихтыярына тиңли. Шул рәвешчә ислам тарихы фактлары аның шигъри фикерләвендә югары әхлакый-

эстетик кыйммәткә ия чагыштыруга, мәгълүм дәрәҗәдә шигъри оппозиция, антитеза элементына әверелә.

Тукайның шигъри фикерләү тирәнлеге даими ачыклауга, шәрехләүгә мохтаҗ. Без шулар аша гына аның даһилык колачын тулырак иңли алачакбыз. «Көзге җилләр»дәге гади искәрмә белән чикләнеп узыла торган шушы юлларга күз салыйк әле:

Тилмереп торса бу ачлар, безгә бәйрәмнән ни ямь?!
Мәркадендә чөнки Ибраһим вә Исмәгыйль җылый.

Тәүрат һәм Коръән аша Ибраһим белән Исмәгыйльнең пәйгамбәрләр булуын беләбез. Ләкин алар ни өчен «җылый»? Чөнки сүз илдәге ачлык чорына туры килгән Корбан гаете хакында бара. Бу бәйрәм – Ибраһим белән Исмәгыйльнең шатлык бәйрәме. Беренчесе үзенең Аллага тугрылыгын улын корбан итеп раслау мәҗбүриятеннән, зарурлыгыннан котылган, икенчесе исән калган. Һәм шушы вакыйга легенда күләмендә илаһияткә тугрылыкны, ятимнәр һәм фәкыйрьләр хакында кайгыртып раслау дәверен башлап җибәрә. Корбан гаете, – асылда, шатлык бәйрәме, шәфкать, мәрхәмәт бәйрәме. Идел буендагы 1911 елгы ачлык бәйрәмнең әнә шул мәгънәсен юкка чыгара. Бәйрәмгә нигез салган пәйгамбәрләр шунлыктан елый. Шагыйрь каләменнән чыккан гади генә ике юл ил һәм кешелек күләмендәге шушы тирән фаҗигане чагылдыра.

Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасына караган кайбер әсәрләрендәге образларны Көнчыгышның легендар каһарманнары белән чагыштыруы градация рәвешендә дини әдәбият персонажлары белән янәшәлектә алына, ул янәшәлекләр исә классик фарсы шигърияте стилендә сурәтле хәрәкәткә китерелә. «Бер рәсемгә» шигырендә, мәсәлән, ул болай:

И кояш! ямьсезлегеңнән син оялырсың, беләм,
Гәр чагыштырсаң йөзеңне син бу бит алмасына.

Күрсә яңлыш бу матур кызның фәкать рәсмен генә,
Шөбһәсез, селтәр кулын Мәҗнүн дә үз Ләйләсенә.

Булсайде оҗмах түрендә әүвәл үк рәсме моның,
Илтифат итмәс иде Адәм дә үз Хаувасына...

Күрсәйде Иблис ләгыйнь дә, кайда баш тартып йөрү!
Баш иярди сәҗдәгә, кайтып тагын Алласына.

Шушы сурәт-төшенчәләр шагыйрьнең хис-кичереш дөньясы киңлеген, аның күз күреме җитмәслек чикләрен сыза, абсолют дәрәҗәгә ирештерә. «Кулың» шигырендә ул кызның кулына карата: «Бер фәрештә күңледәй пакьтер кулың», – ди. Аның сафлыгын, гүзәллеген, камиллеген шушындый сәмави, изге төшенчәләр аша күрә. Мондый чагыштыру һәм парадокслар шагыйрьнең үз күңелен, аның чиксез киңлеген, сафлыгын, бөтенлеген төсмерләтә.

Тукай үтә нечкә хисләр белән сугарылган мәхәббәт шигырьләрендә дә традицион гыйшык каһарманнары сурәтен үз чорының иҗтимагый-мәдәни төшенчәләренә үреп бирә. «Мәхәббәт» шигырендә аның шундый юллары бар:

Барча әхраре мәхәббәт миннән унда, зан итәм, –

Кайда Фәрһад берлә Мәҗнүн! – мин аларның таңчысы!

Игътибар итегез: ХХ йөз башы татар җәмгыятендәге уңнар һәм суллар, ягъни радикаллар һәм соңгыларының Гаяз Исхакый катнашындагы «Таң» газетасы шушы нәфис мәхәббәт шигыре каһарманының нинди ашкынлык белән януын төсмерләтә. Әдәбиятның камил сурәтләре янына шагыйрь үз чорының кискен иҗтимагый агымнары һәм шуның иң күренекле гәүдәләнешләре булган затларны янәшә куя, шул үрелеш аша үз сурәтенең зурлыгын, хис кайнарлыгын гәүдәләндерә.

* * *

Гадәти тикшеренүләрдә без Тукайны башлыча лирик буларак карыйбыз, һәм бу, асылда, хаклы да. Чөнки шагыйрьнең дөньяга карашы, иҗтимагый һәм эстетик идеалы позитив рәвештә аның лирикасында гәүдәләнә. Хәлбуки ул, – дөньяның аз санлы мәгълүм даһиларына хас булганча, шигъриятнең ике төрендә дә бердәй талантлы иҗатчы. Ул, – бөек лирик булган кебек, шул ук дәрәҗәдә даһи сатирик та. Һәм, әйтергә кирәк ки, шагыйрь иҗатының бу тарафы да әдәбият белемендә эре планда яктыртыла торды. Мин Резеда Ганиеваның «Тукай сатирасы» дигән монографик хезмәтен һәм Гали Халит белән Ибраһим Нуруллин хезмәтләрендә бу өлкәнең шактый урын биләвен күздә тотам. Аларда Тукай сатирасының ХХ йөз башы татар иҗтимагый көрәшендә башкарган вазифасы, татар һәм Көнчыгыш сатирик традицияләрен дәвам иттерү, рус һәм Көнбатыш сатира мәктәбен үзләштерү, татар әдәбиятында реалистик иҗат методының шәкелләнүенә сатираның йогынтысы кебек принципиаль-концептуаль мәсьәләләр карала.

Шулай да Тукай сатирасының төп иҗтимагый-тарихи җирлеге нәрсәдә соң? Бу сорауга төгәл җавап бирү өчен, без ХХ йөз башы татар әдәбиятының гомуми торышына күз салырга тиешбез. Анда исә әдәбиятның барлык жанрларында да сатира көчле агым буларак гәүдәләнә. Мәсләге белән Тукайга иң якын торган Фатих Әмирханның: «Фәтхулла хәзрәт» повесте, Галиәсгар Камалның комедияләре, Шакир Мөхәммәдев повестьлары («Япун сугышы, яки Доброволец Батыргали агай»), Шәриф Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» әсәре һ.б. – сатира һәм юмор әсәрләре. Аларны татар дөньясына җиткерүче сатирик журналлар иҗтимагый-әдәби тормышның куәтле авазы, аерылгысыз юлдашлары булганнар.

Сатирик әдәбият – сугышчан көрәш әдәбияты. ХХ йөз башы татар тормышында барган ашкынып яңару хәрәкәте искенең котырып каршы торуын сындырырга, җиңәргә омтылган. Капиталистик мөнәсәбәтләрнең тормыштагы барлык өлкәләргә үтеп керүе гадәти шартларда күзгә ташланып тормаган, ә сатирик әдәбият әнә шул йомылып яткан каршылыкларны ярып, ачып салган. Бу исә мәдәнияткә, әхлакка, барлык кешелек кыйммәтләренә юнәлеш биргән.

Сатирик әдәбиятның иң яраткан каһарманы кем дисәң – мулла, хәзрәт булыр. Ни өчен шулай? 9–10 гасыр ислам шартларында яшәгән халык өчен изге саналган шушы затка нишләп соң каләм әһле шулай ярсып ябырыла? Татар тормышының ашкын яңаруы – һәм эчтәлеге, һәм формасы белән европалашу хәрәкәте. Икътисад булсын, мәгариф-мәктәп системасы булсын, кием-салым, зәвекъ-мөгамәлә өлкәсе булсын, холык-гадәт, көнкүреш, туклану булсын – барлык өлкә һәм тармакларны шушы тыелгысыз яңару шаукымы биләп ала. Милләтнең аяныч сәяси, икътисади һәм мәдәни хәленә ачынган барлык зыялылар инкыйраздан котылуның төп шарты итеп европалашуны күрәләр. Бу идеологиянең кайнар

байракчысы Гаяз Исхакый була. Ә традицион тормышның уяу сакчылары, татар халкын гасырлар дәвамында юкка чыгудан саклап килгән изге затлар – хәзрәтләр, руханилар, әлбәттә. Асылда, татар халкының бердәнбер зыялы катлавы да – шулар. Әмма XX йөз башының әлеге зарури хәрәкәтенә киртә булучылар арасында да аларны күрәбез. Шушы чор сатирасы аша гына хөкем йөртсәк, аларны гел каһәрләргә тиеш булыр идек. Тик бу ашкын «европалашуның» большевиклар сәясәте белән көчәйтелгән XX гасыр нәтиҗәләрен исәпкә алсак, бу хәрәкәтне беркадәр акрынайта алган хәзрәтләребезгә рәхмәтле дә булырга тиешбез.

Гасыр башы татар сатирик әдәбиятында Тукай сатирасының урыны һәм үзенчәлеге нәрсәдә һәм ул ни дәрәҗәдә иде соң? Шагыйрь матбугатта каләм тибрәтүенең беренче чорында ук үткен көлүдән торган һөҗү – юмор-сатира авазын яңгырата. Шунысы кызык һәм игътибарга лаек ки, ул, виртуозларча җиңел тапкырлык белән, һөҗү алымнарының бик күп төрләреннән файдалана.

Милләтнең рухани-эстетик юлбашчысы булган шагыйрь мондый хәтәр тәвәккәллеккә, бәлки, бармас та иде, ләкин гомуми милли яңарыш хәрәкәте эчендә рухани-дини яңарыш агымы да куәтле гөрелте булып катнаша. Муса Бигиев кебек дин реформаторлары руханият тәгълиматын дөнья алгарышына яраклаштыру белән мәшгульләр. Тукайның әлеге һөҗүле чыгышларында әнә шушы тенденция дә төсмерләнә.

Шагыйрьнең зур колачлы «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы басылып чыккач, мәсләктәше Фатих Әмирхан аны «татар галәменең иң оста юмористы» дип атый. Шул рәвешчә татар әдәбиятының классик сатириклары булып тарихка кереп калган эшлеклеләре Тукайны бу өлкәнең иң зур остасы итеп таный.

XX йөз башы татар сатирасының үзәк фигурасы – муллалар темасы – Тукай шигъриятендә ничек яктыртыла соң?

Шагыйрь бөек лирик һәм сатирик икән, бу тема аның иҗатында төрле яклап ачылырга тиеш. Чынлыкта ул шулай да. Әйтик, татар яңарыш хәрәкәтенең рухани остазы булган бөек галим һәм мулла Шиһабетдин Мәрҗанине ул «шәп хәзрәт, милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт» дип атый.

Йөрәк түреннән чыккан «Васыятем» шигырен муллаларга адреслый. Лирикасында ул аларны уңай яктырта.

Ә инде татар тормышының йомыклыгын яклаган, искелеккә ябышып яткан төркемгә аның мөнәсәбәте кискен, һөҗүчел. «Мулланың зары» шигыренә искәрмәдә ул, азәрбайҗан сатирик журналын күздә тотып, «“Мелла Насреддин”нән» дип куя. Шигырь исә Дәрдемәнднең «Үткән көннәр» дигән әсәре калыбында язылган. Чынлыкта шуңа пародия.

И ходаем! бәндәңә әүвәлдә хөрмәт бар иде;
Берзаманнар чалмалыга кадер-гыйззәт бар иде...

Сүз дәшүче юк иде, мин бер караны ак дисәм;
Һай гомерләр! әһле исламда итагать бар иде.

Туры сүзне ярып әйтә алмауны, иманыңа һәм хакыйкатькә каршы барып, махсус исәп хакына ялганлауны ул әхлаксызлык дип атый:

Бик югартын күз салырга башладык әхлакка без,
Кер күңелдә күплегеннән бармыйбыз ак якка без.

Тик хәзер, йөз сумны урлап килгүче угъры кеби,
Күз салабыз чын сүзне әйтердән элек як-якка без.

Бер сүз әйтергә саранлансак гакыллы ярлыга,
Гөл кеби сүзләр чәчәбез акчалы ахмакка без.
(«Әхлаксызлык»)

Кызганыч ки, бу гадәтләр безнең чорга да хас булып кала.

Тукай иониясе бер шагыйрьдә дә булмаганча тирән, көйдергеч һәм гаять киң гомумиләштерүгә ия. Аның гомумбилгеле «Мөнтәкыйд» шигыре, мәгълүм ки, Галимҗан Ибраһимов белән килешкесез бәрелешүләргә бәйле. Бөек прозаик, шагыйрьне кичерәйтеп, хаксызга гаепләп, мәкаләләр белән чыга. Соңрак үзенең шушындый мөнәсәбәтен «Татар шагыйрьләре» дигән китабында чагылдыра.

Шагыйрьнең «Мөнтәкыйд» шигырендә әлеге коллизия яктыртыла:

Ул күрә куй койрыгын да: «Нинди шешкән!» – дип куя,
«Рус табибкә бу татарлар нинди дошман!» – дип куя.

Г.Ибраһимов, әлбәттә, мондый хәлгә төшмәгән һәм мондый сүзләрне әйтмәгән. Әмма Тукай аның шагыйрьгә карата тәнкыйтенең урынсызлыгын, хаталыгын бик төгәл гәүдәләндергән. Ягъни үзендәге көчле сыйфатларны йомшак яклар итеп шәрехләгән, халыкчанлыгын гавами түбәнлек итеп күргән, ә нечкә эстетлыгына күз йомган тәнкыйтьчене, көньяк далалар куеның табигый үзенчәлеген авыру чагылышы итеп алып, шуның белән чагыштыра.

Тукайны, чын сәнгатькәр буларак, рәссам белән чагыштырсак, аның сатира палитрасы да, лирикасы кебек үк, гаять күптөрле төсләрдән, төсмерләрдән тора. Ирония, ачыну, юмор еш кына лирик шигырьләренә дә килеп керә. Чөнки шагыйрь үзенең күпне күрә торган үткен зиһене белән, тормышның шатлыгын, ямен иңләгән кебек, җан өшеткеч якларын да күргән, шулардан интеккән, алар еш кына аның сөенеч-шатлыкларын да чуарлаган. «Көлке түгел» шигырендә ул үз көлүенең асылын болай ачып бирә:

Көлке булса кайвакыт шигърриятемнең кыйссасы,
Анда бар бер җанлы хәсрәт, канлы ләгънәт хыйссасы.

Бу шигырьдән шагыйрьнең каһарман язмышындагы трагик мәгънәне дә төсмерләп була.

Кыскасы, Тукай сатирасы – татарның 1000 еллык шигърият тарихында бөек бер сәнгати-иҗтимагый казаныш ул.

* * *

Шәрекъ-Гареб синтезы XX йөз башы татар әдәбиятында тизләтелгән үсешнең куәтле факторы булды. Аңа кадәр тулысынча шәркый традицияләр эчендә үскән татар шигърияте, үзенең борынгы нигезен һәм тамырларын нык саклаган хәлдә, Европа әдәбиятына, аның фәлсәфи-эстетик һәм иҗтимагый фикер мәктәбенә йөз белән борылды.

Бу куәтле хәрәкәт гасыр башы шигъриятенең һәр өч бөек вәкилендә тирән чагылыш тапты. Рус һәм Көнбатыш Европа шигъриятеннән кызыклы-кызыклы тәрҗемәләрдән башлап, тәкълид рәвешендә барлыкка килгән әсәрләр һәм мәгълүм мотивлардагы

аваздашлык Европа шигъри традицияләренең татар шагыйрьләрендә көчле кайтаваз таба баруын күрсәтә. Әлеге процессның ике тенденциясе игътибарга лаек. Беренчесе – Гареб дөньясы әдипләреннән үзләренә якын, Шәрекъ дөньясына аваздашрак тема һәм мотивларны сайлап алу булса, икенчесе шушы шигърият тәэсирендә үз шигъри аһәңнәрен баету һәм әкрен-әкрен үзгәртеп кору, дияр идем. Төгәл тәрҗемә дигәндә, беренче булып һәм җитди уңышларга ирешкән шагыйрьләр – Дәрдемәнд һәм Сәгыйть Рәмиев. Беренчесенең Пушкинның «Кышкы кич»ен яки Тютчевның «Тал чыбык» шигырен тәрҗемә итүе, икенчесенең Шиллерның «Перчатка»сын яки Демьян Бедныйның «Сука белән Пушка»сын тәрҗемә кылуы шушындый үрнәкләрдән. Ә Тукайда тәрҗемә юк, таяну һәм тәкълид кенә бар. Бу нәрсә дигән сүз? Минемчә, Тукай шигъриятендәге, аның иҗади шәхсиятендәге индивидуаль башлангычның гадәттән тыш куәтле булуы.

Аның «Байроннан», «Гетедән», «Шиллердән», «Шекспирдән», яки «Пушкиннән», «Лермонтовтан» дип куйган искәрмәле шигырьләрендә, атап үтелгән шагыйрьләргә караганда, Тукай шигърияте, Тукайча фикерләү көчлерәк.

Мәзкүр шагыйребезнең тәкълидән язылган әсәрләрендә Шәрекътән Европа шигъри фикерләвенә күпер сузуның сәнгатьчә драматизмын, турырак әйтсәк, газапларын да күзәтергә була. Шәркый үзенчәлеге даһиларча камил шагыйрьдә Гаребне үзләштерү һәр адымда шәркыйлеккә тарта. Искәрмә рәвешендә әүвәл шуны әйтергә кирәк ки, русчадан тәрҗемә өчен дә, тәкълид өчен дә бу телне һәм шул шагыйрьләрне яхшы белү зарур. Тукайның Уральскида, шәһәрдә алган белеме, һичшиксез, бу юлда җитди таяныч булган.

Шагыйрьнең 1906 елда язган «Пушкиннән» шигырендә Шәрекъ-татар шартлары өчен күпмедер дәрәҗәдә актуаль яңгырашлы күпхатынлылыкны гаепләү фикере уздырыла. Лирик шагыйрь шундый язмышлы яшь хатын-кызга теләктәшлек белән мөрәҗәгать итә. Пушкин шигырендәгечә, аңа, фонтанга барып, су чәчрәтеп уйнарга куша, әмма, агымсуга карап, гомернең дә тиз һәм әрәмгә үтәчәген уйларга киңәш итә. Нигезенә фаҗигачел-драматик кичерешләр салынган 9 юллык рус шигыреннән Тукай 10 бәйтлек, ягъни 20 юллык шигырь эшли. Болай җәелүнең сере нәрсәдә? Шагыйрьнең иҗат үзенчәлегендә һәм укучыларның киң катлавына үтемле булуын кайгыртуда, минемчә. Пушкиндагы тыгыз, лаконик шигырь, барыннан да элек, элитар укучыны күздә тота. Ә Тукай үзенә якын киң гавамны кайгырта. Иҗат үзенчәлеге дигәннән, ул тиз язылган булырга охшый. Тәрҗемә өчен, Дәрдемәндчә, ашыкмыйча төпченү сорала. Йөгерек ритмлы Тукай андый салмак тизлекне кабул итмәгән. Алай гына да түгел, ул мавыга һәм урыны-урыны белән читкә дә китә. Менә шул юлларга игътибар белән карыйк әле:

...Вәли ушбу фикерчекне дә уйла:

«Бу су ничек көмеш төсле агадыр,
Агып барганда, чүп-чарны кагадыр;
Агып, күздән югалып, була гаиб,
Гаҗәп, кайда китә соң бу, гаҗаиб?»

Бу су юк булды бит, чыкмый өне дә,
Шулай ук юк булыр яшьлек көне дә.

Әлеге өзекнең өченче юлы мәгънә энергиясеннән, хис һәм тасвир сюжетыннан читкә алып китә. Юкса фикер үзәгендә агымсуның юл уңаендагы эшләре түгел, ә агу тизлеге ята.

Тукайның тәкълидләренә күз салганда, аның Гареб шагыйрьләреннән сайлаган әсәрләре Шәрекъ традицияләре янында нинди яңалыклары, яки мәгънәви төсмерләре белән аерыла соң? Күзгә ташланган иң мөһим үзенчәлек лирик конфликтның характерында. Шәрекъ лирикасының традицион конфликты хөкемдар белән иҗатчы шагыйрь, надан тирәлек белән гыйлем иясе, горур гүзәл белән гыйшык утында янучы лирик каһарман, язмыш белән тормышның газаплы мосафиры, котылгысыз үлем белән тормышка мәхәббәт каршылыгыннан гыйбарәт.

XX йөз башы татар шагыйрьләре арасында Тукайның Европа шагыйрьләреннән сайлаган әсәрләре, башлыча, шуның белән аерыла ки, аларның үзәгендә җәмгыять белән шәхес арасындагы тирән конфликт һәм азатлык мотивы ята. Ул Пушкинның 12 юллык «Узник» шигыреннән 26 юллык, ягъни 13 бәйтлек «Мәхбүс» шигырен эшли, төп мотивларны Пушкиндагыча саклый: тоткын һәм хөр бөркет мисалында сүрелмәс азатлык омтылышы чагыла. Шагыйрь һәр күренешне детальләп җәя, ягъни шәрехли. Шунысы кызык: Тукай рус шагыйреннән формасы ягыннан да парлы рифмаларга корылган үрнәкне сайлаган. Дөрес, Пушкинда строфалар 4 әр юллы. Тукай, аны эзлекле дәвам итеп, аннан 13 строфалы Шәрекъ шигыре ясый.

Лермонтовның «Пророк» шигырендәге җәмгыять һәм шәхес, томана һәм консерватив тирәлек белән гали, игелекле җан – шагыйрь конфликты шул нигездә эшләнгән «Пәйгамбәр» әсәрендә аеруча кискенлек белән гәүдәләнгән.

Бу шигырьгә әдәбият фәне күптәннән игътибар итеп килә. Гали ага Халит анализы әдәбият тарихларының хрестоматик өлешенә әйләнде. Минем үземнең дә аны төрле аспектта яктыртып язган мәкаләләрем бар. Конкрет бу очракта игътибарны менә нәрсәгә тупларга кирәк: пәйгамбәр темасы – Шәрекъ әдәбиятының традицион һәм изге темасы. Ул безнең тарихи реаль пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафаның тормышы һәм бөек эшчәнлеге хакындагы кыйссаларда, яки Тәүрат һәм Коръәндә телгә алынган легендар пәйгамбәрләр хакындагы хикәятләрдә, эреле-ваклы шигъри әсәрләрдә һәм халык иҗатының мөнәҗәт жанрында яктыртылган. Рус шагыйрендә дә, татар классигында да шул кыйссалардагы җыелма язмыш шагыйрьнең үз хәләте белән бергә үрелеп бирелә. Аллаһыдан пәйгамбәрлек вазифасы иңдерелгән зат халыкны якты, туры юлга күндерергә алына да, әмма ул моны аңламаган һәм аңларга да теләмәгән томана мохит тарафыннан мәсхәрә белән каршы алына, нәтиҗәдә калаларны ташлап чыгарга мәҗбүр ителә. Дөньяны һәм аның гыйбрәтле тарихларын үтә күрергә сәләтле акыл, рухият иясе өсте-башы керләнгән, каһәрләнгән көе, картлар өчен, балаларга гыйбрәт итеп сөйләр хәлгә төшә... Кагыйдә буларак, монда да Тукай Лермонтовта гомумиләштереп бирелгән деталь һәм мотивларны җәелдерә төшә, әсәрдәге фаҗига төсмерен көчәйтә һәм шигырьдә үзенең иҗади язмышын да чагылдыра.

Картлар, бармак төртеп, балаларга пәйгамбәрне шулай тасвирлыйлар:

Күрәмсез, нинди беткән һәм арыкланган, фәкыйрьләнгән,<br>
Зәгыйфьләнгән, таланган, өсте-башы нинди керләнгән!

Тукайның: «Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым» («Кыйтга»), «Син үзеңчә изге эш эшлим дигәндә халкыңа, әллә нинди былчырак баулар салалар гакълыңа» («Ваксынмыйм»), «Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы» (« Өзелгән өмид») дигән юллары «Пәйгамбәр» шигыре каһарманының халәтенә бик нык аваздашлар.

Ә шулай да бу шигырьнең Шәрекъ традицияләре янында принципиаль яңалыгы нәрсәдә соң? Теманың яктыртылыш ракурсында, үзенең кискен-тәвәккәл бирелешендә (русча әйткәндә, дерзкий характерында). 1000 еллык мөселман Көнчыгышы шигъриятендә ортодоксаль руханилар телендә дә, тәкъва суфилар телендә дә бу мөмкин булмаган хәл: шагыйрь үзен пәйгамбәр буларак яктырта, дөрес, күчерелмә-метафорик алымнар белән булса да. Ул, илаһияттән Җәбраил аша пәйгамбәрлек вазифасы алдым, ди. Кыскасы, әлеге теманы эшләгәндә, татар шагыйре XIX–XX йөз Европасындагы фикер хөрлегенә таяна. Принципиаль яңалык шунда.

Европа шагыйрьләренә һәм шигъриятенә тартылу Тукайның мәхәббәт шигырьләрендә аеруча үзенчәлекле һәм көчле чагылыш таба. Кешелекнең шушы бөек хисен татыганда, аның күз алдына Европаның иң мәшһүр шагыйрьләре килеп баса:

Бер гүзәлдән кайсы шагыйрь, әйтеңез, рухланмаган?
Байроның, Лермонтовыңмы, Пушкиныңмы – кайсысы?

Шуннан шагыйрьнең үзен дә кемнәр сафында итеп күрүен күз алдына китерергә мөмкин. Мәхәббәттән илһамланып язган шигыренең бәһа-дәрәҗәсен дә ул яхшы төшенә, шуны укучыларга курыкмыйча, горурлык белән хәбәр итә:

Тешләренең гәүһәреннән кабызып алдым менә
Мин бу шигъре, – әйтсәңез лә, энҗедән ким кай төше?
(«Мәхәббәт»)

Һенрих Һәйне иҗаты XX йөз башы татар шагыйрьләренең зиһенен шактый нык били. Тукайның дусты Сәгыйть Сүнчәләй аның «Әлмансур» трагедиясен тәрҗемә иткән. Шагыйрь, дини көчләүне кичергән мөселман татар халкы вәкиле буларак, испан гарәпләре башыннан үткән шундый ук хәлләрдә үз тарихына охшаш фаҗигаләрне күргән. Католицизм тарихындагы фанатизмга нәфрәтле алман-яһүд шагыйре мөселманнар фаҗигасенә теләктәшлек белдерә.

Тукайга исә Һәйненең мәхәббәтне гали хис буларак данлавы якын:

Мин: «Мәхәббәтсез», – дидем, ләкин мәхәббәт төрлечә:
Йолдыз ул күктән атылган җиргә, Генрих Гейнечә.
(«Мәхәббәт шәрхе»)

Тукай үзенең шигъри фикерләвендә Европа мохитенә, Европа реалийларына керә бара. Мәсәлән, татарның милли уянышын сәламләгән «Тартар кошы сайрый» дигән шигырендә шундый юлларны укыйбыз:

Сайрасын былбылларың,
Чалынсын сазлар, татар.
Чыксын шәмсең, эрсен кар,
Шалтырап аксын ермаклар;
Ятмасын мәңге, җитәр! –

Мисле сәлеж Сангатар.

Соңгы мисрагтагы «Сангатар» (Сен-Готард) «Алып тавындагы кар кебек» дигән мәгънәне аңлата. Гыйбарә гарәп-фарсы изафәсе рәвешендә язылса да, аннан шагыйрьнең үзен Европа шагыйре дә дип хис итүен тоярга була. Фикерләве тоташ шәркыять белән сугарылса да, әйтик, шәркый мифологиясе белән (Каф тавы, Сәмруг кош һ.б.) өртелсә дә, телендә Европа шагыйрьләре. Камиллек үрнәген ул аларда күрә. Юкса Риза Фәхретдинев аны «татар мәгаррие» итеп күрергә теләвен яза. Мәгарри, – чыннан да, Шәрекътә һәм дөньяда шагыйрьлекнең камил өлгесе. Әмма үз чорының иҗтимагый шартлары Тукайны Европага тарта. Буржуаз мөнәсәбәтләрдән ризасыз, романтик Европа шагыйрьләре аңа якын.

* * *

Тукайның шәкерт чагындагы хатлары һәм «Исемдә калганнар» дигән хатирәләре җан тетрәткеч документлар булып кала. Аларда ятим баланың таянычсыз, артык тамак булып кагылу-сугылулары, олылар назына һәм бер локъмә тәгамгә мохтаҗ халәте, кулдан-кулга күчеп йөрүләре йөрәк өзгеч фаҗига һәм үкенечләр тулы язмыш булып күз алдына баса. Сабый һәм үсмер чагы шушындый газаплар тирәнлегеннән узганга, ул халык хәсрәтен, дөньяның бер шагыйрендә дә булмаганча, ачы һәм әрнүле хисләргә төреп чагылдыра алган. Татар халкының бу баласын шушындый тетрәнү белән яратып үз итүе тикмәгә түгел: ул – Тукай язмышында үз тарихи язмышының чагылышын күргән. Аның шигърияте аша үзенең бөтен каһарман һәм фаҗигале тарихын танып белгән.

Шагыйрьнең хатлары һәм «Исемдә калганнар» дигән чәчмәсе бу оланны саклап калган изге затларның – ике Саҗидә апасының, Кырлайдагы Сәгъди карт гаиләсенең, Казандагы Мөхәммәтвәли белән Газизә исемле игелекле кешеләрнең (шагыйрь аларны «әти» һәм «әни» дип искә ала), Уральскидагы апасы белән җизнәсенең, Гурьевтагы ике туганының һәм башка бик күпләрнең – якты сурәтләрен теркәп калдырган. «Исемдә калганнар»да үги әбисе мохитендә бер Саҗидә апасының мәрхәмәтле, йомшак җанын ул болай тасвир кыла: «Саҗидә апайның, үги әбидән яшереп кенә, мине юатканын вә сөйгәнен, әби килә башлагач та, минем белән эше юк кеше шикелле, үзенә икенче кыяфәт биргәнен һаман хәтеремдә саклыйм.

Менә шул вакыттан бирле ул апа минем күңелемә фәрештә булып утырган да калган. Күңелем аны уйлый башлады исә, хәзер күземә ап-ак саф бер фәрештә күренә».

1903 елның 30 июнендә Уральскидан Өчилегә апасы Саҗидәгә язган хатында мондый юллар бар: «Мөшфика (шәфкатьле. – Н.Х.) апаем! Синең сабый вакытымда һәм хәзер дә иткән изгелекләреңне кабердә ятсам да онытмам. Анам дарел-бакага рихләт иткәч, бабайлар өендә бәңа мәрхәмәт күзе белән караучы юк иде, мәгәр син бар идең. ...Җәберләренең җәрәхәте җәннәте гаденгә (оҗмах. – Н.Х.) керсәм дә йөрәгемнән китмәс».

Уральскидагы шәкерт Габдуллага Гурьев шәһәреннән ун сум акча җибәргән туганнары Әхмәди белән Әүхәди Абдуловларга 1904 елның 26 апрелендә язган хатында ул болай ди: «Имди сездән үтенечем: бән бичараны үзеңездән гайре адәмнең күзенә тилмертеп карата күрмәңез». Шул хатында ул бай кардәшләренә, югарыда телгә алынган ярдәмнәре өчен, Мотыйгулла хәзрәт һәм хәлфәләренең кылган догаларын әйтеп яза.

Шагыйрьнең ятимлегенә кагылышлы мәгълүматларны тыныч күңел белән укырга мөмкин түгел. Әмма шунда бер бөек хакыйкать тә ачыла: ул – безнең туган халкыбызның җан юмартлыгы, инсани галилеге. Шушы бәхетсез сабый бары халкыбызның олы җанлылыгы аркасында исән кала һәм бөек шагыйрь булып җитешә. Тикмәгә генәмени ул соңрак:

Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!
Азрак үстерде сыйпап тик маңлаемнан милләтем, –

дип язган?

Тукай язмышындагы иң үкенечле хәл – аның кыска гомерле булуы. 27 яшь ул – егетләрнең өйләнү өчен өлгереп килә торган чоры. Иң тәәссефе шул: ул алай тиз үләрмен дип һич уйламаган. Ул титаник иҗат ниятләре белән яшәгән. Сәгыйть Сүнчәләйгә 1911 елның 4 мартында, ягъни вафатына 2 ел вакыт калганда, ул менә нәрсә яза: «Бер поэма хакында башымда әнвагъ (күп. – Н.Х.) төрле хыяллар йөри. Фәкать зиһен варить итеп чыгарганы юк әле. Гаяи хыялым (хыялымның нәтиҗәсе. – Н.Х.) – татарча, татар рухында, татар геройлары белән дөньяга бер «Евгений Онегин» чыгарудыр. Алла ни бирер». Шагыйрьнең кыска гомере татар һәм дөнья әдәбиятын никадәр хәзинәдән мәхрүм итеп калдырган?!

Әмирхан Еники, Хәсән Туфан вафатыннан соң: «Ул үзенең әйтәсе килгән бөтен сүзен дә әйтеп бетерми китте. Бөек шагыйрьләр беркайчан да сүзен әйтеп бетерә алмыйлар», – дигән иде. Бу чыннан да шулай. Әмма аның калдырган хәтле иҗаты да – үлемсез бөек хәзинә! Без ул хәзинә белән үзебезне дөньяның иң бай халыкларыннан хис итәбез.

Нурмөхәммәт Хисамов,
филология фәннәре докторы, профессор

1 Пассионар – ялкынлы, көчле, дәртле.

## Шагыйрьнең күптомлы басмалары

Җиде-сигез еллык иҗат дәверенең иң соңгы сәхифәләрен Габдулла Тукай гайре табигый шартларда, авыруының соңгы чигенә җитеп, Клячкин шифаханәсенә кереп яткач яза. 1913 елның 18 мартында «Кояш» газетасында аның «Уянгач беренче эшем» исемле мәкаләсе (14 мартта язылган) басыла. Бу мәлдә үзен «бәхетсез милләтнең бәхетсез угылы, бәхетсез почмакның әсир былбылы» итеп тойган Тукай анда «7 ел мөддәтендә себерү вә пакьләү» күрмәгән «такмак бүлмәсе»н себерергә тотынганын әйтә һәм: «Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле», – дип, киләчәккә ышаныч-өметен дә белдерә. Ә берничә көн генә элек, җыентыгын төзү белән шөгыльләнгәндә, ул «такмак бүлмәсе»н шактый каты себергән була. Моның нәтиҗәсе буларак, «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асәре» шагыйрь үзе туплаган, үзе ниятләгән күләмдә вафатыннан соң булса да басылып чыга. Тукай китапка шигырьләрен сайлап кына кертә, намусына, күңеленә тигән, җанын әрнеткән гаделсез фикер-карашларны да искә алып, үзе «браковать итмәгән» һәм «яраткан шигырьләр»ен генә җыеп чыгаруны мәслихәт күрә. Җамал Вәлидинең зур күләмле кереш мәкаләсе белән Казанның мәртәбәле «Мәгариф» китапханәсендә 463 битле булып нәшер ителгән бу «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асәре» шагыйрьнең үз заманында китап-рисаләләрендә, газета һәм журналларда дөнья күргән шактый күп кенә әсәрләрен бер җиргә туплаган басма-җыентык буларак озак еллар укучылар ихтыяҗын канәгатьләндереп килә (бернинди үзгәрешсез диярлек 1918 елда кабатлап та чыгарыла).

1926 елда Казанның «Гажур» нәшриятында Ф.Бурнаш «Габдулла Тукай шигырьләре» дигән тагын бер җыентык төзеп бастыра. Китапка, шагыйрь кульъязмаларыннан алынып, моңа кадәр мәгълүм булмаган дүрт, башка басма чыганаклардан тугыз шигырь өстәп кертелә. Мәҗмуга Тукай әсәрләренең әһәмиятен, кулланылыш даирәсен тагын да арттыра.

Классикларыбыз мирасы Совет хакимияте басымы белән революциягә кадәрге язучылар иҗатын сыйнфыйлык позициясеннән чыгып бәяләү тамыр җәйгән вакытта да югалмый. Татар язуын латин графикасына (яңалифкә) күчерү көннәрендә дә, беренче булып диярлек, Тукай иҗатын яңа шартларда укучылар хозурына кайтару бурычы куела. Бу эш, төгәлрәк әйтсәк, Тукайны яңалифтә дә яшәтү, дүрттомлык басмасын1 әзерләү, язучы, «Яңалиф» җәмгыяте рәисе, шул ук исемдәге журнал редакторы Фатих Сәйфи-Казанлыга тапшырыла, һәм ул аны тиз арада үтәп тә чыга.

Басма «Г.Тукай әсәрләре» дип исемләнә. Китапның керешендә төзүченең «Билгеле, моңа кадәр бик аз эшләмәгән бер язучының әсәрләрен бер басмада гына тулы итеп чыгару мөмкин эш түгел, чөнки бөек язучыларның әсәрләре үзләре соңында берничә еллар буенча коллектив көч белән тутырылалар. ...Мин үземне бу юлда башлап җибәрүче дип кенә карыйм, тәмамлау, камилләү, тулы рәвешкә китерү – коллектив эше дип беләм» дип искәртүе аның Тукай әсәрләрен матбугатка әзерләүнең гаять тә җитдилеген яхшы аңлаганлыгын күрсәтә. Җыентыкны Сәйфи-Казанлы «академик нәшер» дип атый һәм, аерым алганда, шагыйрьнең матбугат битләрендә чыккан бөтен әсәрләрен эченә алуын, шигырьләренең тарихы күрсәтелүен, мәкаләләре һәм хатлары да кертелүен, «әсәрләре хакында киң күләмдә тәнкыйть анализы» бирелүен әйтә. Басманың 4 китаптан торачагы, әсәрләрен төзегәндә, хронология методы нигез итеп алыначагы хакында да искәртә. Әмма әлеге план тулысынча тормышка ашмый, «Г.Тукай әсәрләре»нең 3 томы гына дөнья күрә: 1 нче томына (1929) шагыйрьнең 1905–1908 елларда, 2 нче томына (1929) 1909–1913 елларда язылган, 3 нче томына (1931) алдагы 2 томына керми калган шигырьләре, «Исемдә калганнар»ы һәм 91 мәкаләсе кертелә.

Тукай әсәрләренең әүвәлге басмаларыннан бу Өчтомлык кай ягы белән аерыла соң?

Беренче җитди аерма тулылыкка омтылышта. Төзүче, 1914 елда дөнья күргән «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асәре»ндәге барлык текстларга өстәп, томнарның аерым бүлекчәләренә шагыйрь үзе исән чагында чыгып килгән җыентыкларыннан, газета һәм журналлардан эзләп табып, тагын 76 шигырен кертә. Шул рәвешле Өчтомлыктагы әсәрләрнең гомуми саны 502 гә җитә. Бу сан әлеге өчтомлыкта кыйммәтле мирасның (Тукай каләме белән якынча 770 ләп текст языла) иң зур өлеше укучылар игътибарына тәкъдим ителгәнлеген күрсәтә.

Икенче аерма – Тукай әсәрләренә аңлатма һәм искәрмәләр (комментарийлар) язу. Дөрес, күпчелек очракта алар теге яки бу текст турында библиографик мәгълүматны гына эченә алган, ягъни әсәрне Тукайның кайда, кайчан һәм ничә мәртәбә бастыруы гына хәбәр ителгән. Бусы да бик мөһим (кызганыч, хәзер дә әле кайбер басмаларда һәм журналларда әдәби мираска караган текстларның чыганаклары хәбәр ителми). Текстлардагы аңлатма-искәрмә «сорап торган» томанлы урыннар исә, Ф.Сәйфи-Казанлы уенча, әле ул елларда (шагыйрьнең вафатына 15–16 гына ел узган) бернинди өстәмә шәрехләүгә мохтаҗ булмый. Шулай да кайвакыт комментарийларда башка төрле өстәмә мәгълүматлар да китерелә: шигырьләрен кабатлап бастырганда, Тукай керткән үзгәрешләр, шагыйрь ияреп язган кайбер рус авторларының исемнәре һәм әсәрләре, Ишми ишан, Әхмәтҗан Сәйдәшев, Карәхмәт, Заһир Бигиев, Һинди Минһаҗ кебек реаль шәхесләр хакында бер-ике сүз-искәрмә һ.б. Хәер, аерым шәхесләр турында язганда, төзүченең карашларында совет чоры йогынтысы: вульгар-социологизм басымы, сыйнфыйлык күзлегеннән чыгып бәяләү ачык сизелә.

Аңлатма-комментарийларның артык җыйнак язылуына җитди сәбәп, минемчә, томнарның «Төзүчедән» исемле кереш сүзләр һәм Тукай иҗаты турындагы мәкаләләр белән ачылуында да. 1 нче томда мондый язма «Г.Тукай әсәрләренең иҗтимагый һәм сәяси йөзе», «Тукай шигырьләрендә динчелек мәсьәләсе характерлы моментмы?» һәм

«Тукайның дөньяга карашы бар идеме?» исемле өч өлештән тора. 3 нче томдагы мәкалә «Г.Тукай әсәрләрендә пародия, сатира, сарказм һәм юмор» дип атала. Әйтергә кирәк, 20 нче елларда Тукай мирасына объектив бәя әле урнашып җитми, аңа большевистик идеология ноктасыннан бәя бирелә. Бу Ф.Сәйфи-Казанлының фикер йөртүендә дә чагыла. Шунысы мөһим: ул шагыйрьне татар әдәбиятының классигы итеп күрсәтә.

«Габдулла Тукаев мәҗмугаи асәре» белән әлеге Өчтомлык арасында күзгә бәрелеп торган аермаларның тагын берсе – текстларны урнаштыруда хронология ысулының өстенлек итүе. Тукайның үз катнашында төзеп калдырылган җыентыгында әсәрләр җитди шигырьләргә, көлке вә һөҗү, балалар кыйсемнәренә, нәсерләргә бүлеп бирелә, хронология сакланмый. Ф.Сәйфи-Казанлы исә шигырьләрне басылу вакытларын истә тотып урнаштыра (чөнки шагыйрь аларның язылу даталарын бик сирәк очракларда гына теркәп калдыра).

Өчтомлыкның 1 нче томына бәяләмә язган Гомәр Гали басмада «академик нәшер» дип исемләүгә дәлил булырдай үзенчәлек-хасиятләр (басманың керешендә аларны төзүче санап чыккан булса да) тапмавын әйтә. Аныңча, «тиешле гыйльми оешмалар» киләсе томнардан «академик нәшер» сүзен алып ташларга тиешләр. Г.Гали бәяләмәләрендә әйтелгән фикерләргә кушылган хәлдә дә, без Ф.Сәйфи-Казанлының яшь татар текстологиясенең казанышы саналырлык хезмәт башкаруын билгеләп үтәргә тиешбез.

1938 елда, Г.Тукайның вафатына 25 ел тулу көнен билгеләп үтү максатында, Татарстан хөкүмәте комиссиясе Татгосиздатка Татарстан Язучылар союзы белән берлектә «якын вакыт эчендә Г.Тукай әсәрләренең академик басмасын чыгару эшен тапшырырга» дигән карар чыгарганнан соң, Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты Г.Тукайның икетомлык академик басмасын төзүне планга кертә. Бу эш Якуб Агишев белән Хәй Хисмәтуллинга йөкләнә. Авыр сугыш елларында нәшер ителгән 1 нче томда (1943) Тукайның барлык шигъри әсәрләре хронологик тәртиптә (балалар өчен текстлар махсус бүлеккә туплана) урнаштырыла, 2 нче томда (1948) проза әсәрләре 4 бүлеккә җыйнап бирелә: 1) автобиографик очерклар, истәлекләр һәм хатлар (барлыгы 13 хат); 2) иҗтимагый-политик һәм әдәби-критик мәкаләләр; 3) хикәяләр, фельетоннар һәм памфлетлар; 4) мәсәлләр һәм дидактик материаллар. Икетомлык «Габдулла Тукай. Академик басма» дип атала. Чыннан да, ул, тулылыгы, төзелеше, текстлары һәм комментарийларының бирелеше ягыннан караганда, бу исем белән дөнья күрүгә лаек идеме соң? Бу турыда дәлилле фикерне «Әдәбият чыганаклары белеме» дигән монографиясендәге («Фикер» нәшрияты, 1998) «Икетомлыкның үзенчәлекләре» исемле мәкаләсендә Нил Юзиев әйткән иде. Ул, архив материалларын да өйрәнеп, әлеге басманың төзелү, редакцияләнү тарихын ачыклый һәм «Тукайның Икетомлыгы «академик тулы җыентык» дип аталса да, чынында, ул бу дәрәҗәгә күтәрелә алмый. Моның өчен әле Тукай әсәрләренең текстологиясе өстендә фәнни эшләрнең җитәрлек дәрәҗәдә алып барылмавы комачаулый. Шуңа да ул гадәти фәнни басма дәрәҗәсендә кала. Бу басма тибы да Институт галимнәре өчен әһәмиятле казаныш булуын әйтергә кирәк. Шушы басма белән Институтта классикларны текстологик әзерләү буенча фәнни традицияләр салына башлый» дигән нәтиҗә чыгара.

Габдулла Тукайның тууына 70 ел тулу вакытлары якынайганда, Тел, әдәбият һәм тарих институтында шагыйрь әсәрләренең яңа басмасын әзерләү эше кузгатыла. Уральскида туып үскән яшь тарихчы Рәфыйк Нәфыйков «Совет Татарстаны» газетасында (1955 ел, 31 май) аны академик басма итеп чыгару кирәклеген язып чыкса да, ул бары, «Әсәрләр» дип исемләнеп, фәнни-популяр басма буларак кына әзерләнә. Күрәсең, җыентыкны төзегәндә, җентекле текстологик тикшеренүләр өчен вакыт аз булгандыр.

Ниһаять, Тукай мирасының Дүрттомлыгы әзерләнә. Аның баштагы ике томында (Казан, 1955) шагыйрьнең шигъри әсәрләре урын ала, соңгы икесенә (Казан,1956) мәкалә, фельетон, очерк һәм хикәяләре кертелә. Дүрт томның да төзүчеләре – Хәй Хисмәтуллин һәм Якуб Агишев, мәгълүм «Академик басма»ны гамәлгә куючы тәҗрибәле әдәбиятчылар. Икетомлык белән чагыштырганда, күләм ягыннан да, томнарның эчтәлеге

ягыннан да аермалар сизелерлек. Икетомлыкның гомуми күләме 1050 бит булса, дүрттомлыкның күләме 1250 бит.

Алдагы ике басманы чагыштырып караганнан соң безнең алда шундый картина пәйда булды: Икетомлыктагы 21 шигырь Дүрттомлыкка кертелмәгән. Шул ук вакытта Дүрттомлыкта 50 ләп «яңа» текст урнаштырып, төзүчеләр әсәрләрнең санын 550 дән 585 кә җиткергәннәр. Тагын бер әһәмиятле як – басманың 4 нче томына кушымтада «Г.Тукай әсәрләренең һәм аның турындагы әдәбиятның кыскача библиографиясе (1907–1956)» бирелү. 50 ел эчендә басмада дөнья күргән китап, җыентык, мәкаләләрнең бу библиографиясе әле бүген дә үзенең кыйммәтен югалтмаган, бүген дә кулланылышта. Библиографиянең керешендә аны туплаучы Мәсгудә Бурнашева: «Тукай әсәрләренең һәм аның турындагы әдәбиятның тулы библиографиясе якын киләчәктә чыгарылыр дип уйлыйбыз», – дип язган иде. Әмма әлеге эшнең бүгенгә кадәр тормышка ашканы юк. Шуны да әйтергә кирәк: Икетомлыкта басылган «Алла гыйшкына», «Кадер кич», «Иртәнге азан», «Мигъраҗ» кебек дини, милли мотивлар да чагылыш тапкан шигырьләр Дүрттомлыкта читтә калдырыла. Моның сәбәбен Нил Юзиев алда телгә алынган китабында болай аңлата: «Мондый шигырьләрнең урынлаштырылмавына бу елларда иҗтимагый вакыйгаларны бәяләүдә шактый көчәеп киткән вульгар-социологизмның фәнни һәм практик текстологиягә үтеп керү билгесе дип танырга кирәктер. Тукайны атеист итебрәк «бизәп», редакцияләп күрсәтергә омтылу, шул рәвешчә әдәбият белемендәге гомуми хезмәтләрдә генә түгел, классикларның әсәрләрен бастырып чыгару практикасында да чагылмый калмый һәм классиклар портретын заманчалатуга бәйле үзгә бер эз сала».

Узган гасырның 70 нче һәм 80 нче елларында Г.Тукайның тагын ике күптомлыгы басылып чыкты. Аларның беренчесе – Дүрттомлык (шагыйрьнең 90 еллыгына багышлана, 1975–1976 елларда басыла), икенчесе – Биштомлык (100 еллыгына багышлана, 1985–1986 елларда басыла). Ике басма да «Әсәрләр» исеме белән дөнья күрә, академик басма дип күрсәтелми. Икесенең дә гамәлгә куючысы – Рашат Гайнанов: ул – төзүче дә, текстларны, аңлатма һәм искәрмәләрне әзерләүче дә1. Ул, басмадан басмага туплана килгән тәҗрибәне үзләштереп, Тукай текстологиясен тагын да югарырак баскычка күтәрә. Бу басмалар СССРның «җепшеклек» һәм «торгынлык» исемнәре белән тарихка кергән елларында, әдәби мираска сыйнфыйлык карашыннан чыгып бәяләү беркадәр йомшарган шартларда әзерләнә. Биштомлыгы буенча эш Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында (хәзер Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) төзелгән махсус текстология төркеменең фәнни-тикшеренү планнары нигезендә алып барыла. Бу алшартлар Тукай мирасын яңача аңлауга, интерпретацияләүгә һәм текстологик принципларны төгәлрәк куллануга юл ача. Төп чыганаклар җентекләп тикшерелә, нәтиҗәдә текстлар Тукайның иҗади ирек-ихтыярын бозмыйча чагылдырырлык хәлгә китерелә. Аңлатма һәм искәрмәләр дә тулылана төшә, теге яки бу әсәрнең язылу тарихын, эчтәлегенең шул заманнардагы тормыш күренешләре, иҗтимагый вакыйгалар, реаль шәхесләр язмышы белән бәйлелеген ачуга хезмәт итә. Басмаларны текстология фәне таләпләренә җавап бирерлек итеп әзерләү Г.Тукайның авторлыгы ачылып бетмәгән әсәрләргә дә игътибар итүдә, аларның кайберләрен томнарда урнаштыруда да күренә. Дүрттомлыкның 2 нче һәм 4 нче томнарында мондый әсәрләр «Аныкы булуы ихтимал әсәрләр» дигән бүлеккә тупланса, Биштомлыкта аларның исемнәре һәм эчтәлеге төрлечә: 2 нче томда «Тукайныкы булуы ихтимал шигырьләр» дип, 4 нче томда «Тукайныкы булуы ихтимал проза әсәрләре», 1 нче томда «Тукайга нисбәт ителгән һәм өйрәнчек шигырьләр (1901–1907)», 3 нче томда «Беренче өйрәнчек һәм Тукайныкы булуы ихтимал әсәрләр (1904–1906)» дип бирелә. Томнарны өйрәнчек әсәрләр белән ачып җибәрү укучылар өчен кызыклы булмас дигән уй кайчак төзүчеләрне гомуми хронологиягә чыгарма ясарга һәм текстларны азакта урнаштыруга этәрә. Бу алым фәнни-популяр басмалар төзү практикасында очрап тора (мәсәлән, Г.Ибраһимов, М.Гафури, М.Җәлил томнарында). Әмма мондый текстларны «ихтимал әсәрләр» белән бергә урнаштыру укучыларда, боларның кайсысы һичшиксез

авторныкы, кайсысы ихтимал гына, дигән дилемма тудыра. Гомумән алганда, Биштомлык совет режимы шартларында да сөекле шагыйребез иҗатын халкыбызга кайтаруда кыю һәм уңышлы адым булды. Шул заман идеологиясе басымы нәтиҗәсендә кайбер әсәрләрнең басмада урын алмавына, берише текстларның кыскартылып кертелүенә, аңлатмалар һәм искәрмәләрнең мәҗбүри рәвештә сыйнфый карашлар «яктылыгында» язылуларына карамастан, егерме биш ел инде ул һаман да кулланылышта.

XX гасыр ахырында илебезнең иҗтимагый тормышында килеп чыккан кискен, радикаль үзгәрешләр әдәбиятыбызның үткәнен бернинди чикләүләрсез өйрәнергә, әдәби мирасыбызны халыкка кайтару юлында фәнни текстология принципларыннан чигенмичә иҗтиһат кылырга мөмкинлек бирә. Бу юлда беренче булып эшләнергә тиешлесе – Габдулла Тукай әсәрләренең тулы академик басмасын төзү. Ниһаять, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбиятчы-текстологлары шушы гаять мөһим текстологик эшкә керештеләр.

Тукай әсәрләренең алтытомлык булып чыгачак академик басмасында, аерым алганда 1 нче һәм 2 нче томнарында, шагыйрьнең шигъри әсәрләре тупланган. Гәрчә 80 нче елларда дөнья күргән Биштомлыкның баштагы ике томы шулай ук шигъри әсәрләрне эченә алган булса да, яңа ике том аларны гына кабатламый. Үзгәрешләр томнарның составында чагыла. Егерме еллар элек Габдулла Тукай әсәрләре рәтендә йөртелгән ике текстны – «Сөй гомерне, сөй халыкны...» дип башланган шигырьне Сәгыйть Сүнчәләй, «Экспромт»ны исә Нәҗип Думави язганлыгы расланган иде. «Аһ идәрсәм...» шулай ук башка авторныкы булып чыкты. Алар томнарга кертелмәделәр. Ә инде Биштомлыкның 1 нче һәм 2 нче томнарындагы кушымталарда бирелгән алты өйрәнчек шигырь («Приемныйның ишекләре...», «“Шура” шигырьләреннән», «Әхмәтсафа әфәнде...», «Тугъды, көн тугар кеби...», «Рөшеде вар...», «Мәгатыйль кыйлды милләтне...») бу юлы, хронологиягә буйсындырылып, томның башына урнаштырылды. Шулай ук томнарга моңа кадәр төрле сәбәпләр аркасында читләштерелгән алты шигырь («Әнвәр бәк», «Кем ул?», «Фәләннең фәләне», «Булмый», «Тәмсил», «Ана илә Бала») өстәлде.

Академик басмаларга куела торган текстологик таләпләрне күздә тотып, төзүчеләр, барлык текстларны чыганаклары буенча тикшереп, аларга күпсанлы төзәтмәләр керттеләр, искәрмә һәм аңлатмаларны төгәлләштерделәр һәм тулыландырдылар, совет чорында тагылган субъектив бәя-хөкемнәрдән арындырдылар. Барыннан да бигрәк, Тукай үзе исән вакытта төзеп калдырган һәм дөнья күргән барлык басмалар – 1907–1914 елларда басылган 33 китап-җыентыктагы текстлар, «Уклар», «Әлгасрелҗәдид», «Яшен», «Ялт-йолт» журналлары, «Фикер», «Әлислах» газеталарының һәр саны җентекләп тикшерелде. Ике томда да текстлар шагыйрь язганча, үзгәртелмичә җиткерелде.

Аеруча зур игътибар аңлатма һәм искәрмәләрне язуга бирелүен кабатлап әйтергә кирәк. Моның өчен, материал эзләп, төзүчеләр Тукай чоры татар газета-журналларына мөрәҗәгать иттеләр. 1906–1913 елларда чыккан «Йолдыз», «Кояш», «Идел», «Вакыт», «Әлислах» газеталарында, «Шура», «Яшен», «Ялт-йолт», «Дин вә мәгыйшәт» журналларында Г.Тукай темасы күпмедер дәрәҗәдә чагылыш таба. Татарстан Республикасы Милли архивында саклаган цензура материаллары шагыйрь иҗатының һәрчак күзәтү астында торганлыгы турында сөйлиләр. Томнарны төзүчеләр Тукайның теге яки бу әсәре нинди чыганакларга таянып, иҗади файдаланып язылуын ачыкларга омтылдылар. Нәтиҗәдә кайбер әсәрләрен язуга этәргән рус авторларының шигырьләре дә табылды һәм искәрмә-аңлатмаларга урнаштырылды. Аларны Тукай әсәрләре белән янәшә куеп, чагыштырып укыганда, татар шагыйренең һәрчак диярлек иҗади эш итүен, үз уй-фикерен чагылдыруын күрергә була.

Зөфәр Рәмиев,
филология фәннәре докторы

1 Алга таба күптомлыклар Икетомлык, Өчтомлык, Дүрттомлык, Биштомлык дип биреләчәк.

1 Biштомлыктагы материалларны текстологик яктан әзерләүдә Лена Гайнанова катнаша.

1904

* * *

Әхмәтсафа әфәнде1 – фазыйль әдибдер кәнде;
Каләме – могыйне милләт, әзһәре – хакдыр бәнде.

Фамилиясе Байтирәк, мисле дөньяда сирәк;
Бундый инсанлар кайда? – Безнең милләткә кирәк.

Чук яшәсен Сафамыз – шулдыр безнең хафамыз,
Ишанларга кимертелде безнең калын кафамыз.

Бундый әдибләр күбәйсә сынар ишан тешләре;
Теше сынгач онытылыр пылау һәм бәлешләре.

Ишан да, милләт, ди, башлар, утка якыб тәсбихен,
Инсафына кәлүб ташлар мөрид җыйнау тәшвишен.

Җенсән бу зат мишәрдер, димәк, хәйрелбәшәрдер;
Бу затны мәкруһ күрәнләр – барча шәррелбәшәрдер.

Хәзерге әдәби телдә

Әхмәтсафа әфәнде – әйбәт язучы үзе;
Каләме – милләткә файда, язганы – хак көзгесе.

Фамилиясе Байтирәк, аның кебекләр сирәк;
Мондый кешеләр кайда? – Безнең милләткә кирәк.

Күп яшәсен Сафабыз – шулдыр безнең кайгыбыз;
Ишаннарга кимертелде безнең калын җилкәбез.

Мондый әдипләр күбәйсә сынар ишан тешләре;
Теше сынгач онытылыр пылау һәм бәлешләре.

Ишан да, милләт, ди, башлар, утка ягып тәсбихен,
Инсафына килеп ташлар мөрит җыйнау тәшвишен.

Чыгышы белән ул – мишәр, димәк ки, изге кеше;

Аны яратмаганнарның бары да – әшәке кеше.

* * *

Тугъды, көн тугар кеби, бер сахибе һиммәт гани;
Чарасыз мәдх итмәсенә мәҗбүр әйләде бәни.

Исме аның Вәлиулла1, димәк, улыр әүлия;
Хамие дине Мөхәммәд һәм хәбибе әнбия.

Тасвир итде мәдрәсәне гүя бер гәүһәр фишан;
Пакьлеге, гүзәллеге вирәдер оҗмахтан нишан.

Тәҗдид итде мәктәбең ашханә, госелханәсен;
Иҗтиһадла табдул һәрбер мөшкилгә бер чарасын.

Кәлде, тәгъмир әйләде, дәфгъ әйләде зилләтләри;
Галәми игъмар идәҗәк тагъ кисәр һиммәтләри.

Япды җәннәт кеби идеб мәхдүм2 өчен бүлмәйе;
Шунда мохтар итде мәхдүм ятмайы-ултырмайы.

Бундан әүвәл барча искеләр иде.
Халь дилилә мәдрәсә сөйләр иде;
Диер иде: «Сез мине ник бакмыйсыз?
Ник карамыйсыз да ник чистартмыйсыз?»

Агълар ирде: «Банием үлдеме? – диб.–
Йә исә шартладымы, бөлдеме?» – диб.
Дир иде: «Мортаза бай!3 Мортаза бай!
Сән нигә бигрәк саран булдың болай?

Нигә салдың син бәни – карамагач,
Үз малың үз файдаңа ярамагач.
Мортаза бай! Син төзәтмәссең бугай –
Мин телимен Алладан икенче бай».

Күб дә үтмәде – кабул булды теләк,
Мөнкәсир улды һәм әгъразе киләб:

Чыкды аңсыздан Хәмидуллин Вәли,
Тәгъмир итде балядә мәзкүрләри!

Бу затмыш зөбдәэ сангать илаһи,
Инсан имеш дә фитърәте кәмаһи

Мәүлямез әмсалене итсен гадид,
Таки улсын бәхтияр гасры җәдид!

Хәзерге әдәби телдә

* * *

Туды, көн туган кебек, бер игелек иясе бай;
Мактатырга мәҗбүр итте ихтыярсыздан бугай.

Исме аның Вәлиулла, димәк, ул – изге кеше;
Мөхәммәд динен яклаучы, пәйгамбәрләр сөюче.

Бизәде мәдрәсәне ул асылташ кебек итеп;
Гүзәллеге оҗмахны искә төшерерлек итеп.

Мәктәп ашханәсен, юыну бүлмәсен яңартты;
Тырышлыгы белән кыен эшкә чарасын тапты.

Килде дә ямьсез, килбәтсез урыннарны төзәтте;
Тау кисәр эшлекле ул – тотынса, дөнья төзәтер.

Мәхдүм өчен дә бер бүлмәне гүя җәннәт итте;
Мәхдүм дә аны үзенә тору урыны итте.

Моннан элек барсы да иске иде.
Мәдрәсә күңле белән әйтә иде,
Диер иде: «Соң ник мине сез бакмыйсыз?
Ник карамыйсыз да ник чистартмыйсыз?»

Елый иде: «Хуҗам-бай үлдеме? – дип.–
Әллә ул шартладымы, бөлдеме?» – дип.
Әйтә иде: «Мортаза бай! Мортаза бай!
Син нигә бигрәк саран булдың болай?

Нигә салдың син мине – карамагач,
Үз малың үз файдаңа ярамагач.

Мортаза бай! Син төзәтмәссең бугай –
Мин телимен Алладан икенче бай».

Күп тә үтмәде – теләк кабул булды,
Кабат ялваруга урын калмады:

Чыкты аңсыздан Хәмидуллин Вәли,
Нишләгәнен санап чыктым бит әле!
Ул илаһи осталыкка ия икән,
Тумыштан ук игелекле кеше икән.

Алла мондыйларның санын арттырсын,
Әйдә, яңа гасыр бәхетле булсын!

1905

* * *

Голүмең бакчасында дулашалым, идәлем сәйран;
Сәгадәт-бәхтемезгә калсын инсе, җинниләр хәйран.

Татарлар рәфгате, шаны сикез кат күкләрә китсен;
Әбәд-сәрмәд бу милләтне Ходаем бәхтияр итсен!

Борынгы уйкуларны дөшенүбән улалым надим;
Тәрәкъкый вә тәгали юлларына улалым кадим.

Бәһаим дәфтәренә язмасынлар безне дәүләтләр;
Тәхәррек итмәлиез, күстәреб хасләт вә сауләтләр.

Хәятны дәгъва итсәк, мөддәгани идәлем исбат;
Дәлилләр күстәреб, бу кяинати идәлем искят.

Җиһанда болгарың вар улдыгына канигъ улсынлар;
Безем парлак бәхеткә гыйбтачы һәм тамигъ улсынлар.

Тырышып, идәлем журналларың әмсалени тәксир;
Җәһаләт вә наданлык ардусыны идәлем тәксир.

Гәзитең дөрлү әнвагы күбәйсен көн бә көн кат-кат;
Мәгариф мәйданында без, татарлар, уйнаталым ат.

Җәридә файдасы чукча мөҗәррәбдер бу галәмчә;
Мәгыйшәт идәлем дөньяда адәм ибне адәмчә.

Голүмлә дөньяи дотды япун, нәмсә, французлар;
Җәһаләт гафләтилә йоклаганмызлар без аңсызлар.

Шөкер улсын, уянып тордылар әүлядләре гасрың;

Безез әсхабе, әүляде бу гасры мәгърифәт касрың.

Сарылды милләтең яшь каһраманлары каләмләргә:
Мәхәл вармы борынгыдай хәзән, хәсрәт, әләмләргә?
Хәзерге әдәби телдә

* * *

Гыйлемнәр бакчасында күңел ачып йөрик;
Бәхетебезгә кешеләр дә, җеннәр дә калсын хәйран.

Татарларның бөеклеге, даны сигез кат күкләргә китсен;
Мәңге, һәрвакыт бу милләтне Ходаем бәхетле итсен!

Элек йоклап үткәргәнебезне уйлыйк та үкеник;
Алгарыш һәм күтәрелеш юлларына атлап үтик.

Безне дәүләтләр «хайван» дип белмәсеннәр;
Кыю һәм батыр рәвештә алга хәрәкәт итик.

Теләсәк яшәргә, дәгъвабызны исбат итик;
Дәлилләр китереп, бу галәмне сүздән туктатыйк.

Дөньяда болгарлар әле дә бар икәненә ышансыннар;
Якты бәхетебезгә көнләшсен һәм үзләре дә омтылсыннар.

Тырышып, журналларның төрләрен күбәйтә башлыйк;
Кирелек, наданлык гаскәрен җиңеп, сындырып ташлыйк.

Газеталар, журналларны көннән-көнгә кат-кат күбәйтик;
Мәгариф мәйданында без, татарлар, ат уйнатыйк*.

Газетаның файдасы кат-кат сыналган ич дөньяда;
Без дә адәм угълы – адәмчә тормыш итик дөньяда.

Гыйлем белән дөньяны кулда тотты япон, немец, француз;
Без, аңсызлар, наданлык аркасында йоклап калганбыз.

Шөкер булсын, гасырыбызның яшьләре уянып тордылар;
Без – бу мәгърифәт гасыры сараеның иярләре һәм балалары.

Милләтнең яшь каһарманнары каләмгә сарылды:
Элеккечә кайгы-хәсрәт, ачынуларга хәзер урын бармы?

* * *

Чөнанча бездә Камил әл-Мотыйгый,
Ходаның әмренә монкат, мотыйгый,

Карар итде язарга журнал айлык,
Голүмнең мәнбәгы, әфкярә байлык.

Бу журналның наме «Гасрелҗәдид»дер,
Япышканларга һәм хәблел-мәдиддер.

Берең укып, берең улың сәмиган,
Япышыңлар бихәблилләһ җәмиган.

Аллаһың хәбле дидекем иэтиляф,
Димәк, улыр иҗтинаб әз ихтиляф.

Ки сез, картлар, егетләр, дөхтәриләр,
Улың бу журнала һәп мөштәриләр.

Милләтә сәрмая һәм зур мал ирер,
Әүвәл уларак чыкан журнал ирер!

Һәр кимә үз дилилә тәфһим идәр,
Һәр лөзүмле шәйләри тәкъдим идәр.

Көйлеләр, карьялеләр дә карыйк,
Һәр кимә бәркъ ора нурый барикый;

Нитә көнәш тугъмасилә дәр бәһар,
Нурлана бу дөньяда һәр нә ки вар.

Эстәңез сезнең хәрир мәндиленңез, –
Иштә бу журнал ирер кандиленңез.

Журналың һәр кәгазе – миръатеңез;
Алдыңызда парлаян мишкятеңез.

Сезгә вафадар имеш талигъ фәләк:
Мондый зур нигъмәтләри тәкъдир кәрәк.

Шөкридәлем журналың булганына;
Хәмдитә былбыл да ай тулганына.
Мәүлямез әмсалени итсен гадид,

Та ки улсын бәхтияр гасры җәдид.

Каләмне забт идеб вирдем ниһаять;
Буныңла иҗтиза итдем кифаять.

Шигырь бабында юк бәндә мәһарәт,
Фәкать бу тугърыда кыйлдым җәсарәт...

Намем Габдулла – Алла бәндәсемен,
Җәмигы колларың шәрмәндәсемен.
Хәзерге әдәби телдә

* * *

Шулай итеп, бездә Камил әл-Мотыйгый
(Ул буйсынучан) Ходайның әмеренә буйсынып

Карар итте чыгарырга журнал айлык.
Гыйлем, фикер чишмәсе бит ул – байлык.

Бу журналның «Гасрелҗәдид»тер исеме,
Укыганнарга – тотынып бара торган җеп төсле.

Берегез укыгыз да, берегез тыңлагыз,
Барчагыз Алла җебенә ныклап тотыныгыз.

Алла җебе дигәнем үзара якынаю, дуслашудыр,
Димәк, үзара каршылыктан, ызгыштан сакланудыр.

Эш шулай икән, сез, картлар, егетләр,
Кызлар – барыгыз да бу журналга язылыгыз.

Милләткә мая булыр, зур байлык булыр,
Әүвәл буларак чыккан журнал ич бу!

Ул һәркемгә үз телендә төшендерер,
Һәртөрле кирәкле нәрсәләрне тәкъдим итәр.

Авылда да, салада да алып укучыларына –
Барысына да, яктыртып, нурлар бөрки,

Ничек яз башында елмаеп кояш чыкса, шуның кебек,
Дөньядагы һәр бар нәрсә дә нурлана.

Сез хыялланган ефәк яулык та –
Чынында шушы журнал, ул – сезнең шәмегез.

Журналның кәгазе – сезнең өчен көзге,
Алдыгызда яктыртылган чыраг ул.
Тәкъдир сезгә теләктәшлек белән елмая:
Мондый зур бүләкнең кирәк кадерен белергә.

Шөкер итик журналның чыгуына;
Сандугач та бит тулган айны мактый.

Алла мондый журналларның арттырсын санын,
Әйдә, яңа гасыр бәхетле булсын!

Ниһаять, каләмемне туктаттым язудан,
Шуның белән чикләнергә рөхсәт сорыйм.

Шигырь язарга миндә осталык юк,
Тик әле кыюлык итеп кенә яздым.

Исемем Габдулла – Алла бәндәсемен,
Алланың барлык колларыннан иң оялчаны мин.

Мужик йокысы

(Шагыйрь мәшһүр Кольцовның шигыреннән
тәрҗемә вә икътибас ителмештер)

Ник йоклыйсың, мужик?
Яз җитте, һәм үсте
Чирәмнәр йортыңда;
Тор, уян, күтәрел!

Үз-үзеңә кара:
Кем идең, кем булдың?
Нәрсә бар милкеңдә?

Ындырда юк орлык,
Иген юк урырлык;
Атың бар бик начар,
Өч тәңкә торырлык.

Игенең урмаган,
Кибәнең куймаган,

Син үзең дә ялкау,
Хатының – «булмаган».

Исеңнән чыгарма:
Сине бай вактыңда
Дустларың мактады
Алдыңда, артыңда;

Син кайда барсаң да,
Урның иде түрдә,
Акчасыз күп артык
Тыныч яту гүрдә.

Синдә мал беткәнне
Дустларың белделәр;
Алдыңда, артыңда
Кул чабып көлделәр.

Урмаган арышың
Ята кырда ятим;
Хәтерең калмасын,
Бер-ике сүз әйтим:
Урмаган арышың –
Бер еллык табышың;
Аны җил коядыр,
Чыпчыклар җыядыр.

Инде кыш та керде,
Игенне бетерде;
Чаналар астында
Ак карлар шытырдый.

Үзеңдә – ялкаулык,
Хатныңда – аңкаулык;
Кайда кышка азык,
Ачлыктан сакларлык?

Күршеләр, йөк төяп,
Калага саттылар
Һәм, җыйгач күп запас,
Бот сузып яттылар.

Җиктеләр пар аттан,
Өй салып нараттан;

Синең йортта аш юк,
Туярлык таракан.

Синең өй балчыктан,
Бөкрәйгән карчыктай;
Кимреп иске ипи,
Ашыйсың тансыктай.

Хатының, балаң ач,
Ашарга булмагач;
Бу көнне күргәнче,
Өеңне ташлап кач.

Күршеләр бай булды,
Ашлары май булды;
Син, ялкау, йоклагач,
Янчыгың сай булды.

Иттеләр өмәләр,
Җыйдылар гөмбәләр;
Һәр михнәт соңында
Рәхәтле көн дә бар.
Тик яткач, Ходаем
Бирми мал сәбәпсез:
Бишмәтең таланган,
Күлмәгең сәдәпсез.

Хак сүзне әйткәнгә,
Киң күңлең тарайса,
Урныңнан кузгалма,
Йоклый күр, алайса.

Шигырь

Шималь яктан чыгып бәркъ, орды бер нур,
Зыясыннан әһали улды пәрнур.

Мотабикъдер мөсәммасенә исме,
Мөнасыйбдыр дәхи исменә җисме.

Нә дәүләт милләтә, нә бәхт вә талигъ,
Бу көз төньяктан улды шәмес талигъ.

Әгәр итсә иде ислам тәҗәссем,
Бакыб бу «Нур»а идәрди тәбәссем, –

Ничек миръат катында зифа дөхтәр
Көлеб һәм бакдыкынча бакмак эстәр.

Мәхәлле нәшре гали җай шәһәрдер;
Ки нуры тәхте пае падишаһдыр.

«Нур»ың һәр сәтры хави төрле мәгънә,
Каляме хикмәт вә мәгънәя мәбнә.

Вә һәр әхбаре – садыйк, гайре кязиб;
Хәлаикъ калебе җалиб вә җазиб.

Һәр тарафка нур сачәр, мәшһүр улыр;
Сүзләре энҗе кеби мәнсүр улыр.

Чугулсын мөштәри кариәләре һәм
Булынсын милләтең дәрденә мәрһәм.

Җәридә – бер фәридә, наме – «Нур»дыр,
Татара якты көндер һәм сөрурдыр.

Нә мәдхитсәм дә, нәфсем улмый канигъ,
Һаман мәдхитмәя мәйял вә тамигъ.

Аны мәдх вә сәнамыз та әбәддер,
Каләм гүя аны мәдхә әсәддер.

Мәгариф нәшре улсын бездә гадәт;
Буңа багълы дорыр бәхт вә сәгадәт.
Габәс үткәрмәялем маһ вә сали,
Тәрәкъкый идәлем, идеб тәгали.
Тәгассыблар, тәшәйехләр нә лазим?
Улалым җөмләмез бер юла газим.

### Бер бәхре дигәр

«Тәрҗеман» бу милләтең
Дәрденә улсын тәрҗеман;
«Нур» да тәнвирендә тәксир
Итмәсәйде һәр заман.

### «Хәят» өчен янә бер дигәр

Хәятына «Хәят»ың гыйбта
Итде әрмәнстанлар,
Әбәд хәй улсын,
Ачылсын юлына һәб.
Хәзерге әдәби телдә

Шигырь

Төньяктан, яшьнәп яшен, бер нур атылды,
Яктысыннан халыкның күзе чагылды.

«Нур» дип аталуы да бит бик урынлы,
Шулай ук исеменә җисеме дә килә туры.

Милләткә никадәр байлык, бәхет, якты
Киләчәк, чөнки бу көз төн яктан кояш чыкты.

Бар мөселман булалса иде бер гәүдә,
«Нур»га карап елмаер иде ул, гүя

Көзге алдында бер зифа кыз көлә
Һәм, караган саен, аның карыйсы килә.

Бөек, зур шәһәр аның басылу урны,
Патшаның башкаласында чыккан ул нур.

Һәр юлы төрле мәгънәгә ия «Нур»ның,
Чөнки ул хикмәтле сүз-мәгънәдән гыйбарәт.

Аның һәр хәбәре ялган түгел, туры,
Дөрес; халык күңелен үзенә тартып тора.

Бар якка нур чәчә, шуның белән мәшһүр ул,
Сүзләре дә энҗе кебек тезелгән.

Алдырып, укучылар саны гел үссен,
Милләт авыруына шифа булып төшсен!

Газета – тиңдәшсез нәрсә, исеме – «Нур»,
Татарга ул – якты көн, зур куанычтыр.

Ничек кенә мактасам да, артык түгел,

Гел мактап кына торырга тели күңел.

Мактарбыз һәм зурларбыз без аны һаман;
Арысландай булып мактый аны каләм.
Мәгариф тарату булсын бездә гадәт;
Бит шуңа бәйле бәхет-рәхәт.

Бушка узмасын һич безнең һәр ай, һәр ел,
Тәрәккый итеп тотыйк алга юл.

Нигә кирәк искелек, кирелек һәм шәехлек –
Барчабыз бер юлдан тырышып атлыйк.

Башка үлчәмдәге шигырь

«Тәрҗеман» бу милләтнең
Авыруын әйтүче булсын;
«Нур» да агарту эшеннән
Беркайчан да туктамасын!

«Хәят» өчен тагын үзгә үлчәмдәге шигырь

«Хәят»ның яшәп килүенә
Әрмәннәр дә көнләште;
Мәңге терек бул син,
Юлларың гел ачык булсын!

* * *

Бу көндә бер сарай ачды әһали –
Гүзәлдер, мисле эндәр, кадре гали.

Гаҗибдер чәй вә аш әсбабе хали;
Мөрәттәб, монтазамдыр кәл-ләали.

Фираш идәненә зифа паласлар;
Мөзәйян һәр тараф – өстләр вә астлар.

Нәкышләнмеш вә һәр әтрафе миръат;
Түшәмдә парлайыр мисбахы мишкят.

Канадиле сираҗи биңзәр айә,
Мөшабиһ рәүнәкы «Йолдыз сарай»а.

Ятыр өстәлидә дөрлү җәраид,
Ки һәрберсе безем әхвалә гаид.

Гизәр әтрафидә вилданы сәйяр,
Нәмер итсәң, аңа гыйльманы тайяр.

Әлендә бунларың ширбәтләри вар,
Йөрештә җил кеби сөргатьләри вар.

Гүзәлдер һәр җире – гайрәтлә мәгъмур;
Әгәр күрсә калыр хәйрәттә фәгъфур.

Бу миһманханә улды шәһрә фаикъ –
Дәгел миһман, олугъ шаһларга лаикъ.

Будыр шатлык вирән дәрдле колүбә;
Колүбе шат улмаян – варсын клубә.

Ачылмыш яңы гөлләр, бәһрәләр зар,
Вә махсус сухтәләр чөн хөҗрәләр вар.

Җиһанда мисле надир бер клубдыр,
Сөрүрел-җан (вә) һәм нурел-колүбдер.

Улыб бер сүздә бер дәртле җәмәгать,
Чыгыб мәйданә, күстәрде сәнәгать.
Чалышыб, сарф идеб чук парәләр һәм
Дөзүбән дөрлү тәдбир чаралар һәм

Шөругъ итсә, нәләр япмас бу милләт!
Шөругънең юклыгы – милләткә гыйллә т.

Дәвам итсен, яшәсен чук бу бөстан
Һәм улсын шөһрәте дилләрдә дастан.

Нә мәдх итсәм дә, нәфсем улмый канигъ,
Һаман мәдх итмәя мәйяле тамигъ.

Аны мәдхе сәнамыз та әбәддер,
Каләм гүя аны мәдхә әсәддер.
Хәзерге әдәби телдә

* * *

Бу көндә кешеләр бер сарай ачтылар, –
Үзе гүзәл, тиңдәше аз, кадере югары.

Чәй һәм аш савытларының торышы гаҗәп:
Энҗеләр кебек тезелгәннәр.

Идәнендә – зифа паласлар;
Һәр ягы зиннәтле – өсләре дә, аслары да.

Һәр ягы көзгеләр белән бизәлгән;
Түшәмдә кандилләрдә шәмнәр балкый.

Кандилләренең шәмнәре айга охшый –
Бизәлүе «Йолдыз сарае»ныкына охшый.

Өстәлендә төрле газеталар ята –
Һәрберсе безнең хәлебезгә бәйле.

Әйләнә-тирәдә егетләр йөреп тора;
Ул егетләр ни кушсаң да әзер тора.

Боларның кулларында эчемлекләре бар;
Йөргәндә җилдәй тиз йөриләр.

Һәр җире гүзәлдер – тырышып эшләнгән;
Күрсә, Кытай патшасы да шаккатыр.

Бу кунакханә бөтен шәһәргә ямь бирде;
Түгел юлчыларга гына, олы шаһларга лаек.

Бу – кайгылы күңелгә шатлык бирә;
Күңеле шат булмаганнар барсын клубка.

Әле генә гөлләр ачылган – язлар көнләшер;
Кунаклар өчен махсус бүлмәләр бар.

Җиһанда охшашы аз бер клубтыр –
Җанга шатлык һәм күңелләргә нур.
Бер теләктәге кешеләр, бер сүздә булып,
Мәйданга чыгып, зур осталык күрсәттеләр.

Тырышып, күп акчалар тотып һәм
Төрле-төрле чаралар күреп,

Ниләр эшләмәс бу милләт, әгәр керешсә!
Милләтнең чире – керешмәүдер эшкә.

Дәвам итсен бу бакча, озак яшәсен,
Һәм шөһрәте телләрдә дастан булсын!

Күңел канәгатьләнми күпме мактасам да, –
Торасым килә мактап һаман да.

Аны мактавыбыз – мәңгелек;
Аны мактауда каләм арыслан кебек.

## Хөррият хакында

Кайда китте цензурлык,
Коллык, тарлык, ким-хурлык?
Артка карасак борлып,
Ерак анлар калдыя.

Тигез булды законда
Татар, урыс, япун да;
Ак алъяпкыч, зипун да
Там азатлык алдыя.

Барча цензур ябылгач,
Дәрткә дәрман табылгач,
Кызыл кара ясаган
Кярханәләр бөлдия.

Күп яшь егетләр үлде,
Мәетләр дөнья тулды,
Намнары бакый булды
Та кыямәт тидия*.

Шәкерт, студент – бары,
Дарга асылганнары, –
Сез бу арысланнарый
Онытмагыз тидия.

Кызганмады малларын,
Корбан кыйлды җаннарын,
Җан биргәндә, шатланып,
Көлә-көлә үлдия.

Инде китте элгәре
Зынҗырланган телләре,

Милләтнең былбыллары
Сайрап-сайрап тордыя.

*

Китте хәсрәт, әләмнәр,
Иркенләде каләмнәр;
Булсын күп-күп сәламнәр
Рухларына тидия.

Мәмнүн булсын рухлары,
Изге булсын духлары;
Боларның ах-ухлары
Хөрриятне бирдия.

Дустларга бер сүз

Менә, дустлар, мин сезләргә бер сүз сөйлим,
«Йосыф-Ягъкуб китабы»ның көен көйлим;
Ушбу милләт ертыгының җөен җөйлим, –
Җебем кара, инәм каләм булсын имди.

*

И кардәшләр, кул тотышып, алга барыйк,
Башка милләтләрнең хәлен карап карыйк;
Мәдәният мәйданында урын алыйк, –
Егъла-тора, алга таба атлыйк имди.

*

Гыйлем белмәс хайваннарга без охшамыйк,
Тырышмактан, тырмашмактан һич бушамыйк;
Диңгез якасында торып, без сусамыйк, –
Хөрриятнең диңгезләре ташый имди.

*

Чиновниклар безнең канны бик күп имде,
Имәлмәсләр, җитәр инде, җитәр инде!
Мәзлүмнәргә якты, нурлы көннәр килде, –
Азатлыкның кояшы тугъды имди.

*

Һәр милләтләр максудларын хасил итә*:
Депутатлар ясап, Петербургга китә;
Инде нәүбәт без бичараларга җитә, –
Җыйлып-җыйлып, депутатлар сайлыйк имди.

*

Бездә күзе ачык кешеләр дә бардыр,
Бу заманда гафилләргә дөнья тардыр;
Бу хөррият – Манифесте государьдыр, –
Кадрен белеп, кирәкләрне сорыйк имди.

*

Бу эшләрдә зәхмәтләмик муллаларны,
Дин эшендә башчы иттек без аларны;
Яхшы булыр тапшырсак без дөньяларны
Абразауный егетләргә тәмам имди.

*

Барып керик хөрриятнең кочагына,
Тәрәкъкыйнең күкләренә очмагына;
Бу егетләр безне дөнья оҗмахына
Кулдан тотып җитәклиләр, белең имди!

Иттифакъ хакында

Күрең патша хәзрәтен –
Җуйды халык хәсрәтен,
Күргәч фетнә кәсрәтен,
Киңлек бирде, бәдәвам.

Файдаланыйк киңлектән,
Ваз кичик мин-минлектән;
Көчле-көчсез тиңлектән
Файда алыйк, бәдәвам.

Тырышыйк, и хас вә гам,
Һәр көн үзгәрә заман;
Җитәр, йокламыйк һаман, –
Таңнар атты, бәдәвам.

Кызганамын сезләрне,
Ник ачмыйсыз күзләрне?
Киләчәктә бәхетләр
Көтә безне, бәдәвам.

Итик, дустлар, иттифакъ,
Бетсен, кадалсын нифакъ;
Тәнемез айрым булса да,

Бер җан булыйк, бәдәвам.

Якты көннәр алдале,
Җәһел безне алдалый;
Бүлик без бер алманы
Биш кисәккә, бәдәвам.

Җыйналып мәҗлес ясыйк,
Бер-беремездән качмыйк;
Наданлыкка юл ачмыйк, –
Бик күп изде, бәдәвам.
Кайчанга чаклы татар
Ушбу уйкуда ятар,
Бер-берсенә ук атар,
Иттифакъсыз, бәдәвам?

Ачыйк иттифакъка юл:
Ушбудыр иң тугъры юл;
Сыңар җиңнән ике кул
Чыгарыйк без, бәдәвам.

### Алла гыйшкына

Өлфәт илә без дә итик өлфәт Алла гыйшкына;
Тәрк улынсын кибре, газбе көлфәт алла гыйшкына.

Тәэлиф улынсын колүбе милләт Алла гыйшкына;
Дәүрулынсын иске гыйлләт, зилләт Алла гыйшкына.

Бу юла һиммәт итик, и өммәт, Алла гыйшкына;
Бөйлә һиммәт безгә җөмлә сөннәт Алла гыйшкына.

Измәсен безне җәһаләт бөйлә Алла гыйшкына;
Чарасын яз, йә шифаһән сөйлә Алла гыйшкына.

Улмасын гыйльмә тәгассыб пәрдә Алла гыйшкына;
Җанланыйк, баш кузгатыйк һәр йирдә Алла гыйшкына.

Тәрке өлфәт илә милләт кәлде ушбу халә кем, –
Гыйбрәт, и өммәт Мөхәммәд! Гыйбрәт Алла гыйшкына.

Без дә инсан, без дә итик гайрәт Алла гыйшкына;
Калдырыйк бу галәми дәр хәйрәт Алла гыйшкына.

Милләти тәрфига күңлем ашыгадыр, ашкына;

Итмәсен пәрваз күңелем, бастырып куй таш кына.

Лязем улды безгә билне бугмак Алла гыйшкына;
Мәгърифәтме йә һөнәрме? – тугъмак Алла гыйшкына.

Бар һөнәремезгә канигъ улмыйк Алла гыйшкына;
Тәңренең лотфына манигъ улмыйк Алла гыйшкына.
Хәзерге әдәби телдә

Алла гыйшкы хакына

Без дә бер кешедәй дус булыйк Алла гыйшкы хакына;
Эрелек, төче теллелекне ташлыйк Алла гыйшкы хакына.

Милләтнең күңеле аңа юнәлсен Алла гыйшкы хакына;
Иске чир, түбәнлек юк булсын Алла гыйшкы хакына.

Шул юлга омтылыйк, и диндәшләр, Алла гыйшкы хакына;
Мондый омтылыш, тырышлыклар керсен гадәткә
Алла гыйшкы хакына.

Болай итеп, наданлык безне измәсен Алла гыйшкы хакына;
Чарасын яз яки телдән сөйлә Алла гыйшкы хакына.

Гыйлемгә кирелек пәрдә булмасын Алла гыйшкы хакына;
Җанланыйк, кузгалыйк һәр җирдә Алла гыйшкы хакына.

Дуслык булмау сәбәпле, милләт шушы хәлгә килде, –
Гыйбрәт ал, и Мөхәммәд өммәте! Алла гыйшкы хакына.

Без дә кеше ич, итик гайрәт Алла гыйшкы хакына;
Бу дөньяны хәйран калдырыйк Алла гыйшкы хакына.

Милләтне күтәрергә күңелем ашыга һәм ашкына;
Китмәсен күңелем очып, бастырып куй таш кына.

Тиеш булды безгә билне буу Алла гыйшкы хакына;
Мәгърифәт, һөнәр туамы? – бар да Алла гыйшкы хакына.

Бар һөнәребезгә канәгать булмыйк Алла гыйшкы хакына;
Тәңре мәрхәмәтенә каршы килмик Алла гыйшкы хакына.

Хәзерге хәлемезә даир

Хәсәд, кинә илән тулган татарлык –

Төяб илтеб Мәкәрҗәдә сатарлык.

Мөхәррирләр өчен хөрмәтләре юк,
Бу динә зәррәчә хезмәтләре юк.

Каләм әһле каләмгә хөрмәте юк,
Болар гыйндендә кибрең хөрмәте чук.

Сүземә бакыңыз – юллар ачармын,
Үземә бакмаңыз – үзем начармын.

Җәһаләт таптамасын – яньчелермез,
Каләмгә каршы бармыйк – чәнчелермез.

Каләм сәед дорыр руе зәминә,
Сәзадер сурәтен «Нүн» дә яминә.

Мөхәррирләр сәбәб диндә сәбатә,
Ике дөнья җәхименнән нәҗатә.

Болардыр дине исламның гыймады,
Боларга итмәлиез игътимады.

Мөхәррирсез язылдымы бу Коръән,
Мөхәррирсез дөзелдеме бу Форкан?

Мөхәррирләр – ирер исламә кувәт,
Аларда мөҗтәмәгъ һиммәт, фөтүвәт.

Зәгыйфьләргә рәфикъ, сагъларга каид,
Болардыр – мөваззах җөмлә гакаид.

Болар кемдер – буны яхшы белик без,
Боларның кәсрәтен хактан телик без.

Каләм гали, каләм сами каләмдер;
Ходаның каүледә җае къәссәмдер.

Каләм намле, каләм шанлы каләмдер,
Шифадыр дәрдә, сабуны әләмдер.
Хәзерге әдәби телдә

Хәзерге хәлебезгә карата

Көнчелек, үчлек белән тулган татарлык,
Төяп илтеп Мәкәрҗәдә сатарлык.

Язучыларга хөрмәтләре юк,
Бу дингә бөртек тә хезмәтләре юк.

Каләм иясенең каләмгә хөрмәте юк,
Болар каршында тәкәббернең хөрмәте күп.

Сүземә карагыз – юллар ачармын,
Үземә бакмагыз – үзем начармын.

Наданлык таптамасын – яньчелербез,
Каләмгә каршы бармыйк – чәнчелербез.

Каләм – хөкем йөртүче җир йөзендә,
Аның белән ант ителгән «Нүн» сүрәсендә.

Язучылар – диндә ныклыкка сәбәп,
Ике дөнья тәмугыннан котылуга чара.

Болар бит – исламга терәк,
Безгә боларга таянырга кирәк.

Язучысыз язылдымы бу Коръән,
Язучысыз төзелдеме бу Форкан?

Язучылар – исламга көч-куәт,
Аларда юмартлык, омтылыш, ялкынлы дәрт.

Көчсезләргә иптәш, көчлеләргә җитәкче,
Болар – бөтен ислам инануларын ачыктан-ачык күрсәтүче.

Боларның кемлеген яхшы белик без,
Боларның артуын Ходайдан телик без.

Каләм – бөек, каләм – дәрәҗәле;
Ходайның телендә ант урынында ул.

Каләм – данлы, каләм – шанлы; каләм ул –
Чиргә дәва, кайгыны юар сабындыр.

1906

* * *

Рөшде вар, кауле гүзәл, наме – Рәшид;
Җөмлә бу иршад илә улсын рәшид!

Шатлык илә итәлийез өлфәт илә « Өлфәт»и1:
– Тәрк идәлем иддигани һәм тәкәллеф-көлфәти!

Хәзерге әдәби телдә

* * *

Зиһене бар, сүзе гүзәл, исеме – Рәшит,
Шундый җитәкчене һәркемгә җитәкче ит!

Бик куанып, « Өлфәт» белән без дусларча сүз ачыйк:
– Дошманлык, тәкәллеф ише кимчелекләрне ташлыйк!
* * *

Мәгатыйль кыйлды милләтне1 гаталәт вә кәсаләтдән;
Бу хезмәтчөн азад улды у цензур нам әсарәтдән.

Хәзерге әдәби телдә

* * *

Азат итте милләтне ул дәртсезлек һәм ялкаулыктан;
Бу эше өчен азат булды цензур исемле коллыктан.

Шәкерд, яхуд бер тәсадеф

Урамларда гизәр көн бән бәнагяһ
Тәвәкъкыф әйләдем һәм улдым агяһ.
Күрәм бер талиби: тәхсыйлә варыр,
Утырыб хәл җыяр да тагы арыр.

Тишек пима, тишек бишмәт илән ул
Буранлы көндә тотмыш мәктәбә юл.
Суыкның зәмһәрире, зәһре кискен, –
Тагы туктар, тагы атлар у мескин.

Ярым җисме ачылмыш – ялтырыйдыр,
Үзе туңган вә дер-дер калтырыйдыр.
Яба җиләнене, җилдән качадыр, –
Ничә япса да, җил аны ачадыр.

Аны күрәнчә бөйлә хале гъөрьбәт,
Вөҗүдем кайнады, ирешде көрбәт.
У мескини беләнчә кальбе мәҗрух,
Могаззәб улды вөҗдан, ачыды рух.

Күзем дикдем, аңа сөйләдем әшгар,
Бу юл илә һәм ихлас итдем ишгар.
Дидем: и йир йөзендәге фәрештә,
Өмидсең сән бу милләткә һәр эштә.

Оялма бу киемнең тишегендин,
Катаңның катканындин, кыйшыгындин.
Очыб төш дә сәбавәт бишегендин,
Ябыш – айрылма мәктәп ишегендин.

Сәнең фәкърең – дорыр фәхрең, онытма;
Моның дик юк фаразла кайгы йотма.
Сәнең бу вардыгың юл – раһе әслаф;
Бу юл илә йитешмеш җөмлә әшраф.

Бу галәм, бел – фәкыйрьлек галәмедер,
Мөвәкъкать бер хәкыйрьлек галәмедер.
Ниһаятьсез сәгадәттер мәали;
Соңы – рифгать, тәрәкъкыйдер мөгали.
Бу галәмдин әдибләр калкымышдыр,
Тәмам дөнья йа ай тик балкымышдыр.
Сәнең дә йөксәлер бер көн мәкамең, –
Язылыр, ихтимал, алтынлә намың.

Атаңыз, анаңызның шатлыгы сез,
Ике дөньяда йөзләр аклыгы сез.
Каму мөслимләрең уртаклыгы сез,
Безем дине мотаһһар пакьлеге сез.

Голүм әкъфаленең сез ачкычысыз,
Тәрәкъкый күкләренең баскычысыз.
Мәгариф бакчасында әйлә тайран,
Ризык чөн янмасын кальбеңдә ниран.

Үзеңне әгъниядән ярлы күрмә;
Ки пәйдәрпәй бәлешләргә йөгермә.
Каралтма кальбеңи, ашаб кикермә, –

Игендәге чикерткәдәй сикермә.

Бәлеш илә гыйлем бергә җыелмас,
Хирыслы адәм үлгәнчә тыелмас.
Сереңне бирмә, яшер карның ачын;
Ләимдин интизар итмә мәгашың.

Үл ачлыкдин! – тәгам көтмә ләимдин;
Өмид ит ризкыңый Рәхман Рахимдин.
Хәрыйслык гаять әсфәлдер, сәфилдер;
Шәкертләр ризкына Тәңре кәфилдер.

Бу сүзгә итмәсен кальбең тәзәлзел,
Ләимә әйләмә, зинһар, тәнәззел.
Вә бәгъдә айрылыб китдем, тәәссеф!
Тәәссеф, йөз тәәссеф, бең тәәссеф!

У бер якны тотубән, бән дә – бер як;
Куеб китдем аның вәҗгына тирьяк.
Хәзерге әдәби телдә

Шәкерт, яки бер очрашу

Урамнарда гизгәндә мин кинәт
Туктадым һәм искәрдем;
Күрәм бер шәкертне: укырга барыр;
Утырып хәл җыя да тагын китәр.

Тишек пима, тишек бишмәт белән ул
Буранлы көндә тоткан мәктәпкә юл.
Суыкның катылыгы, зәһәре кискен, –
Тагын туктый, тагын атлый ул мескен.

Гәүдәсе яртылаш ачылган – ялтырыйдыр;
Үзе туңган һәм дер-дер калтырыйдыр.
Җиләнен яба, җилдән качадыр, –
Күпме япса да, җил аны ачадыр.

Аны мондый кызганыч хәлдә күреп,
Үзәгем өзелде, кайгы басты.
Ул мескеннең күңеле яралы икәнен белгәч,
Вөҗдан газапланды, җан ачыды.

Күзем текәп, аңа шигырьләр сөйләдем, –
Шушы юл белән ихласымны белдердем.
Дидем: и җир йөзендәге фәрештә,
Син бу милләтнең өмете һәр эштә.

Оялма бу киемнең тишек булуыннан,
Катаңның каткан һәм кыйшык булуыннан.
Очып төш тә балалык бишегеннән,
Ябыш – аерылма мәктәп ишегеннән.

Синең ярлылыгың – синең мактанычың, онытма;
Һәм мондый юк-бар уйлар белән кайгы йотма.
Синең бу барган юлың – галимнәр юлы;
Бу юл белән барлык олы кешеләр җитешкән.

Бу дөнья, бел, – ярлылык дөньясыдыр,
Вакытлы бер хурлык дөньясыдыр.
Максаты – иксез-чиксез бәхет;
Соңы – үсү, бөеклеккә күтәрелү.
Бу дөньядан язучылар күтәрелгәннәр, –
Дөньяга нәкъ ай кебек балкыганнар.
Көне килер: синең дә урының бөек булыр;
Ихтимал, исемең алтын белән язылыр.

Атагыз, анагызның шатлыгы сез,
Ике дөньяда йөз аклыгы сез.
Барлык мөселманнарның уртаклыгы сез,
Безнең саф динебезнең пакьлеге сез.

Гыйлем йозагының ачкычы сез,
Тәрәккый күкләренең баскычы сез.
Мәгариф бакчасында очып йөр,
Ашау-эчү өчен күңлең борчылмасын.

Үзеңне «байлардан ярлы» дип санама;
Тыр-тыр итеп бәлешләргә йөгермә.
Күңелеңне каралтма, ашап кикермә, –
Игендәге чикерткәдәй сикермә.

Бәлеш белән гыйлем бергә җыелмас,
Комсыз кеше үлгәнче тыелмас.
Сереңне бирмә, карының ач булуын яшер;
Сараннан яшәү өчен ярдәм көтмә.

Ачлыктан үл! – саранннан азык көтмә.
Азыгыңны Алладан өмет ит.
Комсызлык – түбән, бик түбән сыйфат ул;
Шәкертләр азыгын Тәңре үзе бирер ул.

Бу сүзгә күңелең тетрәмәсен;
Зинһар, саран алдында түбәнчелек күрсәтмә.
Шуннан соң аерылып киттем, үкенеч!
Үкенеч, йөз үкенеч, мең үкенеч!

Ул бер якка юл тотты, мин – икенче якка;
Аның авыруына дару куеп киттем.

### Яз галәмәтләре

Язлар җитте, карлар эри башладылар,
Толыплылар толыпларын ташладылар;
Киемсезләр иркен йөри башладылар,
Тунсызларга нурлы көннәр килде имди.

Ката, чана табаннары ял итәләр,
Шылтыр-шылтыр юлдин арбалар китәләр.
Трантаслар, велосипед, кареталар
Урамнарны чуарлыйлар бер-бер имди.

Каткан, туңган агачларны хәзер кара:
Һәрбересе яшәрешеп яфрак яра;
Бу урманнар бакча булыр бара-бара,
Һәр агачта сандугачлар сайрар имди.

Җиде кат боз астындин чыгар бака,
Баткакларга, балчыкларга бата-бата;
Куе камыш арасындин бака-бака:
«Бака-кака, бака-кака», – диер имди.

Шул бакалар ярга чыгып бакылдаша,
Берсен берсе аңлашмыйча такылдаша;
Әллә нәрсә киңәшәләр, акыллаша:
Ахры, мантыйк укыганнар бунлар имди.

Кышлар үтеп, яз көннәре килер исә,
Сәхраларда йомшак саба җиле исә;
Аһ, бу көннәр гамькин күңелләрне кисә,
Үткән гомер бер-бер искә төшә имди.

Дәрьяларда бозлар ага тау-тау булып,
Һаваларда кошлар оча болыт-болыт;
И Ходаем, фазлың берлә көнне җылыт,
Үлгән дөнья яңа җаннар алсын имди!

И каләм!

И каләм! Китсен әләм, сән әйлә безне шадыман;
Без дә саяңдә улалым тугъры юла кадыман.

Без өсәраи, көсаляи дә сәүкъит һиммәтә;
Кыйл тәрәххем милләтә – калдырма, зинһар, зилләтә.

Рәфгыйдеп Аурупаи сән гарше әгъләйә кадәр,
Нә ичүн безне дөшердең фәрше әднәйә кадәр?

Милләтең бу хале мәктүбме китабы хикмәтә?
Монхасыйрмы ане гомре хәле мәхзүниятә?

Яз тәгаллемләргә тәргыйб, әйлә тәкъдир къәдрене;
Ит наданлыкларны тәгъриф, зәһрене яз, гъәдрене.

Караны яз «кара» диб һәм игътираф ит акны ак;
Җөпне «җөп» дип язмалысан һәм ушандак такны так.

Бакма һич кәс хәтеренә, милләтең дәрденә бак!
Бәддога – явыз догая һәр заман асма колак.

И каләм, сәндән кәлер һәп бәхтемез, икъбалемез;
Бәкләнәр дүрт күз илә лотфыңда истикъбалемез.

Кичмәсен караңгылыкта маһемез һәм салемез;
Гафилез без, җаһилез – вай хәлемез, вай хәлемез!

Һәр тараф мөслимләри бер-бер идәрләр аһе ваһ!
Нә сәбәбле кәлди безгә бөйлә бер бәхте сияһ?

Әйлә ярдәм безгә һәрдәм, и каләм, кыйл мәрхәмәт;
Дәфгулынсын җөмлә хәсрәт, фәкъру хәкъру, мәскәнәт.
Хәзерге әдәби телдә

И каләм!

И каләм! Китсен газап, ит син безне шат;

Без дә синең аркаңда туры юлга басыйк аяк.

Без әсирләрне, ялкауларны да зур эшкә этәр;
Милләткә мәрхәмәт ит, – зинһар, хурлыкка калдырма.

Европаны күтәреп син югары күкләргә кадәр,
Ник төшердең безне – җиде кат җир астына кадәр?

Милләтнең бу хәле хикмәт китабына теркәлгәнме?
Гомернең һәрбер сулышы хурлык белән чикләнгәнме?

Чакырып яз укырга, уку кыйммәтен тәкъдир ит;
Аңлат наданлыкның начарлыгын, агу икәнен.

Яз караны «кара» дип һәм акны ак,
Җөпне «җөп» дип һәм шулай ук такны так.

Һәр кеше күңелен [генә] күрмә, милләт авыруына бак!
Бәддога – явыз догага һичвакыт салма колак.

И каләм, бәхет һәм якты киләчәгебез синнән килер;
Якты киләчәгебез дүрт күз белән рәхмәтеңнән көтелә.

Үтмәсен караңгылыкта айларыбыз, көннәребез;
Гамьсез дә без, надан да без – вай хәлебез, вай хәлебез!

Һәрьяктагы мөселманнар бер төслүк аһ-ваһ итә,
Безгә мондый кара бәхет нидән килде? – дип әйтә.

И каләм, безгә һәрдаим ярдәм һәм мәрхәмәт ит;
Хәсрәт, хурлык, мескенлекләр – мәңгегә кит!

Ифтиракъ соңында

Шигъръ чук итдем һәвәс кальбем илә, җанымла бән,
Чөнки итдем ифтиракъ җанымла, җананымла бән.

У гүзәл гыйшкында әшгар сөйләмәкне халисән
Кәндемә мөнис идәндем кальбе гирьянымлә бән.

Улды яр әгъярә яр, һәм улды кальбем тарумар;
Иштә яздым шигъреми күздән акан канымла бән.

Агъладыб китдең бези бер залимә, и залимә!
Әкләнеркән нуры хөснең – нуры мөжгянеңлә бән.

Дәм-бә-дәм илһам идәр дәрдең бәңа гыйльмелгаруз;
Нә кадәр яздымса – яздым җөмлә илһамыңла бән.

Яр улыб әгъярә сән, әгъдая көлдерден бези;
Мөхтәрикъ улдым да яндым наре һиҗраныңла бән.

Бетде, вәйран улды шимди асеманым һәм зәмин;
Дөньями, гокъбами екъдым яәс вә хирманыңла бән.

Җан якан азарыңа һич кинәсез мәфтүнеңем;
Һәр заман идәм тәләззез аһе әхзаныңла бән.

Намеңи тәхрир идәрсәм, фаш улыр дөньяйа раз;
Шигъгрә вирдем ихтитам, намеңне китманымла бән.

Хәзерге әдәби телдә

Аерылышу соңында

Бик һәвәсләндем шигырьгә күңелем, җаным белән,
Чөнки аерылыштым мин җаным-җанашым белән.

Ул гүзәлгә чын йөрәгемнән гыйшкымны сөйләүне
Кайгылы күңелем белән юлдашым иткән идем.

Ярым ятларга яр булгач, тар-мар килде бәгырем;
Шуңар инде канлы күз-яшь белән яздым шигырем.

Син, җылатып безне, бер явызга киттең, и явыз!
Гүзәллегеңә сокланып кына яшәгәндә без.

Һәр сулуда шигырь илһам итә сине сөюем,
Күпме язсам да язам тик илһамың белән синең.

Яр булып ятларга, безне дошманнардан көлдердең;
Аерылып миннән, и гүзәл, янган утка дүндердең.

Күгем дә һәм җирем дә вәйран булды, инде бетте,
Җуйдым дөньям, ахирәтем, чөнки син ташлап киттең.

Җан яндыргыч кыйланышыңа бары тик сокланам,
Синең хәсрәтле аһыңнан һәр заман ләззәт алам.

Сер дөньяга фаш була дип, исемең телгә алмадым,
Менә шулай атсыз гына шигырьне тәмамладым.

Шагыйрь вә Һатиф

Һатиф:

Нәдер, шагыйрь, кәчәр һәр анлари налишле әзманең?–
Дулу сәбгы сәмавәт һәп синең атәшле әхзанең.
Зәминә сыгъмады дәрдең ки, итдең күкләрә әгъля;
Нәдер бу бидәва хәсрәт, нәдәндер бәйлә истигъля?

Шагыйрь:

Заманың инкыйлабатына бән һәр дәмдә калканым;
Бәхак бән нар сачар әтрафә бер атәшле вулканым.
Чәкәм дине мөбиннең бән тәдәннисенә аһ-ваһлар,
Идәм бән башка милләтең тәрәкъкыйсенә ваһ-ваһлар.

Һатиф:

Насыл итсен тәдәнни дин, – бу дин илә җиһан мәмлү;
Бу ислам хак дорыр, – әлбәттә, хаклык бигөман ягълү.

Шагыйрь:

Морадымдыр димәкдән «дин» – бу динең җөмлә әрбабы;
Капалдыкча әһали – капланыр диннең дә һәр бабы.
Гыйбарәт итделәр динне тәшәйех: башны бөкмәкдән
Вә көффарә тәнәззелдән, тәзәллел яшьне түкмәкдән.

Һатиф:

Сәңа лязимме агъламак, – у динне башчылар баксын;
Тарикы мөстәкыйм шәмгын аңа юлбашчылар яксын.

Шагыйрь:

Әвәт шөйлә, әвәт шөйлә! Фәкать чук ачыер җаным;
Җәхиме дөньяда булдырды инсафымла вөҗданым.

Һатиф:

Йитәр, шагыйрь, бу фөрьядыңла инҗетмә мәлаикне:
Ки һәркем билмәли кәнди нәдер шәэненә ляикъне.
Хәзерге әдәби телдә

Шагыйрь һәм һатиф

Һатиф:

Ник, шагыйрь, һәр сулышыңны ыңгырашып аласың син?
Җиде кат күкләргә кадәр утлы аһыңны атасың син.
Җиргә сыймадымыни хәсрәтең – күкләргә үк ашты;
Нидән бу дәвасыз кайгы, нидән бу күкләргә ашу?

Шагыйрь:

Заманның үзгәрешләренә мин һаман да калканмын;
Чын-чыннан мин тирә-якка утлар чәчәр бер вулканмын.
Түбәнлеккә төшүенә туры диннең аһ-ваһ итәм,
Башка милләтнең алга китүенә мин ах-ух итәм.

Һатиф:

Ничек инде түбәнәйсен – бу дин белән дөнья тулы;
Ислам бит хак дин, ә хаклык, һичшиксез, гел өстен булыр.

Шагыйрь:

«Дин» дигәндә, шул юлдагыларның барын күздә тотам;
Алар бетсә, диннең барлык ишекләре ябылып бетә.
Динне бит гыйбарәт диделәр ишаннар: баш бөгүдән,
Кяферләр алдында кимсенеп, хурланып яшь түгүдән.

Һатиф:

Сиңа җылау тиешме, – ул динне муллалар кайгыртсын;
Туры юл күрсәтүче шәмен юлбашчылар кабызсын.

Шагыйрь:

Әйе, шулай, әйе, шулай! Әмма җаным бик тә ачына;
Инсафым һәм вөҗданым дөньяны тәмуг ясый миңа.

Һатиф:

Җитәр, шагыйрь, аһ-зар белән фәрештәләрне рәнҗетмә:
Үзенә нәрсә лаек икәнен һәркем үзе белә.

* * *

Сәгадәт юк, фәкать наме сәгадәт; –
Көфуне вирмәмәк безләрдә гадәт.
Көфу улмазса яр, әлбәт, һәлакәт;
Кәфаәт шарт, кәфаәт шарт, кәфаәт.

Тәзәүвеждә ирер мәргуб тигезлек;

Каралыр ит базарында симезлек.
Тотың, мәгъзүр бәни, атам: бән алмам, –
Нәмә лязим алу кыз мисле ям-ям.

Туганнан бирле йөрмеш ирдем уйлап,
Үземдәй кыз илән ятам, дип, уйнап;
Аның мәдхендә дирсез: эшкә оста!
Улырмы яр бәңа оста урыс та.

Хәзерге әдәби телдә

* * *

Бәхет юк, аның тик исеме генә бар, –
Тигез-тиңлеккә юл куймау бездә гадәт.
Ярың тиң-пар булмаса, әлбәттә, һәлакәт,
Пар булу шарт, пар булу шарт, пар булу.

Өйләнештә иң кирәге – тигезлек;
Каралыр ит базарында симезлек.
Кичерегез мине, атам: мин алмыйм, –
Кыз кыяфәтле аждаһа ник кирәк?

Йөргән идем туганнан бирле уйлап,
Үземдәй кыз белән ятам дип, уйнап;
Аны мактап дисез: «Ул эшкә оста!»
Яр булырмы миңа оста урыс та?

«Фикер» гәзитәсенә генә махсус түгел

Языңыз да фикереңезне, фикри фикрә багълаңыз;
Фикридүбән хәлемезне, «Фикр»ә языб агълаңыз.

Фикреңезгә юл вирермез, дәрҗ идәрмез «Фикр»ә без;
«Мәҗмәгыль әфкяр» намене вирмеш идек «Фикр»ә без.

Фикреңезне сыгъдырыр мәйдане васигъ «Фикр»емез;
Милләтә һәр фикри тәфкирә муасигъ «Фикр»емез.

Языңыз әфкяреңез, улсын мөнәүвәр фикреңез;
Фикреңездер – фикремез һәм фикремездер – фикреңез.

Язмалы, дәрҗ итмәле – гольянә кәлсен фикремез;

Бу гокамәтләр бетеб, дөньяя кәлсен фикремез.

Чөн тәвәллед итсә әфкяр, юлланыр һәр кяремез, –
Фикремез будыр безем, мәгълүмеңез, дәркяреңез.

Та әзәлдин бирле безләр фикремез мәхбүс идек,
Кем капамышдыр бези? Мәхбүс идек, мәэюс идек.

Кәлде форсат ул кафәсләрне дә вәйран итмәя,
Һәм алыб сәрбәст нәфәсләрне дә тайран итмәя.

Фикремез улсын мөҗәддәд, – кыйл хәзәр! Искермәсен,
Һәм дә җәнҗалдан, җидальдән кыл кадәр ис кермәсен.

Фикремез тәфрикы өммәт йилләрен исдермәсен,
Исдереб, тәүхиде милләт юлларын кисдермәсен.

Хәзерге әдәби телдә

«Фикер» газетасына гына махсус түгел

Фикерегезне языгыз да фикергә фикер ялгагыз;
Фикерләшеп хәлебезне, «Фикер»гә язып елагыз.

Фикерегезгә юл бирербез, бастырып «Фикер»гә без;
«Фикерләр җыентыгы» исемен бирдек бит «Фикер»гә без.

Бар фикрегезне сыйдырыр: мәйданы иркен «Фикер»нең –
Милләткә фикерләшергә ирек биргән «Фикер»нең.

Фикерегезне языгыз, тик якты булсын фикерегез;
Фикерегездер – фикеребез һәм фикеребездер – фикерегез.

Языйк һәм басып таратыйк, – олы фикерләр кузгалсын;
Бу кысырлык бетеп, дөньяга фикеребез юл алсын.

Чөнки фикерләр кайнаса, эшләр дә алга китәр, –
Бу мәгълүм булсын һәркемгә – шушындый безнең фикер.

Борынгыдан бирле безнең фикеребез тоткын иде;
Кем соң безне мескен итеп тоткында тоткан иде?

Килде форсат кысан читлекләрне итәргә тар-мар,
Килде, иркен сулыш алып, вакытыбыз канат кагар.

Фикеребез торсын яңарып гел, – саклан! Искермәсен;
Үзара җәнҗал-ызгыштан кыл кадәр ис кермәсен!

Фикеребез халыкны таркаткыч җилләр истермәсен,
Истереп, милләтнең берләшү юлын кистермәсен!

Мөридләр каберстаныннан бер аваз

Милләти вәйран идән ишан икәндер, белмәдем;
Ул ишанлар милләтә дошман икәндер, белмәдем.

Милләти иһдам идән, игъдам идән шунлар имеш;
Анларый инкяр идән зи шан икәндер, белмәдем.

Анларый юк итмәк ичөн чын күңелдән чалышан –
Милләти әгълая чалышан икәндер, белмәдем.

Анлара каршы каләм тартанлар – арыслан имеш;
Анларый тәкъдис идән таушан икәндер, белмәдем.

Шунлара коллык идәнләр, кул вирән бичаралар –
Милләти излял идән шәйтан икәндер, белмәдем.

Анларый мөршид санан әгъванлары ахмак имеш;
Безләри иршад идән Коръән икәндер, белмәдем.

Бу ишанлыклар-фәләнләр бер мәҗүсилек имеш;
Нигезе-аслы буның ботлан икәндер, белмәдем.

Чук заманлар әкл идән бунлар бу җансыз милләти;
Бу ишан мәет йиән сыртлан икәндер, белмәдем.

Бунлара табигъ улубән, бер-беренә ук атан
Бу тәвабигъ җөмлә шарлатан икәндер, белмәдем.

Дәрсе гыйбрәт вирде безгә «Инкыйраз» нам бер әсәр;
Аһ, боны язган кеше инсан икәндер, белмәдем.

Кәндеми суфи белеб, хатырлыйордым җәннәти,
Иштә кадрем эт илән якьсан икәндер, белмәдем.

Хәзерге әдәби телдә

Мөритләр каберстаныннан бер аваз

Таркатучы милләтне ишан икәндер, белмәдем;
Ул ишаннар милләткә дошман икәндер, белмәдем.

Милләтне бетерүчеләр нәкъ менә шулар икән;
Аларны кире кагучы – намуслы икәндер, белмәдем.

Чын күңелдән тырышучылар аларны юк итәргә
Милләтне гел күтәрүчеләр икәндер, белмәдем.

Аларга каршы каләм күтәргәннәр – арыслан икән;
Ишанны изге санаучы – куян икәндер, белмәдем.

Ишаннарга коллык иткән, кул биргән бичаралар –
Милләтне аздыручы шайтан икәндер, белмәдем.

Аларны башчы санаучы иярченнәре ахмак икән,
Безләрне туры юлга күндергән Коръән икәндер, белмәдем.

Бу ишанлыклар-фәләннәр бер мәҗүсилек икән,
Нигезе-аслы төпсез бернәрсә икәндер, белмәдем.

Бу җансыз милләтне алар күп заманнар кимергәннәр,
Үләксә ашаучы сыртлан икәндер ишан, белмәдем.

Болар коткысы астында бер-беренә ук аткан
Иярченнәр барсы шарлатан икәндер, белмәдем.

«Инкыйраз» исемле әсәр безгә гыйбрәт сабагы бирде;
Аһ, моны язган кеше инсан икәндер, белмәдем.

Үземне суфи исәпләп, оҗмахны искә ала идем;
Чынында кадерем эт белән бер икәндер, белмәдем.

Гыйшык бу, йа!..

Бер гидае җан фидаем, гыйшкыңа пәрванаем;
Кәл, гүзәл, гарз ит җәмалең: янаем, кил янаем.

И Ходаем, вир гакыл, чөн хәбсә мәхбүс улмыям;
Бу кызың гыйшкында бән диванаем, диванаем.

И гүзәл, кәл каршыма, кәл, кыйл тәбәссем лотфидеп;
Бән дә хәүлеңдә сәнең дәүранаем, дәүранаем.

Әл-аяк багълы, мөхаль кортылмакым, мәсхүреңем;
Та әбәд дәрдең илә әүвараем, әүвараем.

Ач никабыңны йөзеңдән – парласын руе зәмин;
Бән дә әнвареӊ илә парланаем, парланаем.

Сурәтем бәңзәр бәнем бер кансыза, бер җансыза;
Кыйл тәрәххем хәлемә: канланаем, җанланаем.

Вир сөрүр мәсхүреңә, бер кәррә бундан ит мөрүр;
Хаке паеңдә сәнең ауланаем, ауланаем.

Саллаер аһәстә-аһәстә бәни бу мәһде дәрд;
Нә зарар? Ләхдә кадәр салланаем, салланаем.

Юк ифакать та кыямәт, шөйлә бер мәхмүреңез;
Күз вә кашыңдан сәнең айланаем, айланаем.
Хәзерге әдәби телдә

Гыйшык бит бу!

Җанын фида иткән фәкыйрьмен, гыйшкың күбәләгемен;
Кил, гүзәл, күрсәт матурлыгың: янаем, кил, янаем.

И Хода, бир акыл, тоткыннар йортына эләкмим;
Бу кызга гыйшкым сәбәпле диванамын, диванамын.

И гүзәл, кил каршыма, кил, елмайчы рәхим итеп;
Мин дә синең әйләнәңдә әйләнием, әйләнием.

Кул-аяк бәйле, котылу кайда! – сихерләнгәнмен;
Мәңгегә синең дәртеңнән баш әйләнгән, баш әйләнгән.

Йөзеңнән пәрдәңне ал, җир йөзе яктырып китсен;
Мин дә синең нурың белән яктырыем, яктырыем.

Минем сурәтем бер кансыз, бер җансыз нәрсәгә охшый;
Хәлемә мәрхәмәт ит тә: канланыем, җанланыем.

Сихерләнгәнне шатландыр: үтче алдымнан бер кат;
Синең аяк туфрагыңда тәгәрием, тәгәрием.

Бу дәрт бишеге мине әкрен-әкрен генә тирбәтә;
Ни зарар? Үлгәнче тирбәнием дә тирбәнием.

Синнән исергәнемнән үлгәнче котыла алмам;
Күз һәм кашыңнан синең айланыем, айланыем.

Пушкинә

Нәзыйрсыз шагыйрь улдың (афәрин!), Пушкин Александр!
Бәнем дә дәрде шәүкым һәм сәнең дәрдеңлә якьсандыр.

Сәнең әшгареңә, бәнчә, агач, даш билә рәкъсандыр;
Агач рәкъс итмәмәк шагыйрь улан инсанә ноксандыр.

Нә чөн рәкъс итмәсен, шигъреӊ мисале шәмсе рәхшандыр;
Нә шагыйрьдер у кем әшгар аңа Мәүлядан ихсандыр.

Касавәт кәлмәйер кальбә: сәнең шигъреӊ мөнафиһа, –
Нәчек кем шәмсә каршы парлайыр дөнья вә мафиһа.

Кыйраәт әйләдем, әзбәрләдем бән җөмлә асарың;
Кереп гөлзарыңа, бән дә тәнавел иттем әсмарың.

Сәнең бакчаңда гиздем, йөредем һәм әйләдем тайран;
Күрүбән гандәлибаны, тамаша әйләдем сәйран.

Кәлер рәүнәкъ колүбә сүзләреңдән, җанә сайкаллар;
Дикелмәз бөйлә улмадыкча һичбер намә һәйкәлләр.

Мәрамем-матлабым анчак сәнең мәнзум вә мәнсүрең;
Бәнем шәэнемме тәфтиш мәзһәбеңне, дине мәнсүбең?

Әвәт, дәрдем дорыр якьсан, вәликин бәндә юк дәрман,
Бирер дәрмани дә, шаять, җәнабе мән ләһелфәрман.

Хәзерге әдәби телдә

Пушкинга

Тиңдәшсез шагыйрь булдың (афәрин!), Пушкин Александр!
Минем дә дәртем-теләгем нәкъ синең дәртең белән бер.

Синең шигырең көенә агач, таш бии, минемчә;
Биемәслек итеп язу кимчелек шагыйрь кешегә.

Якты кояшка тиң шигырең алдында ник биемәсен;
Илаһи илһамга ия булган көчле шагыйрь бит син.

Күңелгә күләгә төшми, – шигырьләрең якты шундый,
Гүя бөтен дөнья балкый алтын кояш яктысында.

Һәммә әсәрләрең укып, күңелемә ныклап беркеттем, –
Гөлбакчаңа кереп, җимешләреңнән мин авыз иттем.

Синең бакчаңда мин гиздем, гүя анда очып йөрдем;
Сайрар кошларыңны күреп, шунда күңел ачып йөрдем.

Күңелгә – хуш, җанга якты шигырьләреңнән кем туяр!
Шулай булмады исә шагыйрьгә кем һәйкәлләр куяр?

Бар теләк-максатым минем – тезмәң, чәчмәләрең синең;
Минем эшмени тикшерү – карашың синең һәм динең.

Әйе, теләгем бер генә, әмма юк шул миндә куәт;
Өмет итәм, кодрәтле зат бирер дип, дәрман да, шаять.

«Уклар» журналында мөхбир
уланлара тәнбиһ*

И «Уклар» мөхбирләре! Кызганмагыз укларны,
Исраф итмәгез укларны, атмагыз сез юк-барны.

Бездән фәрман шул сезгә: патрон берлә не шалить!
Кирәк җиргә атканда, патроннарны не жалеть!

Атучыга әмеребез – укларны кызганмасын!
Атылмышка нәсыйхәт: йөрәге сызланмасын.

Кечкенә генә бер көйле хикәя

Бар иде бездә Сафи атлы кеше,
Бик юаш, бичара, беркатлы кеше.

Тире сатып, җон алып чыккан теше, –
Бар эше шул, юк кеше берлән эше.

Тиргәше юк, сугышы юк, төртеше;
Рәнҗеми, таякласа да бер кеше.

Дине таза, бик каты тәкъва кеше,
Дикъкате бар, диндә бик әкъва кеше.

Бик матур корылмыш иде тормышы,

Яхшы иде, бик чибәр көн күрмеше.

Бар иде бер Фатыйма нам хатыны;
Язамын бу хатының бер катыны.

Һәр эштә бу Фатыйма уңган иде;
Мактыймын: уңган иде, булган иде.

Һәм дә ямьсез түгел иде төскә дә,
Модный форма күлмәк иде өстә дә.

Бу хатынның һәйбәтилә гайрәте
Һәр заманда җәлеп итәрде хәйрәте.

Сафи – абыстай иде, бу – абзыйдыр;
Дөньяда мондый Сафилар азмыдыр?

Сафи абзыйга бөтенләй баш иде,
Сафи – муен, Фатыйма апай – баш иде.

Сафи абзыйны изәр көрпә кеби,
Кабарып үзе ата күркә кеби.
Сафи абзыйга орышны мул бирер,
Сафи абзый һәр заманда юл бирер.

Башын иеп, арык ат кеби торыр;
Фатыймасы аргамак кеби торыр.

Фатыймапай тарлана һәрнәрсәгә,
Һәм диер: бу нәрсәгә, бу нәрсәгә?

Йә самавыр яки чәйнек шелтәсе;
Лампа янмый – кыска икән филтәсе.

Күз ачырмас, Сафи абзыйны талар;
Әллә кайдан фетнә чыгарыр, табар.

Монда язаем бәланең бәгъзесен,
Мең дә берсен, бәгъзесеннән бәгъзесен.

Бер заманда Фатыймапай иренә:
– Ушбу эшләрне китер! – ди, – җиренә:

Калфагым искерде, яңасы кирәк;

Энҗесе дә, мәрҗәне дә бик сирәк.

Күрмисеңме син фәләннең килнени,
Куфта кигән, мин алардан киммени?

Мин дә сөямен киемне бик кенә,
Ник миңа да алмыйсың син, ник кенә? –

Шул сүз илә мескин ирен төрткәли,
Каршы әйтсә, яңагына сөрткәли.

Сафи абзый китәдер башны бөгеп,
Күзләреннән эссе күз яшьне түгеп.

Сарыф итеп базарда актык тиенени,
Кайтадыр алып хатынның киемени.

Күп тә яздым, кариэм, сез ардыгыз
Һәм чыдамас мәртәбәгә бардыгыз.
Инде язам Фатыйманың тормышын,
Нә рәвештә тормышын һәм йөрмешен.

Бер көне килде моңа карчык явыз,
Бәдбәхет, йөзе кара, бер җалмавыз.

Ушбу карчык йөрмеш иде аздырып,
Һәр хатынны тугъры юлдан яздырып.

Монда да килде бу көн бу карчыгым,
Муйнына асып мәкерләр капчыгын.

Диде: «Кызым, мин сине бик кызганам,
Кызгануымнан йөримен, кузгалам.

Син, кызым, нурлы йөзем, бик яшь әле,
Яшьлегең дә җир йөзенә фаш әле.

Яшь хәлеңдә торма бу картың илән,
Сөймә картыңны, утыр артың илән.

Гомреңе үткәрмә, торма ир илән,
Ир илән торганчы, тор син чир илән.

Торма бер көн дә ирең берлән, кызым,
Тормасана, йолдызым, и кондызым!

Ник торасың син ирең берлән, кызым?

Үтә кайгыда кичәң һәм көндезең.

Бер тиенгә тормый бу картың синең,
Яшьлегең, матурлыгың – алтын синең.

Яки, ирең йоклагач, яшьләрне тап,
Бер сүзе җәүһәргә алмашларны тап.

Яшь егетнең куйны – ожмах, агъзы – бал,
Йөзләре алсу-кызылдыр, буе – тал».

Ушбу сүзләр Фатыйманы җилкетә,
Яшь йөрәк – җүләр йөрәкне селкетә.

Берничә көннәр соңында Фатыйма
Йөртә башлады егетләр катына.

Бер егет үбә килеп, ике егет,
Фатыйманың да кала аузы җебеп.
Кайвакытта баргалыйдыр бакчага:
Гыйффәтен сатарга юк-бар акчага.

Ала башлады егетләр куйнына,
Йоклый иде кул салубән муйнына.

Ирене дә санламыйдыр бер дә һич,
Сафи – абыстай икәнен әйттем ич.

Кичә-көндез уйнамак та уйнамак,
Уйнамакның ахрыны юк уйламак.

Сафи абзый хатынына ялына,
Белсә дә һәм белмәмешкә салына.

Хатынының һәр эшеннән күз буа,
Кара карганы сабын берлән юа.

«Юкны әйтәсез, – ди, – сез, Фатыйма пакь,
Пакь хатын – судан, дәхи дә сөттән ак».

Сафи булмыш Фатыймапайга мөрид,
Шул сәбәптән тәфгале һәп ма төрид.

Ничә кәррә ятлар илә күрделәр,
Хатынын солдатлар илә күрделәр, –

Сафи абзыем һәмишә аклыйдыр,
Хатынында бер гаеп тә тапмыйдыр.

Бу рәвештә үтте-китте биш сәнә,
Соңра алтынчы сәнә килде янә.

Бу сәнә дә Фатыйма – шул Фатыйма,
Чакыра, йөртә егетләр катына.

Сафи абзый да һаман аермыйдыр,
Хатының бу хәленә кайгырмыйдыр.

Фатыйманың шулай, дисәң – инанмыйдыр,
Бу эшә ниндәй йөрәкләр янмыйдыр.

Нишләсен? – Бар бер угыл, бер кыз бала;
Әнкәсе киткәч, болар үксез кала.

Ничек аерсын тизүк юлдашыны
Һәм гомерлек ярыны, кулдашыны.

Шул сәбәптән итә алмыйдыр талак,
Гомрене тәнҗис итә, итә һәлак.

Сафи абзый аңламыйдыр шәргый дә,
Кунмамыш башына шәргың мәргы дә.

Шәргың исе кермәгәндер борнына,
Тире урнашмыш шәригать урнына.

Суфилыкка Сафи абзый суфидыр,
Һәр намазны соңга калмый укыйдыр.

Буш суфи нигә ярый, дин белмәгәч,
Борнына диннең исе дә кермәгәч?

Белсә дин, Фатыйманы тотмас иде,
Көн саен агулы ут йотмас иде;

Тотмас иде каршысында фәхишә,
Фәхишәлек кайсы диндә якыша?

Куркъканы: үксез кала ике бала.
Нигә куркыйм? Калсын унике бала!

Шул иде һәр дәмдә халь вә хадисә*,
Кичмәдә шул хәлдә сале садисә**.

Фатыймабыз шул эшендә даимә,
Бар эше шул – каимә һәм наимә.

Күршеләрнең рәнҗиерди җаннары.
Түзмәерди җаннары, вөҗданнары.

Чөнки күршедә көнен-төнен зина, –
Ижтимагъ итмәз зина берлән гыйна*.

Күршенең аш булмас иде ашлары,
Түгелерди бу эшә күз яшьләре.

Күршеләр сабриттеләр, сабриттеләр,
Ахырында Сафины җәбер иттеләр.

Диделәр: «Син яхшылык берлән аер,
Ушбу шахшыдан канатыңны каер.

Югыйсә син тиз барырсың судлара,
Гомрең үтәр судлара, подсудлара».

Кариэм, уйлап кара бу нинди ир?
Мондый ирне йотмый түзгән нинди җир?

Ушбу тәнбиһләр соңында, чар-нәчар,
Сафи абзый хатының гайбен ачар.

«Кит хәзер, – ди, – инде миннән ихтыяр,
Карчыгың кайда чакырса, шунда бар».

И хатын, чүплеккә төшкән йолдызың,
Бәхтияр итмәс сине карт дуңгызың.

Фатыйма китте алубән ястыгын,
Муйнына асып азык-су капчыгын.

Фагыйләтен, фагыйләтен, фагыйләт**,
Пишкадәм остазымызның рухы шат.

Бәхре сани

Мондыйн соңра Фатыймапай ирсез калды,
Ашсыз-сусыз һәм дә йортсыз-җирсез калды.
Инде карыйк, нишләр икән, чирсез калды,
Калган гомре ничек үтәр, карыйк имди.

Инде иркен чыгып йөри урамлара,
Барып ята яфрак асты урманлара,
Исме керде хикәячек, романлара,
Үткән хәлен көйләп-көйләп язам имди.

Эш үткән шул, бик күрәсе килә ирен,
Балаларын, гомер иткән йортын-җирен;
Белде инде карт шәйтанга булу килен, –
Бигрәк начар эш икәнен сизде имди.

Ялгыз йөри бакчаларда, урманнарда,
Очырыйлар салкын яңгыр-бураннар да;
Гомер итә, бүре кеби, урманнарда, –
Урман – өем, урыс – ирем, диер имди.

Бу көнгәчә булган хәлне монда яздым,
Яза-яза артык язып китә яздым;
И Фатыйма, кызганамын – нигә аздың?
Азмаганны һичбер каләм язмас имди.

Тагы ниләр күрсәң, шуларны язарым,
Язу язмактан ма гадә юк базарым;
Һич әксексез, язарым дигәч язарым, –
Башланган эш ташланмаса кирәк имди.

Дәрдемәнд дәгелмием?

Дәрдемәнд мәсъүл улырмы? Мөбтәлаем, нәйләем?
Җисме җанымлә бәрабәр бер бәлаем, нәйләем?

Нәйләем, аслым, әсасем дәрдә идмеш ибтина?
Та әзәлдән дәрде шәүка мөбтәнаем, нәйләем?

Тәңре гыйшкында шәһадәт итсәләр дәр Гәрбәла,
Бән шәһидем дәр мәхәббәт, дәр бәлаем, нәйләем?

Нәйләем, сармыш бәнем әтрафеми гамь гаскәре?
Гүя мәгърузе дәһаны аждаһаем, нәйләем?

Дәрдемәндане җиһанә бән тәфәүвык әйләдем,

Чөнки һәрбер дәрдә мәбдә, мөбтәдаем, нәйләем?

Сөйлә: күрдеңме бәнем шәклемдә һичбер дәрдемәнд?
Дәрдә сәрдар улмага бән мостафаем, нәйләем?

Кәл, инан, ханым әфәндем, дәрдемәндем бәндәңез;
Һәп сәнең – кальбем, вә кәндем мөштәраем, нәйләем?

Гакълыма һич кәлмәде гомремдә сәндән ма гадә,
Чөнки амалеңдә мәмлү бер сәраем, нәйләем?

Юк тәгали гашыйка бәйнәл-әһали та әбәд,
Санки бән тәхтессәрада бер сәраем, нәйләем?

Хәзерге әдәби телдә

Дәрдемәнд* түгелме мин?

Дәрдемәнд җаваплымы? Бәлагә төшкәнмен, ни эшлим?
Бер бәламен тәнем-җаным белән бергә, ни эшлим?

Кайгы-хәсрәткә корылган аслым-нигезем, ни эшлим?
Кайгы-хәсрәткә батканмын тумышымнан ук, ни эшлим?

Әгәр Гәрбәладә Тәңре гыйшкында булсалар шәһит,
Мин мәхәббәт-бәла юлында шәһитмен, ни эшлим?

Тирә-ягымны кайгы гаскәре чолгаган, ни эшлим?
Гүя аждаһа авызы алдында торам, ни эшлим?

Дөньядагы кайгылылардан да мин иң кайгылысы,
Чөнки мин башлангычы хәсрәт-кайгының, ни эшлим?

Сөйлә: минем кебек бер-бер хәсрәт чигүче күрдеңме?
Сайланганмын баш булырга кайгы-хәсрәткә, ни эшлим?

Кил, ышан, ханым әфәндем, бәндәгез бу – дәрдемәнд;
Күңлем дә, үзем дә сиңа сатылганмын, ни эшлим?

Уема да килмәде синнән бүтән гомремдә бер,
Ни эшлим, сиңа ашкыну дәрте моңлы күңлемдә гел.

Кеше арасында гашыйкка өстенлек мәңге юк, –
Гүя җир астында бер бөртек туфрак мин, ни эшлим?

Гәзитә мөрәттибләренә

Милләтеӊ әфкярени тәртиб идәнләр – сезсеӊез;
Чарасыз дәрдә дәва тәркиб идәнләр – сезсеӊез.

Сезсеӊез, йа, язып, язычыя гайрәт вирән,
Язмая тәшвикъ идән, тәргыйб идәнләр – сезсеӊез.

Сезсеӊез вар гомреӊезне милләтә тәхсыйс идән;
Раһе гафләтдән бези тәхлис идәнләр – сезсеӊез.

Кәнде хөснендән хәбәрсез бер гүзәл чуҗык кеби,
Кадреӊезне кәндеӊез тәнкыйс идәнләр сезсеӊез.

Чөн сәфаһәтләр мөрәттиблеккә һич лязим дәгел, –
Шунларый, билмәм нәдән, тасвиб идәнләр – сезсеӊез.

Пәк мохалифдер мөбәззирлек мөрәттиб шәэненә;
Намөнасыйб ишләри тәнсиб идәнләр – сезсеӊез.

Китсәӊез дә билхата бәгъзан лөзүмсез ишләрә,
Соӊра холкый биннәдәм тәһзиб идәнләр сезсеӊез.

Сезсеӊез милләт юлында даимән каим улан,
Нәфсеӊезне билкыям тәгъзиб идәнләр – сезсеӊез.

Сезгә тәслим әйләмеш милләт бөтен әүракыны;
Анларый энҗү кеби мәнсүр идәнләр – сезсеӊез.

Чәкмәӊез гамь: безчә, сез мәмдухсеӊез, мәкъбүлсеӊез;
Иштә шигъри язмая мәҗбүр идәнләр – сезсеӊез.

*

Бу шигъремъ, шөбһәсез, кәлмештер афакы хыялымнан;
Сези тәкъдирә мәҗбүрем, дәгел кәнде хыялымнан.

Бу сүз ахыр сүземдер: сагъ улыӊ, дустлар, мөрәттибләр;
Сезә даир бераз яздым – кәләнчә икътидарымнан.
Хәзерге әдәби телдә

Газета хәреф җыючыларына

Сез – милләтнеӊ фикерләрен тәртипкә салучылар;

Сез – дәвасыз авыруларга дару табучылар.

Язуга һәм язучыга көч өстәүчеләр дә – сез;
Язуга кызыктыручы һәм өндәүчеләр дә – сез.

Бар гомерегезне милләт эшенә салучы да – сез;
Наданлык юлыннан безне йолып алучы да – сез.

Үз матурлыгын белмәгән гүзәл бала кебек сез –
Үз кадерегезне үзегез кайчак һич белмисез.

Хәреф җыючыга бозыклык бит һич тә төс түгел, –
Ник моны кыласыз? Аны бит өнәми һич күңел.

Акчаны әрәм-шәрәм итү хәреф җыючы эше түгел;
Ә сез шундый яраксыз эшне дә эшләп куясыз.

Яраксыз эш кылсагыз да кайбер чакта, ялгышып,
Соңра аны төзәтәсез, үкенеп һәм аңышып.

Әлбәттә, сез һәрвакыт милләткә хезмәт куясыз,
Хәрефне дә аягүрә газап чигеп җыясыз.

Милләт сезгә барлык кәгазьләрен тапшырган;
Шулар өстенә сез энҗе кебек сүзләр тезәсез.

Кайгырмагыз: сез мактаулы һәм кирәкле, безнеңчә,
Сез бит бу шигырьне язарга да мәҗбүр итүче.

*

Бу шигырем, – чын ки, иң югары хыялым җимеше;
Булдыралмыйм сезгә мин югары бәя бирмиче.

Соңгы сүзем: сау булың, дуслар, хәреф җыючылар;
Сезнең хакта яздым бераз көчемнән килгән кадәр.

Японияне мөселман идәчәк
голяма нәрәдә?

Сез, и чалмалылар, безне буңа дик итдеңез игъфал,
Вә тәхсыйли дә тәгълими сәрасәр итдеңез иһмаль.

Гасырлар кичде мәрзая өфермәклә, төкермәклә;
Языб ялган догаларны вә яхуд ачдыңыз сез фал.

Безә күстәрдеңез һиммәт, йөреб ашларга кәл әнгам;
Сарылыб әклү шөрбә сез, гомумән улдыңыз әккял.

Идеб мәсҗедләри базар, гавамә сатдыңыз әгъмал;
Сатыб гокъбаи дөньяйа, хәкыйкать улдыңыз бәкъкал.

Сезең әүлядыңыз сездән хәрыйслык алдылар мирас;
Ала карга кеби, сез җифәләргә улдыңыз дәллял.

Сезең вар гомереңез кичде хәсәдләрлә яныб һәрдәм;
Нәдән, билмәм, бу рәсмә кальбеңез киберлә малямал.

Безә дин уларак гарзыйтдеңез һәр искелекләрне;
Языб иске яһүди кыйссаларны улдыңыз нәкъкал.

Халыкны аздырыб, яшь каһраманлардан идеб бизар,
Аларны күстәреб динсез, ниһаять, улдыңыз дәҗҗал.

Диләр: исламә кермәк хәзрәти солтаны микадо;
Сези дәгъвәт идәр дәргяһына – тиз варыңыз филхаль!

Күрең япун әһалисен, нәя маил имеш анлар, –
Сезең чапаныңызгамы вә яхуд динәми мәйяль?

Кәлең, бу фигъле хәйрә зәррә кодрәт вармыдыр сездә?
Бу көн ярдәм идәрме гыйльме мантыйк яки гыйльмелфал?

Такыр баш улмая тәклиф идәрмисез янә бунда?
Мыеклар шөйлә, кыркылсын, ки улсын юклыга мәйяль?

Бохарилар бохары бунда улсынмы хөкемфәрма?
Диермисез: бохарилык мөселманлыкка улсын дал?

Йитәр, инсаф идең, артык кәрәк инсаф, хәясызлар!
Япунлар да чапан кисен, диеп куптармаңыз җәнҗал!
Хәзерге әдәби телдә

Японияне мөселман итәчәк
галим-голяма кайда?

Сез, и чалмалылар, безне моңарчы йокыда тоттыгыз;
Уку урынына вакытыбызны бушка әрәм иттегез.

Авыруларга ялган догалар укып, өшкереп-төкереп,
Ялган фал ачып, гасырлар китте үтеп.

Безгә зур эш күрсәттегез: ашка йөрдегез, хайван кебек
Ашау-эчүгә бирелеп, тыгындыгыз бирән кебек.

Халыкка намаз саттыгыз, мәчетләрне базар ясап,
Чын-чын сәүдәгәр булдыгыз, ахирәтне дөньяга сатып.

Балаларыгыз комсызлыкны сездән мирас итеп алдылар;
Ала каргадай, үләксәгә барырга өйрәтүче булдыгыз.

Сезнең бар гомерегез һәрвакыт көнчелектә янып үтте;
Нилектән, белмим, күңелегездә бу кадәр масаю бар.

Безгә «дин» дип һәртөрле искелекләрне тәкъдим иттегез;
Иске яһүд әкиятләрен күчереп язучылар булдыгыз.

Халыкны аздырып, яшь каһарманнардан биздереп,
Аларны динсез итеп күрсәтеп, дәҗҗал булдыгыз.

Япония патшасы микадо мөселман булырга тели, диләр;
Сезне үз янына чакыра – бик тиз шунда китегез!

Күрегез япон халкын, нәрсәгә кызыгалар икән алар:
Сезнең чапаныгызгамы, әллә динегезгәме кызыгалар?

Уйлагыз: бу изге эшкә әз генә булса да көчегез бармы?
Бүген ярдәм итәрме мантыйк яки фал гыйльме?

Анда да такыр башлы булырга тәкъдим итәрсезме?
Мыеклар да юк дәрәҗәсендә итеп кырылсын, диярсезме?

Бохарлыларның сөреме анда да хөкем йөртсенме?
Бохарилык мөселманлык билгесе булсын, диярсезме?

Җитәр, инсаф кирәк, инсаф кирәк, оятсызлар!
Японнар да чапан кисен, диеп җәнҗал куптармагыз!

Хатирәи «Бакырган»

Тулган шәһәр чәйханәсе,
Чәйханәсе, мәйханәсе,
Җөмлә татар бай баласы, –
Бән егъламай, кем егъласын.

Кулда бильяр, карталары,
Эчеп сыра, тарта бары:
Бетерү җиңел ата малы, –
Бән егъламай, кем егъласын.

Бигрәк бозык дуст-ишләре,
Кулларында «дюшес»ләре;
Күргәннәр китәр исләре, –

Бән егъламай, кем егъласын.

Артык надандыр үзләре,
Журналлар күрмәс күзләре;
Йоклап үтәр көндезләре, –
Бән егъламай, кем егъласын.

Болар исраф итә нишләп? –
Кала бер көн ирнен тешләп;
Йөри урыс эшен эшләп, –
Бән егъламай, кем егъласын.

Аталары ишан асрый,
Ишан басты безнең гасрый;
Бар һиммәт шуңар хаслый*, –
Бән егъламай, кем егъласын.

Тапкан бунлар җиңел һөнәр:
Көн дә ашка бара унар;
Ярлы-зарлы, димәс, тунар, –
Бән егъламай, кем егъласын.

Дустлар, тугъры юлдан китик,
Ишаннарга һөҗүм итик;
Тозакларын вәйран итик:
Тагы бер кәррә кормасын!

## Бәет

Бәгъзеләрмез бик суфи,
Көн дә биш намаз укый;
Бурычка йөз мең алгач,
Аны кесәгә салгач...

## Сорыкортларга

Аристократ-сорыкортлар, калын корсак, кечек башлар;
Ашыйлар соң бирән булган кешеләр, ну гаҗәп, ай-яй!

Вә һәрберсе – губернатор, кикерәләр дөбер-шатыр;
Тамак туйгач төкер-какыр, – бөтен эч май гына, май-май!

Чыгып искене бушатыр, бушаткач сузылып ятыр;
Көнен сартир, төнен сартир – менә һиммәтләре, ай-һай!

Халык батсын да бетсен, тик боларның эчләре күпсен;
Авызлары ачык бик киң, ниең бар: «Дай сюда, дай-дай!»

Ашар безне дә бу корсак, басар тиз, без болай торсак;

Әйа корсак, вәйа корсак, җиһанны капладың, вай-вай!

Боларның һәрбере Каф яки Кавказ таулары микъдар;
Болар ни йотмаган инде, беләмсең, Миңлебай* бабай!

Матур булыр бу корсакларга каршы чаралар корсак;
Тотып ярсак боларны без заман үткәрми, картаймай.

Ярыйк, дустлар, ярыйк, дим, чөнки безнең бәхтебез шунда;
Шулар йоткан безем икъбалемезне бер дә кызганмай.

Җитәр инде, җитәр инде, давайте сызганыйк җиңне;
Салып ташлыйк киемне: һич өмид юк җиңне сызганмам.

Һөҗүм кирәк ишаннарга – сорыкорт, гөмбә башларга;
Бетер! Сындыр, кырып ташла, мәгальурра вә билбанзай!

Пәйгамбәрдән калан дин урнына килгән чегәннәрдән
Үзенә башка бер дин, кайдадыр исламымыз, һай-һай!

Эзе дә калмаган диннең, басып киткән мәҗүсиләр;
Моны сизгән мөселманга чыдау мөмкинме җан җанмай?
Ашап яткан сорыкортка кадалдым мисле хәнҗәр мин;
Боларның мәсләге – безне талау бит, бер дә коткармай.

Яза күрмә, җитәр артык, Тукаев, вастырок бар бит;
Куярлар астырып дарга, ятып тор бер дә кузгалмай.

Язам, юк, туктамыйм мин һич, алардан бер дә кот чыкмай;
Нидәндер җаннарым бу куркулардан бер дә сызланмай.

Чебен җанымны чын юлда бирәм беӊ кәррә, кызганмыйм,
Минем чөн мәсләгем-юлым бөтенләй социаллардай.

Бу мәзһәб – бер зәһәб мәзһәб: фәляхи эстәсәң, фәзһәб*;
Моның саликләре, үлгәнче, ялганнарга алданмай.

### Кемне сөяргә кирәк?

Белү мөшкил – кирәк кемне сөяргә?
Үзең аусаң да, аудармый сөяргә?

Син үлсәң (бет!), сине кем кызгана соң?
Синең зәхмеңгә кемнәр сызлана соң?

Бу дөньяда сине кем иркәли соң?
Бәлаләрдән сине кем киртәли соң?

Синең соң хәсрәтең кемнәргә хәсрәт?
Гамеңнең кәсрәте кемнәргә кәсрәт?*

Кеше сатмас кеше тапмак асатмы?
Сине соң кайсы дуст дошманга сатмый?

Синең якты көнең кемнәргә тансык?
Кирәксә, яшь йиренә кара кан сык!

Сине кемнәр генә туйдырмый бер дә?
Күңелсез хәлгә кем куйдырмый бер дә?

Кем үлчи барышын синең барышка?
Бөтен сүзен, эшен синең карышка?

Тырышма, эзләмә юкны әрәмгә,
Табылмас – юк! Әрәм җәһдең, әрәм лә.

Сиңа, дустым, бу сүз ахыргы сүзем:
Үзеңне сөй! Ярат үзеңне үзең!

## Татар кызларына

(Сөям дә, сөймим дә, яратам да, яратмыйм да)

Сөям сезнең сызылган кашыңызны,
Тузылган сачыңызны, башыңызны.

Яратам тәмле, татлы сүзеңезне,
Зөбәрҗәт төсле якты күзеңезне.

Сөям кәүсәрдән әхля ирнеңезне,
Бу мактауга ризалык бирдеңезме?

Сөям кысмыйча нечкә билеңезне,
Ничек дисәм дә аз тәмсилеңезне.

Сөям бигрәк, хосусән, садреңезне;
Ни соң, ул: шәмсеңезме, бәдреңезме?

Сөям кочмакга мәрмәр муйныңызны,
Сөям оҗмахка биңзәр куйныңызны.

Сөям «җаным» дигәндә «җим»еңезне,
Сөям «дустым» дигәндә «мим»еңезне.

Сөям сезнең әдәп-инсафыңызны,
Егет кулы тиюдин сафыңызны.

Яратканым – килешле кәкре калфак,
Очы кәп-кәкре килгән, агъзы ялпак.

Ишан хәзрәт билет бирсә бәңа гәр,
Аныңла җәннәтә керсәм бәрабәр.

Бәнем каршымда хур калфак кимәзсә,
Бәңа: «Җанашым, исәнме?» – димәзсә, –

Диям: «Әстәгъфирулла, анда кермим,
Китәм эгърафә тиз, бер ань дә тормыйм».

Яратмыйм бер дә сезнең җәһлеңезне,
Караңгы салеңезне, шәһреңезне.

Яратмыйм бер дә остабикәләрне,
Сези алдарга оста бикәләрне.

Алар сездән балаларын карата,
Идәнен юсаңыз, бигрәк ярата.

Сабак «бабын наданлык»тан аласыз,
Гомер буе надан булып каласыз.

Утырып сез бозаулар берлә бергә,
Лыкылдыйсыз иҗекне бергә-бергә.

Туып алтын булып, туфрак буласыз,
Мәгарифтән сукыр-чукрак буласыз.

Сезең әүлядыңыз сездәй әдәпсез,
Әдәпсезлектә сабит сез, әбәд сез.

Җиһанда, санки, бер сатлык таварсыз,
Имамнар кайда аударса – аварсыз.

Вә сез әнгам дәгелсез бөйлә хаксыз,
Хокука мөстәхак, бәлки әхаксыз*.

Вакыт кортылмага бу пәнҗәләрдән,
Вакыт ычкынмага эскәнҗәләрдән.

Ышанмаңыз, бабай Сәйдәш надан ул,
Түгел надан гына – анларга хан ул.

Мөхәрриргә

Китмәсен кәйфең, мөхәррир, дирсәләр, дәһри сәңа;
Сән гасәл вир анлара, гәр вирсәләр зәһри сәңа.

Бәнчә, сезне җаһиланең сәүмәсе лязем дәгел;
Сәүмәсен, варсын, сираять итмәсен җәһли сәңа.

Чәкмә гамь! Кяфер дисен, динсез дисен, дәһри дисен;
Кәлмәсен илля ки асла Тәңренең каһри сәңа.

Һәр заман хакны сәвәнләр сез кеби мәкъһур улыр,
Күстәрер бер көн кәлер дә милләтең миһри сәңа.

Бел, мөхәррир! җөмлә җаһилләр сезә дошман дорыр;
Белмәли сән: җөмләтән дусттыр голүм әһли сәңа.

Җаһилең дошманлыгыйлә ифтихар итмәк кәрәк;
Анларың һәр сәбләри бер-бер вирер фәхри сәңа.

Җаһилең мәдхи кәрәксә, вар, йөгер, мәсҗедкә вар;
Ул монафикъ, сат гамәл – һичкем димәз дәһри сәңа.

Дугъры сөйлә, дугъры яз – хәүфитмә һичбер кемсәдән,
Сабир ул, чөн дөшмәмешдер эшләрең сәһли сәңа.

Бәхтиярсән дүрт җәридә сахибе улмакла сән, –
Чөн акар һәр дүрт тарафдан мәгърифәт нәһри сәңа.

Канигъ улма бу кадәрлә, ит тәрәкъкый, алга бас;
Насбидәр әбхаре гыйльмең иң дәрин бәхри сәңа.
Хәзерге әдәби телдә

Мөхәрриргә

Китмәсен кәефең, мөхәррир, денсез дисәләр дә;
Син аларга бал биргәндә сиңа агу бирсәләр дә.

Минемчә, сез наданнарның сөюенә мохтаҗ түгел;
Әйдә, сөймәсен, тик сиңа наданлыгы гына йокмасын.

Чикмә хәсрәт! «Кяфер» дисен, «денсез», «Аллаһсыз» дисен –
Тик сиңа Тәңренең каһәре генә килмәсен.

Һәр заман хакны сөючеләр сездәй каһәрләнгән булыр;
Килер бер көн: милләтең сиңа шәфкатен күрсәтер.

Бел, мөхәррир! Барлык наданнар сезгә дошман;

Син белергә тиеш: гыйлем ияләре барысы дуслар сиңа.

Наданнарның дошманлыгы белән мактанырга кирәк;
Аларның һәр сүгүе – синең өчен мактаныч кына.

Наданнар мактасын дисәң, бар, йөгер, мәчеткә бар;
Икейөзле бул, намаз сат – һичкем сиңа денсез димәс.

Дөресне сөйлә, дөресне яз – беркемнән дә курыкма;
Сабыр бул, чөнки сиңа эшнең җиңеле йөкләнмәгән.

Дүрт газета-журнал иясе булуың белән син бәхетле,
Чөнки сиңа һәр дүрт яктан мәгърифәт елгасы ага.

Булганы белән канәгатьләнмә, тәрәккый ит, алга бас;
Гыйлем диңгезләренең иң тирәне сиңа кояр.

Мәхвидәрмесән?

Мәхвидәрмесән бу рәсмә, дилбәрем, бу шагыйри?
Үлмәдекчә фаригъ улмазмы бу дәрдең шагыйли?

Җаным ул, фазлит бәңа сән, улма җани җаныма;
Бән үләрсәм, шөбһәсез, сәнсең җинаять фагыйли.

Шәэнеңезгә, и мәләк, рикъкать, тәрәххемләр кәрәк;
Сән дәгелсең анларың җанлар алан Газраили.

Кадре гөл былбыл шинас һәм кадре җәүһәр җәүһәри
Итмә тәрҗих бән кеби мәфтүнеңә бер җаһили.

И җәмилә!* Гыйшкыңызда бунча әшгар сөйләдем;
Зәррә микъдар варса мәйлең, кабили ли кабили!

Санки гыйшкың – бер кәлисә, бән – аның накусием;
Инләрем аһ-ваһ идеб, мән насыйри, мән маили.

Пәрдәи фөркатьлә өртелмеш безем ма бәйнемез;
Ирфәгъ, Аллаһөммә, ганна бу караңгы хаили.

Дәрдемә дәрман бәнем вар: йә әҗәлдер, йә висаль;
Бунларың һәрберсе мәмнүн әйләйүр бу саили.

Аңладыңмы, и гүзәл! – Бәс, җаным ул, йә җаным ал,
Ит бәни нәздеңдә үлмәклә сәгадәт наили.

Хәзерге әдәби телдә

Юк итәрсеңме?

Шулай юк итәрсеңме, сөеклем, бу шагыйрьне?
Бу дәрткә дучар кеше үлгәнче аннан котылмасмыни?

Җаным бул, яхшылык ит миңа, җан кыючым булма;
Мин үләм икән, мине үтерүче, шиксез, син буласың.

И фәрештә! Сиңа йомшак һәм мәрхәмәтле булу кирәк;
Син бит аларның җан алучы Газраиле түгел.

Гөл кадерен былбыл белер, асылташ кадерен – белгече;
Минем кебек сөйгән кешедән бер наданны артык күрмә.

И гүзәл кыз! Сезне сөюдән күп шигырь сөйләдем;
Аз гына сөйсәң, мин шиксез кабул итәм, кабул итәм!

Гүя гыйшкың – бер чиркәү, ә мин – аның чаңымын;
Аһ-ваһ итеп, мин ул тавышны көчәйтергә тырышамын.

Безнең арабыз аерылышу пәрдәсе белән капланган;
И Аллаһ! Күтәр син бездән бу караңгы пәрдәне.

Дәртемә минем дару бар: йә үлем, йә кавышу;
Боларның һәрберсе бу сораучыны шатландырыр.

Аңладыңмы, и гүзәл! Йә җаным бул, йә җанымны ал;
Мине яныңда үлү белән бәхеткә ирештер.

Пушкиннән

Синең зәүҗең сән, и яшь кыз, матурны,
Белеп кадрең, тәмең татып ятырмы?

Тагы алты хатын алыр, тагын да
Алыр, – туймас, алыр җан бар чагында.

Була калсаң җиденче, хәл начар, кыз!
Шуңар чаклы йөгер фонтанга, бар, сыз.

Алып чишмә суын түк, сип тә уйна;
Вәли ушбу фикерчекне дә уйла:

«Бу су ничек көмеш төсле агадыр,
Агып барганда, чүп-чарны кагадыр;

Агып, күздән югалып, була гаиб,
Гаҗәп, кайда китә соң бу, гаҗаиб?»

Бу су юк булды бит, чыкмый өне дә,
Шулай ук юк булыр яшьлек көне дә.

Югалды, акты-китте, кайтмый бер дә;
Шулай кайтмый гомергә яшь гомер дә.

Күренмәс булды бу су монда бөйлә,
Диген: «Көндәш эчендә мин дә шөйлә».

Бетәм, гаиб булам, калмый эзем дә;
Бәхил бул, и кичәм һәм көндезем дә!»

Борадәранә нәсыйхәт

Кемсәнең әфкярене һич кемсә мәхбүс әйләмәз;
Матлабындан газими һич кемсә мәэюс әйләмәз.
Тәңремезнең әмредер йа безләрә: «Ля тәйәсү!»
Яшь төрек, бәс, мөстәбид йәд иснәмәз, пус әйләмәз.
Парласын шәмсең сәнен; күрмәзсә – әгъма күрмәсен;
Кәүкәбеңне хак сәнең, хәүфитмә, мәнхус әйләмәз.

Ир кеше амалене күңлендә мәкнүз әйләмәз;
Бер шәҗәрдәй, кәндесен бер йирдә мәркүз әйләмәз.
Үл, шәһид ул, мәшһәдең һичкемгә мәгълүм улмасын;
Хак шәһиди һич рия мәсрүр вә мәһзүз әйләмәз.
Кыйл хәзәр, йир вирмә кальбеңдән таләбдән башкая;
Талибелхак максадындан бер тараф күз әйләмәз.

Хак-хәкыйкать әһлене һәр хәлдә мәрдүд әйләмәз,
Батыйли ибталь идәр, – ин шаэ, мәмдүд әйләмәз.
Фәүтидәр кәлди заман, чук сөрмәдин солтаныңыз;
Зыйлле иблиси дә милләт зыйлле мәгъбүд әйләмәз.
Зогъфе хакдин хәүфидеб, сез итдеңезме иртидад?
Тәрке мәсләк сезләри, әлбәттә, мәсгуд әйләмәз.

Юк дәгел, пәк чук дорур бу милләтә тәэсиреңез;
Чөнки һәммәсләкләри тәэсиреңез, тәксиреңез,
Сез рәисе залимани «Йолдыз»а хәбсидеңез, –

Бөйлә ишләр җөмләси дә һәп сезиң тәдбиреңез.
Юлыңызда сез һәмишә сабит улмыш улсаңыз,
Бәнчә, нә мөмкин улырды һич сезең тәкъдиреңез.

Шимди сез ләхдә кадәр мәддахе залим улдыңыз,
Залимә коллык фәкать тәкъриреңез, тәхриреңез.
Хәзерге әдәби телдә

Туганнарча үгетләү

Берәүнең уйларын икенче берәү бикләп куя алмас;
Теләгендә нык торучыны беркем өметсез итә алмас.
Тәңребезнең безгә кушуы: « Өметсезләнмәгез!»
Шулай булгач, деспот кулын яшь төрек иснәмәс, үпмәс.
Кояшың яктырсын; сукыр кеше күрми икән – күрмәсен;
Курыкма, синең йолдызыңны Тәңре бәхетсез итмәс.

Ир кеше теләкләрен күңелендә яшереп тотмас;
Үзен бер генә урынга агач кебек беркетеп куймас.
Үл, шәһит бул – шәһит урының билгеле булмасын;
Чын шәһитне икейөзлелек һич тә шатландырмас.
Саклан, күңелеңдә урын бирмә таләптән башкага;
Хаклык теләүче үз максатыннан бүтәнгә күз салмас.

Хаклык үзенә иярүчене һәр хәлдә кире какмас;
Ялганны ялганга чыгарыр, – Аллаһ теләсә, озак яшәтмәс.
Вакыт җитте, солтаныгызның бетәр заманы килде;
Милләт иблис күләгәсен Тәңре күләгәсе ясамас.
Хаклык зәгыйфь дип куркып, юлыгыздан чыктыгызмы?
Тоткан юлны ташлау сезне, әлбәттә, бәхетле итмәс.

Юк түгел, бик күп сезнең бу милләткә тәэсирегез;
Чөнки сезнең фикердәшләрегезнең дә тәэсире күп.
Сез изүчеләр башлыгын «Йолдыз»га ябып куегыз, –
Болар барысы да тик сезнең эшегез.
Әгәр сез тоткан юлыгызда нык торса идегез,
Бу хәлгә төшүегез, минемчә, мөмкин булмас иде.

Хәзер кабергә чаклы сез изүчене мактаучы булдыгыз;
Бөтен сөйләгән, язганыгыз – изүчегә коллык итү генә.

Хур кызына

Әгәр җәннәтдә күрсәм бән йөзеңни,
Күрермен ай йөзеңдә үз йөземни.

Беләм инде: бәни мәфтүн итәрсең,
Сихерләрсең, бәни әфсүн итәрсең.

Сәнең хөснең, табигыйдер, сәмави,
Вә һәр гозве ләтыйфеңдер сәнави.

Сөярмен мин сәне дә, бик сөярмен,
Яратырмын, янармын да көярмен.

Калыр мәнсә бәнем әрзый сорурым,
Кәлер җәннәткә махсус бер горурым.

Сәнең һәрбер сүзеңдер җанга рахәт,
Идәр дил һәр сүзеңдән истирахәт.

Сәнең җисмең яратылмыш сәма чөн,
Лисаның зикре-тәсбих чөн, сәна чөн.

Сәсиң әгъля бәлябилең сәсиндән,
Фиракъ эстәрме һичбер кимсә сәндән?

Вөҗүдең һәп мөкаддәс, мөхтәрәмдер
Вә ләмсе без гөнаһкярә әрәмдер.

Гүзәлсең син, матурсың син, матурсың,
Матурларның матурындан матурсың.

Гүзәлсең сән, зөбәрҗәдсең, ләгыльсең,
Вәли сән җир кызы төсле дәгелсең.

Сәнең хөснең, дөрест, һәр мәдхи йөкли,
Вәләкин җир кызы сәндән сөекле.
Хәзерге әдәби телдә

### Хур кызына

Әгәр җәннәттә күрсәм мин йөзеңне,
Күрермен ай йөзеңдә үз йөземне.

Беләм инде: мине әсир итәрсең,
Сихерләрсең, мине әфсүн итәрсең.

Табигый, синең күркәмлегең күкнеке

Һәм һәрбер әгъзаң нәфис, мактаулы.

Сөярмен мин сине дә, бик сөярмен,
Яратырмын, янармын да көярмен.

Онытылыр җир йөзендәге шатлыгым,
Килер җәннәткә хас горурым.

Синең һәрбер сүзең җанга рәхәт,
Синең һәрбер сүзеңнән күңел ял итә.

Синең гәүдәң яратылган күк өчен,
Телең зикер-тәсбих өчен, мактау өчен.

Тавышың сандугач тавышыннан матуррак,
Кем теләр соң синнән аерылырга?

Син үзең һәрвакыт изге, хөрмәтле, –
Без гөнаһлыларга кагылырга да әрәм.

Гүзәлсең син, матурсың син, матурсың,
Матурларның матурыннан матурсың.

Гүзәлсең син, зөбәрҗәтсең, асыл ташсың,
Ләкин җир кызы төсле түгелсең.

Күркәмлегең, дөрес, һәртөрле мактауга лаек,
Шулай да җир кызы синнән сөеклерәк.

### Пыяла баш

Карагыз сез безем хәзрәт миенә,
Миендә мәгърифәт дәрде биимә?

Ачык яздык миен – мисле пыяла,
Әдәп әһле карарга да ояла.

Бөтенләй мөртәсәм фикре миендә:
Ялангач кыз, бәлеш, тәңкә, тиен дә.

Белү юк башканы, бар белгәне шул:
Бөтен зиһне ашап-эчмәклә мәшгуль.

Синең ул нишләсен соң милләтеңни?

Катында милләтең ни, һиммәтең ни?

Абыстайларга җитсә төндә кувәт –
Менә гайрәт! Менә һиммәт! Фөтүввәт!

Рәсемгә ишарә

Шулай чорнап тора безне җәһаләт,
Шулай, тырп итмә! – ди безгә сәфаләт.

Күрәмсез: бу кырык башлы чаян бит,
Ачык күз алдыңызда бит, гаян бит.

Каты ләктек, мәҗаль юк ычкынырга,
Мөхаль бит ычкынубән кычкырырга.

Котылсак та китәргә юлымыз юк,
Оныттык: сагымыз юк, сулымыз юк.

Саташканбыз наданлыкта, адашкан,
Адашмакның да без хәдденнән ашкан.

Бу сурәтләр – ишаннарның тозагы,
Күрәмсез: нинди нык бикле йозагы?

Гаҗәп, хәйран булыр фәрзәнде адәм,
Якын бармыйк – аның асты җәһәннәм.

* * *

Кыямәт якын килде – җир сораучы ярылды;
Галимнәр тәүбә кыйлды, «Аллаһ» дигел, бәдәвам.

Замана ахыры булды – хәятлар мәмат булды;
Көлгәннәр йөзтүбән китте, «Аллаһ» дигел, бәдәвам.

«Фикер»дән көлгән иде – һич сәбәпсез бер «Азад»;
Инде ул китте назад, «Аллаһ» дигел, бәдәвам.

Көз

Күрәмсез, дустларым, көз килде тышта;
Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.

Китә башлады бездән инде кошлар –
Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.

Мисале зәгъфыран саргайды урман,
Игенчеләр игеннәрне дә урган.

Такыр калды татар башы кеби кыр;
Азык эзли – оча тургай да пыр-пыр.

Чыгып баш калкыта сахрада уҗым,
Яшел хәтфә шикелле итә җем-җем.

Кояш та яктысын киметте шактый;
Тәәссеф! Басты золмәт, китте якты.

Колакны шаулата инде суык җил;
Тулып эчкә, өрә, мисле куык җил.

Ничәйтсәң дә, күңелсез көз, күңелсез;
Чәчәксез көз, үләнсез һәм дә гөлсез.

Мазарыстанга охшап калды кырлар;
Чирәмсездер тигез җирләр, чокырлар.

Үлеп торсам иде мин алты айдай,
Эреп бер йокласам мин сары майдай.

Шулай йоклап, бәһар җиткәндә торсам,
Торып тагы яшел җирдә утырсам, –

Бәхетле шул заман, мин бик бәхетле;
Булырмын шаһ, бәхетле һәм тәхетле.

*

Качан соң, и фәкыйрь милләт, бәһарең!
Качан китәр кичең, килер нәһарең?

Килер мәллә кабергә мин сөрелгәч,
Кыямәт көндә мин үлеп терелгәч?

## Государственная думага

(«Ай бәгърем, Нәгыймә» көенә)

Ник бик тиз беттең син, Дума,

Ник җир-ирек алмадың? –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума*?

Ник бик яшьләй картайдың соң,
Ник мәңгегә калмадың? –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Ник безне кызганмадың соң,
Коллыктан коткармадың? –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Залим башлыкларны тотып,
Ник йөрәген ярмадың? –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Ник куылдың син үзең соң,
Ник кумадың үзләрен? –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Ник баш бөктең залимнәргә,
Ник тыңладың сүзләрен?–
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

*

Ач-ялангач мужикларга
Кайда ирек, кайда җир? –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?
Бирәм дидең, вәгъдә бирдең;
Күрсәт җирең? Кайда? Бир! –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Депутатларны кудылар,
Черки төсле, «көш» тә «көш»! –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Иткән гайрәтең бума?

Самый важный генерал да
Түлке күрсәтте күкеш, –
Ах җанашым, Дума, Дума,
Кыйлган гайрәтең бума?

Әйдә, дустлар, бер тибрәник,
Акны Тәңре яклар бит, –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Барлык гайрәтең бума?

Караны бер көн каралтып,
Акны бер көн аклар бит, –
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Милләтә

Җөмлә фикрем кичә-көндез сезгә гаид, милләтем;
Сыйххәтеңдер сыйххәтем һәм гыйлләтеңдер гыйлләтем.

Сән мөкаддәс, мөхтәрәм гыйндемдә варлык нәрсәдән;
Сатмазым бу кяинатә милләтем, миллиятем.

Бәхтиярым – бәндәңи гәр итсәләр нисбәт сәңа;
Гаҗизанә шагыйрең улмакга вардыр ниятем.

Ләфзы «милли» сәвәр кальбем бәнем, билмәм, нәдән?
Әйлә «милли», милләтем, бәхшәйлә мәмнүниятем.

Һәр хыялдан татлыдыр милләт хыялы, ля мөхаль;
Бу хыялятдән кәлүр, гәр кәлсә мәҗнүниятем.

Әйлә шагыйрьлекдә сабит та әбәд, Тәңрем, бәни;
Бу сәбатә мөнхәсыйр мәфтүн вә мәҗлүбиятем.

И фәләк! Ал җаными, лик алма, зинһар, шаными;
Бәнчә, үлмәкдин әшәд мәнса вә мәтрүкиятем.

Үлмәсен, үлсәм дә, наме гаҗизем, фәүтитмәсен;
Кәтмәсен буша бәнем җәһдем вә мәшгулиятем.

Берзаман яд әйләсә билилтифат милләт бәни, –
Иштә будыр максадым, мәэмүл вә мәсгудиятем.

Әйләдем гарзы мәхәббәт бән сәңа, и милләтем;
Дуст күрерсең сән бәни дә – вар буңа әмниятем.
Хәзерге әдәби телдә

Милләткә

Бар уем кичен-көндезен сезнең хакта, милләтем;
Саулыгың – минем саулык, авыруың – минем авыруым.

Син каршымда бар нәрсәдән дә изге һәм хөрмәтле;
Дөнья бирсәләр дә сатмам милләт, миллиятемне.

Синеке дип исәпләсәләр – бәхетле мин;
Игелекле шагыйрең булырга ниятлимен.

Күңелем «милли» дигән сүзне сөя – белмим, нидән?
Милләтем, мине «милли» ит – миңа шатлык бүләк ит.

Һичшиксез, һәр хыялдан татлыдыр милләт хыялы;
Шаша калсам, тик шул хыялдан гына булыр.

Мине шагыйрьлектә мәңге тугъры ит, Тәңрем;
Шунда гына– күңелемнең бөтен теләк-омтылышы.

И күк! Ал җанымны, тик, зинһар, алма шөһрәтемне;
Минемчә, онытылу, тибәрелү – үлемнән яманрак.

Үзем үлсәм дә, гаҗиз исмем үлмәсен, югалмасын;
Минем тырышлыгым һәм эшләрем бушка китмәсен.

Әгәр милләт мине, илтифат итеп, искә алса, –
Шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем.

Мин сиңа яратуымны сөйләдем, и милләтем;
Мин ышанам ки, син дә мине дус күрерсең.

Дөнья бу, йа!*

И күңел, бил багълама, күпне кичергән дөньядыр,
Бу тәдавел ширбәтен халыкка эчергән дөньядыр.

Күп ашап йоткач, тыгынгач Мәскәү абзыйның малын,
Сәйдәш абзыйның көлен күккә очырган дөньядыр.

Ары барып, бире килеп, бер дә файда чыкмагач,
Бу бабайны дин сатар хәлгә төшергән дөньядыр.

Бер заманнарда Рәшидкә «габде милләт» нам виреб,
Хәзер инде «габде корсак»ка төшергән дөньядыр.

Бер заманнар «Тәрҗеман»ны да симертеп җәһдилә,
Бу заман «Камусы гыйльми»ләр кимерткән дөньядыр.

«Ха-ха-ха» журналыны да ха-ха, ха-ха! көлдереп,
Дүрт номердан соңра Газраил китерткән дөньядыр.

Социал «Азат халык»ны черносотенный ясап,
Һади абзый мәсләген мәсләк дидерткән дөньядыр.

Һай, боларны бер дә сүкмәс, бер дә рәнҗетмәс идем!
Нишлим инде, чарасызмын, – тел тидерткән дөньядыр.

«Мөхәммәдия» көе

Бабай Сәйдәш, надан Сәйдәш,
Усал эт төсле тик чәйнәш; –
Безем корган нигезләр
Бер дә селкенмәй дә чайкалмай.

Сөеклемең кабер ташында

Үлмәде, үлсәң дә, күңлемдә сәнең дәрдең һәнүз;
Дустлыгың, инсанлыгың кальбемдә калдырдың һәнүз.

Бел ки, мәүтең, шөбһәсез, мәүтем дорыр, и нурлы йөз;
Сурәтең – чәшмемдәдер, өзнемдәдер – саутең һәнүз.

Аһ, насыл! Без яр идек: сән бән идең, бән сән идем;
Калмады бундан әсәр – калды мәгәр шәүкың һәнүз.

Хәзерге әдәби телдә

Сөеклемнең кабер ташында

Үлмәде, үлсәң дә, күңлемдә синең дәртең һаман;

Дуслыгың, кешелегең күңлемдә калдырдың һаман.

Белче, үлемең, шөбһәсез, минем үлем ул, и нурлы йөз;
Сурәтең – күз алдымда, колагымда – тавышың һаман.

Аһ, ничек! Без яр идек: син мин идең, мин син идем;
Тик хәзер берсе дә юк – калды истәлек кенә.

## «Уклар»

Бик үткен журнал тарала:
Исме ничек? «Уклар»мы?
Иске-москы муллаларны
Һич кызганмый чукмарлый.

Аталар да ваталар,
Кирәк җирне күзлиләр;
Аткач, атылмышка чаклы
Ук бармыйча туктармы?

Хәзрәтләр, хәддин узмагыз!
Онытмагыз «Уклар»ны.
Шаярсаң күрсәтер «Уклар»
Яңак төптән утларны.

## Үз-үземә

Телим булырга мин инсане гали,
Тели күңлем тәгали биттәвали.

Күңел берлән сөям бәхтен татарның,
Күрергә җанлылык вактын татарның.

Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

Хисапсыз күп минем милләткә вәгъдәм,
Кырылмасмы вавы*, валлаһе әгъләм?

## Кичке азан

### 1

Кичке азан!
Кичке азан!
Моңнар, уйлар
Килә аннан;

Төшә искә
Иске заман,
Хөлусән мөс-
тәмәгъ азан.
Фи бәдьиһи
Вә бәгъдә азан.
Күңелне тет-
рәтә, кәән-
нәһү тәсби-
хе рәгъд – азан.
Беләмсез, ни диер азан:

– Китте Касим*,
Китте Казан.
Бетте татар,
Кырылды хан,
Бохар, Хуканд
Һәм Әстерхан.

2

Ханнарга и-
реште хизан,
Җылый-җылый
Бирделәр җан:
Сөембикә
дә Чыңгыз хан;
Нә дәүләт кал-
ды да, нә шан!
Һич калмады
Шаннан нишан,
Калды дингә
Дошман ишан!

3

Аһ, ник соң без
Булдык вәйран? –
Бөтен дөнья
Калды хәйран.
Гаҗиб, нидән
Бу ханәман
Кисәктән әй-
ләде тайран?!

4

Юк шул безләр-

дә берләшмәк;
Юк бергә-бер-
гә гөрләшмәк,
Бер җан, бер тән
Булып, һәр неч-
кә серне бер-
гә серләшмәк.
Үтте бездән
Инде дөнья,
Җан бирәбез
Галәлгомъя.
Дөнья! Актык
Сүзне тыңла:
Бәхил бул без-
дән, и дөнья!

5

Сау бул, дөнья!
Инде беттек;
Бетәргә сүз-
не беркеттек;
Вактында җир-
не селкеттек,
Инде беттек,
Инде беттек!

## Мактанышу

(«Бакырган»нан)

Ишан, ишәк өкешер,
Өкешмәктә мәгънә бар;
Ишәк әйтер: «Мин баймын,
Миндә нукта, җөгән бар».

Ишан әйтер: «Үкермә,
Мин синнән дә бай әле:
Минем чалмам астында
Ат урларга җөгән бар.

Син булсаң да нукталы,
Бик мактанма, туктале;
Мин мактаныйм, син тыңла,
Минем сүзне тот әле.

Мине ишан дигәннәр

Һәрберсе синдәй ишәк;
Минем изгелегемгә
Һичберсе китерми шәк.

Анларны мин нукталыйм,
Һич кызганмыйчук талыйм;
Зур корсаклы байларны
Каезламый туктамыйм.

Булсаң син хайван надан,
Синнән бигрәк мин надан;
Ялкаулык та наданлык –
Бүләк безгә Алладан.

Без халыкны алдыйбыз,
Агуны без «бал» дибез;
Корсак тулгач, милләткә:
– Син аш-сусыз кал, – дибез.

Татарларны мин җигәм,
Минем кулымда җөгән;
Ник җикмәскә, татарлар
Җебегән бит, җебегән.

Кикерсәм дә – изгелек,
Какырсам да – изгелек;
Бер сеңгерсәм – мең сәвап,
Күп яшәсен искелек!

Сиңа сүзем шул, ишәк:
Яхшы булыр килешсәк;
Йөзик ялган эчендә,
Син каек бул, мин – ишкәк.

Булчы син миңа мөрит,
Мине аркаңда йөрет;
Ачыйк гамәл кибете,
Игътикяфләргә керик.

### «Дөнья» көенә

Мин аркаңда туй итим (дөньяда),
Туныйм сине – куй итим (вай дөнья);
Шунда да син тынсыз тор (дөньяда),

Мин сине хуш-хой итим (вай дөнья).

Ишәк әйтер: «И хәзрәт (дөньяда),
Туктап торчы әзерәк (вай дөнья);
Чалмаң ишелгән, чорначы (дөньяда),
Күренсен гөмбәзерәк (вай дөнья).

Әмма бәгъдә, и ишан (дөньяда),
Инандым: сез – галишан (вай дөнья);
Халыкның каралуына (дөньяда)
Чын күңелдән чалышан (вай дөнья).

Беләм нәхаклыгыңны (дөньяда),
Итәм ишәклегемне (вай дөнья);
Халык суфи исмен бирер (дөньяда),
Күрсәтәм шәплегемне (вай дөнья).

Мин белсәм дә алданам (дөньяда),
«Суфи» безгә алда «нам» (вай дөнья);
Миннән башка мөритләрең (дөньяда),
Бигрәк садә «дал» да «лям» (вай дөнья)».

Әдәбият ахшамы ясаучы яшьләремезгә

Сөям мин сезне, сез – чын яшь егетләр;
 Өмид бар сездә, сез – интеллигентлар.

Телем, күңлем, вөҗүдем сезгә разый;
Әле һич күрмәгән сезләрне мазый.

Яңы пешкән, йитешкән сез бәһадир,
Хәзердә яшь бәһадир бибәһадер.

Сези күрдек гасырларча көтеп без, –
Килерсез, дип, һәмишә күз тотып без.

Сәламәт килдеңезме, мәрхәба! сез;
Мөҗәссәм бер сафа, баде саба сез.

Черек милләт өчен сынмас терәк сез;
Тугыз корбан суеп алган теләк сез.

Фараз итдем: Рәсүлулла терелсә,
Мөбарәк җисменә гәр рух өрелсә, –

Сези ул, шөбһәсез, тәбрик идәрди,
Сези тәшвикъ идәр, тәхрик идәрди;

Диерди: каһраманнар! Әйлә гайрәт,
Идеб гайрәт, вирең галәмгә хәйрәт.

Бу – тәрвиҗе бәлягать һәм фәсахәт,
Дәгелдер бу – хәмакать һәм сәфаһәт.

Белермисез! Нә галәмдер бу галәм?
Бу галәм сәр сәгадәтдер ду галәм.

Әбәд тәрк итмәңез, зинһар, бу раһи,
Будыр чөн милләтең раһе рәфаһи.

Ниһаятьсез гүзәл ахшам – бу ахшам,
Бәнем ядымда бу ахшам – сабах, шам.

Хәзерге әдәби телдә

Әдәбият кичәсе ясаучы яшьләребезгә

Сөям мин сезне, сез – чын яшь егетләр;
Өмет бар сездә, сез – интеллигентлар.

Телем, күңелем – бөтен барлыгым сездән риза;
Үткән чорда сезнең ишеләр булмаган.

Сез – яңа пешкән, җитешкән баһадир;
Хәзер яшь баһадир – бәя биргесез.

Без сезне гасырлар буе көтеп алдык;
Килерсез дип, һәрвакыт күз тегәп тордык.

Сәламәт килдегезме – рәхим итегез!
Сез – күңел шатлыгы, таң җиле сез.

Черек милләт өчен сынмас терәк сез;
Тугыз корбан суеп алган теләк сез.

Уйладым: әгәр пәйгамбәр терелсә,
Аның изге тәненә җан өрелсә, –

Сезне ул, һичшиксез, тәбрикләр иде,
Сезне өндәр һәм димләр иде;

Дияр иде: каһарманнар, гайрәт итегез;
Гайрәт итеп, дөньяны хәйран итегез.

Бу – нәфислек һәм матурлыкны арттыру;
Түгелдер бу – ахмаклык һәм бозыклык.

Беләсезме, бу дөнья нинди дөнья?
Бу дөнья – һәр ике дөньяда бәхетнең башы.

Бу юлны, зинһар, мәңге ташламагыз,
Чөнки бу – милләтне алга илтүче юл.

Бу кичә – чиксез гүзәл кичә;
Иртән дә, кичен дә бу кичә минем исемдә.

«Әлгасрелҗәдид»ә маддәтән вә мәгънән
иштиракь идәнләрең лисане хале нә диер?

Тәмам «Гасрелҗәдид», әлхәмде лиллаһ,
Һөмам «Гасрелҗәдид», әлхәмде лиллаһ.

Бу милләтнең тотылган афетаби
Чөн әмр итде, таратдык без китаби.

Караңгылыкда нур нәшр әйләдек без;
Бу үлгән милләти хәшр әйләдек без.

Вә нәфх итдек без, Исрафил кеби, сур;
Улыр, шаять, бу сур бер суры мәнсур.

Акытдык милләтә абелхәяти;
Капатдык шимди без бабелмәмати.

Тәмамән малы милләтдер бу журнал;
Бөтен амале өммәтдер бу журнал.

Тырышдык без бу журнал чөн, чалышдык;
Буның нәшренә шимди без алышдык.

Гомумән иштиракь итдек, сарышдык;
Каләмләрлә, сәмәнләрлә карышдык.

Бу юлда, шөбһә юк, без җан вирермез;
Ниһаять, милләтә нам, шан вирермез.

Калыр бакый бу журнал та кыямәт;
Идәрмез без химаять һәм сыянәт.

Яшә! «Гасрелҗәдид», сән – садрымызсән;
Яшә! Сән – шәмсемезсән, бәдремезсән!

Хәзерге әдәби телдә

«Әлгасрелҗәдид»кә матди һәм мәгънәви
катнашкан кешеләрнең хәл телләре (күңеле) нәрсә әйтә?

«Гасрелҗәдид» тәмам булды, Аллага шөкер,
«Гасрелҗәдид» – җитәкче, Аллага шөкер.

Бу милләтнең тотылган кояшы
Кушты да, без китапны басып тараттык.

Караңгылыкта нур тараттык без;
Бу үлгән милләтне тергездек без.

Һәм, Исрафил кебек, сур өрдек без;
Бу, шаять, җиңүче бер сур булыр.

Милләткә тереклек суы агыздык;
Үлем ишеген бикләтеп куйдык.

Бу журнал – тулысы белән милләт байлыгы;
Бу журнал – бөтен халыкның күңел теләге.

Тырыштык без бу журнал өчен, тырыштык;
Моны бастырып таратуга инде без ирештек.

Һәммәбез катнаштык, хәзерләштек;
Каләмебез, акчабыз белән дә булыштык.

Бу юлда, шөбһә юк, без җан бирербез;
Ниһаять, милләткә дан һәм шан бирербез.

Бу журнал мәңге яшәр;
Без аны сакларбыз һәм якларбыз.

Яшә! «Гасрелҗәдид», син – юлбашчыбыз;
Яшә! син – кояшыбыз, син – тулган аебыз!

1907

## Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр

1

Күп яттык без
Мәдрәсәдә,
Аңламадык
Бер нәрсә дә;
Селкенмәдек
Таш төсле без,
Җилбер-җилбер
Җил бәрсә дә.

2

Чаршау кордык,
Кояш безгә
Нурын чәчеп
Җибәрсә дә;
Каршы тордык,
Кудык, безгә
Яктылыктан
Ни килсә дә.

3

Юрган ябып
Йоклап яттык,
Уйганмадык,
Таң атса да;
Уйланмадык!
Бәхтемезнең
Кояшы ба-
еп батса да.

4

Гамьсез яттык,
Сасы җирдә
Чергән тирес-
тәй черсәк тә;
Чиркәнмәдек,
Бу хәлләрдән
Вакытсыз гүр-
гә керсәк тә.

5

Кибеп беттек,
Саргайдык без,
Корып беттек
Таяклардай;
Иснәп нәҗес
Ләззәтләндек
Бөтенләй кыр-
гаяклардай.

6

Әхлак, вөҗдан,
Инсафларны
Сөреп чыгар-
дык истән дә;
Бозылдык шул-
кадәр начар,
Уздырдык без
Иблистән дә.

7

Ашсыз-сусыз,
Утын-шәмсез
Тар җирләрдә
Яттык сасып;
Гаетләрдә
Төш күргәндә,
Коендык без,
Бозга басып.

8

Капчык ясап

Җиләннәрдән,
Байлар саен
Теләндек без;
Урам саен
Йөгергәләп,
Капка саен
Терәлдек без.

9

Күрде милләт
Арзан безне
Агачтан я-
ки таштан да;
Яурупада
Газиз бит без
Күз өстендә-
ге каштан да.

10

Оят сатсак
та ач булдык,
Азган-тузган
Кызлар төсле.
Бетләп яттык,
Ачлыктан без
Бетләгән <...>
<...> төсле.

11

Укып мантыйк,
Булдык палач,
Чәйнәп сагыз-
лар лач та лач;
Ни он түгел,
Камыр түгел, –
Булдык без пеш-
мәгән калач.

12

Ялкаулыкмы
Кирәк – бездә,

Аңкаулыкмы
Кирәк – бездә;
Булган, пешкән,
Уңган шәкерт
Меңнән бердән
Сирәк бездә.

13

Яшь көннәрне
Наданлыкка
Корбан иттек
тә чалдык без;
Суган саттык,
Борчак аттык,
Бәрбәр булдык:
Сач алдык без.

14

Байлар итте
Бүләк безгә
Аксак-туксак,
Калган кызын;
Шуларга кол
Булдык, галля-
мә булгач, ки-
чен, көндезен.

15

Очраса без-
гә тол карчык,
Хатыннар гәр,
Йортка кердек;
Гөнаһ һич кыйл-
масак та, без
Җәһәннәмгә –
Утка кердек.

16

Ни хурлыклар,
Ни зилләтләр
Күрмәдек без
Бу милләттән;

Күрми изде,
Мескин! Безне
Күзендә бул-
ган гыйлләттән.

17

Хурлау түгел
Татарларны
Бу сүзләрдән
Безнең максуд;
Күзсез булгач
Нишләсеннәр:
Дөньяда юк
Сукырга суд.

18

Сүз юк күзсез
Татарларга,
Сүз бар күзле
Хәзрәтләргә:
Чакырмыйлар
Халыкны без-
нең хәлне аз-
маз рәтләргә.

19

Күрдек анлар-
дан тик корсак,
Алай борсак,
Болай борсак;
Ай-һай тирән
Бирән корсак,
Туймас корсак,
Тулмас корсак.

20

– Ислах! – дидек,
Күңел гәрчә
Ислах булмас-
ны сизсә дә;
Кузгалмадык
Почмаклардан,

Җаннар бик күп-
тән бизсә дә.

21

Хуш, хуш! Хәзрәт-
ләр, без киттек;
Сездән изге-
лекләр көттек;
Көтмәдек тү-
гел, күп көттек;
Киттек шул без,
Инде киттек.

22

Алга, алга!
Алга таба,
Алга, дустлар,
Басыйк табан;
Моңгар чаклы
Җәһел безне
Артка тарткан
да алдаган.

23

Әйдә халык-
ка хезмәткә,
Хезмәт эчен-
дә йөзмәккә;
Бу юлда һәр-
төрле хурлык-
ка, зорлыклар-
га түзмәккә!

Сөальләр

Йа Ходая! нигә төрле-төрле кыйлдың бәндәни?
Ни сәбәб соң җөмлә әдна бәндәләрдән бән дәни?

Ник бәни шад идмәдең, ник әйләдең гамь һәмдәми?
Юхса бәхре гамь мәсиле, мәнсабе дә бәндәми?

Бөйлә кайнар дәмгы гайнем, гайне зәкъкумме? Гаҗәб!
Йә җәһәннәмләр, җәхимләр бу өтелгән тәндәми?

Наре дүзәхдер, хәкыйкать, шагыйрең кальбендәми?
Бу сөаләтең җавабын эстәрем бән Сәндән, и!

Кәшифеләсрар! Кәшеф ит, зәррә юкдыр бәндә ми;
Җаһилем чөн, әрмәзем, бу сирри белмәкдән дәми;

Талигым, бәхтем бәнем һәр каралардан карадыр!
Каралык шундан сирайәт әйләмеш бу бәндәми?

Дугъмамыш улсам җиһанда, кем белер, улмазды шәб;
Мәнбәгы һәр золмәтең дә бәхте-бәдбәхтемдәми?

Гыйльвә гыйшдән ма гадә бән алмадым дөньяда хаз;
Шөбһәдер: бәдтәр бу нәфсем шәйхе Нәҗдидән дәми?

Хәзерге әдәби телдә

Сораулар

Йа Ходай! Нигә төрле-төрле кылдың кешеләрне?
Ни сәбәптән соң мин бөтен түбәннәрдән дә түбән?

Ник мине шат итмәдең, ник кайгы юлдашы иттең?
Әллә кайгы диңгезенең башы да, ахыры да миндәме?

Күз яшем кайнар, әллә ул агулы сумы? – Гаҗәп!
Әллә җәһәннәмнәр, тәмуглар да бу өтелгән тәндәме?

Әллә тәмуг уты, чыннан да, шагыйрьнең күңелендәме?
И, бу сорауларның җавабын Синнән сорыйм мин!

Серләр ачучы! Ач бу серне, үземдә бөртек тә ми юк;
Мин наданмын: бу сер турында тел дә ача алмыйм.

Киләчәгем, бәхетем минем һәр каралардан кара!
Миндәге бу каралык та шуннан йокканмы әллә?

Тумасам дөньяга, кем белә, яхшырак булмас идеме;
Һәр караңгылык чыганагы да шул кара бәхетемнәнме?

Кайгы-хәсрәттән башка мин дөньяда өлеш алмадым;
Шикләнәм: мин шәйхе Нәҗдидән дә начаррак хәлдәме?

Шагыйрьгә

(Михаил Юрьевич Лермонтов хәзрәтләренең бер нәсыйхәте)

Ничек диләр? Сине «шагыйрь» диләрме?
Шигырь язмак белән шагыйль диләрме?

Сәмави сүз! Халык аңлар микән соң?
Аны аңлаучылар анлар микән соң?

Итәм тәнбиһ: кызыкма бу исемгә,
Бу тәнбиһне төшер һәрдәм исеңгә:

Гомердә син бу ат берлән аталма,
Торып җирдән, сәмалардан ат алма.

Сине күрсәтмәсен һичкем дә, дип: «Бу
Менә шагыйрь, мөхәррир бу, әдип бу».

Явар өстеңгә бөһтаннар, хәсәдләр,
Корылыр юлыңа һәртөрле сәдләр.

Хөрриятә

Мөсавәт шәмгыне яндыр гадаләт нурына каршы,
Бези нурыңла нурландыр да кортар ләйле зөлмадән.

Бези габед әйлә мәгъбүд хәкыйкый Тәңрийә анчак,
Иганәт эстәдек без чөн буңа дәк гайре мәүлядан.

Баш икдек, сагыйр улдык һәр шинель кигән санәмләргә;
Көтеб җансыз агачдан җан, бәсар тугъмышдан әгъмадан.

Сән улгыл хәзрәти Хәттаб, бетер һәп потлари табтаб,
Ки калсын Кәгъбәи пакь-пакь Мәнатдан, Лат вә Гоззадан.

Өмүре әһле дөнья бунлара тәслим улынмышдыр,
Табигыйдер ки, йөрмәз бу санәмләр раһе әһдадан.

Дәниләр ашмыш әгъляйә, галиләр дөшмеш әднайа;
Ки сән лотфыңла тәфрикъ ит – аер әгъляйи әднадан.

Кыямәтдер бу көн: шәмсе хәкыйкать мөнхәсиф улды;
Камәрләр иншикакъ итде, гакыллар шашты гаугадан.

Нөҗүме иттихад күкдән дүкелде йирләрә шимди;
Җиһанда хиссе инсият озак кәрратлә Ганкадан.

Зөбанилар, кылыч, туплар, казак, мылтык, палачларла
Мөхатыз һәр җәһәтдән: сагъ вә сулдан, зир вә балядан.

Гарибдер: әһле гыйсъяна сөальсез өзлифәт җәннәт;
Бирелде әһле гаднә йир сәкарьдән – нары көбрадан.

Язылмыш детрәян элләрлә гарзы хале милләт бу;
Шикаятьдер сәңа бездән: әсәрлән кауле шәквадан.

Йитеш насрыңла сән: руе зәминдән сөрделәр безне;
Әмәл юк гайре очмакдан, кәчеб дөнья вә гокъбадан.

Тәмамән фәсех улынмышдыр мәкаль: «Әһле йир чөн йир»;
Мәкам тот, эстәр ирсәң гәр, сәмадан йә сөрәйядән.

Изелделәр әһалилә бәрабәрлекдә динләр дә,
Кәчеб мөслимләр исламдан, насара – дине Гыйсадан,
Нә япсын, нәйләсен – динләр дәхи тупрака инмешләр;
Бәдиһидер ки, дин мөнфәк дәгелдер халкы дөньядан.

Бу дөнья бер такым вәхшиләрә җае сафа улды,
Мосалләт улдылар бунлар безә, билмәм, нә мәгънәдән.

Эчәрләр канларын әһле къолубең, чөнки кан эчмәк
Хәлявәтледер анларча шикәрдән һәм дә хәлвәдән.

Йидермә кяинати, сакла бу Яәҗүҗе-Мәәҗүҗдән,
Вә чәкдер сәдде Искәндәр бөтен әсхабе Думадан.

Безез капуңда ялан ач, камумыз без сәңа мохтаҗ;
Йөзең күстәр, никабең ач, гата кыйл бәхре нәгъмадан.

Илаһи, рәхмәтеңлә шагыйрең тил гокъдәсен хәл кыйл;
Хәбәр вирсен бераз хале әхиббадан вә әгъдадан.

*

Ачыл, гөлзаре әхрар! Нәгъмә саз улсын бәлабилең,
Ки истикъбале милләт раушан улсын ләйле камрадан.

Гомумән мөслимини һәр заман мәэмүре вөждан ит;
Азад ит сакымызны багълаян әгълялы чалмадан.

Хәзерге әдәби телдә

Азатлыкка

Тигезлек шәмен яндыр турылык нурына каршы,
Безне нурыңа нурландыр да коткар караңгы кичтән.

Безне хак Тәңренең колы ит,
Без моңа кадәр башка Тәңредән ярдәм сорадык.

Баш идек, риза булдык һәр шинель кигән санәмнәргә;
Җансыз агачтан – җан, тума сукырдан күз көттек.

Син Хәттаб хәзрәт бул да бар потларны таптап бетер, –
Кәгъбә Мәнаттан, Лат вә Гоззадан пакь булып калсын.

Дөнья халкы эшләре боларга тапшырылган;
Табигый, бу санәмнәр туры юлда йөрмиләр.

Түбәннәр югары ашкан, бөекләр түбән төшкән;
Син рәхмәтең белән бөекләрне түбәннәрдән аер.

Бүген кыямәт: дөреслек кояшы тотылды;
Айлар ярылды, акыллар гаугадан шашып калды.

Инде бердәмлек йолдызлары күктән җиргә түгелде;
Җир йөзендә кешелек тойгылары Ганкадан күп ерак.

Зобанилар, кылыч, туп, казак, мылтык, палачлар белән
Һәрьяктан: уң, сул, ас, өстән чолгап алынганбыз.

Гаҗәп: гөнаһлы кешеләргә сорамый җәннәт бирелде;
Оҗмах тиешлеләр иң куркыныч тәмугка җибәрелде.

Милләт хәлен тетрәгән куллар белән язып бирү бу;
Син бу зарлану сүзләреннән әсәрлән.

Ярдәмгә җитеш: җир йөзеннән сөрделәр безне;
Дөнья һәм ахирәтен ташлап китүдән дә башка чара юк.

«Җир аны эшләүчеләр өчен», – дию тәмам юк ителгән;
Теләсәң, күктә яки йолдызлар арасында урын тап.
Кешеләр белән бергә диннәр дә изелделәр; мөселманнар
Исламны, христианнар Гайса динен ташлады.

Ни эшләсен, ни кылсын – диннәр дә туфракка иңгәннәр;
Билгеле ки, дин кешеләрдән аерым түгел.

Бу дөнья бер төркем вәхшиләргә рәхәт урын булды:
Болар, белмим, ни сәбәптән безнең өскә ябырылдылар.

Болар яхшы кешеләрнең канын эчә, чөнки кан эчү
Аларга шикәрдән һәм дә хәлвәдән татлырак.

Терек дөньяны ашатма, бу Яэҗүҗ-Мәэҗүҗдән сакла.
Дума кешеләреннән Искәндәр ныгытмасы төзеттер.

Без – ишек төбендәге ачлар; һәммәбез – сиңа мохтаҗ;
Пәрдәң ач, йөзең күрсәт; нигъмәт диңгезен бүләк ит.

Илаһым, рәхмәтең белән шагыйрьнең бәйле телен чиш;
Дуслар һәм дошманнар хәленнән ул бераз хәбәр бирсен.

*

Ачыл, азатлык бакчасы! Сандугачларың сайрасын, –
Милләтнең киләчәге айлы кичтән дә яктырак булсын.

Бар мөселманнарны һәр заман вөҗдан кушканча йөрт;
Аякларыбызны багълаган чалма богауларыннан азат ит.

Тартар кошы сайрый

(яки татарский марш)

Тора татар! Тора татар!
Уйкудан тиз тора татар;
Тора! Тора! Тора татар,
Баш күтәргән бар татар!
Үтте төннәр, ай батар,
Чулпан калкар, таң атар!
Тора татар, ди, тора татар, ди,
Сайрый тартар: «Тар-тар-тар».
Тор! Тартыш! Тиз бар, татар...
Тор! Селкен! Кузгал, татар!
Алга адым сал, татар;
Бул син галиел-гальдән гали,
Сезнең бит икъбаль, татар,
Һәрбер милләт җиз торбаны
Сезне кушып тартадыр,

Кычкырталар: торалар, торалар!
Тора татарлар – тора татар!
Гыйльмә рәгъбәт сал, татар,
Ит син шуны алтатар;
Корсын туплар! Мәктәпләр –
Безнең арсенал, татар.
Надан булу – гъәр, татар,
Аңгар дөнья тар, татар;
Алсаң өлеш һәр фәннән,
Бәхтең булыр яр, татар.
Һәрбер ак башка алданмас,
Һичшиксез, алдар татар;
Куркъма, зинһар, аздырмый
Һәрбер тар чалбар, татар.
Үтсен кышлар сездән дә,
Ачылсын язлар, татар;
Сайрасын былбылларың,
Чалынсын сазлар, татар.
Чыксын шәмсең, эрсен кар,
Шалтырап аксын ермаклар;
Ятмасын мәңге, җитәр! –
Мисле сәлеҗ Сангатар.

Теләнче

Кыш, буран, салкын һава, яфрак кадәрле кар төшә,
Җил куа карны, һаман да кар «төшәм» дип тартыша.

Сызгыра җил, ыжгыра, тик кар буранын арттыра;
Шул вакыт мәсҗед катында дөм сукыр бер карт тора.

Кичә-көндез ушбу җирдә, Тәңренең язмыш көне,
Капчыгын тоткан, сорана җәй вә көз, яз, кыш көне.

Кызганыч хәл, кызганыч хәл, бик кыен бит, бик кыен,
Бирсәңезче бер тиен тик, тәңкә түгел бит, тиен!

Әйтсәм әйтим инде сезгә: бу кеше бик бай иде,
Эчкәне балдан, шикәрдән, ашлары тик май иде.

Берзаман тоткан иде шөһрәтләре дә даннары
Бу сукыр картның Казан, Ханкирмән, Әстерханнары.

Ул кибетләр, мин сиңайтим, ул хисапсыз маллары, –

Кайсын алсаң шунсы хәзер: гөлләреме, аллары?

Ул тройка атлары, ул бик матур фәйтуннары, –
Кайда ул төлке толыплар, кайда, ай-һай, туннары!

Шәп иде! Бик шәп иде, мин шуннан артык ни диим?
Шыр ялангач бит, күрәмсез, бирсәңезче бер кием.

Барча хәзрәтләр иделәр бу бабай мәфтүннәре,
Калмады бу карт өчен һич итмәгән әфсүннәре.

Башларын салындырып һәм кәкре-бөкре боргалап
Йөрделәр бу карт янында юрга тайдай юргалап.

Кайда бай хәлендәге җаннан сөекле дустлары, –
Кайда качкан барчасы: Гайнүкләре, Әхмүшләре?
Кызганыч хәл! Кызганыч хәл, бик кыен бит, бик кыен;
Бирсәңезче бер тиен тик, тәңкә түгел бит, тиен!

Биш намаз саен намаз әһленә кул сузып кала;
Күрми һәм хәзрәт бу картны, тик кырын күзне сала.

Ә шулаймы? – Акча барда бар да дуст шул, бар да яр,
Акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр!

Син булмасаң!

И матур! мин янмас идем – яндыручы булмасаң;
Таммас иде җиргә яшьләр – тамдыручы булмасаң!

Бер минутта ташлар идем бу томанлы моңларый, –
Син мине мескин кыйлып моңландыручы булмасаң!

Мәүҗе-мәүҗе улмазды, болганмазды гыйшкың диңгезе, –
Рихе сарсар төсле, син болгандыручы булмасаң!

Әкләнердем беркадәр мин шәмсә, йә бәдрә бакыб, –
Анлари хөснеңлә ләшәй сандыручы булмасаң!

Тәрк идәрдем вәхшәти, – тик кәндеңә тартып бәни,
Кяинатә каршы ям-ямландыручы* булмасаң!

Халисән коллык идәрдем Тәңрия, дәрвиш кеби, –
Күңлеми тәшвишлә шәйтанландыручы булмасаң!

Җаныма касд әйләмәздем хәсрәтемдәй гяһе гяһ, –
Кәндеми кәндемгә дошманландыручы булмасаң!

Кайвакыт Мәҗнүн кеби көлмәс вә шатланмас идем, –
Син агач ат өстенә атландыручы булмасаң!

Шигърә биңзәрди бераз биһүдә әшгарем бәнем, –
Һәр каләм тотканда, истән тайдыручы булмасаң!

Хәзерге әдәби телдә

Син булмасаң!

И матур! Мин янмас идем – яндыручы булмасаң;
Таммас иде җиргә яшьләр – тамдыручы булмасаң!

Бер минутта ташлар идем бу томанлы моңнарны, –
Син мине мескен кыйлып моңландыручы булмасаң!

Дулкынланмас, болганмас та иде гыйшкың диңгезе, –
Көчле җил төсле, әгәр син болгандыручы булмасаң!

Юаныр идем бераз кояшка йә айга карап, –
Матурлыгың белән аларны каплаучы булмасаң!

Кыргыйлыкны ташлар идем, – мине үзеңә тартып,
Җир йөзендәге бөтен нәрсәгә каршы куймасаң!

Дәрвиштәй, Аллага чын күңелдән кол булыр идем, –
Тәшвиш белән күңелемне аздыручы булмасаң!

Хәсрәтемнән кайвакыт үз-үземә кул сузмас идем, –
Үземне үземә дошманландыручы булмасаң!

Кайвакыт Мәҗнүндәй көлмәс һәм шатланмас идем, –
Син агач ат өстенә атландыручы булмасаң!

Язганнарым бераз шигырьгә охшар иде, –
Һәр каләм тотканда, истән тайдыручы булмасаң!

«Тәрбиятел әтфаль»гә

(Бер тыйфле мөслим лисаныннан)

Кальбемә гайбүбәтең тагълар кадәр вирди кәдәр;
Нәрдәсең, вир бер хәбәр: мәхзүнем, и мөшфикъ пәдәр!

Нарасидә бер сабыем, бигакыл диванаем;
Ифтиракыңнан бирү бән бикәсем, биваяем.

Бәхте икъбалемне эстәб юла улмыштың рәван,
Кем һөҗүм итте, пәдәр, – һанги җинаятьпәрвәран?

Зате пакен, нәрдәдер? – дәрьядамы, сахрадамы?
Нәрдәсең, аһ, нәрдәсең: дөньядамы, охрадамы?

Бән әминем кем: Хода вирмәз сәни җаниләрә –
Вәгыд: «Ля хәүфен галәйһим...» динени хамиләрә.

Гарзы хаҗәт әйләмәк чөн киттеңезме «Тур»а сез?
Яки дә гизләндеңезме галәме мәстүрә сез?

Ашдыңызмы юкса фазлән хәзрәти Гайсәйә сез? –
Бәдбәхет тыйфлем ки, калдым саясез, сәрмаясез.

Халкымыздан иштикая киттеңезме Тәңрия?
Бөйлә: «И Хәллакъ! Халыкың әйләмәзләр тәэдия
Фарзыңи – әүлядләрене әйләмәзләр тәрбия.

Нәйләем, каумем бәнем рәэсән гадудер һәр нәйә,
Һәр ишә (һәр фигыле хәйрә) «мардән бәдтәр!» дия.

Әйләдем әмреңлә дәгъват карьятән, шәһрән дә бән;
Итмәде тәэсир, чалышдым хәфьятән, җәһрән дә бән.

Максадым тәнвир иде бу милләтең әтфалене,
Анлара каршы ачыб җәннәтләрең әкъфалене».

*

Сән идең бер сәрмәди ләззәт виричи җаныма, –
Валидем анчак йимәк, эчмәк вирер хайваныма.
Аһ, пәдәр! Сәнсез бәңа дөньяда инсанлыкмы вар?
Улмагым мәгълүме галәмдер химар угълы химар.

Җөмләтән мәсгуд санырдым мөслимин әүлядени:
Кәндеми, әүлядеми, әүлядемең әүлядени.

Аһ, кем! Абаэмез һәп лихияле сыйбъян имеш,
Анлари инсан димәк һәм ифтира-бөһтан имеш.

Хәзерге әдәби телдә

«Тәрбиятел әтфаль»гә

(Бер мөселман баласы теленнән)

Синең югалуың күңелемә тау кадәр кайгы салды;
Кайда син? – бир хәбәр: кайгырам, и шәфкатьле атам!

Мин бер сабый баламын, акылсыз диванамын;
Аерылышканнан бирле мин мин түгел, химаячесез калдым.

Бәхет һәм якты киләчәгемне теләп юлга чыккан идем,
Кем һөҗүм итте, атам, – кайда ул җинаятьчеләр?

Пакь затың кайда? Дәрьядамы, сахрадамы?
Кайда син, аһ, кайда син: дөньядамы, ахирәттәме?

Мин ышанам ки: Ходай сине җинаятьчеләргә бирмәс –
Дин саклаучыларга «Куркыныч юк...» дигән вәгъдәсе бар.

Теләкләрегезне әйтү өчен, «Тур» тавына киттегезме сез?
Яки чит-ят дөньяга яшерендегезме сез?

Әллә юкса хәзрәте Гайсә янына аштыгызмы? –
Мин бәхетсез бала ки, малсыз һәм яклаучысыз калдым.

Халкыбыздан зарлану өчен, Тәңрегә киттегезме? –
Дип: «И Яратучы! Халкың фарызыңны үтәми –
Балаларын тәрбия итмиләр.

Ни эшлим, халкым баштан ук дошман һәр нәрсәгә,
Һәр эшкә (изге эшкә) «еланнан да явызрак!» – дип.

Әмрең белән авылда да, шәһәрдә дә өндәдем:
Яшертен дә, ачыктан-ачык та, – тәэсир итмәде.

Максатым – бу милләт балаларын нурландыру иде,
Ачып аларга җәннәт йозакларын».

Син идең мәңгелек ләззәт бирүче җаныма, –
Тудыручым исә тамагымны туйдыручы гына иде.
Аһ, ата! Синнән башка мин дөньяда кешемени?
Дөньяга мәгълүмдер: мин ишәк улы ишәк инде.

Барлык мөселман балаларын бәхетле саный идем:
Үземне, балаларымны, балаларымның балаларын.

Аһ, кем! Ата-бабаларыбыз сакаллы сабыйлар икән,
Аларны кеше дип исәпләү ялган һәм яла икән.
Күрдегезме?

Әйа, и әһле ислам, күрдегез «Дөнья мәгыйшәт»не,
Ничек соң таптыгыз сез – бу кабахәт мәнбәгы шәпме?

Яшерми әйтегез миннән, китерми шөбһәне, шикне:
Мөхәррир, нашире кемдер – сыермы, әллә ишәкме?

Оят бит бу, мөселманнар, бу нинди шарлатаннар бу?
Ходай орган җәһаләт битниләр кыйлдырмый, нишләтми?

Орынбур кальгасендә юкмыдыр һич тә хәдәсханә?
Нәчөн бу бәдбәхетләр матбага өстендә эш рәтли?

Кем ул «марҗалы», кемдер, санә Аллаһе ганилҗани,
Надан калган гомуми пишкадәмнәрдән дә пишрәкме?

Ничек язган икән ул сүзне, ул ахмак, исергән баш?
Тәгаҗҗеб, әллә ул зат һәр нәҗесләрдән дә писрәкме?

Дөрест, һәрбер халыкта бар дорыр мондый кара йөзләр,
Вәләкин һичбере милләткә мондый сасы иснәтми.

## Яз

Тыныч торма, каләм, дәртеңне яз, яз!
Тагын җитте мөнәүвәр яз, аяз яз.

Яза күр, и каләм, яз, гәрчә аз-аз,
Дәһ булсын, әйләсен дил иһтизаз, яз.

Эрергә башлады бозлар вә карлар,
Томаннар чыктылар җирдән вә парлар.

Төшерә искә язның бу томаны
Дөханы ахыр – ахыры заманы.

Кисәктән җанланып, бозлар агалар;
Чабалар, берсене берсе кагалар.

Белерсең син боларның мәхшәре дип,
Бу бозларны – үлекләр гаскәре дип;

Өрелмеш дип белерсең санки мөгез,
Вә яки мөгезен селкеткән үгез.

Болар әллә бара дәһшәтле судка,
Беленми: кайсы – җәннәт, кайсы – утка.

Бу галәмне тота бертөрле каушау.
Бөтенләй болганадыр, килә шау-шау.

Бөтен сахра гарип төсләр аладыр,
Болыт төсле ала булып каладыр.

Бераздан күрсәтәдер чын төсен җир,
Чәч орлык, сөр сабан инде, бу – чын җир.
Кояш та җып-җылы нурлар сачадыр,
Күңелсез җир йөзе күңлен ачадыр.

Китә, саубуллаша кыш зәмһәрире,
Чыга җиргә яшел чирәм хәрире.

Терелә, җанланадыр халкы галәм,
Яңара халкы Хаува, халкы Адәм.

Шулай шул: уйлата яз төрле якны,
Димәк ки, бер мәматны, бер хәятны.

## Бишектәге бала

Бәхетле нарасыйдә! Тар бишек тә киң әле аңгар!
Ике ат бер тиен, диңгез тубыктан тиң әле аңгар!

Вәләкин бир заман, ул тик бераз үссен дә ир булсын;
Күренер киң җиһан аңгар кабердән һәм ләхеттән тар.

Шиллердән

Син булеш, сөйсәң мине, гыйльмең вә гыйрфаның белән;
Нәрсә белсәң дә, икәү уртаклашыйк аның белән.

Син исә: «Эстәр исәң, җанымны бирермен», – дисең,
Нәрсәгә җаның миңа, нишлим синең җаның белән?

Мөтәшагыйрьгә

Тегермән әйләнә; әйләнсә дә, тартылмыйдыр ярма;
Мәшәкатьләнмә бушка көчләнеп, юл уртасын ярма.

Һөнәрләр күп җиһанда, син дә моннан башка сәнгать тап;
Чабатаң берлә, нинди мәнфәгать бар соң, әдәп таптап?

Тырышма нафилә җиргә вакты гаҗзеңне икъраргa:
Сиңа соң сандугачча сайрамак мөмкинме, и карга!

Тәшагырь итмә, зинһар, кермә шагыйрь битлегенә син,
Кисәрләр койрыгыңны, кермә былбыл читлегенә син.

Пар ат

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап.

Кич иде. Шатлык белән нурлар чәчеп, 7ай ялтырый;
Искән әкрен җил белән яфрак, агачлар калтырый.

Һәр тараф тын. Уй миңа тик әллә ни җырлый, укый;
Нәрсәдәндер күз эленгән һәм тәмам баскан йокы.

Берзаман ачсам күзем, бер төрле яп-ят кыр күрәм;
Аһ, бу нинди айрылу? Гомремдә бер тапкыр күрәм.

Сау бул инде, хуш, бәхил бул, и минем торган җирем,
Мин болай, шулай итәм дип, төрле уй корган җирем.

Хуш, гомер иткән шәһәр! инде еракта калдыгыз;
Аһ! таныш йортлар, тәмам күздән дә сез югалдыгыз.

Эч поша, яна йөрәк, хәсрәт эчендә, уйда мин;
Ичмасам, иптәш тә юк ич, тик икәү без: уй да мин.

Аһ, гөнаһым шомлыгы, бу кучеры бик тын тагын,
Җырламыйдыр бер матурның балдагын йә калфагын!

Әллә нәрсәм юк кеби; бер нәрсә юк, бер нәрсә ким;
Бар да бар, тик юк туганнар, мин ятим монда, ятим.

Монда бар да ят миңа: бу Миңгали, Бикмулла кем?
Бикмөхәммәт, Биктимер – берсен дә белмим, әллә кем!

Сездән айрылып, туганнар! – Җайсыз, уңгайсыз тору;
Бу тору, – әйтергә мөмкиндер, кояш-айсыз тору.

Шундый уйлар берлә таштай катты китте башларым;
Чишмә төсле, ихтыярсыз акты китте яшьләрем.

Бер тавыш килде колакка, яңгырады берзаман:
«Тор, шәкерт! Җиттек Казанга, алдымызда бит – Казан!»

Бу тавыш бик ачты күңлем, шатлыгымнан җан яна;
«Әйдә, чап, кучер, Казанга! Атларың ку: на! на-на!»
Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;
И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.

Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...

## «Тавыш» хакында

Эшчеләр! Шатлык сезгә: чыкты «Тавыш»;
Авыш, эшче! Бу «Тавыш»ка табан авыш;
«Таң»нан ятим булып калган бичаралар,
«Таң» урнына «Тавыш» берлән инде кавыш.

«Тавыш» эше – ялган-риялардан сау эш,
Ак күңелдән саф көенчә чыккан тавыш;
Сез эшчеләр өчен тавыш – якты кояш;
Тик тормагыз! Дәү эш бит бу, бигрәк дәү эш.

Аңлау кирәк: бу «Тавыш» – тик сезнең тавыш,
Сезнең хакны даулар өчен бу кузгалыш;
Һәркемгә, һәрнәрсәгә, һәр тугърыда
Фәкать сезнең күз караштан күзне салыш.

Моннан башка юктыр сезне кызганучы,
Сезнең өчен ике җиңне сызганучы;
Саргаеп чердегез ич, киптегез ич,
Булдымы һич моңар чаклы сызланучы?

Ни күрсә дә сезнең өчен күрер «Тавыш»,
Күтәрәчәк аркасына зур тау «Тавыш»;
Тик сезне сөйгәнлектән үткәрәчәк
Башыннан бик күп хисап һәм тау-тау эш!

Тавышлан! Эшче халык, «Тавыш» белән!
Акмак кирәк бу куәтле «агыш» белән!
Алга атла! Атла алга «сагыш» белән,
Файдаланчы бу форсат һәм табыш белән!

Эшче туган! Тартыш кирәк, кирәк тартыш,
Тартышмаган эшчеләргә бик батар теш;
Изге эштер тартышмаклык хокук өчен,
Тартыш, эшче! Тартыш, зинһар, тартыш, тартыш!

Ләззәт вә тәм нәрсәдә?

Нәрсәдә ләззәт икән? Чөнкем ялан дөньяда кәм –
Мин ләзиз шәйләр, вәли кайсында ләззәт, кайда тәм?* –

Бер матур кызның нәзек билен кысып кочмактамы?
Яки пар юрга җигеп, фәйтун белән очмактамы?

Йә сихерле шишәдән әбелхәят эчмәктәме?
Мәст улып, аляме дөньядан тәмам кичмәктәме?

Яки бер ишә вә йә бер каумә баш улмактамы?**
Могътәбәр бер шаһ улып, әтрафә фаш улмактамы?

Бер ишан булмакла аштан ашка сикермәктәме?
Май тамак төпкә килеп, бик тәмле кикермәктәме?

Әллә гармунчы булып, һәртөрле көй уйнаудамы?
Бер көй уйнап, моңланып, һәртөрле уй уйлаудамы?

Әллә сәүдәгәр булып, табышка шатланмактамы?
«Шәп табыш бүген, хатын!» – дип, төнлә мактанмактамы?

Баш улып бер гаскәрә, алтын нишан алмактамы?

Баш кисеп, каннар түгеп йөрмәктә, җан алмактамы?

Йә кабартма, сумса берлән чәйләп утырмактамы?
Бик озак, бөкләп аяк, корсакны тутырмактамы? –

Бәнчә, бу дөньяда һич чын тәс тә юктыр, ямь дә юк;
Һичберендә бунларың ләззәт тә юктыр, тәм дә юк.

Тик фәкать милләткә хезмәткә мәхәббәт бәндә бар, –
Бәнчә, бунда ямь дә бар, ләззәт тә бардыр, тәм дә бар!

Кем ул?

Кем ул бу милләти тәрфиг идән кәс?
Кем ул телләндерән һәм вирдерән сәс?

Бәһаимдән бези тәфрикъ идән кем?
Төбендән вәхшәти тәхриф идән кем?

Бези дошманлара тәгъриф идән кем?
Бу гамькин милләти тәфрих идән кем?

Караңгыда идек, аттырды «Таң» кем?
Бези бер көлдерән, бер аглатан кем?

Кәчән көнләрне уйга алдыран кем?
Вә бер дә «Инкыйраз»ы аңдыран кем?

Әҗаниб дикъкатене җәлбидән кем?
«Татар» ләфзын «тотар»а кальбидән кем1?

Безем чөн зәхмәтен там әйләйән кем?
Соңындан рәхмәтен гам әйләйән кем?
Хәзерге әдәби телдә

Кем ул?

Кем ул бу милләтне күтәргән кеше?
Кем ул аңа тел биреп, тавышын яңгыраттырган кеше?

Безгә хайван түгеллегебезне күрсәткән кем?
Вәхшәтне төбеннән бозган кем?

Дошманнарыбызга кемлегебезне күрсәткән кем?
Бу моңлы милләтне шатландырган кем?

Караңгыда идек, «Таң»ны аттырган кем?
Безне бер көлдереп, бер елаткан кем?

Узган көннәребезне уйлаткан кем?
Һәм «Инкыйраз»ны исебезгә төшергән кем?

Тирә-яктагыларның игътибарын җәлеп иткән кем?
«Татар» сүзен «тоткар»га әйләндергән кем?

Безнең өчен бөтен зәхмәтне үзенә алган кем?
Соңыннан рәхмәтен уртак иткән кем?

Дөньяда торыйммы? – дип
киңәшләшкән дустыма

Тормак ярый: бертуктамый ялганласаң,
Тугъры сүзле инсаннарга ялганмасаң,
Вөҗданыңнан шәйтан төсле тыр-тыр качып,
Үзең алдап, башкалардан алданмасаң;

Кардәшеңне үз нәфсеңнән алгалмасаң,
Ярлыларны бурлаклар дип сангалмасаң,
Тик бер ялгыз корсагыңны зурайтырга
Бар гомреңне хезмәт иттерсәң, ялласаң;

Һәрбер байны тәхриреӊ берлә ауласаң,
Тәкърирендә тик майласаң да балласаң,
Бу сүз корсак файдасына зарардыр дип,
Хәкыйкатьне яшермәктән оялмасаң;

Эчтән динсез булып, тыштан «дин», «дин» дисәң,
Ярлыларны дошман күрмәк диндин дисәң,
Мин мәсләкле, мин мәзһәбле, мин эшлекле,
Һәр артыклыкның чишмәсе «мин, мин» дисәң, –

Читен тормыш! – Капиталга чукынмасаң,
Хәзрәтендә тезләр чүгеп укынмасаң;
Тор, рәхәтлән, кәп-кәкрене туры дисәң,
Истибдадның намусына тукынмасаң!

Зинһар, иптәш, хаклык сөйгән булып йөрмә,
Ялган сөйлә, күрмә зиндан, күрмә төрмә;
Тип! Дөньяда ач-ялангачларны белмә,
Иске дөнья тузанын ит күзгә сөрмә!

Лязем түгел инсаф, вөждан – бер данә дә,
Һич кирәкми гайрәт итмәк, мәрданә дә;
Килешмидер Коръән уку, тәсбих әйтү
Фәхеш-вәхшәт берлән тулган бер ханәдә.
Тор дөньяда: иманың сат, вөжданың сат, –
Шулай торсаң, гомрең үтәр бигрәк ансат;
Алдаучылар, кяферләргә дөнья җәннәт, –
Гомрең үтсен рәхәт-рәхәт, ансат-ансат.

Мәгълүм инде: мин кушканча тормыйсың син,
Нифакъ берлә ялган сөйләп йөрмисең син;
Җаннан куркып, куян төсле дер-дер тетрәп,
Чын мәсләкне арлы-бирле бормыйсың син.

Үл! Туфрак бул, кайт аслыңа, – аслың яхшы;
Хәнҗәр берлән күкрәгеңә касдың яхшы;
И җир шары! Нидән, белмим, хак сөйгәнгә
Мең кат синең өстеңнән дә астың яхшы.

Хаклык астка күмелгән шул, өсттә түгел,
Шуның өчен астка табан тарта күңел;
Хаклык берлән мәхшәргәчә бергә булыр
Өчен, син дә – тиз бул, тиз бул – җиргә күмел!

Бәхил бул, дуст! Мин һәм тиздән менәм дарга, –
Туйсын ашап җансыз тәнне козгын, карга;
Тормыйм инде – бу дөньядан туйдым инде!
Моңар чаклы торганмын мин гакыл тарга.

Юаныч

Гомер агмы судай ага,
Кага безне алга таба;
Китәр баштан кайгылар да,
Әкрен-әкрен ага-ага.

Алда көннәр дә бар әле;
Укып, милләт, агар әле;
Бер көн килер, ия чыгар,
Бу хәлең мөстәгар әле.

Мәгърифәт эзлә, бар әле,
Истигъдад бездә бар әле;

Адаштым дип егълый күрмә:
Гыйлем чын эз табар әле.

«Ля тәйәсү!»1 әмрене тот!
Оныт нәүмизлекне, оныт;
Күрәмсең: күктә бар болыт, –
Явар рәхмәт, явар әле.

Безне артка тарткан картлар
Мәзарестан таба атлар.

### Бер манигы тәрәкъкыйгә

Батарсың дим – йөгермә Нилгә каршы;
Кире кайтыр – төкермә җилгә каршы.

Батыр дип мактамаслар – чикмә зәхмәт;
Көчек! Зинһар, дим, өрмә филгә каршы.

Кире төште угы башына, Нәмруд
Атып баккан иде Җибрилгә каршы.

Яһүдләр булды мәгъзуб та кыямәт,
Карышып, күз йомып Инҗилгә каршы.

Хәзәр! «Әхҗаре мин сиҗҗил» дә вардыр
Ходадан – вәсвәсә, тазлилгә каршы*.

Тәнакыз юк мисальдә, и мохатәб**,
Ачулансаң да, чү! – тәмсилгә каршы.

«Тәгали ит», – дисәм сезгә – әрәм сүз!
Сәмалар кинәле хинзиргә каршы***.

Сине дәртләндерер гармунлы җыр бу.
Биерсең, бәлки, бу кадрильгә каршы.

### Шүрәле

I

Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай диләр;
Җырлаганда көй өчен «тавыклары җырлай» диләр.

Гәрчә анда тугъмасам да, мин бераз торган идем,
Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем.

Ул авылның, – һич онытмыйм, – һәр ягы урман иде;
Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.

Зурмы? – дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә;
Халкының эчкән суы бик кечкенә – инеш кенә.

Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава,
Җил дә вактында исеп, яңгыр да вактында ява.

Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк;
Күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк.

Бик хозур! Рәт-рәт тора, гаскәр кеби, чыршы, нарат;
Төпләрендә ятканым бар, хәл җыеп, күккә карап.

Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр
Берлә бергә үсә аллы-гөлле гөлләр, гонҗәләр.

Ак, кызыл, ал, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр;
Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр.

Үпкәлиләр чәчкәләрне төрле төсле күбәләк-
ләр килеп, киткән булып, тагын да шунда чүгәләп.

Бервакыт чук-чук итеп сайрый Ходайның кошлары;
Китә җаннарны кисеп, ярып садаи хушлары.

Монда бульварлар, клуб һәм танцевальня, цирк та шул;
Монда оркестр, театрлар да шул, концерт та шул.

Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби;
Биниһая, бихисаптыр, гаскәри Чыңгыз кеби.
Кылт итеп искә төшәдер намнары, дәүләтләре
Карт бабайларның, моны күрсәң, бөтен сауләтләре.

Ачыла алдыңда тарихтан театр пәрдәсе:
Аһ! дисең, без ник болай соң? Без дә Хакның бәндәсе.

## II

Җәй көнен яздым бераз; язмыйм әле кыш, көзләрен,
Алсу йөзле, кара кашлы, кара күзле кызларын.

Бу авылның мин җыен, мәйдан, сабаны туйларын
Язмыймын куркып, еракларга китәр дип уйларым...

Тукта, мин юлдин адашканмын икән бит, күр әле;
Әллә ник истән дә чыккан, сүз башым бит – «Шүрәле».

Аз гына сабрит әле, и кариэм! хәзер язам;
Уйласам аулымны, гакълымнан да мин хәзер язам.

## III

Билгеле, бу кап-кара урманда һәр ерткыч та бар,
Юк түгел аю, бүре; төлке – җиһан корткыч та бар.

Һәм дә бар монда куян, әрлән, тиен, йомран, поши –
Очрата аучы булып урманда күп йөргән кеше.

Бик куе булганга, монда җен-пәриләр бар, диләр,
Төрле албасты, убырлар, шүрәлеләр бар, диләр,

Һич гаҗәп юк, булса булыр, – бик калын, бик күп бит ул;
Күктә ни булмас дисең, – очсыз-кырыйсыз күк бит ул!

## IV

Шул турыдан аз гына – биш-алты сүз сөйлим әле,
Гадәтемчә аз гына җырлыйм әле, көйлим әле.
Бик матур бер айлы кичтә бу авылның бер Җегет
Киткән урманга утынга, ялгызы бер ат җигеп.

Тиз барып җиткән Җегет, эшкә тотынган баргач ук,
Кисә башлаган утынны балта берлән тук та тук!

Җәйге төннең гадәтенчә төн бераз салкын икән;
Барча кош-корт йоклаган булганга, урман тын икән.

Шундый тын, яхшы һавада безнең утынчы исә,
Алны-артны, уңны-сулны белмичә, утын кисә.

Балтасы кулда, Җегет эштән бераз туктап тора;
Тукта, чү! Ямьсез тавышлы әллә нәрсә кычкыра.

Сискәнеп, безнең Җегет катып кала аягүрә;
Аңламастан, каршысында әллә нинди «ят» күрә.

Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Йә өрәкме, нәрсә бу?
Кот очарлык, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу!

Борны кәп-кәкре – бөгелгәндер тәмам кармак кеби;
Төз түгел куллар, аяклар да – ботак-тармак кеби.

Ялтырый, ялт-йолт киләдер эчкә баткан күзләре,
Кот очар, күрсәң әгәр төнлә түгел – көндезләре.

Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе;
Урта бармак буйлыгы бар маңлаенда мөгезе.

Кәкре түгелдер моның бармаклары – бик төз төзен,
Тик килешсез – һәрбере дә ярты аршыннан озын.

V

Бик озак торгач карашып, күзне күзгә нык терәп,
Эндәшә батыр утынчы: «Сиңа миннән ни кирәк?»

– Бер дә шикләнмә, Җегет, син; мин карак-угъры түгел,
Юл да кисмимен, шулай да мин бигүк тугъры түгел.

Гадәтем: ялгыз кешеләрне кытыклап үтерәм;
Мин әле, күргәч сине, шатланганымнан үкерәм.
Тик кытыкларга яралгандыр минем бармакларым –
Булгалыйдыр көлдереп адәм үтергән чакларым.

Кил әле, син дә бераз бармакларыңны селкет, и
Яшь Җегет! Килче, икәү уйныйк бераз кети-кети.

– Яхшы, яхшы, сүз дә юктыр, мин карышмый уйныймын.
Тик сине шартымга күнмәссең диеп мин уйлыймын.

– Нәрсә шартың, сөйлә, и бичара адәмчеккенәм?
Тик тизүк уйныйкчы, зинһар, нәрсә кушсаң да күнәм.

– Сөйлием шартымны сиңа, яхшы тыңлап тор: әнә
Шунда бар ич бик озын һәм бик юан бер бүрәнә.

Мин дә көч-ярдәм бирермен: әйдә, иптәш, кузгалыйк,
Шул агачны бергә-бергә ушбу арбага салыйк.

Бүрәнәнең бер очында бар әчелгән ярыгы,
Шул җиреннән нык кына син тот, и урман сарыгы!

Бу киңәшкә Шүрәле дә күнде, килмичә кире,
Китте кушкан җиргә, атлап адымын ире-ире;

Куйды илтеп аузын әчкән бүрәнәгә бармагын, –
Кариэм, күрдеңме инде яшь Җегетнең кармагын!

Суккалыйдыр балта берлән кыстырылган чөйгә бу,
Хәйләсене әкрен-әкрен китерәдер көйгә бу.

Шүрәле тыккан кулын – селкенмидер, кузгалмыйдыр;
Белми инсан хәйләсен – һич балтага күз салмыйдыр.

Суккалый торгач, ахырда чөй чыгып, бушап китеп,
Шүрәленең бармагы калды кысылды шап итеп.

Сизде эшне Шүрәле дә: кычкыра да бакыра,
Сызлана һәм ярдәменә шүрәлеләр чакыра.

Хәзер инде Шүрәле безнең Җегеткә ялына,
Тәүбә итә эшләреннән, изгелеккә салына:
– Син бераз кызган мине, коткарчы, и адәм генәм;
Мондин ары үзеңә, угълыңа, нәслеңгә тимәм.

Башкалардан да тидермәм, ул минем дустым диеп,
Аңгар урманда йөрергә мин үзем куштым, диеп.

Бик авырта кулларым, дустым, җибәр, зинһар, җибәр;
Шүрәлене рәнҗетүдән нәрсә бар сиңа, ни бар?

Тибрәнә дә йолкына, бичара гакълыннан шаша;
Шул арада яшь Җегет өйгә китәргә маташа.

Ат башыннан тоткан ул, бу Шүрәлене белми дә;
Ул моның фөрьядларын асла колакка элми дә.

– И Җегет, һич юк икәндер мәрхәмәт хиссең синең;
Әйтче, зинһар, мәрхәмәтсез! Кем син? Исмең кем синең?

Иртәгә килгәнче дустлар тәндә җаным торса гәр,
Шул фәлән атлы кеше кысты диермен, сорсалар.

– Әйтсәм әйтим, син белеп кал: чын атым Былтыр минем.
Бу Җегет абзаң булыр бу, бик белеп тор син, энем!

Шүрәле фөрьяд итәдер; аудан ычкынмак була
Һәм дә, ычкынгач, Җегеткә бер-бер эш кылмак була.

Кычкыра: «Кысты, хәрап итте явыз Былтыр мине,
Аһ, үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине?»

Иртәгесен шүрәлеләр бу фәкыйрьне тиргиләр:
– Син җүләрсең, син котырган, син тилергәнсең, – диләр.

Әйтәләр: «Кычкырма син, тиз яхшылык берлән тыел!
И җүләр! Кысканга былтыр, кычкыралармы быел!»

## Театр

Халыкка дәрсе гыйбрәттер – театр,
Күңелдә йоклаган дәртне уятыр.

Театр яктылыкка, нурга илтә,
Кире юлга җибәрми, уңга илтә.

Театр көлдерәдер, уйнатадыр,
Тагы үткән гомерне уйлатадыр.

Күрерсең анда үз хәлең, көләрсең –
Көләрлек булса, булмаса – еларсың.

Күрерсең тормышың нинди: җитешме?
Җитеш булмаса, кай җире җитешми?

Төзәтерсең шуны, тәкмил итәрсең, –
Шулай шактый белем тәхсил итәрсең.

Үсәр яхшылыгың, син яхшы булсаң;
Җылы канлы итәр ул, вәхши булсаң.

Тигез күрә бөтен җанны театр:
Кирәк кол бул, кирәксә – император.

Мөкаддәс ул, бөек ул, гали зат ул,
Тәмам хөр ул, вә бик киң ул, азат ул.

Вә ул дарел-голүм, дарел-әдәптер,
Холыкларны төзәтмәккә сәбәптер.

Вәләкин шарты бар: яхшы төзелсә,
Әгәр һиммәт агачыннан өзелсә,

Ул – алма, мөддәте тулганда пешкәч,
Кызаргач һәм матур булгач, җитешкәч.

«Алтынга каршы»

И Тәгалә! Җир йөзеннән алчы бу алтынны, ал,
Яндыручы бу мөкаддәс җирне – бу ялкынны ал!

Куш мәләкләргә: җиһаныңны тазартсыннар иде,
Барча алтынны, җыеп, дүзәхкә атсыннар иде.

Сап-сары шәйтаннар анлар шунда янсыннар иде,
Җөмлә гасыйлар үчен шунлардан алсыннар иде.

Бу җиһан Иблис вә шәйтаннар белән калыр тыныч,
Бетсен иде шул сары йөз, – шундадыр зур куркыныч.

Бу халыкны шул бозадыр, шул котырта, аздыра;
Ялтырап, күзләрне чагып, тугъры юлдан яздыра.

Мин тәмам гиздем җиһанны – кайда, кайда йөрмәдем,
Тик шул алтыннан – бәла, шәйтан-фәлән һич күрмәдем.

Һәр тараф, һәр җирдә халкың – шул металлның бәндәсе;
Күрмиләр хакны, чөн алтын һәр хәкыйкать пәрдәсе.

Бу халыкча: зөһед, тәкъва, тугърылык та, дин дә шул!
Хәзрәти Коръән, Зәбур1, Тәүрат2 та шул, Инҗил дә шул!

Бер татар шагыйренең сүзләре

Җырлап торам, торган җирем тар булса да,
Куркъмыйм, сөйгән халкым бу татар булса да;

Күкрәк биреп каршы торам, миңа милләт
Хәзерге көн мылтык-ук атар булса да.

Уңга, сулга аумыйм, һәнүз алга барам,
Юлда манигъ күрсәм тибәм дә аударам;
Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә,
Мәгълүмдер ки, курку берлән өркү харам.

Шикләнмибез дошманнарның көчендин без,
Бүгенге көн Гали1, Рөстәмнәргә2 тиң без;
Шагыйрь гомре хәсрәт, кайгы күрсә күрер, –
Дулкынланмый тормый ич соң өлкән диңгез.

Яхшылыкка эреп китәм – балавыз мин,
Мактап сөйлим изге эшне – бал авыз мин;
Бер яманлык күрсәм, сүгәм, мактый алмыйм! –
Ул тугърыда бик явыз, ай-һай, явыз мин!

Яманлыклар тәмам мине котырталар,
Таяк берлә гүя корсакка төртәләр, –
«Нигә болай?» «Ярамый!» – дип сөйләндереп,
«Тфү, чортлар! ахмаклар!» – дип төкертәләр.

Әгәр атса нахак җиргә бер-бер рами
Мине, димим: «Дуст, бу рәмьең һич ярамый»*.
«Яңлыш аттың, иптәш, кире ал, дип, угың», –
Дустлык итәм, кадалганына карамый.

Ачы булгач күңлем, шигърем ачы чыга,
Бәгъзан пешкән дип уйласам да – чи чыга;
Очырмакчы булсам былбыл күкрәгемнән,
Әллә ничек! – Мыр-мыр итеп, мәче чыга.
Мактаулыдыр аллы-гөлле нәрсә төсе, –
Тәмле нәрсә була күбрәк ачы-төче, –
Шулай итеп, ачы-төче язсам да мин,
Чыкса кирәк яхшы ниятемнең очы.

Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам,
Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам;
Тау башына менеп кычкырмакчы булсам,
Биек җир бит, егълырмын дип шүрләп калам.

Максуд җитәр: бара торгач – юл кыскарыр;

Әллә кайда яткан хиссият кузгалыр;
Бөкре түгел, төзәлергә кабер көтмим,
Тәңрем фәйзы минем күңлемгә эз салыр.

Утырышу

Кайвакытта кара күзле, кара кашлы
Матур берлә утырамын кара-каршы;
Шунда ул кыз, әллә ничек сүзгә китеп,
Күргәннәрен, белгәннәрен сөйли башлый.

Мин күзеннән аның күземне алмагач,
Һәр сүзенә «чын, чын» димичә калмагач,
Мин гашыйкны сүз аңлый дип уйлый инде, –
Кадап куйган һәйкәл төсле кузгалмагач.

Кайда аңлау миңа! Бер сүз дә аңламыйм,
Ишетмим дә, тыңламыймын да, санламыйм, –
Бу эшне ул үзе сизсә ачуланыр
Иде, ләкин тугърысы шул: ялганламыйм!

Һич яратмыйм аның шулай саташуын,
Фани дөнья сүзе берлә маташуын;
Телим, ташлап кирәкмәгән вак сүзләрне,
«Сөям, җаным» ләфызларына ашуын.

Һаман сөйли; мин тик ирнен, тешен карыйм;
Йөртәм күзне: калкып чыккан түшен карыйм;
Борнын, аузын, иякләрен, беләкләрен, –
Калмый бармак, тырнак – һәрбер төшен карыйм.

Тыңлыйм, имеш! Юри шулай утыртамын,
Күз алмасын әрле-бирле очыртамын;
Әкрен генә селкенсә дә, кузгалса да,
Торып китә микән әллә дип куркамын.

Мин ул кызны, үз уемча, фәрештә, дим,
Дөнья берлә ваклануын һич эстәмим;
Аңар күрә үземне бик түбән саныйм,
Аның урны фәләкләрдә, гарештә, дим.

Минемчә, тик яралган ул сөелергә,
Сөяргә һәм куанырга, көенергә;
Күргән саен, минем төсле гашыйкларга:
«Бу минеке булмас!» – диеп көенергә.

Минемчә, ул үз кадрене сизсен иде,

Дөнья берлә галякасен киссен иде;
Кайгы нигә? шатлык нигә? гомер нигә?–
Мондый юк-бар нәрсәләрдән бизсен иде.

Сүз тыңлаган булып, итәм йөз тамаша;
Дәртем сыймый эчкә, тулып тышка таша;
Ак кулыннан тотыйм, тотыйм, җибәр, диеп,
Гаклым берлә шул вакытта кул талаша.

Шулай итеп, сәгадәтле сәгать үтә,
«Ул» да торып, үз урнына чыгып китә;
Белмәс хәлне – яшь нәрсә бит – аңлый алмас,
Кычкырсам да: «Кочаклашыйк, тукта! тукта!»

## Сөткә төшкән тычкан

(Бер Америка гәзитәсеннән)

Ничектер, белмимен, бер көн идән асты кошы – тычкан
Егылган да келәттә бер табак сөткә килеп төшкән.

Йөзеп карый табакта арлы-бирле – һич чыгып булмый!
Сыек сөт бит – бата, һич тә табактан ычкынып булмый.

Йөри тычкан, йөзәдер, тик торып булмый, йөрәк түзми,
Йөзәдер аркылы, буйга – котылмактан өмид өзми.

Тырышмак бушка китми бит, бераздан соң була уңгай:
Бу тычкан шулкадәр йөзгән, куерган сөт тә – булган май.

Хәзер бит батмый – тычкан кийрелеп майга аяк баскан;
Сикергән дә табактан ул, чыгып, үз урнына качкан.

*

И карендәш! Син, кирәксә, суга бат йә сөткә бат!
Ит сабыр, күрсәт чыдамлык һәм дә ит гайрәт, сөбат!

## ...га

(Лермонтовтан икътибас)

И матур! Иренмәче, еш-еш кына көзгегә бак!
Күр йөзеңне: нинди нурлы, нинди алсу, нинди ак!

Ул күзең йолдызлыгын һәм ул кашың кыйгачлыгын,
Ул авызның никадәр үпсәң дә туелмаслыгын

Күр дә: бу шагыйрь мине бигрәк белеп мактый, диген;
Бу шигырь мәгънәсе хәзер бик ачык, якты, диген.

Ихтыярсыз, күңлең уйлар: миннән артык юк, диеп;
Сизми калып, син суларсың: мин матурмын, уф! диеп.

Үз-үзеннән разый булыр, яшь күңел дулкынланыр
Һәм диер: ай-һай, матур мин, кем алыр, тик кем алыр?

Шунда уйларсың: бу шагыйрь бушка аһ ормый, диеп,
Аһлары, фөрьядлары, чынлап та, урынлы, диеп.

Йә җанашым, син дә бу хәлдә минем яклы бит, ә?
Раһы гыйшкында һәлак булсам да, мин хаклы бит, ә!

### Авыл хатынының бала тирбәткәндә өмидләре

Әлли-бәлли итәр бу,
Бохарага китәр бу;
Бохарадан1 кайткачтан,
Мулла булып җитәр бу.

Яшел чапан кияр бу,
Ап-ак чалма чорнар бу;
Остабикә кирәк дип,
Бер бай кызын сорар бу.

Сүз дәйтмичә бирерләр;
Кодачалар килерләр:
«Күп яшәсен яшь мулла,
Остабикә!» – диерләр.

Собраньягә барыр бу,
Указ сорап алыр бу2;
Шулай итеп, бу җиргә

Хәзрәт булып калыр бу.

Рәхәт гомер сөрер бу,
Сый-хөрмәтләр күрер бу;
Аллаһ бирса, өй саен
Бәлеш ашап йөрер бу.

Иршатнамә алыр бу;
Зәңгәр йортлар салыр бу;
Мин үлгәчтән, догачы
Булып кына калыр бу.

Гыйззәтем бу, кадрем бу,
Минем йөрәк бәгърем бу;
Куанычым, шатлыгым –
Бу, бу минем бу, бу, бу.
Йокла, угълым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Егълап үтә көндезең.

Сары майдай эр, җаным,
И күңлемнең сайкалы;
Бакчы, күрче: бишеккә
Әкрен генә ай карый.

Мулла әнкәсе булгач
Утырырмын түрдә дә;
Дөньяда да күп файда,
Рәхәт күреп гүрдә дә.

Туган җиремә

Айрылып китсәм дә синнән гомремең таңында мин,
И Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин.

Ул таныш кырлар, болыннар тартты әүвәл хиссеми;
Тарта торгач куймады, кайтарды ахыр җисмеми.

Кысса да синдә фәкыйрьлекләр, ятимлекләр мине,
Изсә дә үз ишләремнән хур вә кимлекләр мине, –

Үтте инде ул заманнар, очтылар шул кош кеби;

Уйласам, ул көннәрем тик кичтә күргән төш кеби.

Бәрсә дә дулкыннарың, һич алмады, гаркъ итмәде;
Алды дүрт ягымны ялкын, якмады, харкъ итмәде.

Бу сәбәптән аңладым мин, и туган җирем, синең
Җанга ягымлы икәндер ялкының да дулкының!

Җөмләтән изге икән ич: инешең, чишмәң, кырың,
Юлларың, авыл, әвен, кибәннәрең дә ындырың;

Һәр фосулы әрбәгъәң: язың, көзең, җәй, кыш көнең;
Барча, барча ак оек, киндер, чабата, ыштырың!

Һәм көтүчең, этләрең, үгез, сыер, сарыкларың;
Барчасы яхшы: бүре, җен, шүрәле, сарикъларың.

## Безне урынсыз яманлыйлар

Сәдакать бездә юкмыш; булмаса, ялганымыз бардыр;
Нифакъ выставкасында күп медаль алганымыз бардыр.

Нәзафәткә ригайәт юк имеш бездә, – нә бөһтандыр!
Аның чөн йорт саен безнең берәр комганымыз бардыр.

Тагын бездә гыйлем әһле – зыялылар да юк, диләр;
Утыз еллап Бохар, Каргалыда торганымыз бардыр.

Татарда акча юк, байлык та юк дип, юкны сөйлиләр;
Урам тулы, кулын җәеп, бурыч сорганымыз бардыр.

Санагать юк, һөнәр юк дип яманлыйлар урынсызга;
Яһүдидән җиңел мал тапкучы ишанымыз бардыр.

Закон белгән юрист юк бездә дип уйлау хата хәтта,
Печән, шалкан базарында закон сатканымыз бардыр.

Табиблек фәне юк дип тә яманлыйлар, ди, дошманнар;
Мәризъләрне ясин берлән сугып екканымыз бардыр.

Мөһәндис барлыгын мөнкир «Көфер почмагы»[1]на барсын;
Күрер шунда: буен-иңен белеп калганымыз бардыр.

Инанмаңыз берәү юктыр диерсә бездә шагыйрьләр;
«Таһир»дән, «Бүз егет»тән2, шөбһәсез, узганымыз бардыр.

Уңай тормыш болай да, һич имибез баш яңалыкка;
Котырсыннар бозык яшьләр, алар: чалбарлары тардыр.
Хәрам уен-фәләннәрдән зарар тимәс, Ходай кушса:
«Һидая шәрхе3» намендә чуен калканымыз бардыр.

Алар алдарлар алдансаң, җәсүр мөфти дә юк, дирләр;
Мәһабәтле, озын буйлы Мөхәммәдъярымыз4 бардыр.

Художниклар вә рәссамнәр дә бардыр, юк диялмаслар,
Мәдинә, Мәккә дип, төрле буяу сатканымыз бардыр.

Җирәнмәслек мөсафирханә һәм ашханә юк, диләр;
«Сарай»дан чисталыкта ким түгел «Болгар»ымыз5 бардыр.

## Китмибез!

Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр:
– Сезгә монда юк ирек, солтан җиренә кит! – диләр.

Китмибез без, безгә анда мондагыдан эш кыен:
Мондагы ун урынына ул җирдә унбиш шпион.

Мондагы төслүктер анда һәм казаклар гаскәре;
Камчылар – шул иске камчы, башкалык – тик фәсләре!

Анда бит бардыр хәзинәне талаучылар, шөкер;
Ач мужиктан соң кисәкне тарткалаучы бар, шөкер!

Без җүләрме, үзебезне утка илтеп ник терик?
Бу кызу җирдән чыгып, тагын сәкарьгә ник керик?

Без күчәрбез, иң элек күчсен безем әмсарымыз,
Һәм дә кайтсын монда үткәргән безем әгъсарымыз.

Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;
Бәйләмеш бу җиргә безне Тәңребез (Гыйззе вә Җәл).

Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт – хөр Русия!
Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе русияһ*!

Ап-ачык бу бер җаваптыр, сүздә түгел, басмада:
– Если лучше вам,
Туда сами пожалте, господа!**

Матбага берлә уйнаган бер байга

Булды кондыз, аслы үзгәрде диеп мин күрсәм үз –
Хәзрәтеңне белмәдем! – Дуңгыз икәнсең син һәнүз!

Матбага алгач, сине инсане галидер дисәм, –
Кайда галилек сиңа, хали икәнсең син һәнүз!

Тугъры юлны тапты бу, тәүфикъ имеш, ярый, дисәм –
Лотфе Хактан пакь икән, гари икәнсең син һәнүз!

Гыйльмә нашир булды бу, яхшы кеше булды, дисәм –
Нәйләем ки, бик кабих, шахшы икәнсең син һәнүз!

Бу сәхи, бер бай кеше тәкмил итәр барын, дисәм, –
Бер хәсис, мәгърур икән, карун икәнсең син һәнүз.

Бу ганидер, милләтә ярдәм вә гаүнәйләр ,дисәм, –
Иске Нәмруд, Самри, Фиргавен икәнсең син һәнүз!

«Белдем инде милләтең дәрден», – дисең, борчак атып, –
Файдасы юк бер хәрам корсак икәнсең син һәнүз!

*

Туктале, бер көн килер дә өйрәтер, әлбәт, ләхет, –
Мильёның ул тар ләхеттә файда бирмәс, бәдбәхет!

Бу кадәр зур, галишан милләт белән ник уйнадың?..–
Ахыры, син милләти каткан тиреӊ дип уйладың!
Туктале, алдыңда, дуст, мәхшәр дә бардыр, суд та бар, –
Каһре Хак бар; тиз янар корсагың – анда ут та бар!

Анда хакимнәр дә алтыннарга һич алданмыйлар;
Анда адвокат та юктыр, – акчага ялланмыйлар.

И аягың коргыры! намусымызны таптадың;
Золмәтеңнең хөрмәтенә шәмсемезне капладың.

Син үзең сүнсәң сүнәрсең, бу кояш сүнмәс әле;

Ул мөкаддәс, залимең әмренә тиз күнмәс әле.

Ташла тиз! пычратма матбугатны, кит! бер якка кит!
И печән өстендә өргән һәм талашып яткан эт!
Мәхбүс

(Пушкиннән)

Утырам мин тимер читлек эчендә,
Каты кайгы, ачы хәсрәт эчемдә;

Караңгыда, каты җирдә, юештә,
Һаман бер төсле җирдә, бер рәвештә.

Күренде бервакытта бер яңа эш:
Ирек-иркендә үскән яшь каракош

Тәрәзәм алдына килде дә кунды,
Чукырга канлы калҗасын тотынды.

Шуны ул бер чукый, тагын да ташлый,
Очар төсле, канатын селкә башлый;

Чукый, йолка, вәләкин анда-санда
Карап-карап куя миңа табан да.

Бу моңлы иптәшемнең күз карашы,
Тагын да әллә нинди ят садасы

Дигән төсле була: «Мондин күчик без,
Канатлан син дә, сахрага очыйк без!

Азатлык кошлары без, әйдә, әйдә,
Бөрадәр! Тиз китик без шунда, кайда

Җәелгән ямь-яшел кырлар, болыннар;
Тавышсыз, тынсыз, аулак һәр урыннар.

Вә шунда, кайда диңгезләр төтен күк
Булып күренәдер күзләргә күм-күк.

Болытлар сәйритә анда, алара,
Алар артында зур таулар агара.

Вә шунда, кайда аулак, җил дә мин тик,
Йөрербез бергә-бергә – син дә мин тик».

Вәгазь

(Лермонтовтан)

Сиңа сүз шул ки: син сөймә, яратма;
Күзеңне тый, – матур кызга каратма.

Кача күр, яхшы саклан, дуст, гыйшыктан;
Күңелне биклә, юл бирмә ишектән.

Гомерлеккә башың әйләндерер ул;
Ирексез әйләр ул, бәйләндерер ул.

Алыр җаның, – сине җансыз ясар ул;
Авыр тау төсле яньчер ул, басар ул.

Һаман артыр, чигеннән дә ашар ул;
Кибәрсең син, – йөрәк бәгърең ашар ул.

Матур сиңа бирер, бәлки, кулын да;
Беразга гәрчә син рәхәттә бул да, –

Үтәр еллар. Читен булыр синең хәл;
Керер сачкә, сакалга шул усал чал.

Кушар ул туктамастан кайгырырга;
Дәлил булыр гомергә айрылырга

Сөекленнән. Бәхетсез син булырсың,
Күңелсез, кызганыч, мескин булырсың.

Бераздан син түшәккә дә егылдың;
Җыерчыклы йөзенә карчыгыңның

Карарсың тилмереп, мәэюс булып син;
Еларсың мөлдерәп, мәхзүн булып син.

Әгәр исеңгә төшсә кайсы чакта,
Качандыр уйнаганы бу яңакта
Күңелле, якты, нурлы яшь гомернең,
Ничек ашкынганы да яшь күңелнең, –

Килер күз алдыңа ул яшь вакытлар,
Сәгадәтләр, күңеллелек, бәхетләр;

Томанланыр, караңгы, ямьсез уйлар
Синең күңлеңне тырнар һәм агулар.

Бу дөньяда тору, дуст! – Ярсыз артык,
Икәү булганчы булмак ялгыз – артык.

Күңеллерәк әҗәлгә баш ияргә
Вә Газраилгә: «Мин ялгыз!»– дияргә.

Күңелдән дә алай ук рәнҗемисең
Дә күрмисең ике хәнҗәр ачысын.

Берәү булсаң, ике җан бирмисең син,
Ике рәт җан ачысын күрмисең син.

Бер гәзитә идарәсе хәленнән

Бәйрәм җиткән. Акча кирәк – касса коры;
Мөхәррирләр язган өчен акча сорый;
Нашир исә, читлектәге бүре төсле,
Идән буе арлы-бирле атлап йөри.

Машинистлар, мөрәттибләр дә бар шунда,
Тарткалыйлар кайсы анда, кайсы монда
Бай абзыйны: «Акча бир дә акча бир», – дип.
Тәңре! Яндырма һичкемне бу ялкында.

Кайсы әйтә: «Мин иртәгә итек алам».
Кайсы әйтә: «Мин амиркан читек алам».
«Бирә күр, бай, бүген, – дидер берсе тагы, –
Гарәфә көн мин авылга китеп барам».

Безнең байның ике күзе ялтырады,
Арды, тәмам эштән чыкты, аптырады;
Кызарынды, бүртенде дә, ачуыннан
Иреннәре дер-дер итеп калтырады:

– Әй конторщик! Счёт яз, ди, Шалкановка,
Мансуровка, Зәйнуллинга, Талкановка;
Игълан хакы тиеш бугай урыслардан,
Яз: Петербург, ничек әле... Балкановка.

– Язган, абзый! Һәр берсенә; алачак юк,
Мин булганда исәпләнми калачак юк;
Бәйрәм өчен биш-ун тәңкә бирче, абзый!

Өйдә бер бөртек чәй, шикәр бер шакмак юк.

Колагында байның тавыш шаулый һаман, –
Һәр хезмәтче хезмәт хакын даулый һаман;
Бара торгач, нашир абзый качып чыга,
Хезмәтчеләр куа эздән табан-табан...
Бәйрәм инде; һәркем ачылган, шатланган,
Яңа кием кигән, пакьләнгән, акланган;
(Әзин җаниб) бу тарафта нишлиләр соң?
– Алданган һәм агач атларга атланган.

Хезмәтчеләр? – мәгълүм инде, фәкыйрь хәлдә,
Кызганычлы, мескен хәлдә, хәкыйрь хәлдә;
Бәйрәм күрмәк кайда инде?! – газап фәкать:
Бу күренешкә егъла да, көл дә, шак та кат!

*

Сиңа, дустым, сүзем шулдыр: татарга сатма матбугат.
Трактир ач татарга, – сат та тор һәртөрле мәшрубат.

Ишек бавы

(Кышкы туйда)

Ишек бавы бер алтын,
Безнең апай мең алтын;
Җылныйм дисәң, бер алтын
Бир, җизни, тыш бик салкын.

Саранланыр чак түгел,
Бир, җизни, комсызланма;
Акча бирми кертмибез,
Тукта, сабырсызланма.

Синең җанашың булса,
Ул – кайнеңнең апасы;
Без билетсез кертмибез,
Бу бит – җәннәт капкасы.

Безне разый кыйл, җизни,
Без каршыңда ризванбыз;
Хур янына илтәбез:
Без вилданбыз, гыйльманбыз.

Безнең апай гәүһәрдер,

Тәннәре чын мәрмәрдер,
Ләгыль, якут, гәүһәрдер,
Аузы балдыр, кәүсәрдер.

Зур дәүләт ич, җизни, бу,
Тагын моннан зур ни бар?
Торма малың кызганып,
Җан бирсәң дә урны бар!

Бирсәң – күп бир син безгә,
Без разый түгел әзгә;
Яудыр алтын, көмештән:
Бакыр төрмә кәгазьгә*.

Байроннан

Бераз елдан соң укып бу шигырьне.
Карарсың, бәлки, бу хәсрәтле җырны,

Вә уйларсың: ничек шагыйрь яраткан,
Ничек янган, синең өчен җан аткан.

Белерсең: инде шагыйрь юк, диерсең;
Егылган ул, сирәк мәхлук! диерсең.

Фикер кыйл: шунда, ди, инде ул үлгән,
Йөрәген бу шигырь астына күмгән.

Гыйлавә

Булмадың ярым вә булмассың, беләм, җефтем минем.
Әмма булдың янмага күңлемдә син – нефтем минем.

Дин, шәригать синдә юк; юк тыелуың, юк бойрыгың;
Син – чабак Иделдәге, тик күрсәтәсең койрыгың.

Син закон-статьяларга баш имисең – хөррә син;
Әйләнәсең, тулганасың – түгәрәк син, көррә син.

Охшату

(Лермонтовтан)

Бер җүләр һәм карт кокетка – икесе дә бер кеше:
Бер савыт инлек, бер уч кершән – аның белгән эше!

Ислахчыларга

Мәгълүмемдер: күптән бирле ислахчы сез,
Ислах өчен чын күңелдән ихласлы сез;
Рәхмәт сезгә! Мәтрүк, мәнси мәктәпләрне
Искә алып күтәрешәсез, яклыйсыз.

Һәр милләттә сезнең кеби фидаиләр
Гыйлем өчен малын, җанын фида итәр;
Тик шундин соң – шундый гайрәт аркасында
Мәктәпләр дә әкрен-әкрен алга китәр.

Бармак берлән каткан җирне казып булмый,
Әлифбасыз (алфавитсыз) язып булмый;
Шуның төслүк, мәктәпләрне төзәтмичә,
– Тәрәккъый! – дип кычкырырга базып булмый.

Ислах дәрьясында йөзсен безнең кораб,
Китсен тугъры, гыйрфан җәзирәсен карап;
Матлуб җиргә сагъ-сәламәт җитешкәнче,
Җил, дулкынны туктатып тор, йа раб! йа раб!

«Әлислах»ка ярдәм итик һәммәмез дә,
Лязем булсын булышмаклык зиммәмезгә;
Кызганыйкмы безнең ярдәм киткән чакта
Төзәлергә вәйран булган кәгъбәмезгә?!

## Фөрьяд

(Бер хатын авызыннан)

Бик нык торам үз хакымны теләүдә мин,
Һәнүз шулук хокук көен көйләүдә мин;
Бала чактук тиберченгән, тик тормаган
Әнкәй бәйләп куйган тыгыз биләүдә мин.

Тарлыклардан күптән! Күптән! Күңлем сынган,
Изелдем күп хокуксызлык җәфасыннан;
Ихтилялчы, юл кисүче булмасам да,
Ун яшь тулгач, унбер яшьтән күрдем зиндан.

Әнкәем бер җасус иде, әткәй – жандар,
Тәрәзәдин караганны күрсә анлар,

Тәмсез ачы сүзләр миңа ява иде,
Тама иде аулак җирдә күздән каннар.

Гөнаһым ни? Нигә кердем бу зинданга?
Гайбем һич юк; кердем анчак кыз булганга.
Нинди каты җәза бит бу: дөнья күрмә,
Кояш күрмә, сахра күрмә, һич кузгалма.

Ансы! Ансы! Китап битенә күз атма,
Аузыңны йом, яктылыктан сүз кузгатма.
Дөнья якты, нурлы димә, ди: караңгы;
Диген: шулай булу лязем мәңге! Мәңге!

Шулай таный бит дөньяны сукыр тычкан,
Шул иманда мулла, хәзрәт, ахун, ишан.
Безнең әткәй-әнкәй инде – шуларга кол;
Алар кушкач, син дә буйсын, син дә ышан!
Хәзер шуңгар ачуланам торып-торып,
Куям бәгъзан күкрәгемә орып-орып:
Күз алдыңда аксын татлы чишмә синең,
Эчми торчы, сусап, шуны күреп торып!

Шул зинданда үсеп җиттем унсигезгә,
Хатын булдым зур корсаклы бер симезгә.
Мәгълүм инде, аңа бардым түгел сөеп:
«Егълау – риза, дәшмәү – риза»га буйсынып1.

Өч баш хатынлы иде ул, мин – дүртенче;
Җыелыштык бер тар йортка без дүрт көнче, –
Кисеп әйтә алмыйм әле дүртенче дип:
Мин булганмын, бәлки, инде ундүртенче.

Уңайсыз бит япь-яшь башка бу өч көндәш,
Көнләшәсең килмәсә дә, көчлән, көнләш;
Сөйми торып, көнли-көнли, кулыңны суз
Шул сурәткә, әхлакың боз, каныңны боз!

Кич булгачдин үзе тагы эчеп кайта,
Аузы-борны сасып, өст-баш тынчып кайта;
Бик зур хаҗи кайткан имеш: әйдә, җөгер
Дүртәүләшеп, дүрт эт төсле, дөбер! дөбер!

Исрек. Ләкин сөя үзе сагынганны,
Куштанлыкны, һаман үзенчә булганны;
Җитми аңгар рәфикъләрчә мөгамәлә:
Синнән сәҗдә тели, сөя табынганны.

Яткызмакчы булсаң, кулыңнан ычкына,
Тәмсез сүзләр сөйли, сүгнә, кычкыра;
Икенче бер көндәш исмен дәшкән була, –
Шул хәлендә яту кайда тыныч кына!
Шау-шу булгач, балалар да уяналар,
Җүнле ирләр күренергә оялалар
Мәгъсум сабый балаларга бу хәл белән,
Мондый начар, мондый ямьсез мисал белән.

Куштанлыгың җиткән булса, кочак була,
Төрле нигъмәт булган була, оҗмах була;
Белеп булмый: эшеннән «ля йөсьәл» ич ул;
Куштанлансаң да, кайчакта пычак була.

Каһәр итсә, һәр хатынның ала котын, –
Йөрәк янып, һаваларга оча төтен;
Яндырадыр – ягам дисә, калдырадыр –
Якмыйм дисә, аның каршында без утын...

Бәйрәм вә сабыйлык вакыты

Сабый вактын сагынмакта һәр шагыйрь дә,
Ачы-тәмле хыялдыр бу һәр шагыйрьгә;
Бәйрәм җитсә, минем дә исемә төшә:
Уйнамакчы булам сыйбъян берлән бергә.

Төшә искә гарәфә кич1 яткан чагым,
Уйлап: «Кайчан таң?» – дип, ул атмаган таңым;
Тәти читек, тәти күлмәк-ыштаннарны
Баш астыма өеп куеп яткан чагым;

Таң алдыннан яңлыш йоклап киткән чагым,
Төшемдә дә нурлы бәйрәм көткән чагым;
Әнкәемнең тавышлары колагымда:
«Гает җитте, тор, аппагым! Тор, аппагым!»

Таң аткачдин урам буе чапкан чагым,
Мәгъсуманә ләззәт, хозур тапкан чагым;
Корбан ите, төрле тәмле аш өстенә,

Гает укып, көлә-көлә кайткан чагым. –

Уйласаң ул якты көнне, килә күз яшь;
Хозур ла соң! Инсан өчен бу хәл, бу яшь!
Бәйрәм көнне күктән җиргә нурлар ага,
Әйтерсең лә чыккан бу көн ике кояш!

Тәңре! Чигерче яшемне, синнән сорыйм;
Теләгемне синнән сормый, кемнән сорыйм;
Бәйрәм көнне генә сабый булып торыйм,
Рәхәтләнеп, сикреп, көлеп, уйнап йөрим!
1908

Бер шәехнең мөнаҗате

И Ходай! мәгълүм сиңа, тик яхшылыкта касдымыз;
Зикремездер: казы, кузый, яшь кенә кыз, каз, кымыз.

Юкны сөйлиләр җәдитләр, чыннан әһлинсафлә без,
Мактыйбыз ич Тәңремезне иштә бу биш «каф»лә без.

*

Ерак кыйл безне син афате нәфсә,
Мөдавим кыйл һаман кафате хәмсә*.
Төрекчәдән

Тән үстерсәң – җиһанда, бер дә шиксез, фил булу мөмкин;
Укып рухыңны гали әйләсәң – Җибрил булу мөмкин.

Янә

Бераз йолдызчылар* бардыр ки, күктән йолдыз эзлиләр;
Түбәнгә күз дә салмыйлар, һаман күкләрне күзлиләр.

Саталар фәлсәфә анлар, оралар дәм дә хикмәттән,
Аяк астында базны күрмиләр шул хәлдә гафләттән.
Тәэссер

(Лермонтовның «Молитва» сәрләүхәле шигыренә тәкълид)

Гомернең иң читен, җайсыз, уңгайсыз бер минутында,

Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында,

Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗаиб сүрә Коръәннән, –
Газаплар мәгънәви бер кул илән алынадыр җаннан.

Оча дилдән бөтен шик-шөбһәләр, һәм мин җылый башлыйм:
Яңакларны мөкаддәс күз яшемлә энҗели башлыйм.

Бөтенләй сафлана күңлем; укыйм иман, булам мөэмин;
Килә рәхәт җиңеллекләр: хәлас булам авыр йөкдин.

Ходайа! Син тыйган эшләр тәмам әкътагъ вә әбтәр, дим;
Иям баш сәҗдәгә: «Аллаһе хак! Аллаһе әкбәр!» – дим.

## Урланган мәгънә

(Төрекчәдән)

– Нихәл, шагыйрь? Кәеф хушмы? – дидем шагыйрьгә беркөнне.
– Кәеф юк, дуст, әле мин күп җәфа чиктем золымнан, – ди.

– Ни булды? Нишләделәр? Әйтче, шагыйрь, кемдер ул залим?
Яшермә инде миннән, кемлеген мин дә белеп калыйм.

– Менә шул: башка шагыйрьләр тынычлык бер дә бирмиләр,
Шигырь язганда, һәр юлга минем мәгънәне урлыйлар.

Алар урлап бетергәчдин минем шигъремдә ни мәгънә
Кала соң? – Калды инде барча әшгаремдә бимәгънә.

Бу шагыйрь дустны мин, мәзлум күреп, гаять тә кызгандым
Вә дәрхаль өстәл өстеннән моның әшгарен эзләндем.

Табып, мин шагыйремнең барча әшгарен карап бактым,
Укып чыктым: бөтенләй буш нәзым, тозсыз шигырь таптым.

Дидем: «Ай-һай, явызлар, нинди залим, уңмаганнар бит,
Моның шигърен алар, чынлап та, алган, урлаганнар бит!»

## Егет илә кыз

Егет:

Сөям чүмеч кеби борныңны, җаным,
Гашыйк булдым, тәмам бетте мәҗалым.

Җанашым, аһ, иләк аузыңны үпсәм!
Ни кайгы, инде мин шул чакта үлсәм.

Кыз:

Мәхәббәтсез! Лыгырдый шунда жукны,
Үзеңдә килмәгән җир бер дә җукмы?

Егет:

Ачуланмасана, Гайниҗамалым,
Сине мин кимсетеп әйтмим лә, җаным.

Синең төсле матур кызлар сирәк бит,
Хатын алсаң, иләк, чүмеч кирәк бит.

Сине алсам, чүмечле һәм иләкле
Булам ич – акча туздырмак кирәкми.

## Шәйтанның муенына

– Сөймә юкка, көймә юкка, йөрмәче шул кыз белә;
Бер дә сөйми ул сине, син юкта ул синнән көлә.

– Көлсә көлсен, шул кирәк шул, анда синең ни эшең?
Әйдә, көлсен ул матур, дөньяга күрсәтсен тешен.

Теш нурын чәчсен дә дөньяны җибәрсен балкытып;
Җире, күге яктырып китсен әле бер ялт итеп!

Шагыйрь

Еллар үтеп, бара торгач картайсам да,
Бөкрем чыгып бетсә дә, хәлдән тайсам да, –
Күңлем минем япь-яшь калыр, һич картаймас;
Җаным көчле булып калыр, хәлдән таймас.

Күкрәгемдә минем шигырь утым саумы?!
Күтәрәм мин, карт булсам да, авыр тауны;
Күңлемдә көн һаман аяз – һаман да яз:
Шагыйрь күңелендә кыш булмый да кар яумый.

Булмамын, юк, картайсам да, чын карт кеби,
Утырмам тик, юк-бар теләк тели-тели;
Менмәмен мин, Ходай кушса, мич башына,
Шигырьләрдән килер миңа кирәк җылы.

Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә;
«Без китәрбез, сез каласыз!» – дип җырлармын,
Җәсәдемне туфрак берлә күмгәндә дә.

## Чын вә ялган

Әүвәле дөньяда жир юк, су гына булган, диләр;
Анда йөзгәннәр, имеш, тик Чын белән Ялган, диләр.

Бу ике дошманга Тәңредән бирелгән бер көймә,
Бәс, утырганнар көймәгә берсе каршы берсенә.

Күп тә йөрми, Чын белән Ялган чыгарганнар сугыш, –
Булмаса дустлык, җитә бит сугышырга бер юк эш.

Көчле кулы берлә Ялган Чынны бер суккан ди дә,
Чын батып киткән, ди, чыкмаска җиһанга мәңгегә!

Тәүлек

Иртә дөнья җанлана,
Мәшрикъ ягы аллана,
Кояш чыгып, нурлары
Төшеп җиргә ялгана.

Яктыра кала, урамнар,
Кырлар, якын урманнар;
Таулар, багълар, бакчалар
Нурга гарык булганнар.

Торды халык, уянды, –
Шау-шу һәрбер төшләрдә;
Көтү-көтү менмәктә
Күккә җитез кошлар да.

Төтен төсле, җирдән дә
Күтәреләдер томан;
Нинди вакыт бу вакыт,
Беләсеңме, и туган!

Бу вакытта йорт саен
Кайный самавыр һаман;
Чәйнекләрдә пешмәктә
Чәй – фирмасы «Караван»!

Өйдә хуш ис чәчелгән,
Һәркем күңле ачылган.
Нинди фирма чәе бу! –
«Караван»дыр, «Караван!»

Көн уртасы шәһәрдә
Гадәтчә шау-шу, тавыш;
Җанлылык бар һәр җирдә,
Селкенү, йөгрү, кузгалыш.

Ашыкмакта һәркем дә,
Артыннан куган төсле;

Барчасы бергә шунда –
Бай, ярлы, эшсез, эшле.

Кайный тормыш, туктамый –
Әйтерсең каты буран;
Шул арада тагын да –
Мәшһүр фирма «Караван».
Чәе исләргә төшеп,
Халык эшне ташлыйлар;
Тәмле-тәмле сөйләшеп,
Чәй эчәргә башлыйлар.

Кич. Аз-азлап тынлана
Шаулап торган бу кала;
Арып-талып юнәлә
Һәркем рәхәткә таба.

Кояш мәгърибкә китә;
Тәмле хуш исле һава
Күңелләрне хуш итә, –
Була җаннарга дәва.

Каплый җирне, тагын да
Түшәлә башлый томан;
Бу вакыт ял иткәндә
Эчәләр чәй «Караван».

Чәен эчә, ял итә, –
Рәхәт таба арганнар.
Һәрберсе дә үзләрен
Михнәттән коткарганнар.

Төн. Ай күктән караган,
Йолдызлар да парлаган;
Ялт иттергән каланы –
Ай нуры алтынлаган.

Халык сүнгән, йоклаган;
Тәннәрдән чыккан «рәван1».
Эчә бунлар төштә дә...
Чәй – фирмасы «Караван».

Алданмаска ляземдер,
Аерып акны карадан;

Шаять, инде мәгълүмдер:
Нинди фирма «Караван»!

### Бер кайгы көнендә*

Беттем мин, яшь малай, беттем гомергә дә;
Эссе кан, көчле җан кайтмас гомер дә.

Бар микән дөньяда миннән бәхетсезләр?
Хатыным, йортым юк, – ятам номерда.

Саргайдым, зәгъфраннан сары мин,
Бу чокырлы йөзләр тулмас гомер дә.

### Саташкан

Яз башы. Бозлар китә, ләкин су очмый – җон ага;
Җон белән бер бүрке үлмеш теп-тере мәҗнүн ага.

Тукта, мин капчык ямыйм, соңра сөйләрмен калганын;
Һәрвакытта шул сүтелгән төшләреннән он ага.

Әрни-әрни ләгънәт әйтәм тискәре бу дөньяга:
Җилле көн булган саен, һәрбер урамда ком ага.

Сач тә җиткән, алдырырга куркыныч, бик куркыныч:
Тотса баштан сачтараш, шылтыр да шылтыр җон ага.

Син генә рәхәт кояшын караталасың – карат.
Ник аласың син аны, ул бит минем алтын тарак!1

Кайвакытта капкалыйм мин ашны – тәмлесен генә;
Тәмле җимешләр эчендә тәмлесе – пилмән генә.

Син генә бар күккә патша; мин тагын токмач та ашыйм*.
Син яшә, һәм мин яшим; әйт: шаш, диген, тагын шашыйм!

Күрә калсам эш белән, тырный еланнар мөгезе;
Яп-ялангач, бик киенгән һәм кеше төсле үзе.

Офтанам, ачуланам һәм каш җыерам дөньяга;
Китмәсен алып туратны, – күктә бер козгын ага.

Мәңгегә шул көйгә барырмы кара таплы бәхет.
Өч җәридә шәп диләр: «Йолдыз» вә «Әлислах», «Вакыт»2.

Юк бу дөнья, каплаган күк, юк бу җирләр берсе дә,
Юк чебиләр, юк песиләр, «пес-пес»е юк, «перс»е дә.

Юктыр, әлбәттә, боламык – ул дадыр әлбә генә;
Юк тарантас, юк карета – барсы да арба гына.

Үпкә

Әйа, дустлар, якын дустлар! Гаҗаиб нинди дустлар сез?
Татарча әйтәм инде: дуст түгел, бәлки ...лар сез.

Әгәр шатлык, бәхет килсә – хәзерләрсез бүләргә сез;
Әгәр ямьсез вакыт килсә – хәзер миннән көләргә сез.

Мәддахе истамбул шагыйрьләре

Ушбулар язган шигырьнең, бик кызык шигърияти:
«Һа! Имеш, солтан, тәти, «Йолдыз» тәти1, кызлар тәти!»

Шекспирдән

Китә рәхәт, «килә башлый» дигәнче;
Яшен һәм юк була, «яшьни!» дигәнче.

...га

Син дисең, имеш ки, шагыйрьгә барам;
Барма, барма – син әрәм аңгар, әрәм!

Үз уеңча, шагыйрь ул җырлый, дисең,
Җыр исә тыңларга күңелле, дисең.

Син алай иткәнче, и кашың һилал!
Бар да бер кош кибетеннән былбыл ал.

Ал да читлеккә куеп сайрат аны;
Мактасын хөснеңне – син саргайт аны.

...гә

Бай баласы бит: аны кимсетмә, яныңнан куып,
Җилкәңә кул салса да, шактый озын баскыч куеп.

Тот, җаным, тот, аумасын – түп итмәсен, тот баскычын;
Шунда ядыңнан чыгарма кассаның да ачкычын!

...гә

Очраган юлда, сине күргән, иелгән ул бүген;
Ул шуңар да шатлана бит – чын җүләр түгел диген!

Күргәнең бармы әле Коръәндәге мәдхияңи?
Ул синең васфеңдә: «ля шәркыйя, ля гарбия»1, – ди!

Күк китабының сине белгәнлегенә шаккатып,
Ул хәзер алган «Сабах»тан2 бер Кәләмулла сатып.

## Алдандым

(Лермонтовка тәкълид)

Һич элекке төсле алдыңда түбәнләнмим хәзер;
Без ераклаштык, ишет: син – син хәзер, мин – мин хәзер.

Инде әмриткән сүзең дә аяте Коръән түгел;
Тәмле сүзең яки шелтәң күңлемә солтан түгел.

Син оныттың; мин дә иркемне саташулар белән
Алмыймын алмаштырып, – бушка маташулар белән.

Җитсен инде! Күп тәләф иттем сиңа елларны мин;
Һай, тоталмам ахры, бик күп кудым җилләрне мин!

Әйе, тилмерткән иде шул ул су төсле күзләрең;
Житте күз, кул җитмәде: күктә шул ул йолдызларың!

Дөньяда һәрнәрсәдән бизгән иде бу яшь йөрәк –
Күрде дошман барчасын; сине сөяргә яхшырак.

Кем белә: егълап аяк астында үткән көннәрем,
Мәгънәсез аһлар белән буп-бушка үткән төннәрем

Бер-бер эш милләткә бирерләр иде, алданмасам, –
Мин, җүләр, гошшакъ рәтенә яшьтән үк ялганмасам.

Җисменә җан өрсәм, үтермәс иде милләт мине;
Та кыямәт зикридәрди, бәлки, тәгъзимләп мине.

Нигә назлы вәгъдәләр биргән идең син ул вакыт?
Ник хәзерге сурәтең күрсәтмәдең соң шул вакыт?

Кувәи шигъриями – җанымны бирдем мин сиңа,
Әйтче, и салкын матур! Каршы ни бирдең син миңа?
Хуш, җаным! – сөймим хәзер сине вә синнән башканы;
Син сөя бир алда тагын берне – миннән башканы!

Барча кызлар алдый, дим, һичберсе юк ки алдамас;
Кайсы кызлар алдамас соң, син фәрештәм алдагач!

Кич мине, мин башны бөкмим, мин үземчә зур хәзер;
Син дә бер мәгъруррә булсаң, мин дә бер мәгъюур хәзер.

Бер ходайсызлык белән ялганлый башлыйм инде мин;
Күз дә йоммый һәр кешене алдый башлыйм инде мин!

Егъламыйм – яшь түгәсем килми хәзер һичкем белән;
Инде мин һәркем белән дә һәрвакыт уйныйм, көләм.

Яшь кулың бер мәртәбә артык тотып кысмак өчен,
Тик шуңар, түгел тагын үпмәк вә йә кочмак өчен,

Мин миңа каршы – гакылсыз яр! Бөтенләй җир йөзен
Сугышырга чакырырга хәзер идем бирүзем.

Актыгы: мин бар вөҗүдемне сиңа иттем фида;
Белмәдең лә, белмәдең кадрем! Гөнаһ! И бивафа!

## Кызык гыйшык

Тирләп, эссе көндә койнырга теләп,
Бер кеше салкын су алды бер чиләк.
Өст-башын салган; вәләкин шикләнә
Су салырга тәнгә, чөнки чиркәнә.

Бер куя җиргә чиләкне, бер тота;
Нишләсен мескен – суык су куркыта.
Күп азаптан соңра гайрәткә килеп,
Суны җилкә аркылы читкә сибеп

Куйды да, – син нечкәләп бер баксана:
«Әл дә тәнгә тимәде», – дип шатлана!

*

Мин моны яздым, бу – гыйшкым мисредер;
Чөнки гыйшкым нәкъ минем шул төследер.
Мин сөям, хәтта ки гакълымнан шашам –
Сөйгәнемнән шүрәле төсле качам.

Юлда күрсәм, күз йомам, күрмим, имеш;
Ут йотып янсам да, сер бирмим, имеш!
Бер шигырь язсам да, ялган кул куям,
Мин сөйгәнне белмәсен дип куркудан.

Тугъры килсәм, сүз сөйлим салкын гына,
Булса да күкрәк тулы ялкын гына.
Бер хәбәр бар: ул хәзер киткән бугай1,
Шәһренә күптән барып җиткән бугай.

Кайда ул миннән җибәрмәк хат-сәлам?!
«Белми китте, күп шөкер», – дип шатланам.

*

Белми, дим дә, бәлки, «белгәндер» әле!
Әллә инде белгәнен белдермәде?
Аңламыйм, төшмим дә аңлау касдына,
Шигъреми җәйдем аягы астына;

Өенә җиткәнче басып кайтса аңар,
Шагыйре зур илтифатыннан санар.

## Өмид

Чыкчы, и фикрем кояшы! Китсен өстеңнән болыт;
Бу үлек вөжданны җанландыр, җылың берлән җылыт!

Мин адаштым, тугъры юлга ул торып күндермәсә,
Дүрт ягым гыйсъян уты – сүнмәс һич, ул сүндермәсә.

Бер бетү чокрында мин, юктыр нәҗат, коткармаса,
Мәңге тотныр нәрсә юктыр, ул, килеп, җеп салмаса.

И минем яктыртучым! Тик син миңа һәр җирдә шәм;
Нәрсә ул дөнья кояшы! Син миңа нур бирмәсәң!

Бер йөзең күрсәтсәнә, тугъсын гүзәл көннәр минем;
Чәчкәләр атсын өмид бакчамда ал гөлләр минем.

Мин караңгыда хәзер; үтсен бу таң атмас кичәм;

Таш йотам, икмәк белеп, һәм зәһр эчәм, саф су дисәм.

Бер тигез җирдер дисәм, бассам аягымны – бата;
Күп вакытта сискәнәм, яңлыш тотып «кош» дип бака.

Кап-караңгы. Уңны-сулны күрмим – астны-өстне мин;
Иркәлим дошманны, чәнчәм чын хәкыйкать дустны мин.

Кыскасы, җансыз да, вөҗдансыз да мин – яктырмасаң,
«Мин әле кая барам?»1 – җуйган эзем таптырмасаң.

Юк, кояшым, мин беләм: син батмагансың мәңгегә;
Син дә, вөҗдан, бер торырсың: ятмагансың мәңгегә.

Юк! Түбән калмас бу җан: фитърәттә гали булган ул,
Кисмәк өстендә каракош – иттифакый кунган ул.

## Тормыш

Авырлык төшсә түз, сер бирми-нитми;
Ни хәлләр яшь егеткә килми-китми?

Бу тормыш кем белән туктар талаштан? –
Сугыш син һич тә армас-туктамастан.

Синең төсле берәү ул: бергә-бер сез,
Көрәшкәнне җиңалмый ул кабересез.

Көрәшмәк куркыныч: күп хәлләре бар,
Вәли, җиңгәч, ганимәт маллары бар.

Канечкеч ул вә ерткыч юлбарыстан;
Качармы юлбарыстан бер арыслан?

*

Җиһанда үлми һәрбер ыңгырашкан,
Вә юлны тапмый калмый һәр адашкан.

Көрәш угърында ар, тал, тирлә, имгән;
Өмид итмә булышмакны ләимнән.

Әгәрчә зәррә мыскал һиммәте бар,
Анын артында тау-тау миннәте бар.

Сәгадәт талына менсәң – үзең мен;
Ни ярдәм килсә дә килсен үзеңдин.

Димәс һичкем: «Минем аркамда менде,
Хәзер җүнләп сәлам дә бирми инде!»

Җавап

Шигъре Лермонтов вә Пушкин – олугъ саф диңгез ул,
Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов, Тукай – өч йолдыз ул.

Син дә шул диңгез ярында, и агу йоткан көчек!
Телләрең сузган буласың, – җитми, җитми, кит күчеп.

Кит хәзер, ләкин китәрдә сал колак бу сүзгә бер:
Барчы, эт, гомрең буе шул күктә өч йолдызга өр!

Тешләре ямьсез матурга

«Әйләнәмдә яшь егетләр әйләнә дә әйләнә;
Мин яратсын дип, үзенчә һәрбере ыспайлана;

Нишлим инде, аптырадым», – дип шикайәт әйләдең;
Мактануга охшатып, беркөн хикайәт әйләдең.

Ул егетләрне качырмак? – бик уңайдыр ул сиңа;
Күрсәтимче мин, алайса, бик асат бер юл сиңа:

Син алар килгәч тәбәссем ит, фәкать бер көл генә, –
Ник аяк бассын шулай иткәч тә берсе бер генә.

## Кулың

Чын бәхетледер кулың тоткан колың;
Гайне кодсият вә гыйффәттер кулың.

Ялтырыйдыр санки нурдан бер балык, –
Бер фәрештә күңледәй пакьтер кулың.

Терлә хәсрәттән агуланган күңел;
И матур кыз! Зәһрә тирьякътыр кулың.

Яшь күңелне тотса ычкындырмый һич, –
Бер сихерле, серле кармактыр кулың.

Һәр бәхетнең башы шуннан башлана, –
Бер бәхет бәхренә тармактыр кулың.

Мин кулың тоткачтан аштым күккә дә, –
Бер дә чиксез гали чарлактыр кулың.

Әйе, буең да зифа, туба кеби, –
Шул мөкаддәс талга яфрактыр кулың.

Шагыйранә сүз бу, аңларсың үзең, –
Бу сыйфатлардан ераграктыр кулың.

Тукта, бер мактыйм әле дип уйладым, –
Әллә ник мактарга ансаттыр кулың!

## «Мөхәммәдия»дән

Диде Камил1 ки, йа Сәйдәш2, оныттым,
Яңылдым юлый, яңлыш юла киттем.

Билем гаҗиз синең судлашуыңнан,
Хиҗаб каршысына ут ачуыңнан.

Хәзер көлмим синең сәйдәшлегеңнән,
Электә булса – булган яшьлегемнән.

Хәзер хаклыйм «Бәянелхак»ларыңны3,
Тәмамилә аңа мөлхакларыңны4.

Камил бәндәң ки кыйлды мәгъсыйәт уш,

Әлеңдәдер, нә кыйлсаң, насыйәт уш.

## Күк сыер

I

Башка хайваннар кеби, ушбу җиһанда күп сыер:
Бар агы, бардыр карасы, әмма бармы күк сыер?

Билгеле инде, сыер һич андый төстә булмый ул;
Юк-югын; юк булса да, безнең тарафта булды ул.

Бар иде безнең авылда картаеп беткән әби,
Берүзе – ялгыз башы, йортында юк бер адәми.

Карты сау чактук гомер иткән ягымлы бер мәче –
Бу әбинең шул иде тик иптәше һәм сердәше.

Бер улы бар, ул да чит җирләргә киткән, эштә ул;
Бер дә кайталмый авылга яз да, көз дә, кыш та ул.

Ач-ялангач түгел иде бу әби, тик ятса да;
Хат яза угълы, сала аз-маз кызыл, күк акча да.

Бервакыт, көннәрдә бер көн, хат яза карчык улы;
Хат белән бергүк утыз сум акча салган берьюлы.

Акчаны алгач, әби киткән нидәндер Әтнәгә –
Ни өчендер, белмим, әллә җан тәрәзә какмага?

Кактым-суктым – әчелде,
Тәңкәләре чәчелде;
Эте чыкты өрмәгә,
Кызы чыкты күрмәгә;
Этен алдым пычакка,
Кызын алдым кочакка.
Юк ла, мин бу вак сәтырларны язам уйнап болай;
«Әтнә» дигән сүзне язгач җырлыйсым килде шулай.

Иске бу такмак, сабый вактымда күп такмаклаган
Такмагым булганга, күңлем дәфтәрендә саклаган.

Бер утырсам ялгызым шул дәфтәремне актарып,
Шул килеп чыкты да яздым, калмасын дип тапталып.

Валлаһи, җандай күрәм мин искеләрнең җырларын,
Күкрәгемдә саклыйм әйтерсең рәсүлнең тырнагын.

Йә, минем кайда хикәям? Ник аны читкә борам?
Юк, зарарсыз: мин шулай язган чагында йөткерәм1.

«Яшен» журналы хакында

Ялтырый милли болытларның арасыннан «Яшен»1;
Бәлки, рәхмәт яңгырыдыр – яшьнәсен ул, яшьнәсен.

Юл табар золмәттә калганнар – төшерсен шәүләсен;
Таш йөрәкләр һәм яшен күргәч укыр «ляхәүлә»сен.

Тотса мәскәүләр якаң

Ни кыйлырсың, хажи абзам, тотса мәскәүләр якаң?
Как ты будешь отвечать там, тотса мәскәүләр якаң?

Сыгъмаз ирдең киң җиһанга, малыңа мәгъруур булып;
Даже в тюрьму сыярсың, тотса мәскәүләр якаң.

«Типтереп» йөрдең тәтәйләрдә, театрны сүгеп;
«Нет, князь, постой!» – диерләр, тотса мәскәүләр якаң.

Әйләнәндә әйләнеп йөргән монафикъ муллалар
Әйләнеп тә карамаслар, тотса мәскәүләр якаң.

Яшьләр өстеннән донос илткәндә яхшы «дустларың»,
Бел, үзеңнүк яптырырлар, тотса мәскәүләр якаң.

Бел, хәзер дөнья кяфергә һәм сиңа җәннәт әле;
«Мөэминә зиндан» булыр ул, тотса мәскәүләр якаң!

Тыңламасаң бу нәсыйхәтне, язу бушка фәкать;
Эш үтәр бит, тыңласаң да, тотса мәскәүләр якаң.

Җитмәгәнме бер хатын, өч-дүрт хатын асрау нигә?
Бер хатынга зар булырсың, тотса мәскәүләр якаң!
ысулы кадимче

I

Мәгәр көннәрдә бер көн, әмре трахтир,
Утырмыштым ки бер пивнойда сирра.

Кулымны селтәдем фани җиһаннан,
Агызда папирос, алдымда сырра.

Трахтирларның ул гашыйкларыннан
Тезелделәр килеп катыма торра.

Диделәр: «Кем, ничөн тик ултырасың?
Давай гармун китерт, безнеңлә җырла».

Китерттем эскрипкә берлә гармун;
Кызыклы барча нәрсә килде монда.

Фәкать бер бүлмәдә, һич кемсә күрмәс,
Китерттек берничә акшарлы кыз да!

Гуләйт иттек, тәмам шунда исердек;
Бөтен бит-баш кызарды, тотты кызма.

Бераздан санки безгә килде илһам:
«Гыйлем» булдык, хәзер без әһле фәтва.

Керештек тикшерергә муллаларны,
Ки ягъни кайсы азгын, кайсы тәкъва.

Сүгеп теттек җәдидләрне дә, ягъни
Алар динсез: шулай язган китапта.

Хәрам дибез театр, тансаларны, –
«Тегендә типтерү» әүля вә әгъля.
Күңелләр калды саф ширк вә заляддән:
Минутта пот вә пот динлелек арта.

Без оҗмах кошлары булдык бу җирдә,
Бөтен бүлмә тулып китте сәвапка.

II

Хисапсыз күп эчелгән – мәлҗегәнмен,
Утырган җирдә – шунда калгыганмын.

Шулук хәлдә миңа бер төш күренде,
Төшемдә бик гаҗәп бер эш күренде.

Сөйлимме мин төшемдә, аһ, нә күрдем? –
Үземне гүяки оҗмахта күрдем.
Тезелгәннәрдер әтрафымда хурлар,
Ки айдан якты йөзләр, балкый нурлар.

Пичәтләнгән шәрабләр алга килгән,
Афисиантлар – бары вилдан вә гыйльман.
Эчемлекләр бөтенләй бесплатный,
Берәү дә бер тиен акча түләтми.

Кызык соң! Бер кулым берлән эчәм мин,
Икенче кул белән хурлар кочам мин.

Кетердәп тәмле пешкән кәтлите бар,
Закускага дәхи кошлар ите бар.

Бераздан бер тарафтан чыкты ризван, –
Тәмам алтын-көмешкә, нурга чумган.

Дидем: «И хәзрәти бәүвабы җәннәт,
Нидән ләкте миңа бу назы-нигъмәт?»

Диде: «Оҗмахлысың, син чөнки динле, –
Химайәт әйләдең пивнойда динне».

III

Төшем шул төшкә җиткәндә уяндым;
«Әле мин кайда?» – як-якка карандым.

Утырган дустларымнан җилләр искән;
Кесәмгә кулны салсам – тайдым истән:

Ходай орган караклар, уңмаганнар,
Кесәмнән пыртманитны урлаганнар.

Шулук хәлдә килеп керде афисиант,
Рәхимсез йөртәдер күзләрне ялт-ялт.

Диде: «Барин, двадцать рублей с вас.
Давайте скорей, – скоро уж час*!»

Дидем: «Динге маи иптәшләр украл;
Сабакылар, они украл да удрал» ** .

Афисиант күп талашмый китте миннән,
Ике данә кылычлы янга килгән.

Ике кулдан икесе килде тотты,
Афисианты яңак төпкә утыртты.

Чыгып барганда, дөп-дөп типкәлиләр,
Яман сүзләр белән сипкәлиләр.

Озак та үтмичә, мин часка кердем,
Төшемнең растлыгын шулчакта күрдем.

* * *

Руслар эш күрәләр,
Мөселманнар төш күрәләр.

## Кемнән ярдәм эзләргә?

(Майковтан тәрҗемә)

Миңа дустлар, танышлар һәм белешләр
Хисапсыз бирделәр яхшы киңәшләр.

Диделәр: «Без сиңа ярдәм итәрбез,
Бераз сабрит, мәдәткә без җитәрбез!»

Диделәр: «Куркъма син һич без барында,
Кирәк чакта төгәлләрбез барын да!»

Ышанмаслык түгел бит, – яхшы сүзләр;
Бирә тәмле өмидләр, – якты йөзләр.

Ышандым, иҗтиһадны ташладым мин,
Һаман уйнап көләргә башладым мин.

Һәнүз көтмәктә мин, – эшсез ятамын;
Һаман да юкны бушка бушатамын.

Көтәм, ярдәмгә һичбер кемсә килми;
Ахырда калдым, ачка көчкә үлми.

Шулай да чыкты бер ихсанлы мөэмин,
Минем гомремне, рәхмәт, итте тәэмин.

Миңа һәр көн бирә ул аш вә нани,
Вә миннәт итми, һич юк имтинани*.

Телим аны кочакларга, үбәргә,
Аңа рәхмәт укып, яшьләр түгәргә.

Кочакларга аны шул гайре мөмкин;
Ул ихсанлы кеше кем? – Улмы? Ул – мин.

## Бер рәсемгә

Бик матур бит, бакчы бу кызның күзенә, кашына;
Мең вә мильюн афәрин бу сурәтең нәкъкашына.

Бу озын сачны каян алган икән соң бу кояш?
Күр Ходайның кодрәтенә, – бер күзең сал башына.

И кояш! ямьсезлегеңнән син оялырсың, беләм,
Гәр чагыштырсаң йөзеңне син бу бит алмасына.

Күрсә яңлыш бу матур кызның фәкать рәсмен генә,
Шөбһәсез, селтәр кулын Мәҗнүн дә үз Ләйләсенә[1].

Булсайде оҗмах түрендә әүвәл үк рәсме моның,
Илтифат итмәс иде Адәм дә үз Хаувасына[2],

Күрсә Һарут берлә Марут[3], юлдан азмаслар иде,
Бәлки бакмаслар иде шәйтаннары игъвасына.

Татлы ирнен үпсә бер мән, кәүсәреңне[4] нишләсен?
Пар килер ул дөньяның үлмәс Хозыр-Ильясына[5].

Күрсәйде Иблис ләгыйнь[6] дә, кайда баш тартып йөрү!
Баш иярди сәҗдәгә, кайтып тагын Алласына.

Булмаса сайраулары мәдхе сәнасында моның,
Кит! Пычак керсен җиһанның барча сандугачына!

## Мулланың зары

(«Мелла Насреддин»нән) [1]

И Ходаем! бәндәңә әүвәлдә хөрмәт бар иде;
Берзаманнар чалмалыга кадер-гыйззәт бар иде.

Кайда аусам мин, халык шул якны куәтләр иде;
Җир йөзе җәннәт иде: дәүләт вә нигъмәт бар иде.

Сүз дәшүче юк иде, мин бер караны ак дисәм;
Һай гомерләр! әһле исламда итагать бар иде.

Ул заманнар һәркем үз хәле белән мәшгуль иде;
Нә бу хәзрәтләрне тәфтиш, нә бу сохбәт бар иде.

Җитмәгәнме мин укыткан? «Мәгърифәт лязем», – диләр;
«Мохтәсар»да[2] хәез, истинҗа, тәһарәт бар иде.

Һәммәсе кяфергә охшашлы бу тар чалбарларың;
Нә мөселманлыкка анларда шәбаһәт бар иде.

Йоклаган, сүнгән татарны баш күтәрттеләр шулар;
Якты көннәр үтте; хәзрәтләргә рәхәт бар иде.

Һичберәү сизмәс иде хәйлә-мәкерләрне минем, –
Мулланы мәгъсум санаудай изге гадәт бар иде.

Куркыта торган идем чын сүзлене тәкфир белән, –
Яшьрен эшләрне ачарга кемдә җөрьәт бар иде.

Бар мөселман шул бозык яшьләр юлын тоткан хәзер, –
Йоклаганмын, үткән ул көннәр ки, форсат бар иде.

Аулар ирдем мин балыкларны бу болганчык судан, –
И кая ул көн ки, халкымда җәһаләт бар иде!

## Авыл җырлары

(Беренче көлтә)

Җанкай, сачең бер көлтә, җиккән атны өркетә;
Баязитов «Нур» гәзитен ничек язып өлгертә?1

Җомры тояк тайларда, матур кызлар байларда;
«Әхбар» тәэмин иткән байлар йөри икән кайларда?2

Талдин тартма ясадым, тар буласын белмәдем;
«Әхбар» бай дип еллык яздым, ябыласын белмәдем.

Үрдәк оча, каз йөгерә, боты озынга күрә;
«Тәрҗеман»ның эче поша «Ислах» кызылга күрә3.

Каф тавы артында үсә самарау-кош баласы;
Һинди Минһаҗ шул җирләрдә дарелфөнүн саласы4.

Ак та була, күк тә була буяучының буявы;
«Хөкүмәт яптырды», – дидер наширләрнең уявы.

Безнең урам аркылы ага суның салкыны;
Тарта Казанның яшьләрен Рәмиевләр алтыны5.

Аргы якта алмагач, бирге якта булмагач;
«Миръат» язмый ни хәлең бар, һичбер эшең уңмагач6.

Эскерипкәм тарый-тарый, тарый булса да ярый;
Мөштәриләр юк, ди, – инде игълан булса да ярый7.

Хәтфә калфак киштәдә, эшләнүе бистәдә;
Морад кебек теләнчене күралмассың төштә дә8.

Приемның, ай, ишеге тар ләхеттән тар икән;
Әчтерханда «Борһан», «Идел» – ике әтәч бар икән9.
Җөгралмадым, җиталмадым, тоталмадым үрдәкне;
Иран халкы онытмыйдыр шаһтан күргән «хөрмәт»не10.

Шәкертләре туза икән, кулларында музыкан;
Шул музыкан уйнаганда, Ишми ничек түзәйкән11?

Мөлхимәләр балдагы төрек халкын алдады12;
Алдаласа алдаласын, үкенечкә калмады.

Авыл җырлары

(Икенче көлтә)

Алтын йөзек фирисә, арасыннан җил исә;
Татар бае хаҗга киткән, шартлый мәллә югыйсә?1

Атланмайны бик яратам: әнкәй атлый шул аны;
Татар хатыны азмыйдыр: чапан каплый шул аны.

Үсә, пешә, тәмле була алмагачның алмасы;
Сузсаң Мәскәүгә җитәрлек ишаннарның чалмасы.

Башыңдагы чабатаңның сиксән сигез серкәсе;
Бу дөньяда шөһрәт алды Бәдигъ мәзин күркәсе2.

Җанкай-җанаш, пумала баш, чыкма урамга җаланбаш;
Җөрмә, шәкерт, кәләпүшсез, урыс булдың, ярамас.

Аягыңда итегең, сахтияндыр читегең;
Мотыйгыйдән сорашыгыз мөхәррирлек читенен3.

Безнең Казанның кызлары киенмәсә дә матур;
Татар башы чокыр-чакыр, себермәсәң дә такыр.

Әйдә, җаный, озат бәни, уйсу җиргә җиткәнче;
«Яшен» сугар татарларда сугарлык җир беткәнче[4].

Быел җәйләр үтте китте, утралмадым арбага;
Сими бае зәкят илтә «Колибри» марҗага[5].

Таң әтәчләре кычкыра – әллә таң ата микән?
Һади «Йолдыз»ны бик мактый – әллә ярата микән?[6]

Ямьсез матур булалмыйдыр, күмер берлән каш тартып;
«Бәдәел мәгариф» саталар, алты сүзен башкартып[7].

Кашың каралыгы җиткән, сөрмә тартасың тагы;
Тычкан оясына сыймый, «Мөхбир» тагасың тагы[8].

Киңәш

Якын дустым! Сиңа миннән киңәш шул:
Кешеләргә сереңне сөйләмәс бул.

Эчеңдә нәрсә янганын үзең бел,
Үзең кайгыр, үзең егъла, үзең көл.

Ачып яшьрен хәзинәңне йөрәктән,
Сөйләшмә бер дә артык сүз кирәктән:

Кешеләр үзләрен анчак сөярләр,
Бәхетсезләрнең өстеннән көләрләр.

Алар ерткыч, алардан читтә бул син,
Алар барда бүрең бер якта торсын.

Серең белгәч кызартырлар йөзеңне,
«Җүләр бу!» – дип ачырмаслар күзеңне.

Кача күр, кош кеби, мактауларыннан,
Хәбәрдар бул ки шунда ау барыннан.

Әгәр басса сине бер-бер заманны
Еламый йомшамас хәсрәт вә кайгы, –

Утыр аулакка, кайда һич кеше юк,
Сабыйдай, тәмле-тәмле күз яше түк.

Килеп керсә берәү нәкъ шул чагында,
Сиңа мин бер киңәш әйтим тагын да:

Диген син: «Күзләрем никтер авырта,
Өзелми яшь ага кич һәм дә иртә!»

## Шатлык вә хәсрәт

(Плещеевтән)

Болытлап көн, яшен яшьнәп, каты күк күкрәгәннән соң,
Тонык, шыксыз һава, күзне ачалмаслык бураннан соң, –

Ачылды бер заманны күк йөзе: инде болыт китте;
Күңелгә шул вакыт бертөрле рәхәтлек тулып китте.

Озаккамы вәләкин бу?.. Бераздан диңгез өстендә
Кара, ямьсез болытлар булдылар пәйда, – шул ук хиндә.

Күрәсең, бу болыт берлә гомерлеккә кояш бергә;
Шулай бергә бугай: шатлык та хәсрәт, канлы яшь берлә.

## Улмы? – ул...

Ул зыялыдыр, беләмсез: мәгърифәт, хикмәт сата;
Манжет алган ун тиенгә, биш тиенгә – ак яка.

Шәп сикергечтер үзе, нәкъ тастымалы тансаның;
Ул аяклар, мин сиңайтим, «траттата да траттата!»

Бер тарафтан бер гәзит тулган аның статьясы,
Чүпләнеп аннан да моннан төрле-төрле сафсата...

## Йокы

(Сәгыйть Рәмиевтән үзгәртелде)

Безне адәм иткән йокы,
Адәмне алга илткән йокы,
Илтеп күккә җиткән йокы, –
Йокы, йокы, йокы.

Юлымызны хак иткән йокы,
Йөземезне ак иткән йокы,
Үземезне багъ иткән йокы, –
Йокы, йокы, йокы.

Раст: чын кеше эше – йокы,
Багъ вә рәхәт җимеше – йокы,
Ачкан рәхәт ишеген йокы, –
Йокы, йокы, йокы.

Гакылга нур биргән йокы,
Мөкаддәс уй биргән йокы,
Су юкта су биргән йокы, –
Йокы, йокы, йокы.

Дәүләт, бәхет биргән йокы,
Милек, тәхет биргән йокы,
Безгә кирәк илла йокы, –
Йокы, йокы, йокы.

Урысча да йокы – йокы,
Кытайча да йокы – йокы,
Кемчәгнә дә йокы – йокы, –
Йокы, йокы, йокы.

Ирләргә дә фарыз йокы,
Кызларга да фарыз йокы,
Фарыз эшнең барсы йокы, –
Йокы, йокы, йокы.

## Мәхәббәт

Җир яшәрмәс, гөл ачылмас – төшми яңгыр тамчысы;
Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы.

Бер гүзәлдән кайсы шагыйрь, әйтеңез, рухланмаган?
Байронның, Лермонтовыңмы1, Пушкиныңмы2 – кайсысы?

Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк,
Парә-парә кисмәсә гыйшык-мәхәббәт кайчысы.

Тешләренең гәүһәреннән кабызып алдым менә
Мин бу шигъре, – әйтсәңез лә, энҗедән ким кай төше?

Бу татар шагыйрьләрен мөмкиндер артка калдыру,
Алга сөрсен гашыйкый анчак мәхәббәт камчысы.

Һич хуҗалыкны кабул итмәм бөтен дөньяга мин,
Булмага мөмкин икән гыйшык, мәхәббәт ялчысы.

Әмма ләззәтле дә соң яшьрен газап, яшьрен яну! –
Бар микән, белмим, моның миннән бүтән аңлаучысы?

Барча әхраре мәхәббәт миннән уңда, зан итәм, –
Кайда Фәрһад берлә Мәҗнүн! – мин аларның таңчысы!

### Төлке һәм йөзем җимеше

(Крыловтан)

Ниһаять карыны ачкач, Төлке дуст бер бакчага керде;
Ул анда өлгереп җиткән йөзем җимешләрен күрде.

Йөземнәр күңгә каршы ялтырыйлар ләгыль, якуттай;
Боларга хәйләкәр ач Төлкенең күзләр яна уттай.

Йөземнәрне ашарга үрелә, сикергәләп карый;
Күрә күз, җитмидер буй, – ул тәмам хәлдән төшеп арый.

Озак михнәтләнеп, калгач йөземнәрне алалмыйча,
Алалмау хурлыгын үз өстенә йөкләп калалмыйча:

«Йөземнәр чи, әле өлгермәгәннәр, пешмәгәннәр, – ди. –
Бозарсың ашказаныңны, килешми эчкә анлар!» – ди.

## Бәйрәм бүген

Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.
Нәрсәдән бу? – Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!1

Бер мөкаддәс хис белән һәрбер кеше хәйран бүген;
Уйный сазым да минем бәйрәм көен, бәйрәм бүген!

Арттыра, күрдем, кояш гадәттәгедән балкуын;
Ул киенгәндер, дидем: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Хис итеп һәр җирдә дә бертөрле хуш ис аңкуын:
Ислемай сөрткән икән дөнья! Дидем: бәйрәм бүген!

Бер теләнчене кочаклашкан күреп бер бай белән:
Күңле нечкәргән! Дидем: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Яр башыннан тыңладым мин бер суның дулкыннарын;
Сөйләшәләр үзара: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Тыңладым әкрен генә искәндә бәйрәм көн җилен;
Ансы да сөйли тагын: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

## Печән базары1, яхуд яңа кисекбаш

### I

Башлыйк әле сүзне Карәхмәт илә,
Яд итәрләр, кем белә, рәхмәт илә.

Алдымызда ат кәмитен күрәлем
Һәм Микитин җәмгатенә2 ирәлем.

Бу Казанда хуп-хуп эшләр күп торыр,
Һич моның тик бери тәкый юк торыр.

Хак тәгалә нәрсә кыйлса ирке бар,
Рус Микитиннең Казанда циркы бар.

Шунда бардыр бер мөселман пәһлеван3 –
Бик озын, бик көчле, гайрәтле җиван.

Шәп батыр: Зәркум кеби, Салсал кеби;
Хәйләгә оста, Сәет-Баттал кеби4.

Бер хикәят килде телемгә арый,
Яхшылап сөйләп биреп булса ярый.

Таңга калсын тиречеләр, итчеләр,
Шәмчеләр дә майчылар, кибетчеләр.

Берзаман бардым Печән базарына, –
Шунда мин таптым азык язарыма.

Иртә берлән кайнамакта бу базар,
Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр.

Кайсысы сатмактадыр, кайсы ала,
Берсе алдый, шунда берсе алдана.

Һәр заманны монда хәлләр шул икән,
Һәркем үз хәле белән мәшгуль икән.

Йөгрешәләр сөртенә дә абына
Барча мөэминнәр «Көфер почмагы»на5.
Нинди эш булган соң анда, нәрсә бар?
Бер сугыш чыкканмы әллә, йә пожар?..

Мин дә чаптым шунда мөэминнәр белән.
Мәскәүски якка6 күз салсам күрәм:

Тәгәрәп юл уртасыннан таш килә,
Таш түгел лә – бер киселгән Баш килә.

Баш килә шундый каты, шундый кызып,
Полный ход килгән трамвайдан узып.

Һәр тараф тулган караучы – юк саны;
Баш «Көфер чаты»на җиткәч туктады.

Күрделәр бер кисек адәм башыны;
Агълаю килде дә түкте яшене.

Гәүдәсе юк бер гаҗәеп Баш ирер;
Шәһит ирер, ике күзе яшь ирер.

Юк аягы, гәүдәсе һәм юк кулы, –
Бер кисек баштыр, һаман сөйләр теле.

Сакалы ак, һәм йөзеннән нур чыкар,
Күз камашыр – һәркем йөзенә бакар.

Йөзен орды туфракка, кыйлды зари,
Зари-зари егълады шәмче Гали.

Башны күргәч, ихтыярсыз җан ачый:
Әй җаным, бу кайсы мескиннең башый?

Агълыйдыр һәркем, күзеннән яшь сыгып,
Агълый, кибеттән кәләпүшләр чыгып.

Һәм аяк астында яткан тиреләр
Барча: «Ай мескин» дә «ай мескин!» – диләр.

Шунда тау-тау торган он капчыклары,
Агълыйлар саилче кыз, карчыклары.

Агъламаска – бер мөселман башы бу,
Һәр мөселман бәндәнең җанашы бу.

Агълый Кисекбаш, моңын-зарын сөйли,
Аксакаллар: «Нәрсә булды?» – дип сорый.

Кызганычлы бер кыяфәт, яшьле күз
Берлә мескин Баш болай дип башлый сүз:

«Баштан үткәнне сөйлимен, тыңлагыз,
Мин хаҗи – бардым хаҗә туксан тугыз.

Күп тәваф иттем Хиҗаз сәхрасыни,
Җиддәсен һәм Мәккәсен, Сангасыни7.

Мин гласныйлыкта тормышдым янә
Бу шәһәрнең Думасында ун сәнә.

Һәм дә Мәскәүдән дә маллар алмышым,
Сумына туксан тиенне чәлмешем.

Итә ирдем көн дә бер Коръән хәтем*,

Алмышым гомремдә унбишләп хатын.

Кич барыр ирдем «Тәтәйләр рәте»нә8,
Әүрелеп көндез кеше сурәтенә.

Бар иде картлыкта алган хатыным,
Бер балам, – аһ, күз нурым! аһ, алтыным!

Карт көнемдә бунлар иптәшләр иде,
Яхшы юлдашлар вә сердәшләр иде.

Тартып алды бунларый миннән Дию,
Сезгә важибтыр миңа ярдәм кыйлу.

Анларый алды да керде коега,
Кайгы куймый күзләремне уйкуга.

Кыйлмасаңыз сез миңа ярдәм әгәр,
Сезгә миннән яүме мәхшәр дәгъва бар!»

II

Шунда картлар җәмгулыб киңәштеләр:
«Нишлибез соң? Агълап, эш булмас!» – диләр.

Кайсы әйтә: «Патшадан солдат сорыйк,
Ул Диюне9 җәдрә берлән аттырыйк».

Кайсы әйтә: «Садри Максуди10 барыр,
Мәсьәләне, бәлки, Мәҗлескә салыр.

Без аның чөн күп тырыштык шар салып,
Ахырында Думага да сайладык».

Кайсы әйтә: «Камчылы ишан11 барыр,
Ул Диюнең, бәлки, сихерен кайтарыр».

Уртадан бер күп белекле карт кеше
Әйтә: «Бу хакта минем фикрем шушы:

Тыңлаңыз, бу – тик Карәхмәтнең эше;
Инде ул, – мәгълүмеңез, көчле кеше.

Ул барып алсын Диюнең җаны,

Кайтарыр ул бу Кисекбаш каныны».

Барча картлар: «Яхшы бу, яхшы!» – диләр.
«Вәт менә рәхмәт! Бабай тапты», – диләр.

Бу бабай фикрен туры итсен Хода!
Итте бер мөэмин кеше шунда нида:

«Миңлебай! Бар, тиз, Карәхмәтне чакыр!» –
Чапты китте Миңлебай чатыр-чатыр.

Үтмәгәндер күз ачып йомган заман,
Килде дә җитте Карәхмәт – каһреман.
Эстәде Башны күтәреп бакмага:
Гайрәтен вә куәтен күрсәтмәгә.

Ничә кем зур әйләде – күтәрмәде,
Зәррә мыскал җиреннән тибрәтмәде.

Һич күтәралмый аны, хәйран кала;
Көчләнә, тирли батыр, хәлдән тая.

Ул Баш әйтә: «Бу Карәхмәт шаштымы?
Ул күтәрерлек җиңел бер башмы бу?

Бер түгел, меңләп Карәхмәт килсә дә,
Хәтта Зайкин, Медведев12 бер булса да,

Һич насыйп булмас аларга кузгату,
Файдасыздыр кузгатырга күз ату.

Чикмәсен бушка газапны – булмый да,
Чөнки бар мең пот тәгассыб бу мидә.

Бу мидә йөзләп гыйнад амбары бар,
Бу мидә мең пот сыраның пары бар.

Бу мидә бардыр җәһаләт ун вагон,
«Мин беләмлек» дәгъвасы – бер мең вагон.

«Иске – изге» фикре бардыр ун келәт,
«Һәр җәдит – кяфер» – егерме склад...»

III

Хазирун: «Аһ, нинди изге баш!» – диләр,
«Тик янә урнына ябышмас», – диләр.

Инде мөэминнәр каты кызгандылар,
Чын күңелдән Баш өчен сызландылар.
Һәм үрә торды батырның чәчләре,
Газбилә аузыннан утлар чәчрәде:

«Мин, – диде, – дөньяда тормыйм, ичмасам,
Шул Дию-залим башыны кисмәсәм.

Бармыймын хәтта Микитин циркына,
Шул Дию башына күңлем җилкенә.

Шунсыз инде бер дә рәхәт күрмәмен,
Һәм Пугач-Зайкин рәтенә кермәмен.

Йә үләм мин, йә шуның муйнын кисәм
Хак гыйнайәт әйләр ирсә*, мин басам».

Бар халык та: «Бар, Карәхмәт, бар», – диләр,
«Бу Кисекбаш хатынын коткар», – диләр.

«Бармыйлармы? Мин барам, әлбәт, барам,
Бармасам, дөнья йөзе булсын хәрам!..»

Бу гаһедтән соңра Башның күзләре
Яктырып китте – ачылды йөзләре.

Ул Баш әйтә: «Әй батыр, рәхмәт сиңа,
Йөкләдем мин бик авыр зәхмәт сиңа,

Барча иркеңнән вә циркыңнан җөда
Булдың инде, бәс сиңа миннән дога.

Әйдәгез, әй әһле базар, берьюлы
Фатиха: уңсын Карәхмәтнең юлы!»

Шулвакыт куллар белән тулды сәма,
Чын күңел берлән кыйла һәркем дога:

«И Ходаем, бир Карәхмәткә мәдәт,

Ушбу юлда бир аңар көч һәм сәләт!»
Берзаман куллар салындылар төшеп –
Күрделәр: килде трамвай җитешеп.

Пәһлеван вагонга җирләште кереп,
Алды «пересадка» берлән бер билет.

Барча мөэминнәр озатып калдылар:
«И Ходаем, рәхмәтеңне сал!» – диләр.

Кузгалып китте вагон, җилдәй бара,
Баш йомарланып китә, җирдән бара.

Башны күргәч, кузгалып гайрәтләре,
Өрде барча итчеләрнең этләре.

Йөгерәләр алды-артлы бер көтү
Кәкре койрыклар! – кая Башны җитү!

Ул барадыр йөгрек аттан да каты
Һәм җәядән аткан уктан да каты.

Үз хәленчә китмәдә тыр-тыр вагон,
Таш ата башка малайлар яльгабун.

Калды уң якта «Китаплар ханәсе»,
Сулда – «Әлислах» идарәханәсе[13].

Бер сәгать, бер көн вә өч көн киттеләр, –
Зур завод Крестовниковны үттеләр[14].

Җиде көне, төне чөнки киттеләр,
Нагяһан бер сахрая ирештеләр.

Шунда җиткәчтен, трамвай туктады,
Баш йомарланып барадыр туктамый.

Туктагач шунда сихерле машина:
«Нишлибез?» – диде Карәхмәт Башына.

Ул Баш әйтә: «Син вагоннан төш хәзер,
Бик якынлашты кирәкле төш хәзер.
Без барыйк азрак җәяү алга табан;
Иштә бу алдыңдагы күлдер – Кабан[15].

Бар дорыр күлнең төбендә бер кое,
Шунда керде ул теге залим Дию!»

IV

Сүз рәте килгәч итәм әзрәк бәян,
Таки яшьрен күл төбе булсын гаян.

Анда һәртөрле гаҗәпләр бар да бар:
Кып-кызыл алтын шәһәр, җиз карьяләр;

Мөгезе мәрмәр боланнармы кирәк,
Алты йөз башлы еланнармы кирәк.

Су анасы, – бик явыз, йөзе кара[16], –
Ел да бер угъланны йә кызны ала.

Шул заман, кем, килде Мәскәү гаскәре,
Бу Казанга туп атарга башлады.

Шул вакыт ханнар, вәзирләр качтылар,
Барча малны ушбу күлгә сачтылар.

Сачтылар алтын-көмешнең һәммәсен,
Ягъни «безнең мал кешегә калмасын».

Шул заманнан бирле, кем, алтын-көмеш
Күл төбендә һич хисапсыз күп, имеш.

«Бер заманда, шөбһәсез, бу күл кибәр»,
Дип гакыллы зур хәкимнәр сөйлиләр.

Киптисә, бер дәфга кузгалып бары –
Күл буеның мәдрәсә талибләре [17]

Барча байлыкны җыячаклар имеш,
Һич һөнәрсез бай булачаклар имеш.

Ел ел артыннан һаман үтмәктәдер,
Күл буе талибләре көтмәктәдер...

V

Әйдә максудка! Алар көтсен әле,
Сүз Кисекбашка килеп җитсен әле.

Ул Карәхмәтнең билендә бавы бар;
Бауның алты мең колачлы буе бар.

Бау белән ул эшне яхшы җайлады:
Бер очын Башның теленә бәйләде.

Бер очын учлап, Кабанга чумды ул,
Туп-туры шуннан коега тотты юл.

Ул төшә, бер көн төшә, өч көн төшә;
Туктамый инмәктәдер көндез-кичә.

Бер – аягы әйләнәдер, бер – башы,
Һәр минут, һәрдәм Хозырдыр юлдашы.

Ул инә, Алла сүзен тәкрар кыйла,
Тышта агълыйдыр Кисекбаш, кайгыра.

Нәкъ төшеп киткәнгә ун тәүлек тула, –
Ахры, җиргә аяклары төртелә.

Пәһлеван, гаять арып, эштән чыгып,
Ун минут торды катып, гакълын җыеп.

Бервакыт безнең батыр ачты күзен:
Бер сарай алдындадыр күрде үзен.

Шундый яхшыдыр ки, һич мондый сарай
Салмагандыр Кәчимеский Ибырай[18].

Капка башында яшел ләүхә тора;
Анда иштә ушбу сүзләр укыла:

«Монда сакин бужи фирка[19] җания,
Табигыйннәр мәзһәбе Гайнания».

Тартты, куптарды Карәхмәт капканы,
Соңра тиз-тиз элгәрегә атлады.

Керде дә күрде: сарайда бер хатын –
Җәлбитәрлек һәр кешенең дикъкатен.

Йөз нуры дүрт якны әнвәр әйләгән,
Тәңренең гыйшкы аңар кяр әйләгән.

Намаз укыр ул ахирәт хатыны,
Аһ итәр – күккә чыгадыр төтене.

Күз яше сәҗдә җирене болгамыш;
Ул Кисекбашның хәлале бу имеш.

Үтте аннан, китте башка бүлмәгә,
Шундый күренеш – кызганычтыр күрмәгә:

Анда биш йөзләп мөселманнар тулы,
Багълыдыр һәрберсенең аяк-кулы.

«Алла, Алла! Саклый күр утдин!» – диләр,
«Кыйл шәфәгать, йа Баһаветдин!»20 – диләр.

Сикерәләр, җенләнәләр үзләре,
Һәм акайган кот очарлык күзләре.

Чөн болар һәп пәһлеванны күрделәр;
Бер авыздан бөйлә фөрьяд кыйлдылар:

«Мәрхәмәт ит, и Карәхмәт, безгә син;
Безне коткар, из Диюнең измәсен.

Һәр минут үткән саен, без куркуда:
Бу Дию һәр көн бишәр адәм суя.
Күп идек без былтыр, үткән көз генә,
Инде калды барчабыз биш йөз генә».

Шунда бер бүлмә күренде – шактый киң;
Күрде батыр: шунда яткан ул ләгыйнь.

Биниһая зур башы – гөмбәз кадәр;
Ни сәбәптәндер башында фәс тә бар.

Салынып төшкән килешсез мыегы –
Бик озындыр, мисле күсе койрыгы.

Бармаклары охшар адәм гәүдәсе, –
Күп татарны имгән ирде ул гасый.

Билгеле инде, Карәхмәт курыкмады;
Ул аны «тор! тор!» диюбән төрткәли.

Нәгърәләр берлән Диюне уйгата;
Һич уянмый уйкусыннан, ул ята.

Төрткәли торгач, ниһаять, уйгана,
Куркынычлы күзләре уттай яна.

Ул Дию уйганды: дүрт якка бакар,
Көфер сүзләр, агъзыйдин утлар сачар:

«Ник йөрисең монда рөхсәтсез кереп,
Һич оялмый тәмле уйкум боздырып?

Белмисең, махсус колониям бар минем,
Мәхкәмәм бар, автономиям бар минем.

Куркъмадың, монда ничек кердең кыеп?
Бар икән йөргән кеше, җаннан туеп!»

Язмыймын сугыш нә рәсмә булганын,
Кайсысы җиңгәнен йә җиңелгәнен.

Гөрзи төшкәч, кайсы билдән батканын,
Кайсысының маңгаеннан батканын.

Кариэм, иткел канәгать барына,
Итмәсәң – әйдә Печән базарына.

## VI

Иртә берлән кайнамакта ул базар,
Анда да монда кызадыр сәүдәләр.

Кызса да гадәттәгечә сәүдәләр,
Әллә ник бүген күңелсездер базар.

Һәр мөселман әллә нигә кайгылы,
Нәрсәгә хәмлитмәгә бу кайгыны?

Юк, аларга кайгырырга юл да бар:
Нәкъ бер айдыр – юк Кисекбаштан хәбәр.

Җәмгулыб өч-дүрт кеше һәр чат саен,
Гәпләшеп кайгырталар Башның хәлен:

Ягъни ул мескингә ни булган икән?
Ике якның кайсысы җиңгән икән?

Әһле ислам шул рәвешчә, яхзәнүн...
Күренә шул хәл ерактан, ах, вагон!

Нәрсә булган? Нинди хикмәт, кем белә? –
Ташбака төсле, вагон әкрен килә.

Өч сәгать үтте күренгәндин бире,
Юк әле асла якынлашкан җире.

«Ник болай бу?» – дип гаҗәпләнгән базар,
Әйләмәктә пассажирлар интизар.

## VII

Тын гына торган вакытта шул рәвеш,
Килде ямьсез, куркынычлы бер тавыш.

Бик каты күк күкрәгән төсле була,
Җир ярылган, тетрәгән төсле була.

Бер – арысланнар акыргандай була,
Бер – көтү ишәк бакыргандай була.

Күз ачырмаслык чыгып комлы буран,
Басты золмәт җир йөзене шул заман.

Һәр тараф золмәт, күренмидер кояш,
Куркуга төште кешеләр – карт вә яшь.

Һич кеше белми: ни хикмәт бу, ни бу?
Әллә чынлап та кыямәт көнме бу?

Әллә бер «койрыклы йолдыз» төштеме?
Әллә Тәңре сур өрергә куштымы?

Дөньяга соңгы минутлар килдеме?
Әллә Ханның мәсҗеде җимрелдеме?[21]

Әллә тәүбә капкасы ябылдымы?
Әллә бер бай корсагы ярылдымы?

Ташпулатлар җөмлә дер-дер селкенә...
Каршылык юктыр Ходайның иркенә.

Әрҗәдә читек-кәвешләр кузгала,
Һәм өеп куйган кәләпүшләр ава.

Танымый дуст дустны, кардәш кардәшен,
Һәр кеше куркып укый «ләхәүлә»сен.

Ни бәла килде Казанның халкына?
Очрадылармы Ходайның каһренә?

VIII

Бәс, шу рәсмә куркышып торган заман
Чыкты аңсыздан кояш, китте тузан.

Күрделәр: җитте килеп мәгълүм вагон,
Тагылып артында бернәрсә тагын.

Ни күрәләр: өнме, ялган төшме бу? –
Тагылып килгән теге фәсле Дию.

И дулый! Мәлгунь Дию, и тартыла!
Акыра ямьсез каты – җир селкенә.

Бите-башы канланып беткән янә;
Әйләнәсендә Кисекбаш әйләнә...

Сөйрәлеп җирдән Дию килгән икән,
Һәм вагон шуннан озак торган икән.

Бу Диюдән ул буран купкан икән,
Куркытучы шул Ходай суккан икән.

Инде һәркем күңленә шатлык тула,
Ул Кисекбаш елмаеп көлгән була.

Шул минут чыкты вагоннан пәһлеван,
Күтәреп башыны арыслан сыман.

Чөн Печән базары халкы күрделәр,
Барча күрешмәк өчен йөгерделәр.

Җөмлә бердән: «Әссәлам» дә «әссәлам!»
Һәм Карәхмәт: «Вәгаләйкем әссәлам!»

Һәр мөселман дәрт белән күккә оча:
Бер – Кисекбаш, бер Карәхмәтне коча.

Чыкты вагоннан тагын бер ир бала,
Бик чибәр – күргән кеше хәйран кала.
Чыкты тагын да чапанлы бер хатын,
Җәлбитәрлек тиречеләр дикъкатен.

Бер хаҗи шул хәл хатынга күз кыса
Һәм дә яп-яхшук оятсыз сүз куша.

Ул Кисекбаш күрде дә бу тәкъваны:
«Тимә хатынга!» – диеп, бармак яный.

«Белмәдем мин!» – дип, хаҗи зари кыйла,
Күзләреннән яшьләрен җари кыйла.

Шул вакытта Камчылы ишан килә;
Ул Кисекбашны тотубән өшкерә.

Күрделәр: Баш яшь егет булды янә,
Кул-аягы, гәүдәсе килде янә.

Бу кәрамәтне күзилә күрделәр,
Тәңрегә мең-мең шөкерләр кыйлдылар.

Ул Дию күздән югалды, юк булып,
Очты Яңа Бистә якка, ут булып.

Сез беләмсез: ул Кисекбаш әл дә бар;
Көн күрә яхшы гына, ул – сәүдәгәр.

Дин юлында күп газап күргән өчен,
Армый-талмый дин өчен йөргән өчен,

Пәһлеванга бирделәр алтын сәгать,
Чылбыры юк, белмимен, нидер сәбәп...

Фагыйләтен, фагыйләтен, фагыйләт,
Ну, Печән базары халкы күңле шат!

## «Кисекбаш»ка гыйлавә

Рәт-рәт итеп гаскәрен куйгач тезеп
Һәм дә җиткезгәч аякка торгызып,

Шунда сәргаскяр үзенчә бер горур
Берлә гаскәргә карап читтә торыр.

Бу «Кисекбаш»ны язып, мин дә шулай
Аз гына мәгърурланып тордым бугай.

Буш вакытта рәткә тезгән җырларым
Булса, сафланды, димен, гаскәрләрем.

Көлкеле чыкты: ярарлык ул ягы,
Әмма бик яхшы түгел гармун ягы.

Сарт китабыннан алынган үрнәге –
Нәзмы шуннан бик мөкәммәл булмады.

Монтазам булсынмыни соң гаскәрең,
Алгач үрнәккә Бохара гаскәрен!

## Ата илә бала

(Кара такта янында)

Яз, газиз угълым: кара тактаны сыз акбур белән!
Һәм кара күңлеңне ялт иттер сызып ак нур белән!

Өч наданга алмашынмас – бер язу белгән кеше;
Мәгърифәт эстәр, иренмәс һич – кеше булган кеше.

## Яхшы хәбәрләр

Язгы яңгыр тамчысы бер башка тамчыдан сорый
(Әллә белмичә сорый, әллә шаярыпмы юри):

«Ни сәбәп, уклар кеби, без берьюлы күктән төшеп,
Бу тәрәзәгә килеп тә бәреләбез шып та шып?»

Бу сөаленә җавапта иптәше әйтә моңар:
«Бу начар өйнең эчендә икмәге юк ярлы бар.

Җиткерәбез без аңар бер бик матур шатлык хәбәр –
Алдагы көзгә арыш, һич шөбһәсез, булыр чибәр».

## Таз

(Бер авыл малае авызыннан)

Мәдрәсәдә бар иде бер таз малай, –
Бик шаян, шуклык белән мөмтаз малай.

Бик тирән – башындагы каткан бүрек,
Бер дә салмый, булмый һич башын күреп.

Кайсы чакта бүркен алып ташлыйлар:
«Әй, кояш чыкты! Кояш чыкты!» – диләр.

Ул заман без барчамыз бик кечкенә,
Зурымызга яшь булыр унөч кенә.

Башчыбыз Таз, берзаман без уйнадык;
Һичберәү күрмәс әле дип уйладык.

Аһ, бәла! Безне казый күргән, имеш,
Уйнаганны ул карап торган, имеш.

Кәйфемезне бик тиз үк кыскартты ул, –
Безне шул чактук хөкемгә тартты ул.

Куркытып казыйга тезләндек хәзер,
Төрле юл котлырга эзләндек хәзер.

«Казый абзый! Безне син кызган», – димез;
«Һәр усаллык башы шул Таздан», – димез.

«И кизү! Бар, тиз китер, ул кайсы Таз?
Мин башын кашыймчы ул Тазның бераз».

Килде Таз. Без тик торабыз куркышып, –
Барчамыз бертөрле хәсрәткә төшеп.

Кушты казый: «Ят! Сузыл! И Таз пәри!
Тал чыбыктан сез котылмассыз әли!» –

Дип, казый безне дә куймый шелтәли;
Шул вакытта Тазга талны селтәде.
Бер-ике сукты казый, – бу нинди эш?
Бер дә чаж-чож итмидер суккан тавыш.

Нәрсәдер бар монда – бер алдау эше,
Иштеләдер каты нәрсә тавышы.

Нәрсә бар? Таз аркасында нәрсә бар?
Камзулын Тазның күтәреп баксалар:

Хәйлә иткән монда да ул Таз-явыз, –
Белмәгә мөмкин рәсемгә баксагыз1.

Казый абзый куйды шаркылдап көлеп,
Гайрәте сүнде, кызык эшне күреп.

Безне гафитте, сугалмый калды ул,
Тал чыбыкка яткыралмый калды шул!

## Су анасы

(Бер авыл малае авызыннан)

I

Җәй көне. Эссе һавада мин суда койнам, йөзәм;
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.

Шул рәвешчә бер сәгать ярым кадәрле уйнагач,
Инде шаять бер сәгатьсез тирләмәм, дип уйлагач,

Йөгереп чыктым судан, тиз-тиз киендем өс-башым;
Куркам үзем әллә нидән, – юк янымда юлдашым.

Бервакыт китәм дигәндә, төште күзем басмага;
Карасам: бер куркыныч хатын утырган басмада.

Көнгә каршы ялтырый кулындагы алтын тарак;
Шул тарак берлән утыра тузгыган сачен тарап.

Тын да алмыйча торам, куркып кына, тешне кысып,
Шунда яр буендагы куе агачларга посып.

Сачләрен үргәч тарап, сикерде төште суга ул;
Чумды да китте, тәмам юк булды күздән шунда ул.

Инде мин әкрен генә килдем дә кердем басмага;
Җен оныткан ахыры, – калган тарагы басмада.

Як-ягымда һич кеше дә юклыгын белдем дә мин;
Чаптым авылга, таракны тиз генә элдем дә мин.

Күрмимен алны вә артны, и чабам мин, и чабам;
Ашыгам, тирлим, пешәм һәм кып-кызу уттай янам.

Бер заманны әйләнеп баккан идем артка таба, –

Аһ, харап эш! – Су анасы да минем арттан чаба.

Кычкырадыр: «Качма! Качма! Тукта! Тукта, и карак!
Ник аласың син аны, – ул бит минем алтын тарак!»
Мин качамын – ул куадыр, ул куадыр – мин качам;
Шулкадәрле кыр тыныч, һичбер кеше юк ичмасам.

Шул рәвешчә чабышып җиттек авылга бервакыт,
Су анасыны куарга күтәрелде барча эт!

«Вау!» да «вау!» да, «һау!» да «һау!» –
бертуктамый этләр өрә;
Су анасы, куркып этләрдән, кирегә йөгерә.

Инде эш җайланды, куркудан тынычландым, дидем;
И явыз карчык! Тарагыңнан коры калдың, дидем.

Өйгә кайттым да: «Әни, алтын тарак таптым!» – дидем;
«Сусадым, ардым, әни, мин бик озак чаптым», – дидем.

Сөйләгәчтен кыйссаны, алды тарагымны әни;
Курка үзе алса да, – уйлый эченнән әллә ни...

II

Яхшы, хуш. Батты кояш. Йокларга яттым кич белән;
Өй эче тулган иде кичке һава, хуш ис белән.

Юрган астында йокыга китми ятам мин һаман;
«Шык» та «шык!» – кемдер тәрәзәгә чиертә берзаман.

Мин ятам рәхәт кенә, тормыйм да кузгалмыйм әле.
Бу тавышка сискәнеп торган йокысыннан әни:

– Ни кирәк? Кем бу? Кара төндә вакытсыз кем йөри?
Нәрсә бар соң төнлә берлән, и пычагым кергери!

– Су анасы мин, китер, кайда минем алтын тарак?
Бир! Бая көндез алып качты синең угълың, карак!

Төшкән айның шәүләсе, мин юрган астыннан карыйм;
Калтырыйм, куркам: «Ходай! – дим, –
инде мин кайда барыйм?»

Һич өзексез «шык»та «шык!» Безнең тәрәзәне кага;
Ул коточкыч сачләреннән чишмә төсле су ага.

Әнкәем алтын таракны, тиз генә эзләп табып
Атты да тышка, тизүк куйды тәрәзәне ябып.

Су анасыннан котылгачтын, тынычлангач, әни
И орышты, и орышты, и орышты соң мине!

Мин дә шуннан бирле андый эшкә кыймый башладым,
«Йә иясе юк!» – дип, әйберләргә тими башладым.

Алтын этәч *

I

Борын үткән заманнарда Мәмәт атлы Һират ханы
Олугъ данлыклы хан булган; җиһан халкы аны таный
Икән, ягъни бу дөньяда беренче патша дип саный.
Мәмәт хан чит халыклардан ала булган олугъ даный.

Сугышса, дер дә дер тетрәткән ул бу фани дөньяны;
Чыгарткан чит халык аузыннан ул күп аһ вә фәганы.
Бара торгач, усал эштән тәмам туйган моның җаны;
Сакалга ак та кергәч, ташлаган артына дөньяны.

Сугышмый башлаган һич; күңле кайткан хәл дә азлыктан;
Ходаи бер кешедәй тормаган бер дә намазлыктан.
Бер ай да үтмәгән, һәр якка ханның хәле фашланган –
Тирә-күрше халыкларга: «Һират ханы юашланган!»

Явызлар, серне белгәч, аңлагач ханга ни булганны,
Тотынганнар тынычсызларга һәр якъдин Мәмәт ханны.
Мәмәткә дәүләтенең чикләрен сакларга «чит»ләрдән,
Тыныч булмак өчен һәр дүрт тарафлардагы чикләрдән,

Тиеш булган хәзер сансыз-хисапсыз гаскәр асрарга.
Торалар каршы, дошманны куа – йокламый гаскәр дә.
Тырышалар, вәләкин барчасына өлгералмыйлар;
Тулы дүрт якта дошман – бер сәгать тә тик торалмыйлар.

Мәмәт хан гаскәре дошман көтеп торганда мәшрикътән,
Менә килеп чыгалар төн ягыннан яки мәгърибтән.
Мәмәт хан гаскәре көткәндә таудан йә тигез җирдән, –
Карыйлар: бихисап дошман килеп тә җитте диңгездән.

Бу хәлдән нинди рәхәт соң? – Хан аулакта елап куя,
Таҗын, тәхтен тәмам ташлап качарга да теләп куя.
Бөтенләй аптырап беткәч чакырды хан багучыны,
Мөнәҗҗим, фалчыны һәм дә хәким исемен тагучыны.
Хәкимгә: «И хәким! Мин бик авыр хәлләргә калдым! – ди,
Йә күрсәт хикмәтеңне, кыйлчы бер эш, кыйлчы ярдәм», – ди.
Хәким, бер капчык аузына кулын сала да сызганып,
Куя хан алдына шуннан гаҗәп Алтын әтәч алып.

Һәм әйтә: «Падишаһым! Син котылдың инде – бик яхшы;
Гомергә дәүләтеңдә бу Әтәч булыр сиңа сакчы;
Бу кошны миннән ал, хан, – мәсҗедең башына кунаклат!
Югартын син аңар һәр дүрт тарафны да карат, саклат!»

Мәснәви

«Булмаса курку сиңа – бу тик торыр;
Килсә дошман гаскәре – бу кычкырыр.

Булмаса дошман – кыйлыр шунда карар;
Булса, борлыр – куркыныч якка карар.

Бер тарафка бакса, дисә: кикрикү! –
Бу борылган якка син гаскәрне ку!»

Хәкимгә патша ни рәхмәт укырга аптырый инде;
«Сиңа нәрсә бирим, әйтче? Ни сорсаң да бирермен», – ди.
Кызулык берлән патша әйтәдер: «Синең теләгеңне
Мин эшләрмен тәвәкъкыфсез – бөтенләй үз теләгемдәй».

II

Ханның мәсҗеде башына бәс Алтын әтәче кунды;
Карый һәр якны: алны-артны, өстне-астны, уң-сулны.
Кагынмый һәм чыгармый тын да – һәр якны тыныч күрсә;
Уянгандай йокыдан, кагынадыр – куркыныч күрсә.

Бәла күргәч тә сайрый, кычкырадыр: «Кикрикүккүк!» – ди;
Әгәр китсә бәла, дәрхаль, торадыр тик кенә – туктый.
Әтәчнең шөһрәте һәр якка китте, инде фашланды;
Сугыштан тартты кулны чит халыклар да – юашланды.

Хәзер дошман кешеләргә Мәмәт ханга һөҗүм кайда! –
Әтәч бикли аларның юлларын алдан да, арттан да.
Үтә бер ел тынычлык берлә, үтмәктә икенче ел;

Аманлык һәр тарафта – исмидер һич куркынычлы җил.

Менә көннәрдә бер көн хан тора куркып йокысыннан;
Килә тавыш колагына: «Һәрап эш! Беттек, и солтан!»
«Ни булды? Нәрсә бар соң?» –
 дип сорый гаскәр башыннан хан.
«Әтәч кычкырды тагын да – килә бугай явыз дошман!»

Һират халкы тәмам куркыштылар, башланды шау-шу да;
Хатыннар, яшь балалар, карт бабайлар төште каушауга.
Ышанмый хан; торып хан, мәсҗеденә ул үзе карый;
Күрә: Алтын әтәч борган башыны көнчыгыш сарый.

Йөгер тиз! Әйдә башла, и җәяүле гаскәр, атларга!
Ашык! И атлы гаскәр, син дә тиз бул! Атлан атларга!
Шулай хан көнчыгышка бихисап гаскәр рәван кыйлды;
Олугъ угълын шуларга баш – беренче пәһлеван кыйлды.

Әтәч тә тынды, һәм әкрен генә тукталды шаулау да;
Тынычланган кеби булды йөрәкләнгән Мәмәт хан да.
Үтә бер көн, ике, өч, дүрт, үтә җиде, сигез көн дә;
Сугыш булганмы? Юкмы? – килми гаскәрдән хәбәр бер дә.

Хәбәр юк ханга. Бер көнне Әтәч тавышлана тагын;
Менә тиз-тиз икенче фирка гаскәр сафлана тагын.
Итә башлык бу гаскәргә Мәмәт хан кечкенә угълын:
«Бу гаскәр берлә абзаңны табып кайт, бар, җаным угълым!»

Үтә көннәр... Үтә әүвәлгесе төсле сигез көн дә;
Ике шаһзадәгә ни булганыннан чыкмыйдыр өн дә.
Һират халкы тагын шауларга башлады, тагын куркъты;
Әтәч тавышлана тагын да: «Кикрикүк» тә «күк!» «күк!» – ди.

Мәмәт инде өченче гаскәре берлә үзе китте
Туры мәшрикъ таба: «Тәңре, үзең ярдәм вә фазлит!» – ди.
Бара көн-төн, һаман ял итми, асла тынмыйдыр үзе;
Ни бар алда? Чыгармы бер-бер эш? – һич белмидер үзе.
Биш-алты көн бара; шаһзадәләр дә, гаскәре дә юк;
Түгелгән кан да юк һич; ичмасам, ат эзләре дә юк.
Менә сигезенче таң атканда, хан туктады бер тауга;
Җәелде гаскәр, атлар да – ничек бу җиргә туктауга.

Күренде хан күзенә тау башында бер кызыл чатыр –
Гаҗәп төсле матур, нинди күңелләрне дә кузгатыр.

Гаҗиб бик матур бер сахра; һава тын, җил дә юк бер дә;
Җиһан йоклый тавыш-тынсыз, бәрабәр – йоклыйдыр кыр да.

Бу нинди куркыныч! – Чатыр тирәсендә бөтен гаскәр
Үлеп ятыр булып тау-тау: кырылганнар, изелгәннәр.
Мәмәт хан, ашыгып, тиз-тиз чатырның алдына бара;
Ни күзләр берлә күрсен! Аһлар ормыйча чыдап кара:

Үлеп ятмыш ике шаһзадә, – бакый йортка күчкәннәр;
Бере күкрәгенә берсе кылычларын чәнечкәннәр.
Күрә шаһзадәләр атландыгы юрга җирәннәрне –
Йөриләр чүпләнеп әкрен генә канлы чирәмнәрне.

Җылый хан, кычкырып: «И җаннарым! И каһәрманнарым
Җаным сөйгән ике шаһзадәм, и рухым, рәваннарым!»
Хан артыннан җыларга башладылар җөмлә гаскәр дә;
Җылый һәрнәрсә, һәркем – җанлы-җансыз барчасы бергә.

Исеркәп ушбу хәлне, кычкырып егълый хәҗәрләр дә;
Салынды, башларын бөкте, иелделәр шәҗәрләр дә.
Шулай торганда, аңсыздан чатыр нурга тулып китте, –
Мәмәт хан каршысына бик матур бер кыз килеп чыкты.

Көлеп, як-якка айдай нур йөзеннән яктылык сачып,
Кочаклап алды ханны – бер фәрештәдәй канат ачып.
Тора хан кыз күзе алдында куркынган поши төсле,
Кояш алдында тын алмыйча каткан төн кошы төсле.

Хан алдында фида булды хәзер һәркем дә, һәрни дә;
Гашыйклыктан онытты ул үлек шаһзадәләрне дә.
Матур кыз ханны кулыннан тотып кергезде чатырга;
Җәюледер мамык мендәр, түшәкләр анда ятырга,
Тулы һәртөрле нигъмәт; ялтырыйдыр алтын өстәлләр;
Чәчәк атып торалар – төрле-төрле гөлләр үскәннәр.
Кытай кәсәләрендә ак, кызыл төсле шәрабләр бар;
Терел, эч тә күңел ач – анда һәр абелхәятлар бар.

Матур кыз берлә вакты бик матур кичә хәзер ханның;
Матур кыз кичә-көндез дә кирәгенә хәзер ханның.
Сыйлый кыз һәм сөя, һәртөрле назлар күрсәтә ханга;
Сихерләнгән, тәмам гашыйк булып беткән Мәмәт хан да.

Бу кыз берлә көлеп-уйнап тәмам атна кадәр торгач,
Күңел ачкач, зәвекъләнгәч вә күп рәхәт-сафа сөргәч,

Мәмәт хан кайта инде яшь бикә берлә Һиратына, –
Ияртеп гаскәрен, саф-саф тезеп һәр дүрт җиһатына.

Хәбәр итте Һиратка – алдан ук күп илчеләр чапты,
Ки ягъни: «Хан сәфәрдән бик сәламәт, сау-исән кайтты!»
Халык каршыга килгән – барчасы бергә җыелганнар;
Хатын-кызлар, балалар – җөмлә хан кайтышка килгәннәр.

Халык ханны сәламли; ханбикә баш селкә фәйтуннан;
Яланаяк малайлар йөгерәләр фәйтун артыннан.
Шулай барганда, аңсыздан Мәмәт хан бер кеше күрә, –
Тәгаҗҗеб берлә фәйтуннан торып карый аягүрә.

Карап күрсә: йөзе нурлы бер аппак бүрекле карт –
Җитен төсле сакалы ак, кыяфәтчә күрекле карт.
«Моны соң кайда күрдем?» – уйлый торгач, ахры белде:
«Исәнме, и хәким бабай, кулың бир, монда кил, кил», – ди.

Хәким, ханга килеп: «Җә, хан, исәпне без өзик инде,
Беләмсең вәгъдәбезне? Син онытсаң, мин онытмыйм», – ди.
«Олугъ хан, вәгъдә бирдең син: фәкыйранә теләгемне
Тәмам бирмәкче булдың бит – бөтенләй үз теләгеңдәй.

Шулаймы? Бәс шулай булса биреп җибәр миңа кызны,
Менә шул яшь бикәңне – ул йөзе ай, күзе йолдызны!»
Хәкимнең сүзләреннән хан ниһаять тә гаҗәпләнде;
«Ни сөйли карт пәри, бу әллә шашканмы гакылдан?» – ди.

«Ни булды, карт, сиңа? Син әллә җенләндең, саташтыңмы?
Әтәч бирдем дигәч тә, әллә син хәддеңнән аштыңмы?
Дөрест, мин вәгъдә бирдем һәм бирәм; әйтмим дә: «Кит, бар!» – дип,
Вәләкин син сора үлчәп, – минем вәгъдәмгә чик бар бит!

Кирәк булса, менә казнамнан ал пот-пот көмеш-алтын;
Сиңа булсын менә пар ат, көмеш көпчәкле бу фәйтун.
Күзең туйганчы һәртөрле читек-кәвеш, кызыл мал ал!
Кирәк булса – вәзир бул яки ярты ханлыгымны ал!»

«Миңа һичнәрсә бирмә, тик бу ай йөзле кызыңны бир!
Әгәр вәгъдәдә торсаң син, бу кыз – чулпан күзеңне бир!»
«Тфү! Чорт, карт пәри!» – диде, бөтенләй кызды инде хан;
Мыек, сачне, сакалны да үрә торгызды инде хан.

«Җитәр, күп шаулама, карт! Мин – Мәмәт ханмын! Беләмсең син?

Сиңа кыз нәрсәгә, һәм нишлисең ул кыз белән соң син?
Алайса, мин сиңа, карт, инде һичбер нәрсә бирмим, ди.
Югал күздән, икенче рәт сине алдымда күрмим, ди.

Тере чакта котыл да бак юлыңны – әйдә кач моннан!
Сөйләшсәң күп, күрерсең күрмәгәнеңне палачымнан!»
Хәким картым тагын булган иде азрак талашмакчы
Мәмәт хан берлә: ник син бирмисең, дип, тарткалашмакчы, –

Утыртты картка хан бер зур тимер чукмар белән башка, –
Егылды карт: теге дөньяга китте бер дә кайтмаска.
Һират шәһре шулук хәлдә давыллап, җилләнеп китте,
Кисәктән әллә нинди бер давыллы җил бәреп китте.

Менә шул хәлдә хан куркъты – төсе киткән, агарынган;
Көлә кыз «ха-ха-ха!» асла гөнаһтан куркъмаганыннан
Мәмәт ханның. Тәгаҗҗеб берлә хан тиз әйләнеп карый
Матур кызга, – эченнән куркъса да, ыспайланып карый.

Озакламый шәһәрнең капкасыннан керделәр инде,
(Котылдылар усал карттан, аны үлтерделәр инде.)
Менә Алтын әтәч аңсыздан урыннан очып төште
Дә дәрхаль кунды фәйтунга; куа хан: «көш!» тә «көш! көш!» – ди.

Әтәч «прых! прых!» итеп ханның башы түбәсенә кунды,
Канатын каккалап ифрат ачы тавышлә кычкырды.
Әтәч ханның башын гайрәтләнеп-гайрәтләнеп чукый;
Карап-карап халыкка, хан башыны «тук!» та «тук!» тукый.

«Ни булган бу Әтәчкә!» – дип, халыкның котлары очты,
Кисәктән хан егылды – фәйтуныннан капланып төште.
Егылгач, бер генә рәт «аһ» диде дә үлде дәрхаль хан;
Халыкта тын да юк һич, тик тора бер җирдә – шаккаткан.

Ә кыз шул хәл гомердә булмаган төсле гаиб булды;
Карыйлар: бу Әтәч кайда? – Әтәч тә бергә юк булды.
Бу ялган инде, әлбәттә, шулай да языла шул бу;
Сабыйлар күңеленә аз-аз уку дәрте сала шул бу.

Соңра

(Лермонтовтан үзгәртелгән)

Бер мәхәббәтнең газабын, михнәтен сизгән кеше,
Бер сөеп арган вә җөмлә нәрсәдән бизгән кеше –

Күңеле бозланган кешедер: һич тагын бер кат сөймәс,
Инде ул беркем өчен дә гамь йимәс һәм «аһ!» димәс.

Бетте әүвәлге очынмаклар – авыр ул гер кеби;
Һич әчелмәскә мәхәббәткә йомылган керпеги.

Сүзләре салмак аның – койган кеби кургаш белән!
Күзләре инде юешләнми аның күз яшь белән.

Һәрвакыт ул инде ялгызлык сөя, золмәт сөя;
Бер пәйгамбәр яки бер дәрвиш кеби – газләт сөя.

Файдасы юк төрле хиссият уты берлән янып,
Күңле калган көл-күмергә әйләнеп, хиссезләнеп.

Мисле шул: урман эчендә бер яшен суккан агач,
Бер хәятының суы коргач, юешлек булмагач, –

Инде ул мәңге тамыр җәймәс, ботакланмас тагын:
Бер янып сүнде – икенче кәррә ярмас яфрагын.

Нәрсәдән?

Нинди ис: һәрбер кеше борынын кысып тоткан бүген? –
Белмисезме? Мин беләм: әлбәт, «Чүкеч» чыккан бүген1.

Ник бүген атлар, сыерлар сөйләшәләр телләнеп? –
Шөбһә юктыр: нәфсе Байбурин нотык тоткан бүген2.

Туктамастан ник мыраулыйлар песиләр чормада? –
Бел ки, «Шура»га Бәшири борныны тыккан бүген3.

Ни сәбәптән өрмиләр этләр, тынычланган җиһан? –
Боснияне йотканда, Австрия тончыккан бүген4.

Ник бүген барча бозау Коръән үбә, Коръән ялый? –
Хәзрәти шаһ, бел ки, биш-алты йәмин йоткан бүген[5].

Нигә тулган чалмалы козгын зиярәт өстенә? –
Бер сыраның мичкәсе, бел, боз булып каткан бүген.

Һәр кибетләрдә товарлар ник гәзиткә чорнала? [6] –
Бел: «Бәянелхак»ны бабай бер вагон саткан бүген[7].

Нигә пивнойда татарларның авыз-борны каный? –
Бел дә тор син: изге Корбан бәйрәме җиткән бүген[8].

Фәләннең фәләне

Татарның – тәгассыбы,
Урысның – аракысы,
Французның – кокеткасы,
Сартның – бәтчәсе,
Төрекнең – тәмәкесе[1],
Итальянның – җырлавы,
Немецның – пивосы,
Кыргызның – кымызы,
Испануляның – үгезе[2],
«Болгар»ның – күсесе[3],
Тимершаһның – «Чүкеч»е[4],
Яһүдинең – алдавы,
Кара гәзитәләрнең шуннан башканы язалмавы[5],
Чинленең – чәче,
Яңа Бистәнең – кәҗәсе,
Башкортның – курае,
Гурко-Литвалның – бодае[6],
«Сабах»ның – сабыны[7],
Мөхәммәдгали шаһның – йәмине[8],
Атлы казакның – камчысы,
Печән базарының – шакшысы[9],
«Сарай»ның – сасысы[10].

Мәрхүм Мөхәммәдзаһир[1] әфәндегә

Шадыман ул мәркадеңдә! – Без онытмыйбыз сине;
Белмәсәк вактында кадрең, инде котлыйбыз сине:

Яктылыкка иң элек атлау вә эз салу белән,

Гаибебезгә туп-туры дустанә күз салу белән.

Гәрчә «үлде» дисәләр дә, син бөтенләй үлмәдең;
Яхшы исмең калды, син мәнси вә мәтрүк улмадың.

Аһ! Синең газмеңдә бәхтең каршы тормый бирсә юл,
«Яшь егет! Күрсәт эшең, манигъ түгелмен», – дирсә ул; –

Иртәрәк милләтне сәүкъ әйләр идең чын эзгә син!
Нинди гали, нинди зур эш эшләр идең безгә син!

Шунда да исмең синең милләт яшәдекчә яшәр,
Милләт үсдекчә үсәр һәм милләт ашдыкча ашар!

Милләтчеләр

Татар халкы! Син үләргә мәхкүм инде,
Дару үтмәс дәрәҗәдә мәсмүм инде;
Тиберченмә! Терелмисең, юл өстендә
Ятма аунап, үзеңне үзең күм инде.

Милләтчеләр сине фәкать алдый гына,
Дигән булып: «Җанланасың син тиз менә».
Алданма син! Калган акчаң өчен алар
Укыйлар ич баш очыңда ясин генә!

Лябед сиңа терлер өчен корбан кирәк,
Җитми мыр-мыр хәтем – чын, саф Коръән кирәк;
Көймә бата; йота торган балык өчен
Фида булган мөрәүвәтле бер җан кирәк1.

Милләтче бик куркак бит ул, судан курка,
Гәрчә «милләт» диеп авыз суын корта.
Кайсы чакта күперсә дә, тиз шиңә бит
Тege – ишек алдындагы ата күркә.

Алданмыйча, газиз башың кабергә керт,
Милләтчеләр барчасы да – эшсез шәкерт;
Алар өчен барыбер: син теләсәң бет!
Алданма син: шәкерт алар, шәкерт! Шәкерт!

Дөрест сүз бу, монда шик-шөбһә кемгә бар?
Тугъры сүзне нинди файда кәтемдә бар?
Күрерсең син шәкертләрнең сәдакатен:

Бер бай үләргә ятканда, хәтемгә бар.

«Милләт!» диләр, – ул чынмыни? Ихласмыни?
Үз корсагын шәкерт алда тотмасмыни!
Әллә ничек рәхмәт берлә җанлансаң да,
Алар сине тагын сугып екъмасмыни?
Биһүдәдер! – сорыкорттан көтмәк гыйлаҗ,
Син бер гали, сатылмаслык иргә мохтаҗ;
Хак Тәңренең каршысында килешмидер
Тәһарәтсез намаз илә корбансыз хаҗ!

Вак-төяк

(Пушкиннән)

Бу дөньяда, табигыйдер, кеше буш булмый дошманнан;
Шулай ансы; вәләкин, и Ходаем, сакла дустлардан!

Төрекчәдән

Кайсы тир кем тирләсә – җанкәм яңагыннан чыга,
Сәлсәбил1 шул инде, бел: фирдәүси багыннан чыга.

«Ник ошатасың аны оҗмахка, син – кяфер!» диләр, –
Бер колагымнан керә дә бер колагымнан чыга.

* * *

Сөю шигъре – агач аттыр «Вакыт»ча;
Зарар юк, ул сөйләр анчак вакытча.

* * *

Яшь бала ул нәрсә белсен – бер тиенгә ат ала;
Нәкъ шулай безнең Шәһид1 – тәҗвид2 язып шөһрәт ала.

Булмаса

Кем белер кадреңне, җаным, дәртле күңел булмаса?
Наз итәр кемнәргә гөл – каршында былбыл булмаса?

Сурәтеңнең иң чыны, бел: шагыйрең күңлендәдер;
Күзгеләрдән чын төсеңне күрмисең – ул булмаса.

Бирмәде Ләйлә кеби мәхбүбәгә дөнья бәһа;
Ул болай бер кыз гына – каршында Мәҗнүн булмаса.

Һич килештермим синең төсле гүзәллек шаһына,
Ичмасам, бер хисле шагыйрь дә килеп кол булмаса.

…гә

(Ядкяр)

Шагыйрем! Кодсиятең булсын синең күңлеңдә сер;
Дөньядан шагыйрь икәнеңне яшер, дустым, яшер.

Белмәсеннәр – кайсы җирдән агыла бу кодрәтең;
Син, ләтыйф тәннәр кеби, күрсәтмәгел чын сурәтең.

Һәрвакыт, һәр җирдә син башка киемнәргә төрен:
Йә җүләр бул, йә мәзахчы бер кеше төсле күрен.

Бирмә сер һичкемгә: сөйләшсәң сөйләш өстән генә;
Көл – караңгы йөз бирү анчак килешмәстән генә.

Читкә бор – сүз килсә каршыңда шигырьләр бабына;
Иптәшең шагыйрь генә бассын аяк михрабыңа.

Итмә үз тормышны; тап башка җиһан, башка хәят;
Дөньяның буш шау-шуы шагыйрьгә чит, шагыйрьгә ят.

Кем генә булсаң да бул – юк ансына һичбер сүзем;
Тик сүзем шулдыр сиңа: саклан булудан үз-үзең!

Бел: килешмидер сиңа бу вак мәгыйшәт, вак тормыш;
Чөнки мәңгегә очалмас, йортта күп асралса кош.

Фәйзы бакый – таҗе шагыйрь* мәңгегә булмас сиңа,
Ваксынып, син төшсәң алтын шылтыравы астына.

Баш имә – зур син – бу әдна җанлылар дөньясына;
Падишаһ син! Бик кирәксә, баш исен дөнья сиңа.

Таш йөрәкләр кырсалар күңлеңне – түз, эндәшмә син;
Эшләре шул: болгасыннар, әйдә, зәмзәм чишмәсен!1

Тукайга нисбәт ителгән шигырьләр

(1901–1907)

* * *

Укыгыз, кызлар, укыгыз!
Күп хәлләрне белегез!
Остабикәләрне ташлап,
Мәктәпләргә керегез!

Муллалар, сезне укытмыйча,
Сезнең үзәккә үтәләр;
Мәдрәсәдә яшь егетләр
Сездәй кызны көтәләр.

Конфет ашаган акчагыз
Үз яныгызга калсын;
Инлек-кершән акчалары
Ваклап җыела барсын.

Шулай ваклап җыйсагыз да,
Бер кесә алтын тулыр;
Тамчы-тамчы тамган судан
Тирән диңгезләр булыр.

* * *

Мөгаллим Нурый
Зур чалма урый, –
Халыкка тугъры
Күрнә, дустларым,

Мөгаллим надан –
Укымый калган;
Укыта ялган, –
Аңла, дустларым.

Нурый да тугъры –
Кыйшык торбадан
Төтеннәр тугъры
Чыкса, дустларым.

Ватык та тишек
Тәрәзә-ишек;
Хәлфәсе – кыйшык
Авыз, дустларым.

* * *

Туйга бардым мин бүген: эчтем кымыз;
Кеше бик күп – бүлмәбез булды тыгыз.
Күп эчелгән – шартлый язды корсагым;
Һич үкенмим, андый туй булмас тагын.

Итчеләр, тиречеләр бик күп иде,
Ит исе, тире исе аңкый иде.
Таз Сабир, Сучы Шакир, Күктәк Галим
Чакырылган, Мөрсәлим һәм Мөстәкыйм.

Бар да сөйли кайда нәрсә алганын,
Бу базарда күпме табыш калганын.

Шул кадәр туйдым тире, ит исенә, –
Валлаһигазим, икенче бармамын!

* * *

Сәнгә хезмәтдер мәрамем язмадан журналымый;
Аңлайуб, дикъкать илә, җаным! укыгыл сән буный.

Хәзерге әдәби телдә

* * *

Сиңа хезмәттер максатым язудан журналымны;
Төшенеп, дикъкать белән, җаным, укычы син моны.

Мә, мә, мә!

Мал вә гыйззәт, мәгърифәт,
Хикмәт вә хөрмәт кирәкмә?
Мә, мә, мә!
Һәммәсе булсын синеңчә –
Мә, мә, Зәйтүнә, мә!

* * *

Безнең әти аягында җыермалы ал читек;
Кычкырма, күке, моңайтып, – безнең күңелләр китек.

Без барасы жулларның ике чите – канаулы;
Без моңаймый, кем моңайсын – калган гомер санаулы.

Шигрин читек, шигрин итек кимә көн дә – керләнә;
Җаныең җатка кала, дигәч, күңелләрем төрләнә.

Кычкырма, күке, каршымда, кычкыр агач башында;
Моңлы бала түгел идем, моңнар төштич башыма.

Менәр идем – тау биек, төшәр идем – жул кыек;
Җыен туган арасында минем күңелем боек...

Һавадин очкан аккошның аузы тулы балавыз;
Хәер-догадин ташламаңыз – кулгызда үскән балагыз.

Кулымдагы кулҗаулыгым дүрт почмагы өй хәтле;
Без җыламый кем җыласын – калган гомер исәпле.

Каләмфер күк кара сачең майлап тарап, үреп сал;
Аерылам, җаный, кил инде – бәхилләшеп үбеп кал.

Күк күгәрчен – күлләрдә, ак күгәрчен – сайларда;
Сагыну түгел, саргаерсың – җиләк пешкән айларда.

* * *

Әй җанашым, Гаделбану!
Кайда миңа сезне алу!

Әйтәсем килә

Мөсадиф улса татарка – качар, йөзен каплар да;
Миңа ул күрсәтер артын, – йөгерер, тиз-тиз атлар да.

Минем шул хәлдә күңлемнән болай дип әйтәсем килә:
– Миңа күрсәтмә сән артың, чөн артың кадре сартларда.

Килешмәс безгә бу эш: бән – татармын, сән дә – татарка;
Юлыңда гизмәли сәрбәст вә җанаш улма сартларга.

Бырак чапаныңый – хурлыкка салма кәндү кәндүзең, –
Бохарилар чапани хас дорур капларга атларга*.

Бохарилар пылау дамлар вә яхуд бәтчәләр дамлар**;
Аларда илтифат итмәс матур кызларга картлар да.

Хатыннар әйләнер артын, ки ягъни бәтчә зан итсен
Дә зәүҗе сәүсен аны, сән гаҗәплән! Бөйлә шартларга.

Бези сән әйләмә тәхкыйрь чапанларла вә артларла,
Безем саф милләти угъратма мондый сасы тапларга.

Бохара һәдиясеседер – схоластикдай вабалар һәп;
Сезә – нисвана – манигъ бу, безә һәм – алга атларга***.

Ничек язмый чыдыйм соң мин? – Тотың мәгъзур, укучылар, –
Бохарилар сәбәп бу рәсмә бүлмәкләргә – шартларга.

Ахырзаман галәмәте

Яэҗүҗ вә мәэҗүҗ тугай,
Озын чапаннан булгай;
Җир йөзе фетнә тулгай
Шомлыгыннан тидия.

Нәфесле булгай үзе,
Үтемле булгай сүзе;
Корсагы гәр туйса да
Туймагай һич тә күзе.

Ашагай җирне-суны,
Өтәч, күркә һәм куйны;
Бик калын булгай муйны,
Камыт сыймас тидия.

Ашагайлар һәм адәм,
Тешләре булгай һәп дәм;
Мисалларыдыр әм-әм,
Орышырлар тидия.

Милләтеңне белмәсләр,
Гыйлләтене күрмәсләр;
Җилкә, корсак симертеп,
Тик ятырлар тидия.

Кайгыру!..

Көткән Дума хәзер туар,
Ләкин Думага кем тулар?
Фәкыйрь халык өмидләре
Өзелмәсме, тулып уңнар?

Думага тулсалар уңнар,
Алар халык күзен буар!
Бичара ач халыкларның
Өмидләре ничек уңар?..

Каты золым качан чумар?
Чын иркенлек качан чыгар?
Бу залимнәр дәвам итсә,
Фәкыйрь халык ничек чыдар?..

Думада җиңсәләр суллар,
Агар «ирек» дигән сулар;
Фәкыйрь эшче, кара халык
Иркен итеп сулу сулар.

Халыкның өмиде туар,
Ачыккан тамагы туяр;
Золым бетеп, хөрриятләр
Нуры берлән дөнья тулар!

Ләкин мондый Дума туңар,
Чөнки залим байлар дулар;
Хөкүмәт тә, эче пошып,
Думамызны тагын куар!

И дустлар! Хәлемез начар;
Ирек нурын качан сачар?
Безнең көткән тигезлекләр
Качан пәрдәләрен ачар?

Хөрриятләр качан агар,
Башымызга качан тамар?
Үземез йокласак, дустлар,
Кемнәр безнең хәлне карар?

* * *

Какма кеше капкасын,
Үз капкаңны кагарлар;
Кешеләрне хурлап йөрсәң,
Төрмәгә дә ябарлар.

Искәрмә һәм аңлатмалар*

1904

31 бит.

*** («Әхмәтсафа әфәнде – фазыйль әдибдер кәнде...»). Тукай үзе исән чакта басылмаган, әмма кулъязма «Әлгасрелҗәдид»нең 1904 елгы 3 нче санында урнаштырылган. Бу кулъязма журнал «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә шәкертләр тарафыннан чыгарыла, Тукай исә аны оештыручы һәм иң актив язышучылардан берсе була. «Әхмәтсафа әфәнде...» шигыреннән алда түбәндәге сүзләр бар: «Мәдрәсәи “Мотыйгыя” таләбәләрендин Габдулла Тукаев намендә кәнҗ шәкерт Әхмәтсафа әфәнде хакында чыкарылмыш улдынгый нәзыми «Гасрелҗәдид»тә дәрҗ улынмасыный истигъдә әйләдегендин, мәгаттәшәккер кабул иделеп, бәр вәҗһе ати асыл нөсхәсендин нәкыль улынды». («Мотыйгыя» мәдрәсәсе шәкертләреннән Габдулла Тукаев исемле яшь шәкерт Әхмәтсафа әфәнде хакында язган тезмә әсарен «Әлгасрелҗәдид»кә кертүне үтенгәнлектән, рәхмәт белән кабул ителеп, төп нөсхәсеннән күчереп алынды».) Басма матбугатта беренче тапкыр «Мәҗмугаи асарь»нең Җ.Вәлиди язган сүз башында (редакцион үзгәрешләр белән) китерелгән. Әмма шигырьнең язылу датасы «1905 ел, 11 гыйнвар» дип ялгыш күрсәтелгән. Беренче дүрттомлыкка «Мәҗмугаи асарь»дән алып кертелгән. Икенче Дүрттомлыкның 1 нче томына, «Әлгасрелҗәдид»тән алынып, « Өйрәнчек шигырьләр» бүлегенә урнаштырылган.

Текст кулъязма журналдан алынды.

1 Әхмәтсафа әфәнде – Әхмәтсафа Байтирәков (? – 1921) – Уральскида «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә Тукай белән бер чорда укыган дусларыннан берсе. Ул, Тукайдан берничә яшькә олырак булып, иң алдынгы шәкертләрдән саналган. Мәдрәсәне тәмамлагач та, анда берничә ел пишкадәм булып тора, әдәби иҗат белән шөгыльләнә. Соңыннан, «Фикер» газетасы чыга башлагач, Саратов өлкәсендәге Яңа Яндовка авылында мөгаллимлек итә, газетаның актив хәбәрчесе була.

32 бит.

*** («Тугъды, көн тугар кеби, бер сахибе һиммәт гани...»). Тукай үзе исән чагында басылмаган. Кулъязма «Әлгасрелҗәдид»нең 1904 елгы ноябрь (15 нче) санында урнаштырылган. Шуннан алып, беренче тапкыр икенче Дүрттомлыкның 1 нче томында « Өйрәнчек шигырьләр» бүлегенә кертелгән. Текст кулъязма журналдан алынды.

Журнал санын ачып җибәргән «Мәҗлесе гыйльмия» дигән кереш сүздә мондый юлларны укыйбыз: «Кичән пәнҗешәнбә кичәсе «әл-Мотыйгыя» мәдрәсәи гамирәсендә мәҗлесе гыйльмия әүвәл дәфга уларак вөҗүдә кәлде. Шәкертләр һәп хазыйр иде. Чук мәсаил хакында әдибанә вә мөдәккыйканә бәхәсләр иделде. Һәр кимә эстәдекени сөйләмәя ихтыяр вирелде. Бер кач зарур маддәләр хакында мәслихәт вә мөзакәрәләр улды вә фәүкыльгадә низамлә иҗраэ улынды. Бу дәфга вәрәкамездә хазыйрьлекчә мәҗлесдә улан җөмлә мәсавиле язмаячагыз, ялгыз мәдрәсәи “Мотыйгыя” әдибе Габдулла Тукаевың шу мәҗлесдә кыйраәт әйләдеге әбъятени дәрҗлә иктифа идәрез, чөнки у зат буныңла җәмигъ нотык сөйләян затлардин тәфәувык итде. Габдулла әфәнде әснаи мөзакәрәдә диде ки: «Рөхсәт итсәңез, мәдрәсәмезнең баш назире Вәлиуллаһ әфәнде Хәмидуллингә хезмәте хәсәнәләрене тәкъдир идеб начизанә тәэлиф әйләдекем әбъяти мәҗлесе гыйльмиядә

кыйраәт илә мөшәррәф улурдым». Тәвакъкыфтән соңра, мәҗлесдә хазыйр уланлар бер агыздан: «Рөхсәт, рөхсәт!» – диделәр. Вә һәм дә риҗаә вә тәмәнни әйләяннәри дә улды. Буның соңында иштә Габдулла әфәнденең укыдыгы әбъяте булыр». («Үткән пәнҗешәмбе кичәсендә әл-Мотыйгыйның төзек мәдрәсәсендә беренче тапкыр буларак «Гыйльми мәҗлес» барлыкка килде. Шәкертләр күп иде. Күп әдәби мәсьәләләр ныклап тикшерелде, һәркемгә теләгәнен сөйләргә ихтыяр бирелде. Кайбер кирәкле мәсьәләләр хакында төпле фикер алышу булды һәм гадәттән тыш тәртип белән барды. Бу язмабызда мәҗлестә каралган барлык мәсьәләләрне дә язмыйча, бары тик мәдрәсәи «Мотыйгыя» әдибе Габдулла Тукаевның шул мәҗлестә укыган шигырьләрен урнаштыру белән чикләнәбез, чөнки бу зат моның белән барлык сөйләүчеләрдән дә өстен чыкты. Габдулла әфәнде чыгышында болай диде: «Рөхсәт итсәгез, мәдрәсәбезнең баш назире (караучысы) Вәлиуллаһ әфәнде Хәмидуллинга күркәм хезмәтләрен тәкъдир итеп язган зәгыйфь кенә бәетләремне гыйльми мәҗлестә укуым белән шат булыр идем». Бераз тынлыктан соң мәҗлестә булганнар беравыздан: «Рөхсәт, рөхсәт!» – диделәр. Шулай ук ялварып, үтенеп сораучылар да булды. Моннан соң Габдулла әфәнденең укыган бәетләре менә болар...»)

Шуннан соң югарыдагы шигырь китерелә. Шигырьнең ахырына тагын мондый сүзләр өстәлгән: «Бундан аңламак мөмкин ула белүр ки, хәмед улсын, мәдрәсәи “Мотыйгыядә” гүзәл әдиб вә шагыйрьләр дә вар...»

Текст кулъязма журналдан алынды.

1 Вәлиулла – Вәлиулла Хәмидуллин – «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә Мортаза Гобәйдуллинны алмаштырган назир (караучы, попечитель), Уральск мөселманнарының җәмгыяте хәйрия рәисе. 1907 елның февралендә Камил Мотыйгыйның наширлек һәм редакторлык хокукы алынганнан соң, «Әлгасрелҗәдид» журналы, «Фикер» һәм «Уральский дневник» газеталарының яңа наширләреннән берсе, «Әлгасрелҗәдид» белән «Фикер»нең вакытлы редакторы була.

2 ...мәхдүм... – Мотыйгулла хәзрәтнең улы Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин; этисенең кайбер дәресләрен алып, мәдрәсәдә торып укыткан К. Мотыйгый өчен, яңа назир аерым кабинет ясата.

3 Мортаза бай – миллионер Мортаза Гобәйдуллин; ул «Мотыйгыя» мәдрәсәсенең бинасын салдыра, матди яктан да азмы-күпме тәэмин итүе сәбәпле, мәдрәсәнең фәхри назире санала, әмма соңыннан бу ярдәменнән баш тарта. Шәкерт Тукай бу шигыре белән, яңа назиргә мәдхия укып, Мортаза байны намуслы эш йөртергә чакырырга тели.

## 1905

35 бит.

*** («Голүмең бакчасында дулашалым, идәлем сәйран...»). Габдулла Тукайның тәүге басма шигыре. «1906 нчы сәнә башында чыкмая башлаячак «Әлгасрелҗәдид» журналының мөфассал игъланы»нда («1906 елда чыга башлаячак «Әлгасрелҗәдид» журналының тәфсилле игъланы») нәшер ителгән. Текст шуннан алынды.

«Мөфассал игълан…»да яшь Тукайның түбәндәге хаты урын алган:

«Уральскидә мәдрәсәи «Мотыйгыя»дән.

29 нчы август, 1905 сәнә.

Мөхтәрәм Мөхәммәдкамил әфәнде!

Чукдин бире чыкарылмасы мәэмүл булынан «Әлгасрелҗәдид» журналының нәшренә мәэзүн улдыкыңызы ишедеб, фәукыльгадә мәсрүр вә мәмнүн улдым. Әгәр безем кебиләрә журналыңыз сәхифәләрендә урын вирелсә, бән бикадәри хәл назмән вә насрән журналыңызда язмакымы вәгъдә идәрем; шу вәгъдәми тәэкид юлында журналыңыз хакында ушбу әбъяте гаҗизанәләреми тәхрир әйләдем. Журналыңызың бер күшәсендә дәрҗ улынмасыны өмид идәрем». («Күптәннән бирле чыгарылуы өмет ителгән «Әлгасрелҗәдид» журналын нәшер итү рөхсәтен алганыгызны ишетеп чиктән тыш шатландым һәм канәгать булдым. Әгәр журналыгыз битләрендә безнең кебекләргә урын бирелсә, мин, хәлем кадәренчә, журналыгызга тезмә һәм чәчмә әсәрләр язып торырга вәгъдә итәм. Бу вәгъдәмне ныгыту максаты белән, журналыгыз хакында шушы зәгыйфь бәетләремне яздым. Журналыгызның бер почмагында басылыр дип өметләнәм».)

Хаттан күренгәнчә, ***«Голүмең бакчасында...» шигыре 1905 елның 29 августыннан элек, ихтимал, язын яки җәй башларында ук язылгандыр.

Совет чорында шигырь беренче тапкыр икетомлыкта басылган (1943).

«Җиһанда болгарың вар улдыгына каниг улсынлар...» – бу юлда Тукайның самими теләге ачыктан-ачык белдерелә: ул, яңа пәйда булып килүче милли матбугат дөньяга Болгар дәүләте һәм аның халкы турында дөрес мәгълүмат бирергә, шул рәвешчә, җаһилләрне белемле итәргә тиеш, дип белә. Шагыйрь бер үк шигырьдә «татар» һәм «болгар» атамаларын янәшә куюы белән аларның бер үк халык икәнлегенә басым ясый, борынгы болгарлар Европа тарафыннан «татар» дип аталган халыкның бабалары булуын ассызыклый.

«Мәгърифәт касрың» – оригиналда бу сүзләр кушылып язылган. «Касыр» урынына «хасыр» диелгән (бу сүз «камау» мәгънәсен бирә). Басмада «к» урынына «х» хәрефе хаталы рәвештә бирелгән булса кирәк.

37 бит.

*** («Чөнанча бездә Камил әл-Мотыйгый...»). «Мөфассал игълан»да «Голүмең бакчасында дулашалым, идәлем сәйран...» шигыреннән соң басылган. Астына «Г.Тукаев» дип куелган. Бу – шагыйрьнең матбугатта кулланган беренче имзасы. Совет чорында шигырь иң элек 1943 елгы академик басмада бирелә.

Текст «Мөфассал игълан»нан алынды. Шигырьнең беренче юлында «чөнанча» сүзеннән соң ялгышлык белән «дә» кушымчасы басылган.

41 бит.

Мужик йокысы. «Фикер» газетасының 1905 елгы 26 ноябрь санында «Мөтәрҗим Габдулла Тукаев» имзасы белән басылган. Бу әсәр – А.В.Кольцовның (1809–1842) «Что ты спишь, мужичок?..» (1839 ел, 25 сентябрь) исемле шигыреннән иркле тәрҗемә һәм «икътибас»ы. Кольцов шигырендә барлыгы 13 дүртьюллык булса, Тукайда ул 19 дүртьюллык тәшкил итә. Бу чагыштырудан шагыйребезнең, чыннан да, Кольцов әсәрендәге теманы шактый гына үстереп баетканы аңлашыла. Шул җөмләдән, Тукай шигырендә мөрәҗәгать объекты булган «мужик»ка аның гаиләсе: хатыны һәм балалары өстәлә. «4 нче дәфтәр»дә (1907) басыла. Шигырьгә биргән искәрмәсендә Габдулла Тукай болай яза: «Иң беренче тәрҗемә вә тәхриремдер». Камил Мотыйгыйның истәлекләр

китабында язылганча, Г.Тукай бу шигырен «әүвәлдән әзерләп куйган». Билгеле булганча, А.Кольцов әсәрен гади халыкка җиңел, аңлаешлы телдә язган. Тукай да, «Что ты спишь, мужичок?..»ны тәрҗемә иткәндә, гап-гади сөйләм телен кулланган. «Мужик йокысы» тел җәһәтеннән шагыйрьнең ул чорда язган назымнарыннан бик нык аерыла. Г.Тукайның «Шигырь китапханәсеннән 4 нче дәфтәр»е турындагы бәяләмәсендә («Әлислах», 1908 ел, 17 нче сан) Ф.Әмирхан болай ди: «Тәрҗемәләр арасында «Охшату» һәм «Мужик йокысы» гонванлы тәрҗемәләре муэффәкыятьсез сайлау дип атамаска мөмкин түгелдер».

«4 нче дәфтәр»нең 1909 елгы икенче басмасында дүртенче дүртьюллык түбәндәгечә:

Мал юк дип зарланма, –
Үзеңнән күр аны;
Чәч иген: җир яхшы, –
Алырсың дөньяны...

Ләкин Фатих Әмирхан бу дүртьюллыкны тәнкыйтьләп, аны урынсыз дип күрсәткәннән соң («Әлислах», 1908 ел, 2 февраль), Тукай шигырьне бер җыентыгына да кертми.

А.Кольцовның «Что ты спишь, мужичок?..» шигыренең тексты:

Что ты спишь, мужичок?
Ведь весна на дворе;
Ведь соседи твои
Работают давно.

Встань, проснись, подымись,
На себя погляди:
Что ты был? И что стал?
И что есть у тебя?

На гумне – ни снопа;
В закромах – ни зерна;
На дворе, по траве –
Хоть шаром покати.

Из клетей домовой
Сор метлою посмел;
И лошадок за долг
По соседям развел.

И под лавкой сундук
Опрокинут, лежит;
И, погнувшись, изба,
Как старушка, стоит.

Вспомни время свое:
Как катилось оно

По полям и лугам
Золотою рекой!

Со двора и гумна
По дорожке большой
По селам, городам,
По торговым людям!

И как двери ему
Растворяли везде,
И в почетном угле
Было место твое!

А теперь под окном
Ты с нуждою сидишь,
И весь день на печи
Без просыпу лежишь.

А в полях сиротой
Хлеб нескошен стоит.
Ветер точит зерно!
Птица клюет его!

Что ты спишь, мужичок?
Ведь уж лето прошло,
Ведь уж осень на двор
Через прясло глядит.

Вслед за нею зима
В теплой шубе идет,
Под снежком порошит,
Под санями хрустит.

Все соседи на них
Хлеб везут, продают,
Собирают казну –
Бражку ковшиком пьют.

«Мужик йокысы» шигыренең тексты «4 нче дәфтәр»дән (1909) алынды.

«Фикер» – 1905 елның 26 ноябреннән 1907 елның 18 маена кадәр Җаекта (Уральскида) чыккан газета. Нашире һәм мөхәррире – Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин.

45 бит.

Шигырь («Шималь яктан…»). «Нур» газетасының 1905 елгы 6 декабрь санында басылган. Алдына Тукайның «Нур» мөхәрриренә хаты урнаштырылган. Аның тексты түбәндәгечә:

«Шәһри Петербургда мөхәррире «Нур» әфәнде хәзрәтләренә.

Безем шу ашагыдагы әбъяте гаҗизанәмези косурына бакмаярак, җәридәңезен почмагына сыгдырсаңыз, кәмале һимммәтеңездән гад идәр идем». («Петербург шәһәрендә «Нур» мөхәррире әфәнде хәзрәтләренә! Безнең шул түбәндәге зәгыйфь бәетләребезне, җитешсезлекләренә карамастан, газетагызның бер почмагына сыйдырсагыз, камил тырышуыгыздан санар идем».) «Шигырь»нең азагына «Үтенеп: Уральскидә мәдрәсәи «Мотыйгыя» шәкерте Габдулла Тукаев, тарих 15 октябрь, 1905 сәнә» дип куелган.

«Нур» – Идел – Урал мөселманнарының беренче газетасы. 1905–1914 елларда Санкт-Петербургта чыга. Нашире – Гатаулла Баязитов.

«Тәрҗеман» – 1883–1918 елларда Бакчасарайда чыккан беренче мөселман төрки-татар газетасы. Нашире һәм мөхәррире (1914 елга кадәр) – Исмәгыйль бәк Гаспралы (Гаспринский) (1851–1914).

«Хәят» – Бакуда 1905–1907 елларда нәшер ителгән мөселман газетасы.

49 бит.

*** («Бу көндә бер сарай ачды әһали...»). Беренче тапкыр Икетомлыкның 1 нче томында (1943) басылган. Шигырьгә мондый искәрмә бирелгән:

«Бу шигырь «Фикер» газетасында басылырга әзерләнгән гранка хәлендә, Татарстан совет язучылары союзына элек Уральскида яшәгән Хәмидуллин фамилияле кеше тарафыннан тапшырылган. Хәзергә чаклы бер урында да басылганы билгеле түгел. Шигырьнең башына «3» цифры куелган. Бу цифр шигырьнең алдында тагын ике бүлек булуын күрсәтә. Шигырьнең бу бүлеге Уральскида «Казан» исемле гостиница ачылуга багышланган булырга тиеш».

Искәрмәдә күрсәтелгән Хәмидуллин (Вәлиулла Хәмидуллин), 1907 елда «Фикер» газетасы К.Мотыйгый-Төхфәтуллин кулыннан алынгач, аның мөхәррире булып китә (нашире – Мортаза Гобәйдуллин).

Шигырь Мортаза Гобәйдуллинның «Казан» кунакханәсе ачылу уңаеннан язылган, ләкин аның кыйраәтханәсендә (уку залында), «Фикер»нең 1905 елгы 4 декабрь санында язылганча, «бик күп гәзитәләр» куелмаганга күрә, шигырь басылмый калгандыр дип фараз йөртергә мөмкин. Башка сәбәп булуы да ихтимал.

«Бу көндә бер сарай ачты әһали»нең соңгы ике бәйте «Шигырь (Шималь яктан...)» әсәренең 12 нче һәм 13 нче бәйтләрен тулысынча кабатлый, шулай итеп, ике шигырьнең бер бәйләмне (циклны) тәшкил итүенә дәлил булып тора.

«Йолдыз» («Йолдыз сарай»ы) – Госманлы дәүләтенең солтаны Сәлим III (падишаһлык еллары – 1789–1807) тарафыннан энисе Миһришаһ Солтан өчен төзеттерелгән. Солтан Габделхәмид II (1876–1909) заманында Госманлы дәүләтенең төп сарае булган.

53 бит.

Хөррият хакында. «Фикер» газетасының 1905 елгы 11 декабрь (3 нче) санында басылган. Әсәр Тукай иҗатында (матбугатта басылган шигырьләрендә) беренче тапкыр «Габдулла Тукаев» дип имзалана. Өченче строфадагы «Барча цензур ябылгач...» дигән юл

«4 нче дәфтәр»дә (1907) «Барча богау алынгач» дип үзгәртелгән; бишенче һәм алтынчы строфалардагы «Дарга асылганнары», «Корбан кыйлды җаннарын» юллары урынына күп нокталар куелган. Бу үзгәрешләр, мөгаен, цензура таләпләреннән чыгып эшләнгән булса кирәк. «4 нче дәфтәр»гә шигырь бөтенләй кертелмәгән. Текст «Фикер»дән алынды.

Шигырь 1905 елгы, 17 октябрь манифесты чыгуы һәм хөкүмәт тарафыннан шәһәрләрдә «гомуми һәм рухи цензураның» бетерелүе («Временные правила о повремённых изданиях», 24 ноябрь) уңае белән язылган. Шул ук елның 19 октябрь – 24 ноябрь аралыгында Русиядә бөтен матбугат органнары тулы ирек, ягъни цензурасызлык шартларында басылган. Ләкин, декабрь башларыннан алып, цензура режимы әкренләп кире кайта башлаган.

«Хөррият хакында» «Бакырган китабы» (XII гасыр, авторы – Сөләйман Бакыргани) шигъри үлчәмендә язылган (һәр дүртьюллыкның азагына «ия»(«ыя») кушымчалы сүз куелу бу калыпның төп күрсәткечләреннән санала).

55 бит.

Дустларга бер сүз. «Фикер»нең 1905 елгы 18 декабрь (4 нче) санында «Габдулла Тукаев» имзасы белән басылган. Икетомлык «Тукай әсәрләре»нә (1929) кертелгән. Текст «Фикер»дән алынды.

«Йосыф-Ягъкуб» китабы – болгар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы (якынча XII йөз ахыры – XIII йөз башы) күздә тотыла. Тукайның шигыре дә шул әсәрнең үлчәме үрнәгендә язылган.

57 бит.

Иттифакъ хакында. «Фикер» газетасының 1905 елгы 25 декабрь (5 нче) санында «Габдулла Тукаев» имзасы белән басылган, шулай ук «4 нче дәфтәр»гә (1907) кертелгән. Текст шуннан алынды.

Тукайның бу әсәре төрки шигъри ядкяр «Бәдәвам» үлчәмендә язылган. Анда исә һәр дүртьюллыкның дүртенче юлы «Аллаһ, дигел бәдәвам!» («даими рәвештә «Аллаһ» диген!») рәдифе белән («рәдиф» – һәр шигъри юл азагында килә торган бер яки берничә үзгәрмәс сүзләр тезмәсе) тәмамлана.

59 бит.

Алла гыйшкына. «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 15 гыйнвар (1 нче) санында «Габдулла Тукаев» имзасы белән, шулай ук «Фикер»нең 1906 елгы 1 октябрь (36 нчы) санында басылып чыккан. «3 нче дәфтәр»гә (1907) кертелгән. Текст шуннан алынды.

«Әлгасрелҗәдид» журналының шул ук (15 гыйнвар) санында «Идарәдән ихтар»ында(ягъни редакциянең аңлатмасында) болай диелгән: «Җөмлә укучыларымыздан гафу үтенәмез. «Әлгасрелҗәдид» журналы бу көнгә кадәр тәәххер итде (кичекте). Декабрь аенда тимер юлларның хәрәкәте тукталдыгыннан, басмаханәмезә матдәләр вакытында килеп йитмәде... Журналымызның бу номеры тәхрират җәһәтенчә дә (язмалар ягыннан да) кәмалә (камиллеккә) ирешмәде, пәк чук (бик күп) тәхрират тәртип улынмады (матбагада җыелмады), артып калды. Аларны да сыгдырмая чалышсак, февраль аена кадәр тәәххер итмәсендән (кичегүеннән) курыктык. Габдулла әфәнденең «Әшгар мәҗмугасе» («Шигырьләр тупламы»), ахунд Мәсгудовның «Тәхсиле гыйлемдә (гыйлем алуда)

тәрбиясезлек»..., Мөхәммәдфатих әл-Кәриминең «Асрау кыз» нам (исемле) әсәре вә гайреләр, вә гайреләр һәп (барысы да) киләчәк номерда басылачаклардыр... Хөрмәтле мөштәриләремездән (журнал алдыручыларыбыздан) риҗа идәмез (үтенәбез): мөмкин кадәр журналны интишарына сәгый идәләр (таралуы өчен тырышлык куйсыннар)».

Бу искәрмәдән Тукайның «Аллаһ гыйшкына» һәм «Хәзерге халемезә даир» шигырьләрен 1905 елның октябре яки ноябрендә иҗат иткән булуы аңлашыла.

62 бит.

Хәзерге хәлемезә даир. «Әлгасрелҗәдид» журналының 1906 елгы 15 гыйнвар (1 нче) санында «Уральскидә Габдулла Тукаев» имзасы белән басылып чыккан. Большевик инкыйлабына кадәр бу шигырь Тукайның бер җыентыгына да кермәгән, бары тик Икетомлыкта (1929) гына кабат дөнья күргән.

Текст «Әлгасрелҗәдид»тән алынды.

«Сәзадер сүрәтен-«Нүн»дә йәминә» («Нүн» сүрәсендәге антка (йәмингә) килешә) – Коръәннең 68 нче «Нүн» («Каләм») сүрәсендәге беренче аятьнең сүзләре күздә тотыла булса кирәк: «Нүн. Вәл-каләми вә ма йәстурун» («Нүн. Каләм белән һәм (кешеләрнең) язу әсбабе булган башка нәрсә(ләр) белән ант итәм»). «Тәфсире Ногмани»дә (Казан, 2009) аятьнең мәгънәсе болай аңлатыла: «Бисмил-ләһир-рахмәнир-рахим. 1. Нүн. Вә Ләүхүл Мәхфузны язган каләм белән һәм фәрештәләр язган кешеләрнең гамәл дәфтәрләре илә ант итәмен».

1906

64 бит.

*** («Рөшде вар, кауле гүзәл, наме – Рәшид...»). «Фикер»нең 1906 елгы 1 гыйнвар (1 нче) санында «Төрле хәбәрләр» бүлегендә имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

Шигырьдән алда: «Декабрьнең 22 көнендә Петербургта фазыйль Рәшид әфәнденең « Өлфәт» намендә улан гәзитәсенең икенче номеры чыкты. Мөндәриҗаты гүзәл вә фасих лисан үзрә язылмыштыр», – дигән сүзләр бар.

Г.Тукай, 1905–1907 елгы инкыйлаб нәтиҗәсендә яуланган азмы-күпме иркенчелекләрдән файдаланып, татар телендә чыга башлаган һәр газета һәм журналны шатланып каршы ала, аларга тәбрик-теләк шигырьләре, одалар яза. Әлеге дүртьюллык та – шушы типтагы одаларның берсе. « Өлфәт»нең үз мәсләген «Шәкерт вә фәкыйрьләр тарафчысы, хакыйкый исламият хадиме, социалистический, милли һәфтәлек гәзитә» дип игълан итүе, «цензурсыз» да булуы яшь шагыйрьгә һичшиксез уңай тәэсир иткән.

1« Өлфәт» – («Нур», «Казан мөхбире», «Фикер»дән соң) 1905 елның 11 декабреннән 1907 елның 9 июненә кадәр Петербургта татар телендә чыккан дүртенче газета. Редакторы һәм нашире – Габдрәшид Ибраһимов.

65 бит.

*** («Мәгатыйль кыйлды милләтне...»). «Фикер»нең 1906 елгы 1 гыйнвар (1 нче санында «Төрле хәбәрләр» бүлегендә имзасыз басылган. Шигырьдән алда: «“Тәрҗеман” гәзитәсе декабрь уртасыннан бирле цензурсыз чыкмая башлады һәм урысча кыйсьмене ташлады. Хәзер «Тәрҗеман»ымыз хәмед улсын».

Текст «Фикер»дән алынды.

1 Мәгатыйль кыйлды милләтне... – Бу урында Бакчасарайда (Кырым) И.Гаспринский мөхәррирлегендә нәшер ителгән «Тәрҗеман» газетасы искә алына. 1905 ел ахырына кадәр татар телендә газета-журналлар нәшер ителмәгәнлектән, аны аеруча яратып укыганнар, үзләренә кирәкле мәгълүматны шуннан алганнар. Газета, 1905 елда цензура бетерелгәч, фәкать гомумтөрки телдә басыла башлап, иректә иҗатка өстенлек бирә. Соңрак Тукай бу газетаны күп тапкырлар тәнкыйть итә.

66 бит.

Шәкерд, яхуд бер тәсадеф. «Фикер» газетасының 1906 елгы 22 гыйнвар (3 нче) санында «Габдулла Тукаев» имзасы белән басылган. «4 нче дәфтәр»дә (1907) алтынчы строфадагы «пимаңның» сүзе «катаңның»га алыштырылган.

Текст «4 нче дәфтәр»дән алынды.

70 бит.

Яз галәмәтләре. «Фикер»нең 1906 елгы 12 март (10 нчы) санында «Габдулла Тукаев» имзасы белән басылган. «4 нче дәфтәр»дә (1907) икенче строфаның икенче юлындагы «пима» сүзе «ката»га үзгәртелгән.

Текст «4 нче дәфтәр»дән (1907) алынды.

71 бит.

И каләм! «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 15 март (3 нче) санында басылып чыккан, «3 нче дәфтәр»дә (1907) урын алган. Текст шуннан алынды.

Бу шигырьне Тукай үзенең «Әшгар мәҗмугасы» өчен 1905 ел азагында әзерләп куйган. «Әлгасрелҗәдид»тә нәшер ителгәннән соң, ул шактый ук популяр булып китә, шул ук журналда һәм «Фикер»дә басылган язмаларда аннан аерым юллар китерелә. Мәсәлән, «Әлгасрелҗәдид»нең 1907 елгы 15 март (3 нче) санында «Идарәдән» (редакциядән) бирелгән белдерүдә «И каләм!»нән:

«И каләм, сәндән кәлер һәп бәхтемез, икъбалемез:
Бәкләнер дүрт күз илә лотфыңда истикъбалемез», –

дигән икеюллык бирелә.

73 бит.

Ифтиракъ соңында. «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 15 март (3 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Моннан тыш, «3 нче дәфтәр»дә (1907) чыккан. Текст «3 нче дәфтәр»дән алынды.

75 бит.

Шагыйрь вә Һатиф. «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 15 март (3 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче тапкыр Икетомлыкның 1 нче томында (1943) бирелгән. Текст «Әлгасрелҗәдид»тән алынды.

77 бит.

***(«Сәгадәт юк, фәкать наме сәгадәт...»). «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 15 март (3 нче) санында имзасыз басылган. Шигырьнең алдына «Бер затә көфү улмаян Сәгадәтбану исемле бер кызы тәклиф итдекләрендә бу шигъре сөйләмештер» («Сәгадәт исемле бер кызны үзенә тиң булмаган кешегә димләгәндә, кыз бу шигырьне сөйләгән») дигән аңлатма бирелгән. Текст «Әлгасрелҗәдид» журналыннан алынды. Әсәр беренче тапкыр Өчтомлыкның (1 нче том) «Тукайга нисбәт ителгән шигырьләр» бабында урын ала.

Тукайның сабакташ дусты Ярулла Муради истәлекләрендә түбәндәге сүзләр бар: «...мин пәдәрләремезнең (әтиләребезнең) миңа үзем эстәмәгән (теләмәгән) бер кызны алырга тәклиф (катгый тәкъдим) итүләрен сөйләгән идем, Тукай иптәш, бакчаның капусыннан (капкасыннан) кереп барган арада гына: «Тукта әле, мин аның хакында бер шигырь әйтим әле», – дип:

Сәгадәт юк, фәкать наме сәгадәт,
Көфуне вирмәмәк безләрдә гадәт, –

дийә матур гына көйләп тә җибәрде» (Тукаев Уральскида. Әстерхан, 1913).

78 бит.

«Фикер» гәзитәсенә генә махсус түгел. «Фикер»нең 1906 елгы 24, 31 март, 9, 17, 23 апрель (11–15 нче) саннарында, һәр санда икешәр бәйтле итеп, газетаның исеме астында «сәрләүхәсез» (исемсез) һәм имзасыз килеш басылып барган. «4 нче дәфтәр»дә (1907) «Фикер» гәзитәсенә генә махсус түгел» исемендә бирелгән. Текст «4 нче дәфтәр»дән алынды.

80 бит.

Мөридләр каберстанындан бер аваз. «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 15 апрель (4 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «4 нче дәфтәр»дә (1907) чыккан. Текст шуннан алынды.

Бу шигырь белән «Сорыкортларга» шигыре турында «Фикер»нең шул ук елдагы 26 ноябрь санында мондый мәгълүмат бар: ««Әстерханда ушбу көннәрдә генә әдәбият ахшамы (кичәсе) булып, ...Габдулла Тукаевның «Мөридләр каберстанындан бер аваз» вә «Сорыкортларга» дигән шигырьләрен музыка илә җырлаганнар. Әдәбият ахшамы әһали (халык) өчен дә, яшь интеллигентлар өчен дә маддәтән вә мәгънән файдалы булган. Әстерхан мөселманнарының да, әдәбият ахшамын күреп, күзләре нурланган».

Моннан тыш, «Фикер» битләрендә (1906 ел, 24 декабрь) әдәбият тәнкыйтьчесе, телче Насретдин әл-Хуҗашинең “Әлгасрелҗәдид” журналы хакында» хаты басылып, анда Тукай шигырьләрен мактаган мондый юллар бар: «Г.Тукаев җәнабләренең «әшгаре миллиясе» (милли шигырьләре) бу журналга аеруча зиннәтләри вирде. Бу журналда иң зыядә (иң нык) бәнем хушыма кәлән (миңа ошаган)... Тукаевның «әшгаре миллиясеДер» ки, гаять ләзиз хиссияте миллияләр уйгатты (ләззәтле милли хисләрне уятты). Бу әшгарьдән (шигырьләрдән) дә иң зыядә хушыма кәләне «Мөридләр каберстанындан бер аваз» сәрләүхәсе (исеме) илә язылган шигырьләр иде ки, бу әшгарьнең эченә алдыгы мәгънәләри, хакыйкатьләри шигырь илә мәйдана куйган ялгыз Тукаев улдыгы кеби, иң дәрдле, иң монтазам, иң гүзәл шигырьләр дәхи Тукаевның агызыннан сөйләнде».

Совет хакимияте елларында идеологик сәбәпләрдән чыгып, шигырьнең унынчы бәйте (икеюллыгы) бастырылмый килде:

Дәрсе гыйбрәт вирде безгә «Инкыйраз» нам бер әсәр;
Аh, буны язан кеше инсан икәндер, белмәдем.
(«Инкыйраз» исемле әсәр безгә гыйбрәт сабагы бирде;
Аh, моны язган кеше инсан икәндер, белмәдем)

Бу бәйттә Габдулла Тукай ул елларда ук инде күренекле язучы һәм сәяси көрәшче булып өлгереп килгән Мөхәммәдгаяз Исхакыйны һәм аның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» романын (1904) мактап яза. Гомумән, «Мөридләр каберстаныннан бер аваз»да Тукай беренче тапкыр милләттәш әдипнең әсәренә соклануын, аңа бик зур әһәмият бирүен басым ясап әйтә. Шулай итеп, «Инкыйраз»да халкыбызның киләчәк язмышын ихлас кайгыртып язган Г.Исхакыйның иҗатына беренче шигъри тәкъриз (уңай бәяләмә) Тукайдан килә.

82 бит.

Гыйшык бу, йа!.. «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 15 апрель (4 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «3 нче дәфтәр»дә (1907) чыккан. Анда җиденче бәйттәге «тәхте» сүзе «хаке» дип үзгәртелгән.

84 бит.

Пушкинә. «Әлгасрелҗәдид» журналының 1906 елгы 15 апрель санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «3 нче дәфтәр»дә (1907) чыккан.

Бәнем шәэнемме тәфтиш мәзһәбеңне, дине мәнсүбең? (Минем эшемме соң мәзһәбеңне вә динеңне тикшерү?) – биредә Тукай А.Пушкинны үзе өчен бары тик олуг шагыйрь үрнәге итеп алуын, аның дини ышанулары, гомумән, нинди дә булса дин вәкиле булуы белән кызыксынмавын ассызыклап әйтә. Мөселман мохитендә яшәү, аның шартларына җавап бирү тиешлеге, әлбәттә, мондый искәрмә бирүне зарур кылгандыр.

86 бит.

«Уклар» журналында мөхбир уланлара тәнбиһ. «Фикер»нең 1906 елгы 8 май санында «Шүрәле» имзасы белән басылган.

Үзе исән чакта, бер җыентыгында да чыкмаган. Беренче тапкыр беренче Дүрттомлыкка (1955) урнаштырылган.

Текст «Фикер»дән алынды.

«Уклар» журналының нибары 6 саны (1906, июнь-июль) гына чыгып кала.

87 бит.

Кечкенә генә бер көйле хикәя. «Фикер»нең 1906 елгы 17 май санында «Гъ.» инициалы белән басылган. Тукай исән чакта, бер җыентыгына да кертелмәгән. Беренче мәртәбә Өчтомлыкта урын алган. Текст «Фикер»дән алынды.

Бертуганы Газизә истәлекләренә караганда («Тукай турында замандашлары». 44 б.), Тукай бу шигыренең сюжетын тормыштан алган: «Габдулла, зурая төшкәч, язган шигырьләрен миңа килеп укый торган иде. Миңа иң беренче укыган шигыре Сафи абзый

белән Фатыйма апа турында иде. Ул шигырен укыгач, мин: «Моны син чыгардыңмы, әллә Камил (Камил Мотыйгый) чыгардымы?» – дидем. «Аларның тормышын Камил кайдан белсен, мин яздым. Мин аларга барып йөри идем ич! – диде».

Өчтомлыкны төзүче Ф.Сәйфи-Казанлы әлеге шигырьнең язылу сәбәпләре хакында түбәндәгеләрне яза: «Камил иптәш Мотыйгыйның сүзенә караганда, поэманың баш герое – Сафи абзыйның хатыны – Тукайның кардәше булган, ул һәм шуны язган. Үзе исән чагында, моны басарга, күчерергә һәм ул язган икәнен әйтергә беркемгә дә рөхсәт итмәгән...» (1 том, 142 б.)

Бертуган Шәрәфләр басмаханәсенең башлыгы Г. Шәрәфкә юллаган хатында (1907 ел, 5 июль) Тукай үзе болай дип яза: «Кечкенә генә бер көйле хикәя» сәрләүхәле шигырь басылмый калса да зарар итмәс зан итәм (дип исәплим)» («Тукай турында хатирәләр». – Казан, 1976. – 74 б.). Аңлашыла ки, шагыйрь бу «хикәянең» үзенә генә мәгълүм сәбәп аркасында күп укучыларга барып ирешүен теләмәгән.

94 бит.

Дәрдемәнд дәгелмием? «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 20 май санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «3 нче дәфтәр»дә (1907) чыккан. Текст шуннан алынды.

Тәңре гыйшкында шәһадәт итсәләр дәр Гәрбәла («Аллаһка омтылып Гәрбәлада шәһит китсәләр») – 680 елда Гәрбәла (гарәп әйтелешендә «Кәрбәла») шәһәрчеге янындагы сугышта хәлифә Язид бине Могавия яугирләре дүртенче хәлифә хәзрәти Гали бине Әбу Талипнең Хөсәен исемле улын һәм аның яраннарын үтерәләр. Тукай шуларны искә төшерә.

96 бит.

Гәзитә мөрәттибләренә. «Фикер»нең 1906 елгы 30 апрель, 8, 17 май һәм 3 июнь (16–21) саннарында, һәр санда икешәр бәйтләп, имзасы куелмыйча басылган. Беренче мәртәбә Өчтомлыкка (1929) кертелгән. Текст «Фикер» газетасыннан алынды.

98 бит.

Японияне мөселман идәчәк голяма нәрәдә? «Фикер» газетасының 1906 елгы 3 июнь (20 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, «3 нче дәфтәр»дә (1907) чыккан. Текст шуннан алынды.

Япониядә мөселман активлыгы XIX гасырның урталарыннан башлана. Бу илгә Госманлы империяторлыгыннан шактый санда кунаклар килә. Әлбәттә, алар берочтан дәгъвәт һәм тәблигъ, ягъни ислам динен пропагандалау эше белән дә шөгыльләнә. Русия мөселманнарыннан иң башта Япониядә ислам динен системалы төстә тарату эшчәнлегенә сибирияле (себердән чыккан татар) Габдрәшит Ибраһимов (Рәшит казый) керешә. Ул, Япониягә махсус барып, ил буйлап сәяхәт итеп кенә калмый, бәлки төрле катлау халык вәкилләре, шул исәптән югары урыннарда мөһим вазифаларны башкарган дәүләт мәэмүрләре белән дә очраша, япон халкының ислам диненә бик уңай каравына инана.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында японнардан шактый гына кеше мөселман була. Традиция буенча, беренче япон мөселманы итеп Ошатаро Нода санала. Ул, ислам динен 1891 елда Истанбулга килгәч кабул итеп, үзенә Габделхәлим исемен ала. 1890 елларда тагы ике япон (Ямада һәм Ариджа) мөселман булалар, Габделхәлил белән Әхмәд

дип исемләнәләр. Гомумән, Япониядә ислам таралу процессы шул елларда һәм аннан соң да сизелерлек тәрәккый итә.

Япон галимнәре сүзенә караганда 1905 елда Идел-Урал мөселманнарыннан бер гаилә япон шәһәре Осакага барып, анда беренче мәчет ачалар.

Ул көннәрдә шактый мөселман газеталары Япониядә ислам таратуга кагылышлы хәбәрләр бастыралар. Мәсәлән, «Таң» газетасының 1906 ел 26 май санында түбәндәгене укыйбыз: «Бөтен татар гәзитәләре бу ел июль числасында Япуниядә була торган дин тикшерү җәмгыяте хакында язалар. Һәммәсе Япуниядә исламның таралуына вә Япуния халкының ислам динен кабул итәчәкләренә бик зур өмедләр баглыйлар». « Өлфәт»тә (1906, 30 март, 17 нче сан) бу тема мөнәсәбәте белән мондый хәбәр басыла: «Япун-Кытай тарафларына дине исламны үгрәтмәк, нәшер итмәк өчен Һинд мөселманнары «Әнҗемәне ислам» («Ислам җәмгыяте») исемендә бер җәмгыять ясамышлар. Шу (шул) җәмгыять әгъзаларыннан Һиндстанның иң биек (зур) мәдрәсәләрендә беренчелек шаһәдәтләрене алмыш Хафиз Хөсәен Хан һәм дә Хафиз Габделгафур Мәгази хәзрәтләре «Япуния мәмләкәтенә күндерелмешләр».

Русия мөселман газеталарында хәтта «микадо да ислам диненә керергә әзер» кебек хәбәрләр, күргәнебезчә, буш урында тумый. «Япунияне мөселман идәчәк голяма нәрәдә?» шигыренең текстыннан аңлашылганча, Тукай бу мәсьәләгә шактый ук зур әһәмият биргән. Аның фикеренчә, Русия мөселманнары дәгъват миссиясен алып барырга җыеналар икән, Япониягә «чапан» һәм «бохарилык» кебек искелек символларын күрсәтергә түгел, ә бәлки япуннарга чын дин өйрәтергә тиешләр. Монда без Тукайның ислам диненең авторитеты өчен ихлас җан атуына шаһитбыз.

101 бит.

Хатирәи «Бакырган». «Уклар» журналының 1906 елгы 1 июнь санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә Биштомлыкның 1 нче томына (1985) кертелгән. Текст «Уклар»дан алынды.

XII гасырга караган «Бакырган китабы» күп кенә болгар-татар шагыйрьләре (Мәүла Колый, Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари һ.б.) иҗатына тәэсир иткән. Әлбәттә, Тукайга да йогынтысы зур булган. «Хатирәи Бакырган» шигыре, исеменнән үк аңлашылганча, “Бакырган” әсәренә хөрмәт йөзеннән яки, кимендә, аның вәзен һәм ритмикасына соклану сәбәпле язылган.

102 бит.

Бәет («Бәгъзеләрмез бик суфи...»). «Фикер»нең 1906 елгы 21, 24 һәм 27 (24, 27 нче) саннарында «Биик усал» имзалы «Алай-болай» фельетоны эчендә бирелгән. Беренче мәртәбә Биштомлыкның 1 нче томында (1985) басылган. Текст «Фикер»дән алынды.

«Алай-болай» фельетоны Казанда чыккан «Бәянелхак» газетасы нашире Әхмәтҗан Сәйдәшевкә (1840–1912), аның демократик юнәлешле яшьләрне тыярга тырышып азаплануына каршы язылган. «Бәет»тә исә Сәйдәшевнең, динне яхшылап белмәгән килеш, яшьләргә дин сабаклары биреп маташуы тәнкыйтьләнә. Икеюллыктан алда мондый сүзләр языла: «Гәзитәгә бер аять язгансың, шуны да дөрес яза алмагансың. Синең шикелле ушбу түбәндәге бәйтнең мөсәддикы (бәйтнең дөреслеген раслаучы) булган татарларга халыкны сәләфе салихин тарикына (элекке диндарлар юлына) өндәргә оят дип беләбез».

103 бит.

Сорыкортларга. «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 20 июль (7) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Өчтомлыкның 1 нче томында (1929) чыккан. Текст «Әлгасрелҗәдид»тән алынды.

1 Каф... таулары – мөселман космологиясендә җирне уратып алган тау сырты; ул «ачыкланган»ны «ачыкланмаган»нан аерып тора. Мифларга караганда Каф тавында сәмруг кошы яшәгән.

105 бит.

Кемне сөяргә кирәк? «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 20 июль (7) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, «3 нче дәфтәр»дә (1907) чыккан. «Мәҗмугаи асарь»дә (1914) «Пушкиннан мөкътәбәс» («Пушкиннан файдаланылган») дип өстәлгән. Пушкинның «Евгений Онегин» шигъри романындагы XXII строфасында (дүртенче бүлек) түбәндәге юллар бар:

Кого ж любить? Кому же верить?
Кто не изменит нам один?
Кто все дела, все речи мерит
Услужливо на наш аршин?
Кто клеветы про нас не сеет?
Кто нас заботливо лелеет?
Кому порок наш не беда?
Кто не наскучит никогда?
Призрака суетный искатель,
Трудов напрасно не губя,
Любите самого себя,
Достопочтенный мой читатель!
Предмет достойный: ничего
Любезней, верно, нет его.

Пушкин строфасында 14 юл булса, Тукай шигыре 20 юл тәшкил итә.

106 бит.

Татар кызларына. «Уклар» журналының 1906 елгы июль (2) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Тукай үзе исән чакта бер шигъри җыентыгына да кермәгән. Өчтомлыкта (1929) урын алган. Текст «Уклар»дан алынды.

1 Китәм әгърафә тиз... – әгъраф – җәннәт белән җәһәннәм арасындагы урын.

108 бит.

Мөхәрриргә. «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 15 август (31) санында, «Фикер»нең 1906 елгы 18 август (31) саннарында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Янә «Борһане тәрәкъкый»ның (М.Исмәгыйлов-Ширванский һәм Н.Гасрый мөхәррирлегендә Әстерханда гомум төрки һәм татар телендә чыккан атналык газета) шул ук елгы 7 сентябрь санында

басыла. Бу факт шигырьнең аерым иҗтимагый әһәмияткә ия булуын ассызыклап күрсәтә. Әсәр «4 нче дәфтәр»гә (1907) кертелгән. Текст шуннан алынды.

Шигырь «Бәянелхак» газетасында Камил Мотыйгыйга каршы юнәлешле мәкаләләр бастырылуга, аны «дәһри» дип гаепләүләргә җавап рәвешендә язылган. Демократик мәсләкле журнал һәм газеталар мөхәрриренең эшчәнлеге Уральскидагы мөртәҗигъләрнең (реакционерларның) дә ачуын китерә, алар «Бәянел- хак» тәнкыйтенә фактта теләктәшлек күрсәтәләр, Камил Мотыйгыйның басмаханәсенә зыян салырга ниятлиләр.

110 бит.

Мәхвидәрмесән? «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 15 август (8) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, «4 нче дәфтәр»дә (1907) чыккан. Текст шуннан алынды.

112 бит.

Пушкиннән. «Уклар» журналының 1906 елгы август (3) санында Пушкинның исемсез шигыре соңында, «Тәрҗемә вә тәшрих» рубрикасы астында, «Шүрәле» имзасы белән басылган. «3 нче дәфтәр»дә (1907) Пушкинның исемсез назымы һәм Тукайның «Пушкиннан» шигыре «Пушкин ислам хатыннары хакында» рубрикасы астында бирелә. Текст шуннан алынды.

Исемсез бу шигырьнең 1824 елда язылуына дикъкать итсәк, шул ук елда язылган «Фонтану Бахчисарайского дворца» шигыренә рухы һәм өлешчә эчтәлеге җәһәтенчә якын булуын күрәбез, ягъни ул Кырым сәяхәтенең бер иҗади җимеше итеп каралырга хаклы.

Түбәндә Пушкин шигыре китерелә:

«Пока супруг тебя, красавицу младую,
Между шести других еще не заключил,
Ходи к фонтану близ могил
И черпай воду ключевую,
И думай, милая моя:
Как невозвратная струя
Блестит, бежит и исчезает –
Так жизнь и юность убегает,
В гареме так исчезну я».

114 бит.

Борадәранә нәсыйхәт. «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 15 сентябрь (9) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, «4 нче дәфтәр»дә (1907) чыккан. «Әлгасрелҗәдид»тә шигырьгә «63 нче номер «Вакыт» җәридәсендә (газетасында) мөндәриҗ (басылган) яшь төрекләрнең бәгъзе (кайбер) әшгаренә (шигырьләренә) каршы» дигән искәрмә өстәлгән. Текст «Әлгасрелҗәдид»тән алынды.

«4 нче дәфтәр»дә (1907) шигырьнең Габделхәмит II гә караган дүрт юлы «Әлгасрелҗәдид»тәгегә караганда бераз үзгәртелә. Җыентыкта алар түбәндәгечә:

1. «Фәүтидәр кәлде заман, чук сөрмәдән Хәҗҗаҗыңыз;
2. Сез рәисе җаһилани (наданнар башлыгын) «Йолдыз»а хәбсидеңез;
3. Шимди сез ләхдә кадәр мәддахе җаһил улдыңыз;
4. Җаһилә коллык фәкать тәкърireңез, тәхриреңез».

1 Яшь төрек (яшь төрекләр) – 1880 еллар азагында оештырылган «Иттихад вә тәрәкъкый» фиркасе тарафдарлары. Төркиядә парламентар хакимият урнаштыру идеясе ягында булган «иттихад вә тәрәкъкый»челәрнең шактые, солтан эзәрлекләвеннән качып, Көнбатыш Европада яшәргә мәҗбүр булганнар, анда берничә газета нәшер иткәннәр. Тукайның шигыре язылганнан соң якынча бер ел үтүгә, «яшь төрекләр», Истанбулда инкыйлаб ясап, Габделхәмит солтанны, парламент төзүгә мәҗбүр итеп, 1909 елда бөтенләй хакимияттән читләштерәләр. Нәкъ Тукай язганча («Сез рәисе залимани «Йолдыз»а хәбсидеңез»), башта солтанны «Йолдыз» сараенда бикләп тоталар, аннан соң инде Салоники шәһәре янындагы виллага сөрәләр.

2 Хәҗҗаҗ (Хәҗҗаҗ бине Йосыф әс-Сәкафи) – Өмәви ханәданыннан (династиясеннән) Габделмәлик һәм Вәлид I хәлифәләрнең Хиҗаздагы һәм Гыйрактагы валисе (губернаторы). Кансызлыгы һәм рәхимсезлеге белән дан казана. Кайбер табигыйннәр (сәхабәләрнең шәкертләре) аны тәкфир кылалар (кяфер булуда гаеплиләр). Тукай Габделхәмит солтанны Хәҗҗаҗга тиңләштерә.

116 бит.

Хур кызына. «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 15 сентябрь (9) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, «3 нче дәфтәр»дә (1907) чыккан. Текст шуннан алынды.

Шигырь М.Лермонтовның «К деве небесной» (1831) әсәреннән икътибас (алу, файдалану) рәвешендә язылган. Бу хакта Тукай болай язган: «Төрекләргә тәкълид (иярү) вакытында Лермонтовтан бик зәгыйфь бер тәрҗемәм» («Мәҗмугаи асар», 1914).

Лермонтов шигыренең тексты түбәндәгечә:

Когда бы встретил я в раю
На третьем небе образ твой,
Он душу бы пленил мою
Своей небесной красотой;
И я б в тот миг (не утаю)
Забыл о радости земной.

Спокоен твой лазурный взор,
Как вспоминание об нем;
Как дальний отзыв дальних гор,
Твой голос нравится во всем;
И твой привет и твой укор,
Все полно, дышит божеством.

Не для земли ты создана,
И я могу ль тебя любить?
Другая женщина должна
Надежды юноши манить;
Ты превосходней, чем она,
Но так мила не можешь быть!

118 бит.

Пыяла баш. «Уклар» журналының 1906 елгы сентябрь санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Академик басманың 1 нче томында (1943) урын алган. Текст «Уклар»дан алынды.

Журналда төп текст алдыннан адәм башы ясалган һәм рәсем астында русча болай язылган: «Квартиранты в черепе некоего «благомыслящего» татарина. Больше «Стрелы» («Уклар» журналы) при исследовании пока никаких предметов не могли найти, но... все-таки открыли там еще и изрядное пустое пространство...»

Шигырьнең ике бәйте (бер сүзе үзгәртелеп) 1906 елгы, 24 сентябрь санында чыккан «Фикер» газетасы битләрендә дә бирелә:

Карагыз сез безем хәзрәт миенә,
Миендә мәгърифәт дәрде бииме?..
Бөтенләй мөртәсәм фикре миендә:
Кымыз, шурпа, бәлеш, тәңкә, тиен дә.

120 бит.

Рәсемгә ишарә. «Уклар»ның 1906 елгы сентябрь санында «Шүрәле» имзасы белән чыккан, «4 нче дәфтәр»дә (1907) басылган. Текст шуннан алынды.

Журнал битенә капшавычлары белән мөселманнарны чорнап алган чаян рәсеме урнаштырылган, аның астына: «Ушбуның кеби хорафате игътикад астында» һәм «В тисках предрассудка, суеверия и невежества» дип аңлатма бирелгән.

122 бит.

*** («Кыямәт якын килде – җир сораучы ярылды...»). «Уклар» журналының 1906 елгы октябрь санында «Хәсрәт» псевдонимы белән басылган. Берничә мәртәбә Биштомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

Журналда шигырь Тукайның «Куркынычлы хәбәр. Кыямәт» атлы сатирик әсәреннән соң басылган. Үлчәме һәм рәдифе (рефрены) мәшһүр «Бәдәвам» китабыннан алынган.

1 «Азад» – 1906 елда (1 февраль – 30 май) Казанда атнасына өч тапкыр нәшер ителгән иҗтимагый-сәяси юнәлешле газета. Җәмгысы 56 саны чыгып өлгерә. Рәсми нашире һәм мөхәррире – Габдулла Апанаев, гамәлдә исә мөхәррирлекне Галиәсгар Камал башкарган.

2 «Азат халык» – 1906 елда (4 июнь – 12 сентябрь) Казанда чыккан атналык газета, «Азад»ның фикри дәвамчысы. Г.Камал мөхәррирлегендә барлыгы 15 саны чыгып кала.

123 бит.

Күз. «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 15 октябрь санында «Г.Т.» имзасы белән чыккан. «4 нче дәфтәр»дә (1907) һәм «Мәҗмугаи асарь»дә басылган. Соңгысында «Такыр калды татар башы кеби кыр» дигән юлындагы «татар» сүзе «фәкыйрь» дип үзгәртелгән. Текст «4 нче дәфтәр»дән (1907) алынды.

125 бит.

Государственная думага. «Фикер»нең 1906 елгы 22 октябрь һәм 5 ноябрь (бераз үзгәртелеп) саннарында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Өчтомлыкта бирелгән. Текст «Фикер»дән алынды.

Шигырь 1906 елның 9 июлендә чыккан патша манифесты нигезендә I Дәүләт думасының таратылуы уңаеннан язылган.

1 Ник баш бөктең залимнәргә... – бу сүз бик үк төгәл түгел. Дума таратылганнан соң, аның 230 әгъзасы, Выборг шәһәрендә җыелып, «Халык вәкилләреннән халыкка» исемле мөрәҗәгать кабул итәләр, халыкны хөкүмәткә салым түләмәскә, патша армиясенә бармаска өндиләр. Бу депутатларның һәммәсе дә, кулга алынып, 30 көнгә төрмәгә ябылалар.

2 Бирәм дидең, вәгъдә бирдең, күрсәт җиреңʔ.. – I Думада закон проекты төзелә һәм аның буенча җир, эре биләүчеләрдән тартып алынып, гади игенчеләрнең хосусый милегенә тапшырылырга тиеш була.

127 бит.

Милләтә. «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 15 октябрь санында «Гъ.Т.» имзасы белән чыккан. «4 нче дәфтәр»дә (1907) басылган. Текст шуннан алынды.

129 бит.

Дөнья бу, йа! «Уклар» журналының 1906 елгы октябрь санында «Шүрәле» имзасы белән чыккан. «Шигырьләр» җыентыгында (төзүчесе – Ф.Бурнаш) басылган. Текст «Уклар»дан алынды.

Шигырьнең вәзене, кафиясе (рифмасы) һәм рәдифе (рефрены) «Бакырган китабы»ннан алынган. Хәтта аның беренче бәйте (икеюллыгы) «Бакырган»дагысыннан бер генә сүзе белән аерыла. «Бакырган»да ул түбәндәгечә:

И күңел, бил баглама, күпне кичергән дөньядыр,
Бу үлем ширбәтен халыкка эчергән дөньядыр.

1 Сәйдәш абзый – Әхмәтҗан Яхъя улы Сәйдәшев (1840–1912), Лаеш өязеннән чыгышлы Казан сәүдәгәре һәм хәйрияче-химаячесе. «Торгово-промышленное товарищество Ахметзян Сайдашев с сыновьями и Бакий Субаев в Казани» ширкәте хуҗаларыннан берсе. Чәй, шикәр, шешә, пыяла һ.б. продукция чыгарган. Шәһәрдә йогынтысы көчле булганга, «татарский губернатор Казани» кушаматы белән дә йөртелгән. Милләте өчен күп тырышлык куйган затларның берсе. 1906 елның 31 мартыннан алып консерватив мәсләкле «Бәянелхак» газетасы нашире. Яңалыкка һәм тәрәккыятькә омтылган Габдулла Тукайның милли традицияләрне яклап барган Ә. Сәйдәшев белән низагы котылгысыз булган. Шул ук вакытта Сәйдәшевнең Тукайның кайбер җыентыкларын чыгарырга матди булышлык күрсәтүе дә мәгълүм.

2 Рәшид – Габдерәшид Ибраһимов (1857–1944). Себер төркиләреннән. Галимҗан Ибраһимов тарафыннан «тарихи кыңгыравык» дип аталган күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Санкт-Петербургта чыгарылган « Өлфәт» газетасы нашире һәм мөхәррире, «Автономия, яки Идарәи мохтария», «Чулпан йолдызы» һ.б. китаплар авторы, «Иттифак әл-мөслимин»не төп төзүчеләрдән берсе, ислам дәгъватчысы, сәяхәтче. 1906 елның 1 гыйнварында чыккан «Фикер» газетасында Тукай « Өлфәт» газетасын нәшер иткәне өчен Г.Ибраһимовны болай мактый:

Рөшде вар, кауле гүзәл, наме Рәшид;

Җөмлә бу иршад илә улсын рәшид!
Шатлык илә итмәлиез « Өлфәт» илә өлфәти:
Тәрк идәлем иддигани һәм тәкәллеф-көлфәти!
(Камил зиһене бар, сүзе матур, исеме Рәшид;
Барысы да бу җитәкчелек астында тугры юлга бассын!
Куанып « Өлфәт» белән дуслык корыйк:
Дәгъвачылык һәм тәкәллефне читкә ташлыйк!)

(Биштомлык. 1 нче том. Б. 319 б.)

Тукайның Г.Ибраһимовка мөнәсәбәте үзгәрүе аның социал-демократлар фикерен шактый ук үз итеп, либераль милли буржуазиягә һәм аның идеологиясенә каршы торуы белән аңлатыла булса кирәк. Гомумирәк әйткәндә, бу низагта традицион һәм яңалык салынган фикерләрнең бәрелешүе, өлкән һәм яшь буыннар арасындагы табигый каршылыкның четерекле яклары чагыла.

3 «Тәрҗеман» – Русия төркиләренең Исмәгыйль бәк Гаспралы (Исмәгыйль Гаспринский) (1851–1914) наширлеге һәм мөхәррирлегендә 1883 елда чыга башлаган беренче газетасы. «Камусы гыйльми» (тулы исеме – «Камусы гыйльмия вә фәнния» ягъни «Фәнни энциклопедия») исә анда басылган фәнни мәкаләләрнең рубрика исеме.

4 «Ха-ха-ха» – И.Гаспринский 1906 елда чыгарган көлке журналы.

5 «Азат халык» – Казанда 1906 елның 4 июненнән башлап 12 сентябренә кадәр чыккан демократик юнәлешле газета. Нашире һәм мөхәррире – Галиәсгар Камал. Газета ябылгач, ул «Йолдыз» газетасына эшкә күчә. Тукайның моңа ачуы килә.

6 Һади абзый – Әхмәдһади Максуди (1868–1941), күренекле нашир, мөхәррир һәм мөгаллим. 1906 елдан 1918 елга кадәр мәшһүр, иң зур тиражлы «Йолдыз» газетасын чыгарган. 30 дан артык фәнни һәм дини әсәр авторы. Аның «Мөгаллиме әүвәл» һәм «Мөгаллиме сани», «Гыйбадәте исламия» кебек китаплары халык арасында аеруча популярлык казана. Әдәбиятта һәм җәмгыятьтә «инкыйлаб» ясауны ниятләгән яшь иҗатчылар вәкиле буларак, Тукайның Максудига да дәгъвасы булмый калмаган, әлбәттә.

130 бит.

«Мөхәммәдия» көе. «Уклар»ның 1906 елгы октябрь санында «Тәртә башы» имзасы белән басылган. Чәчмә рәвешендә «Фикер»нең 1906 елгы, 3 июль санында ук «Алай-болай» фельетоны эчендә бирелә: «Бабай Сәйдәш, надан Сәйдәш, усал эт төсле тик чәйнәш; безем корган нигезләр бер дә селкенмәй дә чайкалмай». Шул ук фельетонның икенче өлешендә тема болай дәвам иттерелә: «Безне дә Әхмәтҗан абзый окружныйга бирә: әйдә судлаш, давай судлаш. Әйдә, Сәйдәш, әйдә чәйнәш!» (1906 ел, 21 июль).

Гомумән, 1906 елда Әхмәтҗан Сәйдәшевкә яшьләрдән, аеруча шәкерт халкыннан шактый «эләгә». Мәсәлән, « Өлфәт» газетасының шул елдагы 5 гыйнвар санында «Таләбәдән бере» («Шәкертләрдән берсе») имзасы белән «Казаннан мәктүп» дигән язма урнаштырыла. Аның авторы Ә.Сәйдәшевне яманлап болай яза: «...Сәйдәшев вә гаунәсе (ярдәмчеләре) кара йөз тарафдары улмакны (булуны) мөнасыйб (хуп) күрәләр, шул максада мәбнә (нигезләнеп) 22 октябрьдә крестный ход артыннан егерме кадәр имам бәрабәр (бергә) тәкбир әйтеп йөрделәр». Моннан тыш, Ә. Сәйдәшевне Казан

мөселманнары бойкот кылалар, дип яза да хатын «бу язылмышларның һичберсе һәзел (шаяру) вәйә (яки) мобаләга (күпертү) дәгелдер (түгел)» дигән сүзләр белән тәмамлый.

Сәйдәшев бу гаепләүләрне кире кага һәм « Өлфәт»нең 23 февраль санында рәддия бастыра. Анда, җөмләдән, шундый сүзләр бар: «Казанда крестный ход артыннан йөргән кеше һич булмады, имамнарыбыз белән Казанның ничә мең мөселман губернаторга 17 нче октябрь Манифестын тәбрик итү өчен җыелып бардык». Еллар узгач, христианнарның тәре йөртүләре белән мөселманнарның Манифест чыгу уңаеннан губернаторны тәбрик итәргә барулары бер вакытка туры килү совет тарихчылары өчен «буржуаз динчеләрне» «фаш итү»гә менә дигән сылтау булып хезмәт итә.

1 «Мөхәммәдия» – госманлы шагыйре Мөхәммәд Язычы угылы Чәләбинең (XV гасыр) зур күләмле шигъри әсәре. Идел-Урал төрки-татарлары арасында искиткеч шөһрәт казанып, гасырлар буе укылды һәм хәзер дә укыла.

Текст «Уклар» журналыннан алынды.

131 бит.

Сөеклемең кабер ташында. «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 15 ноябрь (11 нче) санында «Гъ.Т.» инициаллары белән басылган. «4 нче дәфтәр»гә кертелгән. Текст «Әлгасрелҗәдид»тән алынды.

132 бит

«Уклар». «Уклар»ның 1906 елгы ноябрь (6 нчы) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Өчтомлыкның 1 нче томына урнаштырылган.

Текст «Уклар»дан алынды.

133 бит.

Үз-үземә. «Әлгасрелҗәдид» журналының 1906 елгы 15 ноябрь (11 нче) санында «Гъ.Т.» имзасы белән чыккан. «4 нче дәфтәр»дә (1907) басылган. Текст шуннан алынды.

Шигырьнең исеме астына Тукай «Пушкиннең бер шигыреннән мокътәбәс» дип куйган. Сүз рус шагыйренең «Про себя» дигән дүртьюллыгы (дөрес, аның Пушкин әсәре булуы әле дә исбатланмаган) хакында. Ул түбәндәгечә:

Великим быть желаю,
Люблю России честь,
Я много обещаю –
Исполню ли? Бог весть!

«Әлгасрелҗәдид»тәге «Күрергә шаһлыгын, тәхтен татарның» дигән юл «4 нче дәфтәр»дә «Күрергә җанлылык вактын татарның» рәвешендә үзгәртелгән. Гадәтенчә, Тукайның «мокътәбәс» шигырь-тәрҗемәләре, яңа фикер һәм сурәтләр өстәлү сәбәпле, оригиналдан шактый күләмлерәк чыккан. «Үз-үземә» очрагында да бу кагыйдә саклана.

134 бит.

Кичке азан. «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы ноябрь (11 нче) санында, «Фикер»нең шул ук елгы 26 ноябрь (44 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән чыккан. «4 нче дәфтәр»дә

(1907) басылган. Бу басмаларда төп исеме – «Һәм мәнзум, һәм мәнсур» («Шигъри дә, чәчмә дә»), аннан җәя эчендә «Кичке азан» дип куйган. «4 нче дәфтәр»дә (1909) исә «Кичке азан» исеме алга куелган һәм:

Беләмсез, ни диер азан:
Китте Касыйм,
Китте Казан.
Бетте татар,
Кырылды хан,
Бохар, Хуканд
Һәм Әстерхан, –

дигән юллары төшереп калдырылган.

«Әлгасрелҗәдид» журналында шигырьдән соң Тукайның аңа аңлатмасы урнаштырылган. Ул түбәндәгечә:

«Русларда вә башка мөтәмәддин (мәдәниятле) милләтләрдә һәр сәтыры (юлы) ике сүздән гыйбарәт, ләкин гаять мәгънәле шигырьләр вардыр. Мин, монда нәмунә (үрнәк) өчен Лермонтовның бер шигырен алып, шул ук мотивка «Кичке азан» сәрләүхәсилә (исеме белән) гаҗизанә (зәгыйфь) бер шигырь яздым.

Вверху одна
Горит звезда,
Мой взор она
Манит всегда;
Она влечет,
И с высоты
Меня зовет
Таков же был
Тот светлый взор,
Что я любил
Судьбе в укор.
Мук никогда
Он зреть не мог;
Как та звезда
Он был высок.
Усталых вежд
Я не смыкал,
И без надежд
К нему взывал.
Лермонтов».

Бу – «Звезда» («Вверху одна...») шигыре, әмма кайбер урыннарда яшь Тукай аны күчереп алганда төгәлсезлекләр җибәргән, «ум», «нежный», «далек», «взирал» сүзләре урынына «взор», «светлый», «высок», «взывал» дип куйган. Монысы, мөгаен, әсәрне яттан күчереп язуы аркасында булгандыр.

Һәрхәлдә, искәрмәдә бары тик Лермонтов шигыренең метрикасы турында әйтелә, тәрҗемә (икътибас) ителгән шигырьнең исеме исә билгесез кала. Хәлбуки «Кичке азан» – рус шагыйре И.И.Козловның «Вечерний звон» әсәреннән (1827) ирекле тәрҗемә. Үз нәүбәтендә Козлов шулай ук аны инглиз (дөресрәге, ирландияле) шагыйре Томас Мурның (Thomas Moore, 1779–1852) «Those evening bells» («Шул кичке чаң», 1818) исемле шигыреннән ирекле тәрҗемә иткән, тик оригиналның исемен, Тукай шикелле үк, күрсәтмәгән. Соңыннан (якынча 1830 елда) атаклы композитор А.А.Алябьев Козлов шигырен музыкага сала, һәм ул мәшһүр җыр булып китә.

«Кичке азан»ны Г.Тукай иң элек үзе (бер иптәше белән) «Казан» кунакханәсе залында «рус-мөселман концерты»нда укый. Бу хакта «Фикер»нең 1907 елгы 18 март санында мондый хәбәр басылган: «Г.Тукаев илә Сиражетдин Билюков әфәнделәр чыгып, Шәрекъ ысулынча тезләнеп, милли кием илә «Кичке азан» шигырене укыдылар...»

«Кичке азан» метрикасы һәм беренче юллары белән «Вечерний звон»га охшаса да, биредә Тукай, башка тәрҗемә-икътибасларындагы шикелле үк, теманы киңәйтә һәм бөтенләй диярлек үзгәртеп җибәрә.

1913 елда Габдулла Тукай кайчандыр илһамланып язган шигырен инде уңышсыз әсәргә тиңли, аны басылачак әсәрләр җыентыгына кертмәскә катгый карар кыла («Уянгач беренче эшем»).

136 бит.

Мактанышу. «Фикер»нең 1906 елгы 19 ноябрь (43 нче) санында «ахыры бар»лыгы искәртелеп, имзасыз басылган. 1914 елгы «Мәҗмугаи асарь»гә кертелгән. Текст газетадан алынды.

Шигырь «Бакырган китабы» вәзенендә язылган. Ул гына түгел, ике дүртьюллыгында «Бакырган»дагы җөмлә төзелеше һәм күп сүзләре кабатлана. Тукайда «оҗмах» – «ишан»; «тәмуг» – «ишәк»; «фиргавен» – «нукта», «җөгән» сүзләре белән алышынган. Мисал итеп, түбәндәге шигырьне китерик:

Оҗмах, тәмуг өкешер (мактанышыр),
Өкешмәктә (мактанышуда) мәгънә бар;
Тәмуг әйтер: «Мән баймын,
Мәндә фиргавен һаман бар».
Оҗмах әйтер: «Юк сәндә,
Җөмлә (барча) пәйгамбәр мәндә...»

Тукай шигыренең исеме дә, аңлы рәвештә бу өзекнең эчтәлегенә туры китереп, аңа назыйрә (охшату) рәвешендә куелган.

138 бит.

«Дөнья» көенә. «Фикер»нең 1906 елгы 3 декабрь (45 нче) санында имзасыз басылган. Дин әһелләрен шактый ук дорфа тәгъбирләр белән сыйфатлаган бу һиҗви (сатирик) әсәр Тукай исән чакта кабат нәшер ителмәгән, фәкать 1914 елда гына «Мәҗмугаи асарь»дә басылган.

Текст «Фикер»дән алынды.

139 бит.

Әдәбият ахшамы ясаучы яшьләремезгә. «Әлгасрелҗәдид» журналының 1906 елгы 5 декабрь (12 нче) санында «Гъ.Т.» инициаллары һәм «ахыры бар» дип басылган. «4 нче дәфтәр»гә (1907) кертелгән. Текст шуннан алынды.

Уральскида ясалачак бу әдәби кичә турында Габдулла Тукай «Фикер» газетасының 22 октябрь санында «Әдәбият ахшамы, яки Литературно-музыкальный вечер» дигән мәкалә бастырып чыгара, укучыларны анда катнашырга чакыра. Газетаның 1907 елгы 18 март санында шул «ахшам»нан репортаж бирелгән.

141 бит.

«Әлгасрелҗәдид»ә маддәтән вә мәгънән иштиракь идәнләрең лисане хале нә диер? «Әлгасрелҗәдид»нең 1906 елгы 5 декабрь (12 нче) санында «Гъ.Т.» инициаллары куеп басылган. «4 нче дәфтәр»дә (1907) урын алган. Бу җыентыкның 1909 елгы басмасына шигырь кертелмәгән. Текст «4 нче дәфтәр»дән (1907) алынды.

1 Вә нәфх итдек без, Исрафил кеби, сур... – ислам динендә Исрафил – дүрт төп фәрештәләрнең берсе. Кыямәт көнендә ул, сур (быргы) кычкыртып («нәфех итеп» – өрдереп), фани дөнья гомеренең төкәнеп, ахирәт дөньясы башлануын белгертәчәк.

1907

143 бит.

Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр. «Әлгасрелҗәдид»нең 1907 елгы 25 гыйнвар (1) санында, шулай ук «Фикер»нең 27 гыйнвар санында шул ук имза белән (икенчесендә исеме – «Чыккан шәкертләр ни диләр») басылган. «Мәҗмугаи асарь»гә (1914) 7, 9, 10, 19 строфалары төшереп кертелгән. Текст «4 нче дәфтәр»дән(1907) алынды.

Шигырь Тукайның «Мотыйгыя» мәдрәсәсеннән Уральскиның «Казан» кунакханәсенә күчкән көннәренә карый. Бу хакта ул үзе «Фикер»нең 21 гыйнвар санындагы белдерүендә түбәндәгеләрне яза: «Мин бу көннәрдә генә мәдрәсәи «Мотыйгыя»дән чыктым. Бинаән галәйһи (шуңа күрә) дустларым вә якыннарыма игълям итәмен (белдерәм) ки, бу көннән ары миңа язачак мәктүпләренең адресын болай язсыннар: Уральск, гостиница «Казань», А.Тукаеву. Бакый (мәңге) ихтирам: Г.Тукаев».

Шигырь, зур шәкерт дөньясына мөрәҗәгать иткәне сәбәпле, шәкертләр арасында тиз таралып, алар тарафыннан җылы кабул ителә һәм күп кенә мәдрәсәләрдә әдәбият ахшамнары вакытында кычкырып та укыла.

XX гасыр башы милли шигъриятебездә яхшы ук танылган Мөхәммәдгариф Шәрифи Тукайның бу шигыренә иярербрәк, «Иске мәдрәсәдән чыккан бер шәкертнең зары» исемендә шигырь бастыра (Ялт-йолт. 1912. № 33).

149 бит.

Сөальләр. «Әлгасрелҗәдид»нең 1907 елгы 25 гыйнвар (1) санында «Габдулла Тукаев» имзасы белән чыккан. «4 нче дәфтәр»дә (1907, 1909) басылган. Текст «4 нче дәфтәр»дән (1907) алынды.

1 «Шөбһәдер: бәдтәр бу нәфсем шәйхе Нәҗдидән дәми?» – Шәех Нәҗди – ваһһабилар хәрәкәте һәм тәгълиматына нигез салучы, «Китабе әт-тәүхид» («Аллаһның берлеге

турында китаб») авторы Мөхәммәд бине Габделвәһһаб (1703–1791). Мөселманнарның күпчелеге ваһһабилыкны зарарлы секта дип санийлар. Ваһһабилар исә исламдагы дүрт мәзһәпкә, шул исәптән Әбу Хәнифә мәзһәбенә, «сукырларча ябышуны» кире кагалар, бары тик үзләрен «чын мөселман» дип атыйлар. Тукай заманында «исламны асылына кайтару»(ягъни Идел-Урал регионындагы җирле ислам традициясенә, «иҗтиһад»ка хилаф килгән) идеясен алга сөргән ваһһабиларга карата мөнәсәбәт, әлбәттә, тискәре булган, шуңа күрә дә Тукай «мин шәйхе Нәҗдидән дә начармы?» дип яза.

151 бит.

Шагыйрьгә. «Әлгасрелҗәдид»нең 1907 елгы 15 февраль (2) санында «Г.Тукаев» имзасы белән чыккан. «3 нче дәфтәр»дә (1907) басылган. Текст шуннан алынды.

Шигырь – М.Ю.Лермонтовның «Г[ну] Павлову» исемле әсәренең ирекле тәрҗемәсе. Журналда барлыгы 8 бәйт (икеюллык) бар.

Бу сүзләрне язып «Гасрел җәдид»кә,
Итәм тәкъдим Нәҗип берлән Мәҗиткә, –

дигән соңгысы (ул йолдызчыклар белән аерылган) «3 нче дәфтәр»дәге тексттан төшереп калдырылган.

Лермонтов шигыренең тексты түбәндәгечә:

Как вас зовут? Ужель поэтом?
Я вас прошу в последний раз,
Не называйтесь так пред светом:
Фигляром назовет он вас!
Пускай никто про вас не скажет:
Вот стихотворец, вот поэт;
Вас этот титул только свяжет,
С ним привилегий вовсе нет.

1 Нәҗип берлән Мәҗиткә – Нәҗип Думави (1883–1933) белән Мәҗит Гафури (1880–1934) күздә тотыла.

152 бит.

Хөрриятә. «Әлгасрелҗәдид»нең 1907 елгы 15 февраль (2 нче), « Өлфәт»нең 1907 елгы 1 март саннарында «Г.Тукаев» имзасы белән чыккан. «4 нче дәфтәр»дә басылган. Соңгы басмада әсәр җитди үзгәртүләргә дучар була. Беренчедән, шигырьнең исеме «Мөхәммәдия»дән дип куелган. Икенчедән,

Зөбанилар, кылыч, туплар, казак, мылтык, палачларла
Мөхатыз һәр җәһәтдән: сагъ вә сулдан, зир вә балядан.
Эчәрләр канларын әһле къолубең, чөнки кан эчмәк
Хәлявәтледер анларча шикәрдән һәм дә хәлвәдән, –

строфалары урынына күп ноктаалар куелган.

Өченчедән,

Йидермә кяинати, сакла бу Яэҗүҗе-Мәэҗүҗдән,

Вә чәкдер сәдде Искәндәр бөтен әсхабе Думадан, –

строфасыннан «Думадан» сүзе алып ташланып, урынына күп нокталар куелган.

Дүртенчедән,

Баш икдек, сагыйр улдык һәр шинель кигән санәмләргә, –

дигән юлда «шинель кигән» гыйбарәсе «кечек башлы»га үзгәртелгән. Билгеле ки, болар цензура таләпләреннән чыгып эшләнә, чөнки 1907 елда, кара реакция хакимлек итә башлаган шартларда, инде хөррият турында хыялланырга гына кала.

« Өлфәт»газетасы мөхәррире Габдеррәшид Ибраһимов «Әдәбият галәме» рубрикасында басылган «Хөрриятә» шигыре текстына мондый искәрмә бирә: «Әлгасрелҗәдид»нең һичбер нөсхәсе юк иде ки, яңа шагыйремез Г.Тукаев җәнабләренең гүзәл шигырьләре илә зиннәтләнмеш улмасын» («Әлгасрелҗәдид»нең яңа шагыйребез Г.Тукаев җәнабләренең матур шигырьләре белән бизәкләнмәгән бер генә саны да юк иде»)...Без, ядкяр улсын өчен, Г.Тукаев җәнабләренең шу соң № да (15 февраль № да) дәреҗ иделмеш «Хөрриятә» гонванлы шигырен бу йирдә нәкыль идийерез» («Без, истәлеккә булсын дип, Г.Тукаев җәнабләренең шушы соңгы санда (15 февраль санында) басылган «Хөрриятә» исемле шигырен бу урында күчереп бастырабыз»).

1 Мәнат, Лат вә Гозза – Исламга кадәрге чорда гарәпләрнең төп мәҗүси мәгъбүдләре (табынган потлары). Әл-Латка – «сукаеф», әл-Гоззага – «кораеш» һәм «бану кинанә», Манатка «бану һилал», «әл-гаус», «әл-хәзрәҗ» кабиләләре багынган.

2 Ганка – риваятьләрдә Каф тавында яшәгәнлеге фараз ителгән зур кош, «Сәмруг кошы» дип тә әйтелә. Ганка гаделлек һәм бәхет символы санала. Икенче мәгънәсе – исеме бар, җисеме юк нәрсә.

3 Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ – борынгы риваятьләр буенча, хәзерге Монголия һәм Тибет җирендә яшәгән кечкенә буйлы, кысык күзле кавем. Ислам динендә «дөнья бетәр алдыннан кешеләргә рәхимсез кыргый халыклар ябырылачак, алар бөтен җанлы мәхлукларны тереләй ашап барачак» дип гөман ителә. Тукай нәкъ шуңа ишарә ясый. Коръәннең «Әнбия» сүрәсендәге 96 аятьтә мондый сүзләр бар: «Хәтта иза футихат Яэҗүҗ вә Мәэҗүҗ вә һүммин күлли хәдәбин йәнсилүн» («Хәтта Яэҗүҗ вә Мәэҗүҗнең диварлары ачылганга чаклы вә алар барчасы һәр югары урыннан мәхшәр җиренә килеп җыелырлар»).

4 Сәдде Искәндәр – тынычлык шартларында яшәгән халыкларны юлбасар яэҗүҗ-мәүҗүҗләрдән сакларга дип Искәндәр Зөлкарнаен тарафыннан төзелгән биек там (дивар, стена).

Шигырьнең тексты «Әлгасрелҗәдид»тән алынды.

156 бит.

Тартар кошы сайрый. «Фикер»нең 1907 елгы 11 март (10 нчы) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басыла, аннан соң Икетомлыкта дөнья күрә. Текст газетадан алынды.

Шигырьнең дүрт юлы «Әлгасрелҗәдид» журналының 1907 елгы 15 апрель (4 нче) санында «Мәгариф хәяттыр» исемле мәкалә эченә мондый рәвешле китерелгән: «Мәгариф

хәяттыр. Мәгариф хәяттыр. Мәгариф хәяттыр. Һәр бәхетне, һәр сәгадәтне, һәр нәҗатны(котылуны) анчак (фәкать) голүм (гыйлемнәр) вә мәгърифәттән генә көтмәк кирәктер...»

11 нче «Фикер»дәге тартар кошының:

Гыйльмә рәгъбәт сал, татар,
Ит син шуны алтатар;
Корсын туплар! Мәктәпләр –
Сезнең арсенал, татар, –

дигән сүзләре тәмамилә бу «Мәгариф хәяттыр» мәкаләсенең мәзмүнедер (эчтәлеге). Өмид анчак мәктәпләрдә генә».

1 Алтатар – алты патрон корулы «наган» револьверы.

2 Куркъма, зинһар, аздырмый һәрбер тар чалбар... – кадимчеләрнең (традиционалистларның) европача чалбар киеп йөрүчеләргә тискәре караштa булуы күздә тотыла.

158 бит.

Теләнче. «Әлгасрелҗәдид»нең 1907 елгы 15 март санында, шулай ук «3 нче дәфтәр»дә (1907) басылган. Текст соңгысыннан алынды.

Тукай бу шигырен Уральскида чакта ук «Казан» кунакханәсендә узган әдәби-музыкаль кичәдә сәхнәдән сөйләгән. Бу хакта «Фикер»нең 1907 елгы 18 март санында мондый хәбәр бар: «4 нче пәрдә күтәрелгәч, Г.Тукаев теләнче киеме киенгән Хәкимҗан Йосыфовның өстенә карап «Теләнче» сәрләүхәле (исемле) шигырене сөйләде. Бу шигырьне укыганда көйләмичә, нәсер шикелле итеп, җөмләләрен аерып, калын тавыш белән әйтә иде».

Г.Кариев үзенең истәлекләрендә Тукайның шигырь сөйләвен «халык бик яратты» дип яза. (Тукай турында замандашлары. – Казан, 1960. – 44 б.).

160 бит.

Син булмасаң! «Әлгасрелҗәдид»нең 1907 елгы 15 март (3 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән чыккан. «3 нче дәфтәр»дә (1907) басылган. Текст шуннан алынды.

162 бит.

«Тәрбиятел этфаль»гә. «3 нче дәфтәр»дә (1907) басылып чыккан. Текст шуннан алынды.

Шигырь Мәскәүдә барлыгы биш саны чыгып калып, март аенда нәшер ителүдән туктаган «Тәрбиятел этфаль» («Балаларны тәрбия кылу») журналының (нашире һәм мөхәррире Мөхәммәдзаһид Шамил (1868–1920), нашире һәм җаваплы мөхәррире Хөсәен Байбәков (? – 1919 елдан соң), җаваплы сәркәтибе Фатих Әмирхан) ябылуына мөнәсәбәтле рәвештә язылган.

166 бит.

Күрдегезме? «Фикер»нең 1907 елгы 2 апрель (13 нче) санына кушымтасында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

1 Дөнья мәгыйшәт (1906 елның 31 декабреннән – «Дөнья вә мәгыйшәт», наширләре – Ш.Шәфигуллин, М.Дәүләтшин, мөхәррире – З.Хәйруллин, 1907 елның 13 апреленнән – «Дин вә мәгыйшәт» («Дин һәм тормыш»), нашире – М.Хөсәенов, мөхәррирләре – Ф.Даутов һәм Г.Ханисламов) – Оренбургта 1906–1917 елларда чыккан кадимче-консерваторлар журналы.

167 бит.

Яз («Тыныч торма, каләм, дәртеңне яз, яз!»). «Әлгасрелҗәдид»нең 1907 елгы 15 апрель (4 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылып чыккан. «Ахыры бар» дип куелган. Текст шуннан алынды.

1 Өрелмеш дип белерсең санки мөгез – Исрафил фәрештәнең сур өргәне күздә тотыла.

2 Халкы Хаува, халкы Адәм – Адәм пәйгамбәр белән Хаува нәселе, ягъни җир халкы.

169 бит.

Бишектәге бала. «Әлгасрелҗәдид»нең 1907 елгы 15 апрель (4 нче) санында чыккан. Шулай ук «3 нче дәфтәр»дә (1907) басылган. Текст астына «Лермонтов», аннан соң «Г.Т.» дип куелган. Текст «3 нче дәфтәр»дән алынды.

Шигырь М.Ю.Лермонтовның «Дитя в люльке (из Шиллера)» (1829) исемле әсәреннән икътибас кылынып (файдаланып) язылган. Соңгысының тексты болай:

Счастлив ребенок! И в люльке просторно ему: но дай время
Сделаться мужем, и тесен покажется мир.

Оригиналдан аермалы буларак, Тукай шигыре дүрт юлдан гыйбарәт.

170 бит.

Шиллердән. «Әлгасрелҗәдид»нең 1907 елгы 15 апрель (4 нче) санында, шулай ук «3 нче дәфтәр»дә (1907) басылган. Автор, «Бишектәге бала»дагы кебек үк, астына «Лермонтов» һәм «Гъ.Т.» дип куйган. Текст «Әлгасрелҗәдид»тән алынды.

Шигырь М.Ю.Лермонтовның «К***» (из Шиллера) әсәреннән икътибас итеп язылган. Соңгысының тексты түбәндәгечә:

Делись со мною тем, что знаешь,
И благодарен буду я.
Но ты мне душу предлагаешь:
На кой мне чорт душа твоя!..

171 бит.

Мөтәшагыйрьгә. «Әлгасрелҗәдид»нең 1907 елгы 15 апрель (4 нче) санында «Г.Т.» инициаллары куелып басылган. «3 нче дәфтәр»дә чыккан. Текст шуннан алынды.

Бу шигырь заманында зур аңлашылмаучылыкка, хәтта җәнҗалга сәбәп була, шуңа күрә ул җәнҗалга турыдан-туры караган шигырь һәм хат язышуны монда бирергә булдык.

Шигырь текстында «вакты» сүзе куштырнаклар эченә алынганга, «Вакыт» газетасы нашире, шагыйрь Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) аны үз адресына юлланган дип кабул итеп,

«Әдәбият мәҗмугасе»ндә («Вакыт»ның кушымтасы, 1907, 12 сан) «Шагыйрьгә» исемле әсәрен бастырып чыгара. Анда, җөмләдән, түбәндәге юллар бар:

«Ничөн бу хиддәт, и шагыйрь,
Нәдер бу ярганың ярма?
Эчеңдә бармы йә бер чир,
Вәйә синдә күңел тарма?
Әдиплек шәэнени саклап,
Әдәпле сирәт эзләп тап,
Бигүк түрләргә уздырма
Катаңны да хата мактап.
Бирелмә ул кадәр зарга,
Сиңа көндәш түгел карга;
Вәли бик калкынып очма,
Сакын, тап булма шоңкарга!..».

Әлбәттә, Тукай мондый кискен гаепләүне буш калдырмый, тиз генә «Йолдыз» газетасында (1907, 12 июль) «Аңлашу» дип атап, җавабын да урнаштыра: «Мөхтәрәм «Вакыт» гәзитәсенең 12 номер «Әдәбият мәҗмугасе»нең ахыргы сәхифәсендә һич мөнәсәбәтсез вә хаксыз уларак «Мөтәшагыйрьгә» дигән шигыремә каршы мине тәхкыйрь юллы язылмыш шигырьләр дәреҗ ителмеш.

Бәнем «Мөтәшагыйрьгә» шигырене язуым асла «Вакыт» гәзитәсенә юнәлтеп түгелдер. Шул шигырьне язганда, «Вакыт» гәзитәсе минем хәтеремә дә килгәне юктыр.

Беләм ки, минем шигыремдә «вакыт» ләфзының мөгътәриза (җәя) эченә хатамы йә үземнең синтаксик кагыйдәсенә мөсаһәлә итүемнәнме (күз йомуымнанмы) төшүе мөхтәрәм «Вакыт» мөхәррирләрен шөбһәгә төшермештер. Миңа «Вакыт» гәзитәсен кимсетергә бер дә юл юктыр. Чөнки «Вакыт» гәзитәсе әшгар мәҗмугасе (җыентыгы) түгелдер ки, мин аны тәнкыйть итеп «мөтәшагыйрь» исемен бирим.

Икенчедән, мин һәммә ислам гәзитәләрен җаным кадәр сөямен, һичберсенә тел озату минем шәэнем (эшем) түгелдер.

Минем бәгъзе (кайсыбер) вакытта, дөрест, «Борһане тәрәккый»дә (бу газета турында «Мөхәрриргә» шигыренә караган искәрмәдән карагыз) бер дә кирәкмәгәнгә урын алган бәгъзе шигырьләргә эчем пошадыр. «Мөтәшагыйрьгә» шигыре, ихтимал, шундый эч пошулар сәбәпле ихтыярсыз язылган булыр.

Инде «Вакыт»тан түбәнчелек белән үтенәм ки, Хода хөрмәте өчен, бу яңлыш уларак киткән фикерне кайтып алсын. Мин бу кадәр нахак сүзләрне тәхәммәл итә (түзә) алмыйм.

Гаҗиз: Габдулла Тукаев».

«Вакыт»ның 19 июль санында Тукай хатына мондый җавап басыла:

«Аңлашуның җавабы

Мөхтәрәм Габдулла әфәнде!

Мәгълүм шигырьләреңездә «вакыт» кәлимәсене мөгътәриза эченә куюыңызга бер сәбәп күрмәдекемездән безне касд итдекеңезне зан әйләмеш идек. Соңра исә ерак вә якын җирләрдән кәлмеш мәктүпләрдән беркач әдибләрнең бигайниһи безем кеби бер занда улдыкларыны аңладык.

Ушбу тараф мөселманнарының Мәгарриләре улачак әдиб (дип) өмидләнеп тордыкымыз бер затның (занымызга күрә) бөйлә салкын мөгамәләсенә вәҗһе тапмадыкымыздан сөкүт илә кәчмәк дә бер әдиб хакында рәва улмадыгыннан тәхкыйрь касдыйлә дәгел, бәлки зарафәт юлында нәсихәт итмәк ниятенә мәбни шөйлә шигырьләр басылынды.

Шимди сез үзеңезнең шигырьләреңездә безне ирадә әйләмәдекеңезне сөйләрсез вә сезләрә хитаб иделмеш шигырьләрнең кире алынмасыны эстәрсез. Без дә, мәмнүният илә морадыңызга муафыйк итеп, 12 номер «Әдәбият мәҗмугасе»нең соң битендә сезләрә хитаб иделмеш шигырьләрне тәмам алдык. Вә сезнең шигыреңез нә хөкемдә калмыш исә, bездә язылмыш шигырьләр бигайниһи шул хөкемдә калыр.

«Йолдыз» могътәбәр гәзитәләрдән улдыгы өчен безем кашымызда һәм мөхтәрәмдер. Шуның өчен мәктүбеңезне аңа вирдегеңезгә бер сүземез юк. Фәкать кәндемезә тугры юлламыш ула идеңез, даһа гүзәл вә даһа самими улачак иде. Һәрхәлдә вазыйфамыз әүвәлгесе кеби сезә хәерхаһлыктыр».

Хатның тәрҗемәсе: «Мөхтәрәм Габдулла әфәнде!

Мәгълүм шигырегездә «вакыт» сүзен җәя эченә куюыгызга бер сәбәп тә күрмәвебез өчен безне күздә тотып язгансыздыр дип уйладык. Бераздан безгә ерактан-якыннан килгән хатлардан берничә әдипнең дә нәкъ безнеңчә уйлаганнарын белдек.

Бу як мөселманнарының Мәгарриләре булачак әдип дип өметләнеп торган затның (уебызга күрә) мондый салкын мөгамәләсенә сәбәп тапмаганыбыз өчен бу хәлгә (әдиплек хакын истә тотып) дәшмичә калуны мәгъкуль күрмәдек. Бу шигырьне, (Сезне) мыскыл итү максаты белән түгел, ә бәлки нәзакәтле рәвештә үгет-нәсихәт бирү ниятеннән чыгып бастырдык.

Хәзер Сез шигырегездә безне исәптә тотмавыгызны әйтәсез, Сезгә мөрәҗәгать иткән шигырьне кире алуыбызны телисез. Без дә бик рәхәтләнеп һәм теләгегезгә муафыйк төстә 12 нче сан «Әдәбият мәҗмугасе»нең соңгы битендәге Сезгә караган шигырьне бөтенләй алдык. Шулай итеп, Сезнең шигырегез ни хәлдә калган булса, бездә басылган шигырь дә шундый ук хәлдә калыр.

«Йолдыз» могтәбәр газеталардан берсе булганы өчен, без дә аны ихтирам итәбез, шуның өчен дә хатыгызны аның сәхифәләрендә бастыртуыгызга сүз әйтмибез. Тик шулай да, әгәр ул хатыгызны туп-туры безгә җибәргән булсагыз, матуррак та, самимирәк тә булыр иде. Һәрхәлдә Сезгә хәерхаһ булуны әүвәлгечә кебек үк үзебезнең вазыйфабыз дип беләбез».

Бу хатка имза куелмаса да, аның авторы, ихтимал, «Вакыт»ның мөхәррире Фатих Кәримидер. Хатның тулысынча диярлек ул чорның әдәби төрек телендә (бу махсус шулай эшләнгәндер) язылуы Тукай белән «Вакыт» газетасы арасындагы барлыкка килгән «боз»ның әле ул көннәрдә генә эремәгәнлеген күрсәтә.

1 Мәгарриләре – Әбел-Галә әл-Мәгарри (973–1057/58), күренекле гарәп шагыйре һәм фикер иясе.

172 бит.

Пар ат. «Фикер»нең 1907 елгы 6 май, «Әлгасрелҗәдид»нең 25 май саннарында, шулай ук «3 нче дәфтәр»дә (1907) басылган. Соңгысында шигырьнең азакκы юлындагы «нечкә билләр» «нечкә билем»гә үзгәртелгән.

«Пар ат» «The Russian Rewiev» («Русияне күзәтү») дигән инглиз журналының 1914 ел, №1, III томында тәрҗемә ителеп (Тукайның кыскача тәрҗемәи хәле дә бирелеп) урын алган.

Текст «3 нче дәфтәр»дән (1907) алынды.

174 бит.

«Тавыш» хакында. «Тавыш» газетасының 1907 елгы 14 май (4 нче) санында «Тавыш» дип, «Г.Тукаев» имзасы белән чыккан. «4 нче дәфтәр»дә (1907) «Тавыш хакында» дип үзгәртелеп басылган. Шигырь шул ук елның 23 апрелендә бу газета чыга башлау мөнәсәбәте белән язылган.

Текст «4 нче дәфтәр»дән (1907) алынды.

«Таң йолдызы» ябылганнан соң, «Тавыш» аның дәвамчысы буларак матбугат мәйданына чыга. Аның мөхәррире Сәгыйть Рәмиев, газета укучыларына мөрәҗәгать итеп, беренче санның кереш мәкаләсендә болай яза:

«Авызларыбыз – пичәтле, телләребез бәйле булу сәбәпле, күп вакытлар сезнең белән сөйләшергә, сезнең белән күрешергә тугры килми торса да, «исән кешеләр бер күрешәләр» сүзе буенча без тагы сезнең белән сөйләшергә, тагы татлы-татлы күрешергә башлыйбыз».

С. Рәмиевнең газетаның алга таба нәшер ителүе өмете акланмый, аның алты саны гына чыгып, эше туктатыла.

«Тавыш хакында» шигыренең соңгы дүртьюллыгында эсерларның «В борьбе обретешь ты право свое!» – «Тартышуда гына табарсың хакыңны!» шигаре чагылыш тапкан.

175 бит.

Ләззәт вә тәм нәрсәдә? «Әлгасрелҗәдид»нең 1907 елгы 25 май санында «Г.Тукаев» имзасы белән чыккан. «3 нче дәфтәр»дә (1907) басылган. Текст «Әлгасрелҗәдид» тән алынды.

Тукайның бу шигыренә охшатып, Зариф Бәшири дә «Ләззәтле хәят» исемле назымын яза. Ул «Шура» журналының 1908 ел, 16 санында дөнья күрә. Шагыйрь, нәкъ Тукайча, ләззәтнең «зур урын («бөек мәнсаб») алып, акча яки «татлы азык» ашап, «нәфис кием» киюдә түгел, ә бәлки халыкка хезмәт итүдә күрә:

Тугърысын әйтәм сиңа, и карендәш!
(Дикъкать ит, колагың сал уяу гына):
Ләззәт вирер: матбугатта ат уйнатып,
Тарихтан урын алмак максадыйлә –
Милләтә пәһлевандай күкрәк киереп
Хезмәт итмәк тугры (бер нык) мәсләк илә.

176 бит.

Кем ул? «Әлгасрелҗәдид»нең 1907 елгы 25 май (5 нче) санында «...» имзасы белән басылган. «4 нче дәфтәр»гә (1907; 1909) кертелгән. Журналда шигырьнең азагында «Соңы бар» дип куелган.

Текст «4 нче дәфтәр»дән (1909) алынды.

Бу шигырь, Гаяз Исхакыйга багышланганы һәм аның иҗатына ифрат югары бәһа биргәнлеге сәбәпле, совет хакимияте елларында Тукайның һичбер басмасына да кертелмәгән. Бары тик СССРда үзгәртеп кору һәм хәбәрдарлык чоры башланганнан соң,

профессор Ибраһим Нуруллин аны «Социалистик Татарстан» газетасының 1989 елгы 9 апрель санында кыскартып бастыра алды. «Кем ул?» шулай ук унбиш томлы «Гаяз Исхакый әсәрләре»нең VIII томына кертелде (Казан, 2001. 38 б.)

Шигырь милли әдәбиятыбызда Гаяз Исхакыйга карата язылган беренче мәдхия үрнәге булуы җәһәтеннән аерым игътибарга лаек. Ул «Мөридләр каберстанындан бер аваз»да күтәрелгән теманы («Дәрсе гыйбрәт вирде безгә «Инкыйраз» нам бер әсәр...) тирәнәйтеп, киңрәк яссылыкта дәвам иттерә.

«Таң» – Г.Исхакый редакторлыгында чыккан газета.

1 «Татар» ләфзын «тотар»а кальбидән кем?(«Татар» сүзен «тоткарлык» сүзенә үзгәрткән кем?) – бу шигъри юлда Г.Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» романындагы «татар» атамасын милләткә халыктан ераклашкан «морзалар» такты һәм шул эше белән милләткә зарар китерде дигән фикере ассызыклана.

178 бит.

Дөньяда торыйммы? – дип киңәшләшкән дустыма. «Таң мәҗмугасе» журналының 1907 елгы (1 июнь) 2 нче санында басылган. «3 нче дәфтәр»дә (1907; 1909) урын алган. Текст «3 нче дәфтәр»дән (1907) алынды.

Фатих Әмирхан «Әлислах» газетасының «Яңа китаплар» рубрикасында «Габдулла Тукаев шигырьләре»нә («3 нче дәфтәр», 1907) язган тәкъризендә (бәяләмәсендә) бу шигырьне «һәр җәһәттән тәкъдир ителергә лаек» әсәр, дип сыйфатлый һәм «мөтәкәллиф (кыланчык) төрекләшкән» шигырьләренә капма-каршы итеп куя (Әлислах. 1907. 3 декабрь).

180 бит.

Юаныч. «Бәянелхак» газетасының 1907 елгы 24 июль (197 нче) санында кыскартылып басылган. Бу хакта «Казан мөхбире» газетасы «Идарәдән җаваплар» рубрикасында мондый аңлатма бирә: «Мөхтәрәм шагыйрь Габдулла әфәнде Тукаев җәнапләренә: «Җуаныч» басылды, ләкин, мәгаттәәссеф, күрдегезчә, кыскартылмыштыр. Шигырьләрегез мәгальмәмнүният дәреҗ ителәчәктер» (1907 ел, 27 июль, 234 нче сан).

Текст «Бәянелхак»тан алынды.

1 Ля тәйәсү... – Өметсезлеккә бирелмәгез.

181 бит.

Бер манигы тәрәкъкыйгә. «Әлислах» газетасының 1907 елгы 5 ноябрь (5 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән чыккан. «4 нче дәфтәр»дә (1907; 1909) басылган. Соңгысында шигырьгә:

Яһүдләр булды мәгъзуб та кыямәт,
Карышып, күз йомып Инҗилгә каршы, –

дигән ике юл өстәлгән.

Текст «4 нче дәфтәр»дән (1907) алынды.

1 Кире төште угы башына, Нәмруд... – мөселман легендар традициясенә караганда, Алла белән көндәшлек итү ниятендә булган мөстәбид (тиран) Нәмруд, Бабил (Вавилон) манарасын күккә кадәр төзи алмагач, дүрт бөркет тоткан сандык эченә кереп, югарыга оча

һәм күккә таба ук ата. Җәбраил (Җибрил) фәрештә исә бөтен атылган укларны кире аның өстенә төшерә.

2 Яһүдләр булды мәгъзуб та кыямәт – борынгы яһүдләрнең Муса пәйгамбәрне тыңламыйча, аның сүзенә күнмичә, Инҗил китабын кире кагулары, шул рәвешчә, Аллаһның каты ачуына мәңге дучар булуларына ишарә ясала.

3 Әхҗаре мин сиҗҗил(дөресрәге, Хиҗәрәтәм мин сиҗҗил) – бу гыйбарә Коръәннең кимендә өч сүрәсендә («Һуд», 82 нче аять; «Хиҗер», 74 нче аять; «Фил», 4 нче аять) бар. Тәфсирчеләр аны «җәһәннәм утында кыздырылган ташлар» дип аңлаталар.

182 бит.

Шүрәле. «3 нче дәфтәр»дә (1907) басылган. Ахырында шагыйрь мондый аңлатма бирә:

«Мин бу «Шүрәле» хикәясен Пушкин вә Лермонтовларның шундый авыл җирендә сөйләнгән хыялый хикәяләрне язуына истинадән (таянып) яздым. Өмид юк түгел әле: бара торгач, үз арамыздан маһир рәссамнар чыгып, шүрәленең кәкре борын, озын бармак, мөгезле башларын һәм дә кулы кысылуларын, шул тасвир кыйлынган урманнарны – һәммәсен тәрсим кылып (рәсемгә төшереп) чыгарырлар. Авыл җирендәге хыялый хикәяләрнең һәммәсен язып чыгу файдадан башка бернәрсә дә булмас зан идәрем. Гъ.Т.»

Текст «3 нче дәфтәр»дән (1907; 1909) алынды.

187 бит.

Театр. «Әлислах»ның 1907 елгы 26 ноябрь санында «Г.Тукаев» имзасы белән чыккан. «4 нче дәфтәр»дә (1907) басылган. Соңгысында:

Кирәк кол бул, кирәксә император, –

дигән юлдан «император» сүзе төшереп калдырылып, урынына күп нокталар куелган.

«4 нче дәфтәр»нең 1909 елгы икенче табгында (басмасында):

Тигез күрә бөтен җанны театр:
Кирәк кол бул, кирәксә император, –

икеюллыгы «юкка чыккан». Билгеле ки, бу үзгәртүләр – патша цензурасы таләпләрен үтәү нәтиҗәсе.

Текст «Әлислах»тан алынды.

188 бит.

«Алтынга каршы». «3 нче дәфтәр»дә (1907) басылган. Текст шуннан алынды.

1 Зәбур – Даут пәйгамбәргә иңдерелгән китап.

2 Тәүрат – Муса пәйгамбәргә иңдерелгән китап.

189 бит.

Бер татар шагыйренең сүзләре. «3 нче дәфтәр»дә (1907) тулысынча басылган, 1909 елгы басмасында исә шигырьнең икенче дүртьюллыгы төшереп калдырылган.

Куркмаслыкта күңлем мисле «эс-эр» минем,
Күңлем дүзәх, аузымнан ут чәчрәр минем.
Дошман бозмый фикрем, уем җәмгыятен,

Аңар каршы керпекләрем гаскәр минем.

Текст «3 нче дәфтәр»дән (1907) алынды.

1 Гали – холәфаи рашидиннән (тугры юлдагы дүрт бөек хәлифәләрдән) дүртенчесе(656–661), хәзрәти Гали ибне Әбу Талиб (600(?)–661), Мөхәммәд пәйгамбәрнең кияве һәм сәхабәсе. Гайрәте һәм куәте белән дан казанган.

2 Рөстәм – борынгы Иран мифологиясендә бик көчле баһадир, Фирдәүсинең «Шаһнамә»сендә баш каһарманнарның берсе.

191 бит.

Утырышу. «3 нче дәфтәр»дә (1907) басылган. Текст шуннан алынды.

Бу шигырь Тукай тарафыннан шәхсән 1908 елның 29 мартында Казанның Биржа залында (Проломная, хәзерге вакытта Бауман урамы) булган әдәбият ахшамында укылган. «Казан мөхбире»ндә (31 март саны) чыккан язмага караганда, әсәр тыңлаучыларда матур тәэсир калдырган.

193 бит.

Сөткә төшкән тычкан. «3 нче дәфтәр»дә (1907; 1909) басылган. 1909 елда чыккан «Яңа кыйраәт» китабында исә соңгы икеюллыгы төшереп калдырылган.

Сөткә төшеп бата башлаган хайван турындагы сюжет борынгы ярым легендар мәсәлче Эзоп (безнең эрага кадәр VI гасыр) иҗатына барып тоташа. Вернон Джоунсның инглиз теленә тәрҗемә ителгән Эзоп мәсәлләре (V.S .Vernon Jones. AESOP'S FABLES BY AESOP, 1912) арасында «The frogs in the milk (The two frogs)» («Сөткә төшкән бакалар») исемлесе бар. Анда ике бака сөт эченә егылып төшеп, берсе батып үлә, икенчесе исә бөтен көчен җыеп йөзә башлый һәм нәтиҗәдә сөт, куерып, майга әйләнә дә, бака, аңа басып, савыттан сикереп чыга. Американ традицион мәсәлләре арасында «The Mouse in the milk» («Сөткә төшкән тычкан») дигәне дә бар, ягъни аның исеме Тукай шигыренекеннән бөтенләй диярлек аерылмый. Дөрес, американ мәсәлендә сөткә берничә тычкан килеп төшә: «One day... some mise were running along a beam when it broke and all the mise fell into a churn of milk…» (Беркөнне берничә тычкан такта өстеннән йөгергәндә, ул сынган да, бөтен тычканнар сөт тулы киле эченә барып төшкәннәр...) Аннан соң бөтен тычканнар, бәладән котылу юлларын эзләп тә тормастан, сөткә батып үләләр, арадан бары берсе генә тырышып-тырышып йөзүен белә... Нәтиҗә, әлбәттә, уңай була.

Күргәнебезчә, Тукай үз шигырендә бер генә тычкан белән канәгатьләнә, ягъни борынгы мәсәлгә микъдар ягыннан үзгәреш кертә.

Текст «3 нче дәфтәр»дән (1909) алынды.

194 бит.

...га («И матур! Иренмәче...»). «3 нче дәфтәр»дән (1907; 1909) алынды.

Әсәр Михаил Лермонтовның «К***(Глядися чаще в зеркала...)» исемле шигыреннән (1829) файдаланып язылган. Аның тексты түбәндәгечә:

Глядися чаще в зеркала,
Любуйся милыми очами,

И света шумная хвала
С моими скромными стихами
Тебе покажутся ясней…
Когда же вздох самодовольный
Из груди вырвется невольно,
Когда в младой душе своей
Самолюбивые волненья
Не будешь в силах утаить,
Мою любовь, мои мученья
Ты оправдаешь, может быть!..

195 бит.

Авыл хатынының бала тирбәткәндә өмидләре. «3 нче дәфтәр»дә (1907; 1909) басылган, шул ук елда «Борһане тәрәкъкый» газетасы сәхифәләрендә урнаштырылган.

1 Бохарага китәр бу... – Бохара мәдрәсәләренең берсенә барып укуга ишарә.

2 Собраньяга барыр бу, Указ сорап алыр бу... – Урта Русия һәм Сибирия (Себер) мөселманнарының Мәхкәмәи шәргыясе, соңыннан Диния нәзарәте дип аталган төп оешмасы. Екатерина II указы нигезендә 1788 елда Уфада ачылган.

Имам-хатыйблыкка кандидатлар Мәхкәмәи шәргыягә барып махсус имтихан тапшыра торган булганнар, аннан соң муллалыкка указ (мәншүр) алып, мәхәллә имамы вазыйфасын башкарганнар.

Текст «3 нче дәфтәр»дән (1909) алынды.

197 бит.

Туган җиремә. «3 нче дәфтәр»дә (1907; 1909) басылган. 1911 елда Тукай үзе төзегән «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» хрестоматиясенә исеме үзгәртелеп («Туган илемә») кертелгән, соңгы юлы:

Яхшыдыр барлык яманың, бар, минемчә, юкларың, –

дип үзгәртелгән.

Текст «3 нче дәфтәр»дән алынды.

198 бит.

Безне урынсыз яманлыйлар. «Әлислах»ның 1907 елгы 10 декабрь (10 нчы) һәм 1908 елгы 8 гыйнвар (14 нче) саннарында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Шигырьнең башында «М.Һади Ширвани артыннан» дигән сүзләр бар. Димәк ки, әсәр азәрбайҗан шагыйре Мөхәммәд Һадинең (Мөхәммәд Габдессәлимзадә Һади Ширвани) (1879–1920) әлегә ачыкланмаган шигыреннән файдаланып язылган.

Шигырьнең беренче исеме – «Бездә истигъдад бар» («Бездә сәләт бар»).

1909 елда «Безне урынсыз яманлыйлар» «Габдулла Тукаев диваны»нда (Казан, «Шигырьләр көтепханәсе»ннән 8 нче дәфтәр) бирелә. «Шура» журналының 1909 елгы 15 февраль санында «Тәкъриз» рубрикасында «Бидаяте ислам». «Тәгълимел Коръән». «Габдулла Тукаев диваны» дигән гомуми исем астында бу җыентык турында түбәндәгеләр әйтелә:

«Габдулла Тукаев диваны» исә мәгълүм шагыйрьләрдән Габдулла әфәнде шигырьләреннән гыйбарәт бер мәҗмугадыр. Башка шигырьләре кабиленнән (кебек) бу диванында улан (булган) шигырьләре һәм гүзәл вә рәгъбәтледер (бу урында – самими, эчкерсез)...»

«Безне урынсыз яманлыйлар» шигыре, башка авторларның әсәрләре белән беррәттән, 1908 елның 2 гыйнварында Казандагы Купеческое собрание залында булган әдәбият кичәсендә сәхнәдән укыла.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

1 Көфер почмагы – Казанда «Печән базары» мәчете чаты. Традиционалистлар, кадимчеләрнең җыелып, аерым алганда, җәдитчеләрне «яурупача» киенгәннәре өчен хурлаулары белән даны чыккан урын.

2 «Таһир»дән, «Бүз егет»тән – Әхмәт Уразаев-Кормашинең (1855–1883) «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» (1876 – тәүге басмасы) белән «Кыйссаи Бүз егет» (1874) дастаннары күздә тотыла.

3 «Һидая шәрхе» – Борһанетдин Әбүл-Хәсән Гали бине Әбубәкер әл-Мәргиланинең (1152–1192) хәнәфи фикъһе буенча китабы күздә тотыла. Мәдрәсәләрдә укытылган.

4 ... Мөхәммәдъярыбыз бардыр – Мөхәммәдъяр Мөхәммәдшәриф улы Солтанов (1837–1915), «Башкорт» сословиесеннән, «Башкорт-мишәр гаскәре» («Башкиро-мещерякское войско») офицеры, кантон башлыгы. 1886 елда мөфти итеп раслана.

5 «Сарай»... «Болгар»ымыз бардыр – Казанның Печән базары тирәсендәге кунакханәләр («номерлар»).

200 бит.

Китмибез! «4 нче дәфтәр»дә (1907) басылган.

Шигырь III Дәүләт Думасы сессиясенең 1907 елгы 18 май, 15 нче утырышында килеп чыккан җәнҗал мөнәсәбәте белән язылган. Анда мөселман фракциясе әгъзасы, Уфа депутаты Кәлимулла Хәсәнев, Русиядәге мөселман мәктәпләре һич тә хөкүмәт яклавын күрмиләр дип, хакимияткә шикаятен белдерә. Уң карашлы Дума әгъзаларыннан карагруһчылар (Тукай «гөруһе русияһ» дип нәкъ менә шуларны атый) В.Пуришкевич, И.Сазонович, А.Клеповский, бу чыгышка ачулары килеп: «Русиядәге тәртипләр ошамаса, әнә Төркиягә китегез!» – дип кычкыралар. Шигырь шул ук май аенда язылган булса кирәк. Ул Шәрәфләр матбагасына май аенда язылган башка шигырьләр белән җибәрелгән, күрәсең.

«Китмибез!», зур иҗтимагый көчкә ия булганы өчен, «4 нче дәфтәр»нең 1909 елгы чыгарылышыннан цензура таләбе буенча алына.

Текст «4 нче дәфтәр»дән (1907) алынды.

201 бит.

Матбага берлә уйнаган бер байга. «4 нче дәфтәр»дә (1907) басылган. Текст шуннан алынды.

«Фикер» газетасы белән «Әлгасрелҗәдид» журналының Уральскиның күренекле мөселман сәүдәгәре Мортаза Гобәйдуллин кулына күчеп тә, аның гамәлләре аркасында тернәкләнеп китә алмавы, 1907 елның май азагында ябылуы, матбаганың да сатылуы мөнәсәбәте белән язылган. Әлбәттә, шулкадәр көч куйган басмаларның тукталуы Тукайны

ачуландырган, һәм ул шул ачуын бик усал шигыре аша турыдан-туры Мортаза Гобәйдуллинга юнәлдергән.

1 Самри – Самири – Муса пәйгамбәр Синай тавында Аллаһы Тәгалә иңдергән Тәүрат китабын алган вакытта, яһүд Самири алтын бозау сыны ясап, кавемдәшләренә шуңа табынырга кушкан. Бу вакыйгага караган хәлләр турында Коръәннең «Таһа» сүрәсендәге күп кенә аятьләр сөйли. Тукай, Самири исемен телгә алып, аның мәкер һәм хыянәтне символлаштырганын белдерә.

203 бит.

Мәхбүс. «Әхбар» газетасының 1907 елгы 12 декабрь санында басылган, шулай ук «4 нче дәфтәр»гә (1907) кертелгән. «Пушкиннән» дип куелган.

«Мәхбүс» – А.С.Пушкинның «Узник» (1822) дигән шигыреннән ирекле тәрҗемә вә икътибасы. «Узник»ның тексты түбәндәгечә:

Сижу за решеткой в темнице сырой.
Вскормленный в неволе орел молодой,
Мой грустный товарищ, махая крылом,
Кровавую пищу клюет под окном.

Клюет, и бросает, и смотрит в окно,
Как будто со мною задумал одно.
Зовет меня взглядом и криком своим
И вымолвить хочет: «Давай улетим!»

Мы вольные птицы; пора, брат, пора!
Туда, где за тучей белеет гора,
Туда, где синеют морские края,
Туда, где гуляем лишь ветер…да я!..

А.С. Пушкинның шигыре 12 юлдан торса, Тукайның ирекле тәрҗемәсе 26 юл тәшкил итә.

204 бит.

Вәгазь. «Әлислах»ның 1907 елгы 17 декабрь (11 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «4 нче дәфтәр»гә (1907) кертелгән. Анысында «Лермонтовтан» сүзе өстәлгән.

Текст «4 нче дәфтәр»дән (1907) алынды.

Тукайның бу әсәре М.Ю.Лермонтовның «Опасение» (1830) исемле шигыреннән файдаланып язылган. «Опасение»нең тексты болай:

Страшись любви: она пройдет,
Она мечтой твой ум встревожит,
Тоска по ней тебя убьет,
Ничто воскреснуть не поможет.

Краса, любимая тобой,
Тебе отдаст, положим, руку…
Года мелькнут… летун седой
Укажет вечную разлуку…
И беден, жалок будешь ты,
Глядящий с кресел иль подушки
На безобразные черты
Твоей докучливой старушки,

Коль мысли о былых летах
В твой ум закрадутся порою
И вспомнишь, как на сих щеках
Играло жизнью молодою…

Без друга лучше дни влачить
И к смерти радостней клониться,
Чем два удара выносить
И сердцем о двоих крушиться!..

206 бит.

Бер гәзитә идарәсе хәленнән. «Әлислах»ның 1907 елгы 24 декабрь (12 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «4 нче дәфтәр»гә (1908) кертелгән. Газета һәм китапта:

Бәйрәм өчен 5–10 тәңкә бирче, абзый!
Өйдә бер бөртек чәй, шикәр бер шакмак юк, –

дигән шигъри юллар җәяләр эченә алынган.

Текст «Әлислах»тан алынды.

В.Бәхтияров үз истәлегендә бу шигырьнең кемгә атап язылуын түбәндәгечә аңлата: «...Мәскәүнең зур байларын алдап, яңадан баеп киткән мәшһүр Сәйдәшевләр (аталы-уллы), искелекне яклаучылар, татар арасында булган һәр яңалыкка каршы торучы, бигрәк тә шәкертләр хәрәкәтенә аяк чалучы, шәкертләр хәрәкәтен бастырырга тырышып йөрүчеләрнең башлыклары иде. Шул Сәйдәшевләр тарафыннан чыгарыла торган «Бәянел-хак» газетасының хәлен сурәтләп, «Бер гәзитә идарәсе хәленнән» дигән шигырен яза. Шигырь «Әлислах»ның 12 нче санында басылып чыга. Шуннан соң Сәйдәшев идарәне судка тарттырырга йөрде. Ләкин эше барып чыкмады.» Әсәр кабат «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы, 9 нчы (15 июль) санында исемсез һәм «Кызганычлы» дигән имза белән, дүртенче строфадагы «Арды, тәмам эштән чыкты, аптырады» дигән һәм ахырдагы алты юлы төшереп калдырылып басылган. Шигырь журналның соңгы уналтынчы битенә (буш калган урынга гына) тыгызлап урнаштырылган; югарыда күрсәтелгән юлларның калганлыгы күренеп тора. Журналның 10 нчы (1 август) санында түбәндәге төзәтмә бирелгән:

«Тасхих.

«Ялт-йолт»ның үткән номерының ахыргы сәхифәсендәге шигырьне дикъкать белән укыган кешеләр: «Моны ни өчен басканнар икән?» – дип уйлаганнардыр. Чөнки ул моннан ике-өч сәнәләр әүвәл басылган һәм укылган иске шигырь иде.

Ул менә шушы рәвешчә хаталык берлән табгы ителгән:

Ул вакытта дачада торучы секретаремыз «Шүрәле» әфәнде мәзкур шигырьне рәсем ясарга тема иттереп шәһәргә идарәгә җибәргән.

Идарәдә, ничектер, шул шигырьнең үзен басарга кирәк икән дип уйлаганнар. Секретарь әфәнде исә «Ялт-йолт»ны басылып тәмам булгач кына күргән.

Идарә».

Шулай итеп, «Кызганычлы» имзасы Тукайныкы булмавы, хаталык нәтиҗәсе икәне дә ачыла. Бу «Тасхих»нең әһәмияте шунда: «Яшен», «Ялт-йолт» журналларына барлык диярлек рәсем асларына сурәт ясау өчен темаларны Тукай бирүе янә бер кат раслана.

208 бит.

Ишек бавы. «4 нче дәфтәр»дә (1907; 1909) басылган.

Текст «4 нче дәфтәр»дән (1909) алынды.

209 бит.

Байроннан. «4 нче дәфтәр»дә (1907, 1909) басылган. Текст шуннан алынды.

Инглиз шагыйре Джордж Байронның (1788–1824) шигъри әсәрен М.Ю.Лермонтов (1814–1841) «В альбом (из Байрона)» дигән исем белән тәрҗемә итә. Тукай шигыре Лермонтовка иҗади иярү нәтиҗәсендә туган. Бу шигырь Лермонтов тәрҗемәсендә түбәндәгечә:

Как одинокая гробница
Вниманье путника зовет,
Так эта бледная страница
Пусть милый взор твой привлечет.

И если после многих лет
Прочтешь ты, как мечтал поэт,
И вспомнишь, как тебя любил он,
То думай, что его уже нет,
Что сердце здесь похоронил он.

210 бит.

Гыйлавә. Шигырь «4 нче дәфтәр»дә (1907, 1909) «Байроннан» шигыре артыннан ук, кушымта буларак басылган. «4 нче дәфтәр»дә дә (II табгы, 1908) шулай урнаштырылган.

Текст «4 нче дәфтәр»дән алынды.

211 бит.

Охшату. «4 нче дәфтәр»дә (1907), «Габдулла Тукаев диванында» (1908) һәм берникадәр төзәтүләр белән «4 нче дәфтәр»дә дә (1909) урнаштырылган. Әсәр

М.Ю.Лермонтовның «Эпиграмма» (1829) исемле шигыреннән иҗади тәрҗемә ителгән. Лермонтовта ул түбәндәгечә:

Дурак и старая кокетка – все равно:
Румяны, горсть белил – всё знание его!..

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан (1908) алынды.

212 бит.

Ислахчыларга. «4 нче дәфтәр»дә (1907) басылган.

Текст китапның икенче басмасыннан алынды.

XX гасыр иҗтимагый тормышы һәм 1905–1907 елгы инкыйлаб дулкыны тәэсирендә дөньяга килгән татар шәкертләре хәрәкәте милли мәгариф системасын үзгәртү, дини дәресләр белән янәшәдә, дөньяви фәннәр укыту, мәдрәсәләрнең эчке тәртипләрен заманчалату кебек таләпләр белән чыгалар. Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре арасында оештырылган әлеге хәрәкәт «Ислахчылар» булып тарихка кереп кала. Аның исеме «Әлислах» комитеты исеменнән килә. Мәгълүм ки, хәрәкәтнең идеологы, төп җитәкчелекне алып баручы – Ф.Әмирхан. Ул «Әлислах» комитетының атналык кулъязма газетасы буларак чыгарылган «Әлислах»та бу хакта программ характерда мәкаләләр бастыра, шәкертләр, һәм, гомумән, татар халкын кызыксындырган фәнни яңалыклар белән таныштырып бару өчен, рус басмаларыннан алып төрле язмалар урнаштыра. Бигрәк тә Ф.Әмирхан тарафыннан язылган баш мәкаләләрдә «Ислахчылар»ның төп максатлары ачык чагыла. Мәсәлән, 1907 елда «Казан, 3 октябрь» мәкаләсендә ул: «Татарның мәгыйшәтене асылыннан сүтеп төзәтергә кирәк! Безгә аның урынына яңа мәгыйшәт кирәк: әүвәлдәге наданнар урынына ачык фикерле вә зыялылар, әүвәлдәге мөтәгасыйблар урынына ачык фикерле вә яңа хәрәкәтләрне алып баручылар, әүвәлдәге үз кулларында булган нәрсәләрне дә ычкындыручылар урынына һөнәр вә сәнагатьле, мәгыйшәт сугышында мәгълүб булмаслык (җиңелмәслек) татарлар кирәк! Әүвәлге сыйныф икенчесенә урын бирергә, үзләре андый тәрбия ала алмаганнар вакытлары узмаганнарга шундый тәрбия бирергә кирәк, ягъни тәрбия вә гыйлемханәләремезне әсасеннән (нигезеннән) ислах итәргә кирәк!..» Шунысы билгеле: 1905–1907 елгы инкыйлаб вакытында инде алдынгы карашлы татар яшьләре арасында шул заман өчен әһәмиятле саналган Европа һәм рус мәдәниятенә тартылу, шуның тәэсирендә белем алу, русча укырга тырышу, гимназияләр һәм университетларда укырга омтылу теләге нык көчәя. Шул ук елның «Казан, 10 октябрь» исемле язмасында: «Хәзергә кадәр булган шәкертләр хәрәкәте күземезгә күренгән ушбу нәтиҗәләрне бирделәр: «...2) мәдрәсә тәмам итеп мулла вә мөдәррис булуны үзләренә мәкъсуд иткән кешеләрнең гадәде күп дәрәҗә кимеп, мәдрәсәдә артык гомер заигъ итмичә мөгаллимлеккә чыгучыларның гадәдләре артыуы; 3) шәкерттән чыгып русча тәхсил итә башлаган «бывшие шакирды» сыйныфының көннән-көн гадәде артыуы; ...» – дип, XX гасыр башы өчен татар шәкертләрендә уңай якка үзгәреш барлыгына үз мөнәсәбәтен белдерә. «Ислахчылар» бу елларда шактый уңышларга да ирешәләр, мәсәлән, мәдрәсәләргә дөньяви фәннәр керттерү, иске фикерле мулла, хәлфәләрне эшләреннән алдыру һ.б. шундыйлар. Тукайның «Ислахчыларга» шигыре шәкертләр хәрәкәтен хуплап, кыюрак көрәшергә өндәп язылган. «“Әлислах”ка ярдәм итик» дип, шагыйрь болай да матди яктан

авырлыклар белән һәм байлар, иске карашлы муллаларның каршылыклары белән чыгарылган шәкертләр газетасына булышлык итәргә кирәклегенә басым ясый. Ләкин дини эчтәлектәге газета һәм журналлар шәкертләр башлаган дини, милли укыту системасындагы кайбер үзгәрешләргә каршы тәнкыйть фикерләре белән чыга. «Чүкеч» мәҗмугасы 1908 елда, бигрәк тә июнь – декабрь саннарында, «Әлислах»ның матди яктан авырлыгыннан, шәкертләрнең соңгы акчаларын җыеп нәшер ителүеннән көлеп, сатирик рухтагы язмалар бастыра.

213 бит.

Фөрьяд. «Әлислах»ның 1908 елгы 1 гыйнвар (13 нче) санында «Феакут» анограммасы белән басылган (гарәп хәрефләре белән бирелгән «Тукаеф»ны сулдан уңга укыганда шулай килеп чыга). «Әлислах»тагы «Бала чактук тыпырчынган, тик тормаган» шигырь юлы «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) «Бала чактук тиберченеп, тик тормаган» дип бирелгән. «Әлислах»та «Ахыры бар» дип куелган булса да, шигырь тәмамланмаган.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

1 «Егълау – риза, дәшмәү – риза»га буйсынып. – Октябрь инкыйлабына кадәр мөселман хатын-кызлары күптөрле гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителгән. Шул исәптән кызларны яратмаган кешегә, мулла-мәзингә, байларга яки карт-корыга көчләп кияүгә бирү гадәти күренеш булып саналган. Алар, ризасызлыкларын белдереп еласалар да, үзләрен яклап бер сүз әйтә алмыйча, барыбер «риза! риза!» дигәннәр; соңыннан бу канатлы сүзгә әйләнеп киткән.

217 бит.

Бәйрәм вә сабыйлык вакыты. «Әлислах»ның 1908 елгы 1 гыйнвар (13 нче) санында «Гъ.Т.» имзасы белән «Габдулла Тукаев диваны»на кертелгән. «Фөрьяд» шигыре белән янәшә нәшер ителгән.

Текст «Әлислах»тан алынды.

1 Гарәфә кич – Корбан бәйрәме алды киче. Бу исем Мәккә шәһәреннән егерме чакрым төньяккарак урнашкан, озынлыгы 11–12, киңлеге 6,5 чакрым чамасы булган Гарәфәт тавы атамасыннан алынган. Ислам дине ышанулары буенча, оҗмахтан куылган Адәм белән Хаува нәкъ шул тауда очрашканнар. Мөселман дине кабул ителгәнче, тауның исеме Һилал дип йөртелгән, һәм ул мәҗүсиләрнең гыйбадәт кылу урыны булып исәпләнгән. Бүген исә Гарәфәт тавы – фәкать мөселманнарның изге хаҗ йолаларын башкара торган җире, бәйрәмнәр үткәрү урыны.

1908

218 бит.

Бер шәехнең мөнаҗате. Шигырь «Әлислах»ның 1908 елгы 8 гыйнвар (14 нче) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. «4 нче дәфтәр»гә (1907, 1909) кертелгән. Әсәргә теманы С.Рәмиев биргән. Ул үзенең истәлекләрендә: «Күп сүзләр арасында муллалар турында да сүзләр булып, мин аңар бер остазым Габдерәхим әфәнде Дәмини җәнабларыннан ишетдегем «Кафате хәмсә»не сөйләдем. Ягъни «Муллаларның сөйгәне

казы, кузый, каз, кыз, кымыз гына инде: үзләре, боларны җыеп, «Кафате хәмсә» дип атыйлар икән», – дидем.

Бу сүзне Тукаев бик яратты да: «Туктале, мин моңардан бер нәрсә эшлим», – дип, үз номерына чыгып китте һәм бер ун-унбиш минуттан соң кулына:

И Ходай! мәгълүм сиңа, тик яхшылыкта касдымыз;
Зикеремездер: казы, кузый, яшь кенә кыз, каз, кымыз, –

дип язылган бер кәгазь күтәреп керде», – дип язды. (Тукай турында истәлекләр. 1986, 116–117 б.).

Текст китапның икенче басмасыннан (1909) алынды.

219 бит.

Төрекчәдән («Тән үстерсәң...»). Шигырь «Әлислах»ның 1908 елгы 21 гыйнвар (16 нчы) санында «Хәкиманә сүзләр (Төрекчәдән)» исеме белән басылган. «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) «Төрекчәдән» дип нәшер ителгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

220 бит.

Янә. Шигырь «Әлислах»ның 1908 елгы 21 гыйнвар (16 нчы) санында «Төрекчәдән» шигыреннән соң йолдызчыклар (***) белән басылган. Шагыйрь газета басмасында «йолдызчылар» сүзенә астөшермәдә «мөнәҗҗимнәрнең татарчасыдыр» дигән искәрмә биргән. «Габдулла Тукаев диваны»нда бу искәрмә тәкъдим ителми. «Диван»да (1908) «Янә» исеме куелып дөнья күрә.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

221 бит.

Тәәссер. «Әлислах»ның 1908 елгы 21 гыйнвар (16 нчы) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Газетада «Төрекчәдән» һәм (***) белән, «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) исә «Янә» шигыреннән соң нәшер ителгән. «Әлислах»та «Лермонтовның «Молитва» сәрләүхәле шигыренә тәкълид» дип, «Диван»да «Лермонтовтан тәкълид» дип кенә куелган.

Тукай күңел төшенкелеге вакытында еш кына Лермонтовның шушындый әсәрләренә мөрәҗәгать итә. Күренекле рус шагыйре кичергән кебек үк кичерешләр, каршылыклар эчендә яшәве, иҗат итүе ике шагыйрьне рухи яктан берләштерә һәм күпмедер дәрәҗәдә аларда рухи якынлык барлыгы турында да сөйли.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан (1908) алынды.

Лермонтовның «Молитва» (1839) шигыре түбәндәгечә:

В минуту жизни трудную
Теснится ль в сердце грусть:
Одну молитву чудную
Твержу я наизусть.

Есть сила благодатная

В созвучье слов живых,
И дышит непонятная,
Святая прелесть в них.

С души как бремя скатится,
Сомненье далеко –
И верится, и плачется,
И так легко, легко...

Бу шигырь басылып чыгу уңае белән Вәкыйф Суксуви (Җәлал) «Идел» газетасының 1910 елгы 6 апрель (244 нче) санында «Тәфәккер» исемле шигырь бастырган. Ул түбәндәгечә башлана:

Күңел төшкән чагында тез бөгеп мин утырыр булсам,
Йә Коръән, йә хәдисне тагать (буйсыну) илән мин укыр булсам,
Тирән, киң Хакны, хикмәт чишмәсенең барлыгын күрәм,
Хисапсыз сер вә фәнләр суының ташканлыгын күрәм.
Хокук һәм дә сәясәт диңгезенә мин чумам бердән,
Элекдән лаө булып калган күңелне пакь кыйлам тирдән.

222 бит.

Урланган мәгънә. Шигырь «Әлислах»ның 1908 елгы 23 февраль (20 нче) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. «Әлислах»тагы өченче юлның «...кем соң ул залим?» дигән сүзләре «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) «...кемдер ул залим?» дип үзгәртелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан (1908) алынды.

223 бит.

Егет илә Кыз. «Әлислах»ның 1908 елгы 23 февраль (20 нче) санында «Кыз илә Егет (Авылда)», «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) «Егет илә Кыз» исеме белән басылган. «Әлислах»та шигырь ахырында «Г.Тукаев» имзасы куелган.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

224 бит.

Шәйтанның муенына. «Әлислах»ның 1908 елгы 17 март (23 нче) санында «Гъ.Т.» имзасы белән басылган, «Габдулла Тукаев диваны»на (1908) кертелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

225 бит.

Шагыйрь. «Әлислах»ның 1908 елгы 17 март (23 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «Утырмам тик төрле теләк тели-тели» дигән унынчы юл «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) «Утырмам тик, юк-бар теләк тели-тели» дип үзгәртелгән. «Без китәбез» дигән гыйбарә «Без китәрбез» дип үзгәртелгән. «Диван»да шигырьнең соңгы юлындагы «җәсәдемне» сүзе «Ходамны» дип басылган. Бу – типография хатасы булса

кирәк, «Әлислах»та әсәрдәге мәгънәгә туры килгән «җәсәдемне» рәвешендә нәшер ителгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

226 бит.

Чын вә Ялган. «Әлислах»ның 1908 елгы 27 апрель (28 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) текст үзгәртелеп китерелә («Анда йөзгәннәр икән...» – «Анда йөзгәннәр, имеш...», өченче юлдагы «кимә» «көймә» дип үзгәртелгән).

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

227 бит.

Тәүлек. «Бәянелхак» газетасы чыгарган «Мәгълүмат» (1908) исемле игълан-рекламалар җыентыгында «Караван» чәй фирмасының рекламасы рәвешендә имзасыз басылган. Шигырьнең баштагы өч строфасы бераз үзгәртелеп һәм:

Шушы вакыт балалар
Мәктәп таба баралар;
Букчалары артында,
Алар гыйлем дәртендә, –

дигән юллары өстәлеп, «Иртә» исеме астында Г.Тукайның «Күңел җимешләре» исемле җыентыгында (Казан: «Сабах» көтепханәсе, 1911)* аерым шигырь итеп басылган. Беренче тапкыр икенче Дүрттомлыкның 1 нче томына кертелгән.

«Тәүлек» шигырен әдип һәм галим Нәкый Исәнбәт (1899 – 1992) «Казан утлары» журналының 1966 елгы 4 нче санында искәрмәләр белән бастырып чыгара.

Текст «Мәгълүмат»тан алынды.

Тукай әлеге шигырен «Күңел җимешләре» (1911) исемле китабының тышлыгына «Берничә сүз» исеме белән мәкалә урнаштырылган, анда түбәндәге юллар бар: «Габдулла әфәнденең шигырьләре, аларның әдәбиятымыз эчендә алган мөхтәрәм урыннары тугрысында сүз сөйләп тору гаммәгә мәгълүм булган бер хакыйкатьне тәкърар булыр иде.

Халкымыз тарафыннан хосусый бер игътинаэ вә хосусый бер шок белән укыла торган бу шигырьләр, эчләрендәге милли аһәң, милли хиссият, милли гармонияләре белән күптән инде татарның йөрәгенә тирән бер эз калдырып киләләр. Кавагыйде әдәбия җәһәтеннән нәзым вә шигырьләрне аерырлык хәлгә һаман әле килеп йитмәгән халкымызның да төрле гонваннар астында нәшер ителә торган әллә никадәр нәзым мәҗмугалары белән Габдулла әфәнденең шигырьләрен саташтырмавын хәтеремезгә алсак, бу шигырьләрнең татар күңелендә никадәр тирән хис калдырганлыгын тугры тәхмин итәрмез. Шулай, Габдулла әфәнденең гомуми шигырьләренә вә аларның әһәмиятенә даир сүз сөйләп торырга хаҗәт юк. Фәкать бу «Күңел җимешләре» мәҗмугасындагы бер хосусият аерым игътибарны җәлеп итәдер. Габдулла әфәнде мәҗмуганың иң өске бер йиренә: «Инкисар ит гадәтеңчә, ян, күңел, сызлан, күңел!»

дигән девизын язып куя да, шул юлны тәгъкыйб итеп китә: күңел чынлап та яна, чынлап та сызлана. Ул әүвәл эзләнеп карый, ниһаять, бер тынычсызлык һәм гасабилык белән тормышның кадагын, иң мөһим нурлы бер почмагын табарга тырыша.

Бу шигырь турында Вафа Бәхтияров түбәндәгечә яза: «Тукай үзенең тормышындагы кайбер хаталарны искә төшереп... шул вакыттагы «Кәрван» чәй фирмасының чәйләрен мактап язган шигырен күрсәтә иде. ...Бу шигырь өчен Тукай «Бәянелхак» идарәсе аркылы егерме биш сум акча да алды». (Тукай турында истәлекләр. Казан, 1986. 80 б.)

1 Тәннәрдән чыккан «рәван»... – монда «тир чыгу» мәгънәсендә, киная. Рәван җан – төш күргәндә тәннән чыгып йөри торган җан дип ышанудан гыйбарәт мифик төшенчә.

230 бит.

Бер кайгы көнендә. «Әлислах»ның 1908 елгы 27 апрель (28 нче) санында «Шүрәле» имзасы белән «Күңелсез минутта» исеме астында басылган. Г.Тукайның «Шүрәле» тәхәллүсе белән чыккан «Яшен ташлары» дигән җыентыгында (Икенче җөзьэ. Казан: « Өмид» матбагасы, 1912)* «Бер кайгы көнендә» дип үзгәртелгән.

Эссе кан, иске шан
Кайтмый гомер дә, –

дигән юллар «Яшен ташлары»нда:

Эссе кан, көчле җан
Кайтмас гомер дә, –

дип үзгәртелгән. 1905–1907 елгы инкыйлаб күтәрелешеннән соң Русиядә кара реакция еллары башлана. Сүз һәм вөждан иреге кысыла, бер-бер артлы инкыйлаб дулкынында дөньяга килгән вакытлы матбугат ябыла башлый. Боларның берсе дә Тукай иҗатына тәэсир итмичә калмый. Шуңа өстәп, Казан һәм татар иҗтимагый тормышындагы тискәре атмосфера да шагыйрьдә рухи кризис башлануга этәргеч ясый. Шул шартларда, күңел төшенкелеге кичергән вакытларында лирик, лирик-фәлсәфи шигырьләр иҗат итә.

Текст «Яшен ташлары»ннан (1912) алынды.

231 бит.

Саташкан. «Әлислах»ның 1908 елгы 19 май (30 нчы) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Шигырь Сәгыйть Рәмиевнең «Алданган» (Әлислах. 1908. 4 май) исемле шигыренә, аның формасын саклап, пародия рәвешендә язылган, шулай ук аның «Кайвакытта уйлыймын мин...» дип башланган шигырендәге образ-гыйбарәләр дә файдаланылган.

«Алданган» шигыре түбәндәгечә:

Бетте. Төштем. Үлде рухым.
Калмады һич рәхәтем;
Көн – авыр, төн – бер кабер, бер
Ел тоела сәгатем.

Ачынам, ачуланам һәм
Каш җыерам дөньяга…

Һаман алдый. Юк хакыйкать!
Мин, су, дим, ул – йон ага.

Юктыр, әлбәттә, кояш та
Ул дадыр – хәйлә генә!
Юктыр ай да, юк aләм дә,
Барысы да – шәүлә генә!

Юк бу дөнья капланган күк,
Юк бу җирләр берсе дә!
Юк табигать, юк кешеләр,
Үлесе дә юк, терсе дә!

Юк чыны бер нәрсәнең дә!
Чын «юк» үзе дә юк хәзер!
Беттем. Алдандым. Янамын...
Бар торышым ут хәзер.

Үттеләр, шәп шылтырап аккан
Судай, шат көннәрем;
Бер караңгы һәм төтенле
Көнгә алышты төннәрем.

Бар да карыйлар миңа
Ямьсез тутыккан күз белән,
Кычкыралар йөземә
Тәмсез, ачулы сүз белән.

Очрасам яңлыш берәүгә,
Яисә күрсәм эш белән,
Күренә елан, тырный күңелемне
Агулы теш белән.

Әрни-әрни ләгънәт әйтәм
Тискәре бу дөньяга,
Мин, мәхәббәт нуры, дим, ул
Аерылу шәмен яга.

Мәңге шул көйгә барырмы
Кара таплы бәхет?
Әллә әйләнер микән җил
Һәм исәр татлы вакыт?

С. Рәмиевнең «Кайвакытта уйлыймын мин...» дип исемләнгән шигыре:

Кайвакытта уйлыйм мин
Уйны – тәмлесен генә,
Тәмле уйларым эчендә
Тәмлерәге – «син» генә!

«Син» генә бар хәсрәтемне
Тараталсаң тарат!
«Син» генә рәхәт кояшын
Караталсаң карат!

«Син» генә – бар күккә патша,
Аш! – диген, күккә ашыйм!
«Син» генә – рух биргән Аллам,
«Син» яшә! Һәм «мин» яшим!

Тукайның дүртьюллык строфалары «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) икеюллыкка әйләндерелгән. Газетада басылган икенче юлдагы «рухы үлмеш» гыйбарәсе «Диван»да «бүрке үлмеш» дип, үндүртенче мисрагтагы «син, шаш, дисәң, тагын шашыйм» – җыентыкта «әйт: шаш, диген, тагын шашыйм» дип үзгәртелгән. Тукайның дүртьюллык строфалары «Диван»да (1908) икеюллыкка әйләндерелгән. «Әлислах»тагы:

Юк чыны һич нәрсәнең дә, –
Чын юктыр, иптәш, юк хәзер.
Бу да шатлык бит: мөселман,
Ди, Громов-поп хәзер, –

дигән шигырь юллары төшереп калдырылган.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

1 Ник аласың син аны, ул бит минем алтын тарак! – Татар мифларыннан күренгәнчә, Су анасының кайчагында басмага чыгып утырып, ай яктысында үзенең озын чәчләрен алтын тарак, көмеш тарак белән таравы турында әйтелә. Шагыйрьнең әлеге шигъри юллары «Су анасы» әсәрендә урын алган. Димәк, шигырь, нәшер ителгәнче, күпкә алдан язылган булган дигән нәтиҗә чыгарырга мөмкин.

2 Өч җирдә шәп диләр: «Йолдыз» вә «Әлислах», «Вакыт». «Йолдыз» –1906 елның 15 гыйнварыннан 1918 елның 21 июненә кадәр, «Әлислах» 1907 елның 3 октябреннән 1909 елның 22 июленә кадәр Казанда басыла, «Вакыт» исә 1906 елның 6 февраленнән 1918 елның 26 гыйнварына кадәр Оренбургта нәшер ителә. Болар өчесе дә заманы өчен прогрессив карашларны алга сөргән газеталар буларак билгеле.

3 Бу да шатлык бит: мөселман, ди, Громов-поп хәзер... – 1905 елның гыйнварында Русиядә башланган инкыйлаб тәэсирендә патша хөкүмәте халыкка азмы-күпме гражданлык хокуклары биргән «17 нче октябрь» манифесты игълан итә. Шуның тәэсирендә соңрак дәвер чукындырылган татарлар мөселманлыкка күчә, христиан динен тотучы башка милләтләрдә дә борынгы диннәренә кайту процессы бара, сирәк кенә булса да, руслар арасында да ислам динен кабул итү күренешләре күзәтелә. Моның бер мисалы – Уфа губернасы Бирск өязе Березовка авылында дьякон гаиләсендә туган Иван

Александрович Громов. Ул 1907 ел башында ислам диненә күчкән. «Бәянелхак» газетасының 1908 елгы 14 июнь (180 нче) санында аның тәрҗемәи хәле турында мәгълүмат бирелә. Ул башта семинария тәмамлый һәм Минзәлә өязенең Кармалах (газетада шулай язылган. – Төз.) авылына псаломщик итеп җибәрелә, берникадәр вакыттан соң Минзәлә шәһәре соборында дьякон, регент һәм мәктәптә балаларга җыр укыту вазифаларын башкара. Аннан ул, Златоустка күчеп, «Бәянелхак»та язганча, штатный дьякон булып тора. Утыз елдан артык христиан диненә хезмәт иткән дьякон Громов исламга күчү теләген архиерей җитәкчелегенә белдереп гариза яза. Әмма аның үтенече канәгатьләндерелми. Бу вакыйганы «Бәянелхак» түбәндәгечә бәян итә: «Хәзергә эше фигълиятькә чыкдыгы (гамәл кылынганы) юк. Кәндисе Казанда тормакчы буладыр. Ләкин юлында рәсми манигълар (киртәләр) күптер. Хәзер бу адәм рус матбугатының игътибарыны кәндисенә көндән-көн җәлеп итмәктәдер. Табигый, аның язуы «чын руслар» рухында булып, әхлак вә әдәпкә мохалиф (каршы) сүзләре хаиз иде (эченә алган, җыйган). Мөгътәбәр «Вакыт» гәзитәсенең мөхәррире Фатих әфәнде Кәримов Казанда мөхәрриремезнең дачасында (сайфиясендә) мәзкүр мөгътәбәр пирнурани илә мосахәбәдә (сөйләшүдә) булынарак, мөшар иләйһинең (югарыдан күрсәтелгән кешенең) рәсемене алып, гәзитәсенә басмак булмыш иде. Шаять, «Вакыт»та, яхуд «Әдәбият» мәҗмугасында күрелсә кирәк. Сабикъ кәшиш (элеккеге рухани) Громов – шимди Яхъя Искәндәрев. Ачык чәһрәле, ак сач вә сакаллы, хуш табигатьле бер карт адәмдер». «Бәянелхак» газетасы бу «изге адымы» өчен попны мактап, аңа ярдәм итәргә чакырып яза. «Йолдыз» газетасы редакциягә Громовка иганәдән җыелган егерме дүрт тәңкә акча керүен хәбәр итә ( 1908 ел, 1 февраль) һ.б. Соңыннан бу попның мөселманлыкка «чыгуы», архиерей җитәкчелегендә миссионерлар белән бергә, христиан руханилары оештырган бер провокация икәнлеге ачыла. Тукай монда шул вакыйгадан көлә.

232 бит.

Үпкә. «Әлислах»ның 1908 елгы 27 май (31 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «Габдулла Тукаев диваны»на (1908) кертелгән. «Әлислах»та икенче юл: «Гавамча әйтәм инде; дуст түгел, бәлки... лар сез» рәвешендә бирелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

233 бит.

Мәддахе Истамбул шагыйрьләре. «Әлислах»ның 1908 елгы 27 май (31 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән «Истамбул шагыйрьләре» исеме куелып басылган. «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) «Мәддахе Истамбул шагыйрьләре» дип үзгәртелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

1905–1907 елгы инкыйлаб дулкынында дөньяга килгән, заманы өчен алдынгы карашлы «Азат халык» газетасы (1906 ел, 18 июнь саны) түбәндәгечә язган иде: «...Истибдадны химая өчен халыкның караңгыда торуының лөзүме бик бәдиһидер... Төркия гәзитәләрен, кирәк көнлек, кирәк һәфтәлек гәзитә булсын, милли шигырь, әбъят вә хикәяләр язудан манигъ кыйлганлыкларын да укыдык. Бу көндән соң бу гәзитәләрниләр генә язарлар икән? Әле хәзергә Испания короленең өйләнүе илә бөтен сәхифәләрен тутыралар! Бервакыт бу да калмаячак, гәзитәләрен тутырыр өчен языла торган милли хикәяләр дә булмаячак. Сәясәттән язарга да ярамый, дөньядагы тәрәккыятьтән дә ярамый, тәнәззелен

дә язарга ярамый. Димәк ки, бу көндән соң гәзитәләрне тутырырга вөҗдансыз мөхәррирләр лязем булачактыр

1 Йолдыз тәти – Госманлы Төркиянең Стамбулдагы солтаннар резиденциясе.

234 бит.

Шекспирдән («Китә рәхәт...»). «Әлислах»ның 1908 елгы 27 май (31 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән «Шекспирдән дә бер сүз» исеме куелып басылган. «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) «Вак-төяк» дигән гомуми исем астында «Шекспирдән» дип бирелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

235 бит.

...га («Син дисең...»). «Әлислах»ның 1908 елгы 3 июнь (32 нче) санында «...гә (Мәслихәт)» исемендә «Шүрәле» имзасы белән басылган. «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) «...гә» «...га»га алмаштырылган, «(Мәслихәт)» сүзе төшереп калдырылган. Соңгы строфаның беренче юлындагы «куеп» сүзе «Әлислах»та «ябып» дип бирелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

236 бит.

...гә («Бай баласы бит...»). «Әлислах»ның 1908 елгы 3 июнь (32 нче) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. «Габдулла Тукаев диваны»на (1908) кертелгән.

Дүрттомлы «Әсәрләр»нең 1 нче томында бу шигырьдә сәүдәгәр Бәдретдин Апанаевның бик мактанчык улы Гали Апанаев турында язылганлыгы әйтелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

237 бит.

...гә («Очраган юлда...»). «Әлислах»ның 1908 елгы 3 июнь (32 нче) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган, «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) чыккан. «Әлислах»та өченче юл «Күргәнең бармы синең Коръәндәге мәдхияңи» рәвешендә килә. Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

Шигырь Тукайның яратып йөргән кызы Зәйтүнә Мәүлүдовага багышланган.

1 «Ля шәркыя, ля гарбия...» – Коръәндә Алланы сыйфатлаганда, ул бар, әмма уңда да түгел, сулда да түгел, алда да түгел, артта да түгел, аста да түгел, өстә дә түгел, ләкин бар дигән мәгънәне аңлатканда китерелгән сүзләр.

2 «Сабах» – 1902 елда Казанда бертуган Әхмәдуллиннар «Көтепханәи ибтидаи» («Башлангыч мәктәп китапханәсе») дигән китап кибете ача, соңрак исеме «Көтепханәи Сабах Габделвәли Әхмәдуллин» дип үзгәртелә.

238 бит.

Алдандым. «Әлислах»ның 1908 елгы 10 июнь (33 нче) санында, «Лермонтовка тәкълид» дип әйтелеп, «Шүрәле» имзасы белән басылган, соңыннан «Габдулла Тукаев диваны»на (1908) кертелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

Тукай бу әсәрен М.Ю.Лермонтовның «К* («Я не унижусь...»)» шигыреннән (1832) иҗади тәрҗемә иткән. Лермонтовта ул түбәндәгечә:

Я не унижусь пред тобою;
Ни твой привет, ни твой укор
Не властны над моей душою.
Знай: мы чужие с этих пор.
Ты позабыла: я свободы
Для заблужденья не отдам;
И так пожертвовал я годы
Твоей улыбке и глазам,
И так я слишком долго видел
В тебе надежду юных дней
И целый мир возненавидел,
Чтобы тебя любить сильней.
Как знать, быть может, те мгновенья,
Что протекли у ног твоих,
Я отнимал у вдохновенья!
А чем ты заменила их?
Быть может, мыслию небесной
И силой духа убежден,
Я дал бы миру дар чудесный,
А мне за то бессмертье он?
Зачем так нежно обещала
Ты заменить его венец,
Зачем ты не была сначала,
Какою стала наконец!
Я горд! – Прости! Люби другого,
Мечтай любовь найти в другом;
Что б то ни было земного
Я не сделаюсь рабом.
К чужим горам, под небо юга
Я удалюся, может быть;
Но слишком знаем мы друг друга,
Чтобы друг друга позабыть.
Отныне стану наслаждаться
И в страсти стану клясться всем;
Со всеми буду я смеяться,
А плакать не хочу ни с кем;
Начну обманывать безбожно,
Чтоб не любить, как я любил, –
Иль женщин уважать возможно,
Когда мне ангел изменил?
Я был готов на смерть и муку
И целый мир на битву звать,
Чтобы твою младую руку –

Безумец! – лишний раз пожать!
Не знав коварную измену,
Тебе я душу отдавал;
Такой души ты знала ль цену?
Ты знала – я тебя не знал!

240 бит.

Кызык гыйшык. «Әлислах»ның 1908 елгы 17 июнь (34 нче) санында «Мәҗнүн» имзасы белән басылган. Тукай бу имзаны башка шигырьләрендә кулланмый. Аста «12 июнь, 1908» датасы бар. «Әлислах»ның 1908 елгы 24 июнь (35 нче) санында «Кызыклы гыйшык» шигырендә киткән хатаны төзәтеп уку өчен, «Тасхих»та: «Үткән номерда «Кызыклы гыйшык» сәрләүхәсе шигырендәге «җилкәне», «җилкә» вә «нечкәләтепне», «нечкәләп» дия укырга тиеш», – дигән искәрмә бирелгән.

Серноводскида дәваланып яткан Ф.Әмирханга 1908 елның 23 июнендә язган хатын шагыйрь түбәндәге сүзләр белән башлый:

«Фатих әфәнде! Сәлам, конечно.

Хатыңызны алдым. «Әлислах»та «Кызык гыйшык» шигырен яраттыңызмы? Керпе үзенең кабыгына кереп яшеренгән төсле, мин дә, сөю хакында бер нәрсә язсам, ялган имзалар артына сыгынам».

Шигырь Тукайның Зәйтүнә Мәүлүдовага булган мәхәббәте тәэсире белән язылган. Анда Тукайның үзенең шәхси хәленә карата ачы иронияce булган:

Тирләп, эссе көндә койнырга теләп,
Бер кеше салкын су алды бер чиләк...
Суны җилкә аркылы читкә сибеп
Куйды да... «Әл дә тәнгә тимәде», – дип шатлана!–

дигән юллар, бу әсәр басылганга чаклы байтак вакыт элек, «Фикер»нең 1907 елгы 13 май (иң соңгы 18 нче) санындагы «Думаның хәле» дигән баш мәкаләдә, иҗтимагый күренешкә ирония буларак, түбәндәгечә яңгырый: «Инде хөкүмәткә бер дә тимичә генә яңлыш тиелеп китсә, каршысына тез чүгәргә мәҗбүр булган Думаның дәвам итүе дә, итмәве дә барыбер кебидер. Бер кеше, комган берлә салкын су алып коенганда, суны тәненә тигезмичә, читкә түккәндин соң: «Әле дә ярый тимәде», – дип куана, имеш. Думаның урта партия кешеләренең хәрәкәте дә шул кешенең коенуы кабиленнән генә булырга охшыйдыр. Ни булса да, Думаның хәле бик кызганычтыр. Дума ике ут арасындадыр».

Шулай итеп, бу ике әсәр арасында бәйләнеш ярылып ята.

«Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) шигырьгә «Белмим дим дә...» дип башланган соңгы алты юл өстәлгән.

«Кызык гыйшык» шигырен Тукай 1908 елның 11 октябрендә Купеческое собрание залына (хәзерге Островский урамындагы Яшь тамашачылар театры бинасы) җыелган ислахчы яшьләр әдәби кичәсендә сәхнәдән укый.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

1 Бер хәбәр бар: ул хәзер киткән бугай – Тукайның мәхәббәт тотып йөргән кызы Зәйтүнә Мәүлүдова, Казанга яз башларында килеп, язучы Марсель Гариф мәгълүматына караганда, 1908 елның 12 июнендә Чистайга китә. Димәк, шагыйрь Зәйтүнә Мәүлүдованың Казаннан китү хәбәрен ишетеп, шигырь шул ук көнне хәбәр ишетелү белән иҗат ителгән.

241 бит.

Өмид. «Әлислах»ның 1908 елгы 2 июль (36 нчы) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Әсәр астында «28 июнь 1908 сәнә» дип куелган. «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) «Әлислах»тагы «Мин адаштым, изге юлга ул торып күндермәсә» дигән өченче юл «Мин адаштым, тугъры юлга ул торып күндермәсә» дип, «Күп вакытта сискәнәм, кош дип тотып яңлыш бака» дигән ундүртенче юл «Күп вакытта сискәнәм, яңлыш тотып «кош» дип бака»га үзгәртелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диван»ыннан алынды.

1 «Мин әле кая барам?» – Тукайның кая барырга, ни эшләргә белмичәрәк аптырап торган чагында әйтергә яраткан сүзләре. Аның бу сүзләре шигырьләрендә дә, 1908 елның 23 июнендә Ф.Әмирханга язган хатында да очрый. Аны дуслары да яхшы белеп, Тукайны үзара: «Мин әле кая барам?» әле ул», – дип көлеп әйтә торган булганнар (кара: «Замандашлары», 95 б.).

2 Кисмәк өстендә каракош – иттифакый кунган ул. – Монда Тукай үзенең «Тавыклар һәм Каракош» дигән (И.А.Крыловның «Орел и Куры» исемле мәсәленнән) иҗади рәвештә башкарылган чәчмә тәрҗемәсенә ишарәли. Мәсәлдә кисмәк өстенә кунган Каракоштан көлгән тавыкларга кошлар патшасы: «Кайвакытта безгә тавыктан да түбән төшәргә тугъры киләдер. Әмма тавыкларга һичбер вакытта болытларга җитү насыйп булмыйдыр», – дип җавап бирә, ягъни кисмәк өстенә кунаклау вакытлыча гына. Шагыйрь дә үзенең төшенкелеген, өметсезләнүен вакытлыча гына ди; фикерем кояшы батмаган, ул чыгачак, ди һәм менә «Иһтида» (1911 елның 13 маенда язылып, 15 июньдә «Шура» журналының 12 нче санында басылып чыккан) шигырендә:

Килеп чыкты хәзер фикрем кояшы золмәт артыннан,<br>Түгел инде вакытлы, мәгънәсе юк хискә мин корбан, –<br>дип белдерә.

242 бит.

Тормыш. «Әлислах»ның 1908 елгы 13 июль (37 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, «Габдулла Тукаев диваны»на (1908) кертелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

243 бит.

Җавап. Беренче тапкыр Ф. Бурнаш тарафыннан төзелгән «Г.Тукай шигырьләре» (Казан, «Гажур» нәшере, 1926) җыентыгында басылган. Әсәрнең язылу тарихы «1911» дип куелган. Төзүче астөшермәдә: «Бу шигырь бер җирдә дә басылмаган. Ләкин кемгә җавап урынында язылганы мәгълүм түгел», – дигән искәрмә биргән. Беренче

Дүрттомлыкның 2 нче томына искәрмәдә шигырьнең «Тукай кулъязмалары арасыннан табылып, Октябрь революциясеннән соң гына басыла башлавы» әйтелә.

Әсәрнең кулъязмасы сакланмаган.

Текст «Гажур» басмасыннан алынды.

1970 елның урталарына кадәрге тикшеренүләрдә «Җавап» шигыре әдип Галимҗан Ибраһимовка төбәлгән дигән фикер үткәрелә. Ләкин Тукай чоры вакытлы матбугатын җентекләп күзәтү-тикшерүләрдән шигырьнең Г.Ибраһимовка түгел, бәлки шагыйрь Зариф Бәширигә (1888–1962) «Җавап» икәнлеге ачыклана. Икенче Дүрттомлыкның 2 нче томына (1976) һәм Биштомлыкның 1 нче томына (1985) язылган искәрмәдә Р.Гайнанов моңа шактый төгәллек кертә.

З.Бәшири Оренбургта нәшер ителгән «Чүкеч» мәҗмугасында 1908 елның апрель башыннан эшли башлый. Беренче сатирик шигырьләре һәм публицистик язмаларында ук татар иҗтимагый хәрәкәтендә барган төрле характердагы кимчелек яисә күренешләргә тәнкыйди фикерләрен белдерә килә. Шул ук елның җәй айларыннан «Әлислах» белән «Чүкеч» журналы арасында фикер тартышлары башлана. «Әлислах»та «Чүкеч» журналында басылган кайбер материалларны тәнкыйтьләгән язмаларда Г.Тукай имзалары да бар. Нәтиҗәдә «Чүкеч»тә, газета мөхәррире һәм Тукай сатирасына җавап йөзеннән, З.Бәшири шигырьләр, эпиграммалар, фельетоннар бастыра, аларда Тукай тәхәллүсләре белән басылган шигъри әсәрләр, сатирик язмаларыннан көлгән фикерләр кабатлана. Бу чыгышларда шагыйрьнең шәхесенә кагылган дорфа кинаяләр, Тукайның шигърияten түбәнсеткән сүзләр шактый очрый. Мәсәлән, «Чүкеч»нең 1908 елгы 65 нче санында Тукай шәхесенә таш аткан берничә урын бар. «Мин менә шушылар илә ислахчы» язмасында: «Шүрәледән башка татар шагыйрьләре булуында шөбһә итәм. Сөйләргә тугры килгәндә, аны татар Пушкины дия генә сөйләем» дип искә алса, «Тәгатыэ әфкяре» (капма-каршы фикерләр) бүлегендә шагыйрьнең «Гөмберррт» тәхәллүсеннән көлә: «Иптәш! Тукай нидән үзенең имзасын «Дөмберррт» куя башлады икән?

– Аның берәр сәбәбе бар. Менә ничек ул әфәнде эчендә әллә нинди хыяллар йөрткән. Мәсәлән, Оренбургка баруы шикеллеләр. Бервакыт ул пешми калганда, хыяллары дөмберррт итеп ишелеп төшкән. Яисә, баш авыртып кайткач, яткан кроваты дөмберррт итеп ишелеп төшкәндер...» Төрле характердагы сатирик памфлет яки фельетоннарның күпчелеге З.Бәшири яисә аның тәхәллүсләре белән язылса да, бу мәҗмуганың, гомумән, Казанда нәшер ителгән «Әлислах» газетасына һәм «Яшен» журналына тискәре мөнәсәбәттә булуын күрергә мөмкин. Ләкин «Чүкеч» XX гасыр башы вакытлы татар матбугатын, кайда гына басылуына карамастан, үзенең һөҗүви угына алырга онытмый. Шул сәбәпләре мәҗмуганың мәсләге һәм аның авторы З. Бәшири Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камалларның шигъри һәм башка сатирик эчтәлектәге язмаларында бик еш тәнкыйтькә эләгә. З.Бәшири исә, «Мөтәрҗим шагыйрьгә» дигән памфлет язып, Тукайны шагыйрь түгел, тәрҗемәче генә дип күрсәтергә тели.

Син дә Пушкин, Лермонтовның
Бозгалап шигырьләрен
Шатланасың түшне киереп,
Мин дә бит шагыйрь диеп.

Тукай мондый әдәпсез хурлауларга тыныч кына карап тора алмаган, әлбәттә. Боларның барысына җавап итеп, ул әлеге «Җавап» шигырен яза. Ләкин Тукай шигырьне үз вакытында бастырып чыгармаган. Моның сәбәбен «Сәфилгә каршы язарга теләгән каләмгә» (Яшен. 1909, 2 март, 7 нче сан) шигырендә шагыйрь үзе үк:

Юк, маташма, и каләм! – калсынчы – шундый юк белән;
Борчак атмак көлкедер тау-таш ватарлык туп белән.
Ни эшең бар? Юкмыни, язсаң, югары нәрсәләр?
Угърашып торма җиһанда иң түбән мәхлук белән! –

дип күрсәтә. Тукайның «Җавап» шигыре үзенең эчтәлеге белән З.Бәширинең «Мөтәрҗим шагыйрьгә» (Чүкеч. 1908, 21 июнь) шигыренә турыдан-туры җавап дип санаганда, аның язылу датасы итеп 1908 елның июнь-июль айлары күрсәтелә ала.

244 бит.

Тешләре ямьсез матурга. «Әлислах»ның 1908 елгы 13 июль (37 нче) санында «Шүрәле» имзасы белән «Тормыш» шигыреннән соң «Тешләре ямьсез бер кызга» исеме астында басылган. «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) «Тешләре ямьсез матурга» дип бирелгән. Җиденче юлдагы «күрсәтимче» сүзе «“Диван. 5 нче дәфтәр” дә (1908) күрсәтмиче» дип басылган. Әсәр Зәйтүнә Мәүлүдовага багышлап язылган дигән фикер бар. Әхмәт Фәйзи архивында сакланган язмаларда, блокнотларында исә шигырьнең Ф.Агеевнең хатыны Суфия Коләхмәтовага (Г.Коләхмәтовның сеңлесе) атап язылуы хакында мәгълүмат теркәлгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

245 бит.

Кулың. «Әлислах»ның 1908 елгы 20 июль (38 нче) санында «ГъТ.» имзасы белән басылган. Бу рәвештә (ноктасыз) имзаны Тукай беренче тапкыр шунда куллана. Шигырьнең исеме астында җәяләр эчендә «Мактый беләм микән дип кенә мактаган» дип куелган. В.Бәхтияров истәлегендә шигырьне Зәйтүнә Мәүлүдовага багышланган дип яза. «Тукай турында истәлекләр»гә (1986) язылган искәрмәдә «ирония белән тәмамлана торган бу шигырьне Тукайның сөйгән кызы Зәйтүнәгә багышлап язу ихтимало юк» дигән юллар бар. Шигырь «Габдулла Тукаев диваны»на (1908) кертелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

246 бит.

«Мөхәммәдия»дән. «Әлислах»ның 1908 елгы 20 июль (38 нче) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган һәм «Габдулла Тукаев диваны»на (1908) кертелгән.

Бәкер Яфаров «Тукай сатира һәм пародияләренең антиподларына карата» исемле мәкаләсендә «Бу шигырь Мөхәммәд Чәләбинең (XV гасырда яшәп иҗат иткән төрек шагыйре) «Мөхәммәдия» китабындагы «Ифтитахе рисаләи Мөхәммәдия» бүлеге тезмәсенә пародия» дип яза.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

«Казан мөхбире» газетасының 1906 ел 31 июль (126 нчы) санында имзасыз мондый бер хәбәр бар:

«Бәянелхак» сахибе Әхмәтҗан Сәйдәшев Уральскидә «Фикер» сахибе Төхфәтуллинне судка биргән. Сәбәп – 25 июнь «Фикер»дәге Сәйдәшевне тәхкыйрьләр, имеш».

Шигырьдәге эчтәлек түбәндәге вакыйгаларны искә төшерә: «Фикер»нең 1905 елгы 17 май (18 нче) санында «Тәрәкъкый хакында бер-ике сүз» дигән баш мәкалә басыла. Бу язмада XX гасыр башында яшәгән татар халкының тәрәкъкыйпәрвәрлеккә ирешә алмавының төп сәбәпләренең берсе – хатын-кызның пәрдә артында яшәргә мәҗбүр ителүе, ягъни качуы, татар иҗтимагый хәрәкәтендә катнаша алмавы күрсәтелә; «хатыннарны әсирләр итеп асрамыйк» дип халыкка мөрәҗәгать ителә. Мәкаләдә тасвирланган вакыйгага «Фикер»нең башка саннарында да шактый урын бирелә. Күләмле мәкаләләр, шигырьләр басыла, качуның зарарлары санап үтелә. Шуны искәртү кирәк: XX гасыр башында дөньяга килгән татар вакытлы матбугатында хатын-кыз иреге мәсьәләсе төрле аспектта, һәрдаим яктыртылып килә. Уральскида нәшер ителгән «Фикер» газетасында дөнья күргән язмаларга каршы Казан сәүдәгәрләре Ә.Сәйдәшев җитәкчелегендә чыккан «Бәянелхак»та, качуның дөреслеген раслап, төрле чыгышлар басыла. «Бәянелхак»ка җавап йөзеннән «Фикер» үзенең 25 июнь (23 нче) санында «Тугъры җавап» исемле кечкенә генә бер мәкалә урнаштыра: «Казанда «17 октябрь союзы»ның члены Ахмакҗан абзый, – и, яңлыш ычкынды ла, – Әхмәтҗан абзый «Габделхак»* исемле гәзитендә «Фикер»дә качмау хакында яздыгымызга каршы ачуланып, ни әйткәнене үзе дә аңламаенча, бер җавап язган иде. Бунарга каршы рәфикымез «Таң йолдызы» ушбу сурәттә бик яхшы һәм тугры җавап биргән. Без шуның берлә хәзергә кифайәтләнәмез».

Моннан соң «Таң йолдызы»ның Сәйдәшевкә җавабы урнаштырылган. Чын дөресе исә, Сәйдәшевнең Камил Мотыйгыйны судка бирүе «Казан мөхбире»ндәгечә «Фикер»нең 25 июнь саны өчен түгел, бәлки 18 нче санда урын алган кечкенә генә хәбәр сәбәпче була.

Кара реакция чорында Камил Мотыйгый, 1905–1907 елгы инкыйлаб дулкынында формалашкан прогрессив карашларыннан бераз чигенеп, «Бәянелхак»та мәкаләләр бастыра башлый. Тукайның бу шигыре шул уңайдан язылган.

Тукай «Мөхәммәдия» китабындагы түбәндәге шигырьне үрнәк итеп алган:

Диде адәм ки, йа Раббем, оныттым,
Янылдым юлый, яңлыш юла киттем.
Билем гаҗиз синең хикмәтләреңдин,
Дилем кыска синең нигъмәтләреңдин, –

рәвешендә килә.

1 Камил – бу урында нашир, җырчы Камил Мотыйгый (Камил Мотыйгулла улы Төхфәтуллин) (1883–1941) күз уңында тотыла.

2 Сәйдәш – сүз сәүдәгәр һәм эшкуар, җәмәгать эшлеклесе Әхмәтҗан Яхья улы Сәйдәшев (1840–1912) турында бара.

3 Бәянелхак – 1906 елның 31 мартыннан 1914 елның 6 апреленә кадәр Казанда татар телендә нәшер ителгән иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. Нашире һәм мөхәррирләре – Ә.Сәйдәшев, М.Сәйдәшев, Ш.Иманаев.

4 ...тәмамилә аңа мөлхакларыңны – Мөлхак – кушымта дигән сүз; бу урында Тукай реакция елларында «Бәянелхак»ның кушымтасы гына булып калган «Казан мөхбире» газетасына һәм «Бәянелхак»та шагыйрь-публицистның үзе катнашлыгында чыккан

«Яшен», «Әлислах» кебек газета-журналларда заманы өчен прогрессив саналган карашларга каршы көрәшү өчен оештырылган «Без» исемле «сатирик» кушымта-бүлеккә ишарәли.

247 бит.

Күк сыер. Шигырь «Әлислах»ның 1908 елгы 27 июль (39 нчы) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «Ахыры булыр» дип куелса да, ахыры күренмәде. Газетада шигырьнең 15 нче юлында «Әтнәгә» куш җәя эченә алынган, 24 нче юлда исә «Әтнә» сүзенә куш җәя куелмаган. «Габдулла Тукаев диваны»на (1908) кертелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

1 ...мин шулай язган чагында йөткерәм – 1907 елның октябрендә Казанга кайткан Тукайда ятимлек тормышының «бүләге» – сәламәтлеге какшау үзен сиздерә башлый. 1907 елның 30 декабрендә апасы Газизә Госмановага язган хатында: «Әле бу арада бик яхшы гына авырып алдым. Хат яза алмадым», – дигән юллар бар. 1908–1909 елларда, шагыйрь язганча, бизгәк тоту хәлләре еш кабатлана.

249 бит.

«Яшен» журналы хакында. «Яшен» журналының 1908 елгы 1 август (3 нче) санында мәҗмуга чыга башлавына багышлап язылган. «Август башы» исемле мәкаләнең ахырына урнаштырылган. «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) мөстәкыйль шигырь итеп бирелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

1 «Яшен» – 1908 елның августыннан 1909 елның 24 июненә кадәр Казанда татар телендә нәшер ителгән сатира һәм юмор мәҗмугасы. Нашире һәм мөхәррире, рәссамы – Г.Камал, секретаре – Г.Тукай.

250 бит.

Тотса мәскәүләр якаң. «Яшен»нең 1908 елгы 3 нче (1 август) санында «Гөмберррт!» имзасы белән басылган. Бу тәхәллүсне Тукай беренче тапкыр шунда куллана. Бәкер Яфаров «Тотса мәскәүләр якаң» шигырен «Бакырган» китабындагы бер тезмәгә пародия итеп язылган дип күрсәтә. Тукай «тюрьму» һәм «Нет, князь, постой» сүзләрен кириллицада яза. «Яшен»дә шигырьнең 9 нчы юлында «яхшы дусларың» куш җәягә алынган. «Габдулла Тукаев диваны»ның (1908) эчтәлегендә булса да, шигырь үзе кертелмәгән. Биштомлыкның 1 нче томына (1985) язган искәрмәдә Р.Гайнанов: «Моны цензура үткәрмәгән дип аңларга кирәк: матбугат буенча вакытлы комитет документларында Тукайның бу шигыренә карата «нежелательно» дигән сүз очрый (ТАССР Үзәк дәүләт архивы, 32-фонд, 1-тасвирлама, 235-архив берәмлеге, 6–7 бб.)», – дип аңлатма бирә. Кызганыч ки, күрсәтелгән фонд, Татарстан Милли архивында, Матбугат буенча вакытлы комитет фондына, гомумән, карамый. Бу фонд элек тә, бүген дә 420 нче сан белән йөртелә. 199 нчы жандарм һәм 420 нче матбугат буенча вакытлы комитет материаллары арасында безгә кирәкле мәгълүмат табылмады. Бүген шигырь «Диван» җыентыгының эчтәлегендә булып та, тексты булмавының сәбәбе ачык кала. Шигырь 1911 елда гына «Яшен ташлары» (2) җыентыгында чыга. Басмаларда үзгәреш юк.

Текст «Яшен»нән алынды.

Әсәр «Бакырган китабы»ның бер шигырен үрнәк итеп язылган һәм «Яшен»дә «Бакыргандин» дип куелган. «Бакырган»да ул шигырь:

Нә кыйлырсың, мескин адәм,
Тотса Газраил якаң?
Ничек җавап бирерсең,
Тотса Газраил якаң?
Байдырмыз дип йөредең,
Фәкыйрьне күзгә элмәй;
Байлыгың һич сәүдә итмәс,
Тотса Газраил якаң!..–
рәвешендә килә.

251 бит.

Ысулы кадимче. «Яшен»нең 1908 елгы 3 нче (1 август) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Журналда әсәрнең II бүлеге, 10 нчы юлында «Афициант» булып басылган. Бу сүз мәҗмуга һәм «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) башка урыннарда «афисиант» рәвешендә языла. «Яшен»дә 41–42 нче юллар:

Кетердәп тәмле пешкән кәтлитеме?
Закускага дәхи кошлар итеме? –

дип бирелгән. Басмаларда зур үзгәреш юк.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

Әлеге әсәрне Бәкер Яфаров Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия» китабындагы «Сәбәбе тәэлифе китабы “Мөхәммәдия”» исемендәге тезмәсенә пародия рәвешендә язылган дип күрсәтә. Ул шигырь:

Мәгәр көннәрдин бер көн, әмре тәкъдир,
Утырмыштым Кәлибүлидә сирра.
Әлеми чикмешдем җөмлә халыктан,
Дилемдә зикер иде, кальбемдә – зикра.
Кәлибүлинең ул гашыйкларындин
Дезелдиләр кәлеп катыма торра...* –

дип башлана.

254 бит.

*** («Руслар эш күрәләр...»). «Яшен»нең 1908 елгы 1 август (3 нче) саны тышлыгында рәсем астында имзасыз басылган. Рәсемдә шәһәр Думасына сайланган гласныйлар тезелешеп утырганнар, фикер алышалар. Рус гласныйлары сөйли, татар өстәлгә башын салып йоклый.

Текст «Яшен»нән алынды.

Бу икеюллык беренче тапкыр әдип Н.Исәнбәт тарафыннан «Казан утлары» (1966, 4 нче сан) журналында басылган. Ул әлеге шигырьне Тукайныкы булуын раслап түбәндәгечә яза: «Бу журнал Тукай инициативасы белән чыгарылып, кайбер номерлары баштанаяк дип әйтерлек аның каләме белән язылган. Шулай булгач, журналның беренче номерының тышлыгындагы карикатура астына язылган беренче сүз-мәкаль – шигырь формасындагы бу ике юл да – анык булырга туры килә». Мәкаләдәге фикерне истә тотып, икенче дүрттомлыкның 2 нче томында (1976) «Тукайныкы булуы ихтимал шигырьләр» бүлегенә

урнаштырылган. Соңгы тикшеренүләр исә «Уклар», «Яшен» һәм «Ялт-йолт» кебек сатирик һәм юмористик журналлардагы рәсем асларының барысы да диярлек Тукай тарафыннан язылганлыгын күрсәтә.

255 бит.

Кемнән ярдәм эзләргә? «Әлислах»ның 1908 елгы 6 август (40 нчы) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «Майковтан тәрҗемә» дип куелган. «Габдулла Тукаев диваны»на (1908) кертелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

А.Н.Майковның (1821–1897) немец шагыйре Һ.Һәйне буенча эшләнгән тәрҗемә һәм вариацияләре 1852–1867 еллар эчендә языла. Алар 42 бүлектән тора. Тукай тәрҗемәсендәге шигырь 5 нче бүлеккә карый һәм ул 1852 елда иҗат ителгән. Тукай бу әсәрне иҗади эшкәртеп, татар халкына хас бизәлешләргә баетып биргән. Русча шигырь түбәндәгечә:

Много слышал добрых я советов,
Наставлений, ласки и обетов;
Говорили: «Только не ропщите,
Мы уж вас поддержим, погодите!»
Я поверил, ждал, заботы кинул,
И едва от голода не сгинул...
Да нашелся добрый человек, –
Поддержал, спасибо, он мой век.

Каждый день он хлеба мне приносит
И в награду ничего не просит...
Обнял бы его я, – да нельзя!
Человек-то добрый этот – я.

256 бит.

Бер рәсемгә. «Әлислах»ның 1908 елгы 8 сентябрь (44 нче) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган, «Төрекләргә тәкълид» дип куелган. Газетада «Шөбһә юк...» дип башланган 8 нче юл «Диван»да (1908) «Шөбһәсез...» дип бирелгән; 8 нче һәм 6 нчы строфаларның урыны алмаштырылган.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан (1908) алынды.

1 Ләйлә, Мәҗнүн – азәрбайҗан әдәбияты классигы Низами Ганҗәвинең (1141–1209) «Ләйлә вә Мәҗнүн» исемле поэмасы геройлары. Урта гасыр шәрекъ әдәбиятының бу гүзәл үрнәген Урта Азиядә исә беренче булып Алишер Нәвои төрки телдә яза. Соңрак дәвер, ягъни XVI гасырда, күренекле азәрбайҗан шагыйре Фөзули да «Ләйлә һәм Мәҗнүн» поэмасын иҗат итә. Гомумән, мөселман, шул исәптән, төрки дөньясында бу күркәм сюжетка корылган әсәр яисә дастаннарны шактый очратырга мөмкин.

2 Адәм, Хаува – пәйгамбәрләр тарихы Адәм белән Хаувадан башлана. Дини мифология буенча, алар – җир йөзендәге беренче кешеләр. Иблис коткысы белән оҗмах эчендәге агачның җимешен ашаганнары өчен Аллаһ Тәгалә аларны оҗмахтан кудыра.

3 Һарут берлә Марут – Аллаһ Тәгалә тарафыннан кешеләрнең бозыклык эшләүләрен тыю һәм шуны бетерү өчен җиргә төшерелгән фәрештәләр. Җирдә бу ике фәрештә хатын-кызлар белән чуалып үзләре дә зур гөнаһларга бата, хәтта кеше үтерүгә кадәр барып җитә. Шуның өчен Аллаһ Тәгалә аларга ике юл тәкъдим итә, берсе – яшәү, икенчесе – киләчәк. Фәрештәләр икенчесен сайлый. Дини риваятьләр буенча, алар бүген дә Вавилон төрмәләренең берсендә ахырзаманда үзләренең тоткыннан азат булуларын көтеп яталар, имеш.

4 Кәүсәр – дини мифологиядә җәннәттәге татлы сулы чишмә исеме.

5 Хозыр Ильяс – дини мифология буенча, кешеләргә авыр чакларында һәрвакыт ярдәм кулы сузарга әзер торган һәм дөнья беткәнче үлмичә яши торган изге зат.

6 Иблис ләгыйнь – дини мифологиядә, шайтаннар башлыгы, Аллаһ Тәгаләгә каршы баш күтәргәне өчен мәңгегә ләгънәтләнеп җиргә сөрелгән һәм һәммә бозыклык аның кушуы буенча башкарыла.

257 бит.

Мулланың зары. «Яшен»нең 1908 елгы 2 сентябрь (10 нчы) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «Габдулла Тукаев диваны»на (1908) кертелгәндә “Мелла Насреддин”нән икътибас» дип куелган. Әсәр азәрбайҗан әдәбияты классигы Сабирның «Жалоба старика» исемле шигыреннән иҗади тәрҗемә ителгән («Мелла Насреддин» журналы кул астында булмау сәбәпле шигырьнең русчага тәрҗемәсе алынды). Әсәр «Мелла Насреддин»ның 1906 елгы 12 нче санында басылган. Сабир шигырендә тасвирланган вакыйгада гади картның үткән тормышын сагыну белән чикләнсә, Тукайда киңрәк фикер алына, XX гасыр башы өчен иске карашлы дип саналган татар муллаларының элекке хокукларын югалта барулары, инде узгандагы хакимлекләр кайтмаячагы, шуңа үкенү һәм сагыну хисе ярылып ята. Шигырь бу ягы белән дә иҗади һәм әһәмиятле. Мәскәү дәүләт университеты профессоры Азиз Шәриф «Абдулла Тукай и Сабир» исемле мәкаләсендә болай ди: «По характеру своего поэтического творчества и по индивидуальному жизненному пути Сабир и Тукай очень близки друг к другу. Они не встречались, но не подлежит сомнению, что знали друг друга по печатавшимся в те годы в газетах и журналах стихотворениям».

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан (1908) алынды.

Сабирның «Жалоба старика» шигыренең русчасы түбәндәгечә:

До чего ж я постарел! Палка выпала из рук.
Где ты, молодость моя?
Слабость разлита во мне, мой удел теперь – досуг.
Стал терпеть убытки я.

Горя больше в десять раз – лишь начну я вспоминать
О моих прошедших днях!
О, добьюсь ли в жизни я тех счастливых дней опять?
Ох, увы, увы, Аллах!

Поседела борода, согнута моя спина, –

Чем я спину разогну?
Ежедневно мажет хной бороду мою жена –
Изгоняет седину!

Нет, еще я не забыл развеселых дней моих –
С пеньем, музыкой, вином!
Как башку я разбивал сотням слабых и нагих
Этим самым кулаком!

Так на поприще своем добывал я серебро,
Так я золото копил!
Грозной силой кулака я присваивал добро, –
Где ты, где ты, юный пыл?

Нет, не сжать мне кулаков, не свершить моей мечты:
У меня опоры нет!
Такова моя судьба. Я спустился с высоты.
Кто спасет меня от бед?

Все молчат, молчат в ответ!
Где же ты, шумной славы след?
Лишь о юности тоску
Я лелею, стар и сед!

1 Сабир – Сабир (Мирза Алекпер оглы Таирзадә) (1862–1911), азәрбайҗан шагыйре.

2 «Мелла Насреддин» – азәрбайҗанча рәсемле сатирик журнал, 1906 елда Тифлиста басыла башлый, аңа нигез салучы – Җәлил Мәмәдкулизадә. 1912 елда журнал төрле сәбәпләр белән туктатыла. 1913 елдан кабат үз эшчәнлеген дәвам итә. 1914 елның октябрендә тагын ябыла. 1917 елның башларында торгызылса да, шул ук елда цензура мәҗмуга чыгаруны тыя. 1921 елда – Тәбриздә, 1922 дән 1931 елга кадәр Бакуда нәшер ителә.

3 «Мохтасар» – кыскача дини кагыйдәләр китабы.

258 бит.

Авыл җырлары (беренче көлтә). «Яшен»нең 1908 елгы 2 сентябрь (10 нчы) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Шигырь исеме астына «Һәртөрле көйгә килә. Беренче көлтә» дип язылган. Ахырга: «Беренче көлтә тәмам. Киләчәк номерларда икенче вә өченче көлтәләр дә бәйләнеп басылсалар кирәк», – дип куелган. Бу тәртип Тукайның үзе исән чакта чыккан җыентыкларында юк.

Текст «Яшен»нән алынды.

«Чүкеч» мәҗмугасы, Казанда нәшер ителгән «Әлислах» газетасын һәм «Яшен» журналын никадәр тәнкыйтьләп язса да, «Яшен»дә «Авыл җырлары» басылуны хуплап каршы ала. Ул бу хакта болай ди: «“Яшен” журналы 2 нче номерасында «Авыл җырлары» язган. Бу җырлар һәркемнең җаен үз гадәтемезчә аңладыгыннан, без боларны күңелле

журналларына тәмам лаеклы табабыз. Рәмиевләр алтыны артыннан чабучы яшьләргә беленүе бераз әллә ничегрәк булса да, яңа системда булган бу җырларны каршы күтәрәмез вә шатлык илә тәбрик итәмез». Журналда «Авыл җырлары»ннан өзек тә тәкъдим ителә:

Безнең урам аркылы ага суның салкыны;
Тарта Казанның яшьләрен Рәмиевләр алтыны.

Хәтфә калфак киштәдә, эшләнүе бистәдә;
Морад кебек теләнчене күралмассың төштә дә.

Каф тавы артында үсә самарау-кош баласы;
Һинди Минһаҗ шул җирләрдә дарелфөнүн саласы, –

кебек юлларны күчереп бастыра. Бу факт, фәкать Казан белән Оренбургта дөнья күргән матбугатларның фикри каршылыклар нигезенә корылган бәхәсләр булуын раслаучы бер мисал.

1 Баязитов «Нур» гәзитен ничек язып өлгертә? – Петербург ахуны Гатаулла Баязитов (1847–1911) тарафыннан нәшер ителгән «Нур» газетасы 1905 елның 2 сентябреннән 1914 елның 22 июненә кадәр Санкт-Петербургта чыга. Газета күп очракларда патша хөкүмәте карарлары, татар милли буржуазиясенең идеологлары һәм үзенең бик озын язылган дини эчтәлектәге мәкаләләре белән тутырыла. Тукай шуннан көлә.

2 «Әхбар» тәэмин иткән байлар йөри икән кайларда...

«Әхбар» бай дип еллык яздым, ябыласын белмәдем...

«Хөкүмәт яптырды», – дидер наширләрнең уявы... – 1907 елның 10 декабреннән «Әхбар» («Хәбәрләр») газетасы чыгарыла. Анда, беренчедән, патша Русиясенең эчке һәм тышкы сәясәтен яктырткан материаллар күпләп урнаштырылу, шуларга өстәп, төрле вакыйгалар турында мәгълүмат бастыру белән, икенчедән, тора-бара ул милли буржуазия мәнфәгатьләрен яклауны икенче планга калдырып, аның тоткан кыйбласы радикальрәк төс ала баруы, өченчедән, хөкүмәт башына Столыпинның килүе белән Русиядә кара реакция көчәеп, матбугат органнарына кабат цензура кайту да тәэсирсез калмый. «Бу көннәрдә ишетдекемез ышанычлы хәбәргә караганда, – дип яза «Казан мөхбире» газетасы (1908, 21 июль), – «Әхбар» гәзитәсен тәэмин итүче байлары моннан соң гәзитәне дәвам иттермәскә карар биргәннәр икән». Кемнәр соң ул байлар? Алар: С.Аитов, С.Галикәев, С.Мусин, Г.Мөэминев, В.Гайнуллин, Ә.Әҗимев, Г.Юнысов, Г.Казаков һ.б. Үзләренә бер яктан да файда китермәгән газетадан алар кул селтәргә ашыгалар, нәтиҗәдә «Әхбар» 1908 елның 30 июнендә чыгудан туктый, әмма әлеге байлар «газетаны хөкүмәт туктатты» дигән хәбәр тараталар. Тукай әнә шул хәлләргә кагыла.

3 «Тәрҗеман»ның эче поша «Ислах» кызылга күрә. – 1905–1907 елгы инкыйлаб дулкынында татар иҗтимагый тормышында үзгәрешләр барган бер заманда чор өчен алдынгы карашлы татар яшьләре, шәкертләрнең мәнфәгатьләрен яклап, демократик рухтагы әсәрләр, мәкаләләр басканы өчен, «Әлислах» ны И.Гаспринский (1851–1914) наширлеге һәм мөхәррирлегендә басылган «Тәрҗеман» (1883–1918) газетасы күп тапкырлар тәнкыйтьләп чыга. Гомумән, бу елларда Казан, Оренбург һәм башка төбәкләрдә нәшер ителгән газета-журналлар «Тәрҗеман» газетасы алып барган милли-

мәдәни һәм сәяси кыйбланы вакыт-вакыт тәнкыйтьләп узуны кулай күрәләр. Монда шуңа ишарә.

4 Һинди Минһаҗ шул җирләрдә дарелфөнүн саласы.– Һиндстанда укып кайткан Һинди Минһаҗ дигән кушаматлы кеше (Кадерматев Минһаҗетдин Йосыф улы, 1871–1925), элекке Саратов губернасы Хвалын шәһәрендә Һиндстан мәдрәсәләре тибында югары уку йорты (университет) салдырам дип, халыктан акча җыйный, әмма ул акчаны үз кирәгенә тотып бетерә. Бу турыда 1906 елда ук «Казан мөхбире» газетасында (21 июль саны) болай язылган: «...Минһаҗ Йосыф әфәнде.., мәктәбе ибтидаиләре дә булмаган, ничә еллардан бирле уку-укытудан мәхрүм бер халыкка «күтәрә алмаган зурны күтәрә» дигән кабилдән әллә ниткән йөз мең сумлык, дүрт этажлы «Мәдрәсәи галия» салам, дип сөйләп йөреп, без приговорга имзаларымыз язылган имамнарны бөтен галәмгә бәднам кылуы (яман атыбызны таратуы) бер тарафта торсын, хәтта үземез берлә утырдыкыны вә мәслихәт кылышканы да юктыр. Өязгә килгән вакытында йөземезгә карап: «Мин үзем гакылсыз вә ахмак булып, сезләрнең ике тиен көмешкә ярамаган приговор вә имзаларыңны алып, үз-үземне бәднам кылдым. Юк исә сездән башка да акча җыйный аладыр идем», – дигән сүзләрне әйтергә, яхуд күземезгә күренмәй качып йөрергә уйламый вә тартынмыйдыр иде»... Бу вакыйга уңаеннан «Яшен»нең 1908 елгы 1 нче (3 август) санында мондый рәсем дә бар: тау башындагы шәһәр уртасында Казан университеты бинасына охшатылган ак колонналы зур бина. Аның уртасыннан Һинди Минһаҗның фәс кигән башы калкып тора, баштан тирә-якка кояш нурлары кебек нур сибелгән. Аска «Хвалынский тавы башында Минһаҗетдин Йосыф тарафыннан салынган университет» дип язылган. Тукай шул хәлләрне искә ала.

5 Тарта Казанның яшьләрен Рәмиевләр алтыны. – Закир (Дәрдемәнд, 1859–1921) һәм Шакир (1857–1912) Рәмиевләр – Уралдагы алтын приискасы хуҗалары. Бу ике милләтпәрвәр татар халкының мәдәни тормышында да күркәм эз салып калдыралар. Аларның матди ярдәме белән Оренбургта сәяси һәм әдәби «Вакыт» газетасы, иҗтимагый-мәгърифәти һәм әдәби-публицистик «Шура» (1908 елның 10 гыйнварыннан 1917 елның 31 декабренә кадәр чыккан) журналы нәшер ителә. 1909 елдан «Вакыт» нәшрияты оештырылып, анда Р.Фәхретдин, Ш.Камал, Г.Ибраһимов һәм башкаларның китаплары дөнья күрә. Алар наширлегендә басылган «Вакыт» һәм Шура»ның сыйфатын яхшырту нияте белән кайбер журналистларны, язучыларны Казаннан чакырту ягын да карыйлар һәм шул газета һәм журналда эшләү өчен, Оренбургка күчеп китәләр. Тукайга да чакыру ясала. «Әле Оренбурдан да мине чакырып хат килде, – дип яза ул апасы Газизә Госмановага 1908 елгы 27 март хатында.– «Вакыт» гәзитәсендә, «Шура» журналларында эшләргә... Ләкин мин хәзергә анда бара алмыйм». Казанга зур өметләр белән кайткан Тукайда күңел төшенкелеге башлана. Моңа өстәп Оренбургка бара алмауның сәбәбен горур Тукай апасы Газизә Госмановага (1908, 27 март) язган хатында: «Оренбур язучылары илә гәзитә аркылы бераз чәкәләшеп алган идек. Шуңа күрә алар хатны үземә язмыйча, бер иптәшемә язып, мине чакырганнар», – дип аңлата. Шул шартларда Оренбургтан Фатих Кәрими аңа атап чакыру хаты юллый. 1908 елның 23 июнендә Казаннан Серноводскида дәваланучы Ф.Әмирханга язган хатында ул: «Бу хәл туйдырды инде тәмам. Оренбургка Ф.Кәримов чакырган иде. Анда барсам, бәлки, үземә мөгаййән (билгеләнгән) эш булуы һәм серьезный кешеләр тирәсе файдалы булыр иде дим. Нишлим? Барыйм микән?

Монда «Әлислах» ходка китсә, көлке журналы да чыкса, үземнең кальбән сөйгән гәзитә вә идеямә хезмәт итәр идем», – дигән юллар бар. Тукай Оренбургка «Вакыт» газетасында эшләргә бармаган.

Шагыйрь бу вакыйганы үзенең «Авыл җырлары»нда көлеп искә ала. «Чүкеч» мәҗмугасы исә, Тукайдагы әлеге шигырь юлларын: «Яшен» журналында «Тарта Казанның яшьләрен Рәмиевләр алтыны» дия бер көлке җыр язылмыш иде. Казанның яшьләрен Рәмиевләр алтыны тарткан кебек, бөтен чирләрне дә, белмәм, нәрсә тарта?» – дип яза һәм, мәҗмугадан аңлашылганча, начар гадәтләр дә Казаннан күчә дигән фикер калдыра. «Чүкеч»тә урын алган әлеге фикергә «Әлислах»ның 1908 елгы 50 нче санында сатирик рәвештә җавап та бирелгән.

6 «Миръат» язмый ни хәлең бар, һичбер эшең уңмагач.– «Миръат» –татар милли хәрәкәте лидерларыннан берсе Габдрәшит Ибраһимов (1857–1944) тарафыннан 1900–1903, 1907–1909 еллар арасында барлыгы 22 сан чыгарылган журнал тибындагы китаплар һәм брошюралар җыентыгы. Г.Ибраһимов 1905 ел ахырыннан Петербургта « Өлфәт» исемле газета оештыра. 1907 елда ул тукталгач, яңадан «Миръат»ын чыгара. Бу брошюраның төп мәсләге милләткә дини-әхлакый тәрбия бирүгә корылган.

7 Мөштәриләр юк, ди, – инде игълан булса да ярый. – Казанда 1906–1914 елларда сәүдәгәр Әхмәтҗан һәм Мөхәммәтҗан Сәйдәшевләр тарафыннан чыгарылган «Бәянелхак» газетасына ишарә. Газетаның күпчелек өлешен рекламалар, эчке һәм тышкы хәбәрләр алып торган. Басылган аналитик материаллар Тукай һәм шул заманның алдынгы карашлы татар яшьләрен канәгатьләндермәү сәбәпле, бу газетага язылучы сирәк була.

8 Морад кебек теләнчене күралмассың төштә дә. – Татар байларының кайберләре хаҗ кылырга, Мәккә шәһәренә үзләре бара алмасалар, башка берәүне акча белән яллап җибәргәннәр. Бу акчаны «бәдәл» дип, кеше өчен барып хаҗ кылучыны «бәдәлче» дип атаганнар. Бу урында Тукай тарихчы, дин галиме һәм публицист Мораделмәккине (Мөхәммәтморад Рәмзи әл-Мәкки (1854/55–1934)) искә ала кебек.

9 Әчтерханда «Борһан», «Идел» – ике этәч бар икән.– Әстерханда чыккан «Борһане тәрәкъкый» («Прогресска дәлил», 1906 елның маеннан 1911 елның февраленә кадәр татар һәм төрек телләрендә басылган) һәм «Идел» (1907–1914) газеталары. Әстерханда нәшер ителгән «Борһане тәрәкъкый» газетасы белән «Шураи ислам» җәмгыяте идарә итсә, «Идел» газетасы исә заманы өчен алдынгы карашлы саналган «Җәмгыяти исламия» идарәсендә яши. Газеталар арасындагы төп каршылык нәкъ шул оешмалар төрле мәсьәләләрнең чишелешен хәл иткәндә туа да инде. 1908 елның 11 март санында «Идел» газетасының мөхәррире «Заһидулла Шәрифуллин» имзасы белән басылган язмада ул ачык күренә. Анда: «Борһане тәрәкъкый»ның 13 нче саны идарәмезгә килде. «Юбилей» сәрләүхәле бер мәкалә, 2 мәктүб, 3 Әстерхан хәбәре, 3 дәхили, 2 хариҗи хәбәрдән башка бөтен мөндәриҗәне (эчтәлекне) «Идел»гә вә «Идел» мөхәрриренә һөҗүмдән, тугрысы, бер шарлатанлыкдан гыйбарәт улдыгыны күрдек, укыдык, чук тәәссефләр итдек. Тәәссефемез, динсез – Фәлән, белмәмешләр дия язулары өчен түгел, фәкать һәфтәгә бер мәртәбә чыга торган милли бер гәзитәнең гарызы вә мәнфәгаты шәхсия өчен һибә ителүе монфәга (гомуми файда) урнында амәле шәйтаниягә (шәйтаннарга өмет) корбан улуы өчендер...

Өч елдан бирле динсезлек, мәлгунлек, монафикълык илә фәтва вирелгән, динсезлекләре җәмгыятьтә йәминнәр илә тасдыйк кылынган. Бөтен гәзитә сәхифәләрендә язылган, тутырылган кешеләргә доносить итәләр, шаһид булалар дия уфкәләргә

(үпкәләргә) ничек урын булсын? Чөнки динсез бит алар!..» Бу тартыш һәм бәхәсләр шактый дәвам итә. «Ялт-йолт»ның 1911 ел, 4 нче саны (23 июнь) тышлыгында да пыр тузып ике әтәч талашуын һәм тирә-якка йоннар очуын сурәтләгән рәсем урнаштырылган. Аста әлеге икеюллык китерелә.

10 Иран халкы онытмыйдыр шаһтан күргән «хөрмәт»не. – Иран халкын аерата каты кысуы, барлык прогрессив хәрәкәткә дошманлыгы белән танылган Иран шаһы Мөхәммәтгали (1872–1925) Ирандагы буржуаз революция хәрәкәте нәтиҗәсендә 1908 елда тәхеттән төшерелә. Тукай шуңа ишарә ясый.

11 ...Ишми ничек түзәйкән? – Ишми ишан – Ишмөхәммәд Динмөхәммәдов (1839–1919), элекке Вятка губернасы Малмыж өязе (хәзер Татарстанның Балтач районы) Түнтәр авылы мулласы. Патша охранкасы агенты, доносчы булуы турында мәгълүматлар сакланган. Иске карашлы мулла буларак, ул 1905–1907 елгы инкыйлаб дулкынында татар тормышына үтеп кергән демократик идеяләргә, җәдидчелеккә каршы көрәш алып бара. Донос белән шөгыльләнү 1917 елның 1–11 май көннәрендә Мәскәүдә узган Беренче Бөтенрусия мөселманнары корылтаенда делегатлар алдында фаш ителә. Ул Октябрьдән соң большевиклар суды карары буенча атып үтерелә.

12 Мөлхимәләр балдагы төрек халкын алдады. – Мөлхимә – төрек пашасы (дворяны), дипломат.

260 бит.

Авыл җырлары (икенче көлтә). «Яшен»нең 1908 елгы 3 сентябрь (30 нчы) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Ахырга « Өченче вә дүртенче көлтәләре дә бәйләнмәктә. Идарә» дип куелган.

Текст «Яшен»нән алынды.

1 Татар бае хаҗга киткән, шартлый мәллә югыйсә? – Бу урында шартлау – бөлү, банкротка чыгу мәгънәсендә. Татар байлары, сәүдә эшләре начарлана башласа, үзләренә ышанычны югалтмау өчен, Мәккәгә хаҗ кылырга китә торган булганнар. Монда шуңа ишарә.

2 Бу дөньяда шөһрәт алды Бәдигъ мәзин күркәсе. – Бәдигъ – Казанның Яңа бистә мәзине; «Казан мөхбире» газетасында «Игъланнар» бүлегендә түбәндәге белдерү бар: «Бәдигъ мәзиннең ата күркәсе чыгып качмыш. Китерүчегә бер сум һәдия кыйлыначак» (1906, 3 февраль, 32 нче сан). Бу вакыйга байтак еллар юмор-сатира объекты булып кала, кечкенә генә бер эш-хәл чамадан артып китсә, аны «Бәдигъ мәзин күркәсе» дип көлә торган булалар. Әле 1911 елда да «Ялт-йолт»та түбәндәге көлкене укыйбыз:

Төрле хәбәрләр.

...Тройски. – Монда чыгуы ихтимал булган көлке журналына мөхәррир булыр өчен мәшһүр Бәдигъ мәзин күркәсен чакырып телеграм биргәннәре ишетелде һ.б.

3 Мотыйгыйдән сорашыгыз мөхәррирлек читенен. – Уральск шәһәрендә 1905–1907 елларда «Фикер», «Уралец» һәм «Уральский дневник» газеталарын, «Әлгасрелҗәдид», «Уклар» журналларын чыгарган нашир һәм мөхәррир Камил Мотыйгый күздә тотыла. Газета һәм журналларда шул заманга хас прогрессив карашларны алга сөргәне өчен, К.Мотыйгый иске фикерле татар муллалары һәм байлары тарафыннан шактый тәнкыйтьләнә, патша властьлары күзәтүенә эләгә, хөкемгә дә тартыла һәм, ниһаять, наширлек һәм мөхәррирлек хокукларыннан мәхрүм ителә.

4 «Яшен» сугар татарларда сугарлык җир беткәнче. – Г.Тукай, Г.Камал, Ф.Әмирхан тарафыннан оештырылган һәм чыгарылган рәсемле сатирик «Яшен» журналы (1908–1909) татар иҗтимагый тормышында булган тискәре күренешләрне сатира объекты итеп ала, алардан ачы көлә, хәтта татарлар яшәгән башка төбәкләрдәге сатирик күренешләрне дә күз уңында тота, аларга да өлеш чыгара. Тукай язганча, «Яшен»нең нурлары еракларга барып җитә.

5 Сими бае зәкят илтә «Колибри» марҗага.– Татар байларының азып-тузып йөрүләренә ишарә. «Колибри» – трактир исеме.

6 Һади «Йолдыз»ны бик мактый – әллә ярата микән? – Казанда 1906 елның 15 гыйнварыннан 1918 елның 21 июненә кадәр чыккан иҗтимагый-сәяси «Йолдыз» газетасының мөхәррире Һади Максуди (1868–1941) үз газетасында үзен һәм газетасын мактаган мәкаләләр, хатлар, шигырьләрне дә бастыра. Монда шуңа ишарә ясала.

7 «Бәдәел мәгариф» саталар, алты сүзен башкартып. – 1906 еллардан соң башлангыч мәктәпләр өчен әлифба һәм уку китаплары төзү бик модага кереп китә. Кулына каләм тота белгән һәркем диярлек шундый китаплар язуны үзенең «милли бурычы» дип саный. Бу китапларның күбесе педагогик, методик таләпләргә җавап бирмәгәннәр һәм бер-берсеннән «биш-алты» сүз белән генә аерылганнар. Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал, Г.Ибраһимов кебек алдынгы эшлеклеләр мондый хәлгә каршы чыкканнар. Тукайның югарыдагы юллары шушы хәлләрне чагылдыра. Ул телгә алган «Бәдәел мәгариф» – имам Галимҗан Барудиның (1859–1921) «Сөаль вә җаваплы бәдәел мәгариф» («Сорау һәм җаваплы башлангыч белем») дигән китабы. Гарәп телен (башлыча Коръәнне) дөрес укырга өйрәтә торган бу китапның 1914 елда, мәсәлән, бик аз гына үзгәртелеп, унбишенче басмасы чыга (Казан: «Милләт» көтепханәсе).

8 Тычкан оясына сыймый, «Мөхбир» тагасың тагы. – 1905 елның 29 октябреннән Казанда беренче татарча газета буларак чыга башлаган «Казан мөхбире» соңыннан «Бәянелхак»ка кушымта булып кына кала. «Бәянелхак» үзе исә аз таралган, башлыча игъланнар басу исәбенә яшәгән газета. Тукай шушы хәлдән көлә.

261 бит.

Киңәш («Якын дустым...»). Шигырь «Әлислах»ның 1908 елгы 15 сентябрь (45 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, «Габдулла Тукаев диваны»на (1909) кертелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

262 бит.

Шатлык вә хәсрәт. «Әлислах»ның 1908 елгы 23 сентябрь (46 нчы) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Бишенче юлдагы «кисәктән» сүзе «Габдулла Тукаев диваны»нда (1909) «бераздан» дип үзгәртелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

Әсәр XIX йөз рус шагыйре А.Плещеевнең (1825–1893) «К чему мечтать о том, что после будет с нами» дип башланган шигыреннән иҗади тәрҗемә ителгән. А.Плещеевнең бу шигъри әсәре 1846 елда язылган һәм өч кисәктән тора. Беренчесендә табигатькә хозурлану булса, икенче һәм өченче кисәгендә кешенең социаль хәле тасвирланган. Тукай әсәрендә исә фикер башкачарак – шагыйрьнең дөньяга лирик-фәлсәфи карашы чагыла. Бу

очракта Тукай «Плещеевтән» дип куйса да, шигырьдә фикер тирәнрәк алынган. А.Плещеев шигыре түбәндәгечә:

1

К чему мечтать о том, что после будет с нами,
О том, чего уму постигнуть не дано...
Хоть часто тернии здесь смешаны с цветами,
Но все ж земную жизнь бесславить вам грешно.
Отратного и в ней, поверьте, много, много...
Смотрите: гром затих, и ясен свод небес...
И тучи прочь бегут лазурною дорогой,
И шепчет им вослед привет прощальный лес.
Смотрите, как луга вокруг благоухают,
Упитана дождем зеленая трава,
И легкий ветерок с волной реки играет,
И рожь златистая колышется едва...
Прекрасен этот мир! Возможно наслажденье!
К чему ж о гробе нам всечасно говорить...
Здесь ласки жен и дев и страсти упоенья,
Здесь сердце может всё, что хочет, полюбить!

2

Да! Этот мир хорош; но право наслаждаться
Даровано ли всем могучею судьбой?..
Здесь узники вдали от родины томятся,
Там в рубище бедняк с протянутой рукой.
Тот солнечных лучей напрасно ищет взором, –
Не заглянут они в окно тюрьмы его...
Другой на небеса глядит с немым укором, –
От зноя отдохнуть нет крова у него!
Не для него красы улыбка молодая,
Его трудов другим всегда назначен плод.
Под тяжким бременем нужды изнемогая,
Прекрасным этот мир бедняк не назовет!..
Но пред лицом творца равны его созданья –
И там найдет бедняк за муки воздаянья!

3

Да, верю, верю я, что все пред ним равны...
Но люди не для мук – для счастья рождены!
И сами создали себе они мученья,
Забыв, что на кресте пророк им завещал
Свободы, равенства и братства идеал

И за него велел переносить гоненья.

263 бит.

Улмы? – Ул... «Әлислах»ның 1908 елгы 23 сентябрь (46 нчы) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. «Габдулла Тукаев диваны»на (1908) кертелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

Бу шигырьнең язылу тарихы турында Тукай һәм Әмирханның дусты, «Әлислах»ның рәсми мөхәррире Вафа Бәхтияров (1881–1960) түбәндәгеләрне әйтә: «...“Бәянелхак” (Тукай «Бәянел шап» дип атый иде) газетасының секретаре, шул вакытларда көчәнеп язган, шагыйрь булырга йөргән һәм яшьләр арасында яхшы танцевать итүе белән танылган Рәкыйб Рәкыйби (1887–1963) турында Тукай үзенең «Улмы? – Ул...» шигырен яза». (Совет әдәбияты. 1945. № 3–4. 50 б. ) «Бәянелхак»та Рәкыйповның Г.Тукайга, Ф.Әмирханга, Г.Камалга карата көнчелек, үчлек белән язылган «фельетон»нарын да очратырга мөмкин. «Улмы? – Ул...» сатирик шигыренә З.Бәшири дә «Ул дисезме?» («Чүкеч». 1909. № 63.) памфлетын бастырып чыгара. «Чүкеч»нең 1908 елгы, 15 март (42 нче) санында «Сөальләр» бүлегендә Рәкыйб Рәкыйбинең бу сыйфатларыннан көлгән түбәндәге язма да бар: «Казанга килгәндә 5 тиенлек эшләпә, билендә 22 тиенлек каеш булып, үзенең «Сарай» нумерасына түләргә акчасы булмагач, «Бәянелхак» мөхәрриренең тарелкасын ята-ята ялау сәбәпле, «Сарай» нумерасының бәласеннән котылып, ярты аршын биеклегендә яка киеп, әдәбият кичәләрендә, дележур булып, үзе белән танцевать итүче кыз булмагач, биючеләрнең биюне бүлеп, музыканы туктатып, халыкның: «Син музыканы туктатасың? Бию тәмам булмаган бит, – дигән сүзенә каршы «Тот не ваше дело», – диючене кем диләр».

264 бит.

Йокы. «Яшен»нең 1908 елгы 3 сентябрь (30 нчы) санында «Сәгыйть» имзасы белән басылган. Тукай шигырьләрендә бу тәхәллүс башка очрамый. Шигырь астында: «Идарә. Югарыдагы шигырьләрдә, яңлышлык илә, «уку» диясе урыннарда «йокы» дип язылган. Яңадан дөресләп укуыңызны риҗа идәмез. Әгәр дә йокы шулкадәр яхшы эш булса иде, безнең татарлар күптән алга киткән булыр иде», – дигән искәрмә бирелгән.

«Яшен ташлары»нда (1912): «Сәгыйть Рәмиевтән үзгәртелде», – дип куелган. Бу әсәр С. Рәмиевнең «Әлислах»та (1907, 3 октябрь, 1 нче сан) басылган «Уку» исемле шигыренә пародия рәвешендә язылган.

Текст «Яшен ташлары»ннан (1912) алынды.

С.Рәмиев шигыре:

Безне адәм иткән уку,
Адәмне алга илткән уку,
Илтеп күккә йиткән уку,
Уку, уку, уку.

Юлымызны хак иткән уку,
Йөземезне ак иткән уку,
Үземезне баг иткән уку,

Уку, уку, уку.

Рас, чын кеше эше уку,
Багъ вә рәхәт җимеше уку,
Ачкан рәхәт ишеген уку,
Уку, уку, уку.

Гакылга нур биргән уку,
Мөкатдәс уй биргән уку,
Су юкта су биргән уку,
Уку, уку, уку.

Дәүләт, бәхет биргән уку,
Милек, тәхет биргән уку,
Безгә кирәк илла уку,
Уку, уку, уку.

Урысча да уку – уку,
Кытайча да уку – уку,
Кемчә генә дә уку – уку,
Уку, уку, уку.

Ирләргә дә фарыз уку,
Кызларга да фарыз уку,
Фарыз эшнең барсы уку,
Уку, уку, уку

265 бит.

Мәхәббәт. «Әлислах»ның 1908 елгы 30 сентябрь (47 нче) санында «Г.Тукай» имзасы белән басылган, «Габдулла Тукаев диваны»на (1908) кертелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

1 Фәрһад, Мәҗнүн – Урта гасыр шәрекъ шигъриятендә еш тасвирланган, шашкын мәхәббәтне гәүдәләндергән образлар.

266 бит.

Төлке һәм йөзем җимеше. «Әлислах»ның 1908 елгы 13 октябрь (48 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган, соңыннан «Габдулла Тукаев диваны»на (1908) кертелгән. Газетада шигырьнең исеме астында «Крыловтан» дип куелган һәм җиденче юл «Озак зәхмәтләнеп» дип башлана.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

Әсәрне И.А.Крыловның (1769–1844) «Лисица и виноград» исемле мәсәленнән иҗади тәрҗемә иткән. Крылов үзе исә, Жан Лафонтен (1621–1695) мәсәлен нигез итеп алып, рус халкына хас деталь белән баетып, милли әсәр тудырган. Ул шигырь түбәндәгечә бирелә:

Голодная кума Лиса залезла в сад;
В нем винограду кисти рделись.
У кумушки глаза и зубы разгорелись,
А кисти сочные как яхонты горят;
Лишь то беда, висят они высоко:
Отколь и как она к ним ни зайдет,
Хоть видит око,
Да зуб неймет.
Пробившись попусту час целый,
Пошла и говорит с досадою: «Ну, что ж!
На взгляд-то он хорош,
Да зелен – ягодки нет зрелой:
Тотчас оскомину набьешь».

267 бит.

Бәйрәм бүген. «Әлислах»ның 1908 елгы 13 октябрь (48 нче) санында «Төлке һәм йөзем җимеше» исемле мәсәл белән бергә «Г.Тукай» имзасы астында басылган, «Габдулла Тукаев диваны»на (1908) кертелгән. «Диван»нан алып, аны Петербургта нәшер ителгән «Нур» газетасы да (1910, 29 ноябрь) күчереп баса. «Әлислах»та икенче юл «Нәрсәдән бу? – Билгеле, бәйрәм бүген, бәйрәм бүген» рәвешендә килә.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

1 ... бәйрәм бүген, бәйрәм бүген – Тукай бу урында мөселманнарның изге бәйрәме – Ураза гаетен искә ала. Бәйрәм 1908 елда 1–2 октябрь көннәренә туры килгән.

268 бит.

Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш. 1908 елда язылган һәм шул ук елда аерым китап булып басылган. («“Шигырь көтепханәсе”ннән 7 нче дәфтәр». Казан, И.Н.Харитонов литотипографиясе; тышлыкның 4 нче битендә Шәрәф типографиясе, 1908 дип язылган.) Шул ук елның декабрь аенда әсәрнең икенче басмасы да дөнья күрә. Текст шуннан алынды. «Әлислах»ның 1908 елгы 13 октябрь санында Купеческое собрание залында (хәзерге Островский урамындагы Яшь тамашачылар театры бинасы) 14 октябрьдә әдәбият кичәсендә Г.Тукай үзенең «Кызыклы гыйшык» һәм «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасын укыячагы турында хәбәр урнаштырылган. Бу кичәгә катнашкан Ф.Әмирхан үзенең «Әлислах»та бастырган бәяләмәсендә болай ди: «Тукаев бу әсәрен ислахчыларның соңгы әдәбият кичәләрендә укыганда, халык, җөмлә тәмам булганын да көтә алмыйчан, самими бер көлкегә тотылып, бөтен залны тутырып кул чабалар һәм, укучыны бүлеп, әллә никадәр вакытлар туктап торырга мәҗбүр итәләр иде. Вакыйган да, бу әсәр татар әдәбиятында шигырь белән язылган көлкеләрнең иң мөкәммәл вә максудына иң муафикъ чыкканыдыр. Тукаев монда Печән базары мәгыйшәтенең иң садә вә иң горфи генә эшләрен дә шулкадәр көлкеле итеп тасвир итә ки, укучы ихтыярын кулыннан җибәрә /.../ Тукаевның бу әсәрен һәм «Яшен»дә көлке шигырьләрен укый торгач, аңар татар галәменең иң оста юмористы диясем килә башлады» («Әлислах», 1908, 24 ноябрь, 52 нче сан). 1908 елның 26 октябрендә Ф.Әмирхан Оренбургтагы дусты Исмәгыйль Аитовка

язган хатында да: «Безнең әдәбият кичәсе»ндә Тукаевның «Кисекбаш»ы укылды (үзе укыды). Халыкның көлә-көлә эчләре катты, һәм Тукаевны да бүлә-бүлә кул чабу белән сыйладылар».

«Йолдыз» газетасының 324 нче һәм 326 нчы саннарында, «Әлислах»ның 5 ноябрь (50 нче) санында поэманың басылуы турында игъланнар урнаштырылган. Татар вакытлы матбугатында поэманың икенче басмасы басылуы турында да хәбәр ителгән. Татар вакытлы матбугаты поэманың нәшер ителүен хуплап каршы алса, «Чүкеч» журналы («Әлислах» белән ике арадагы фикер каршылыклары булуы нәтиҗәсендә) поэмага башкача тискәре мөнәсәбәт белдергән. Мәсәлән, аның 1908 елгы 60 нчы санында мондый юллар бар: «Музейханәдә Борһан әфәнденең камчат бүрегене жиртовать итү тугърысында бер авыздан камчат бүрекне кабул идәргә ике кешедән комиссия сайлап, 32 сәнә киеп йөргән ислам такиясе дә жиртовать идәргә үтенергә карар биргән.

Шымчы Вәлинең үтенүе буенча, Габдулла Тукаевтан «Яңа Кисекбаш» кеби итеп «Камчатбаш» нам китап язарга үтенергә, Ишморатов Габдрахманнан шул китапны нәшер идәргә, Ишмөхәммәд дамелладан шул китапка цензурны рөхсәт бирүне үтенергә карар биреп, Садыйк мулла Иманкуловка йиренә йиткерергә тапшырылды». Журналның 65 нче санында да поэмага таш ату сизелә. Анда: «Яңа Кисекбаш»тагы «бармак яный» сүзе дөрест булып, адәмнең бармагы башында була башлаган», – дигән сүзләр бар.

Әсәр урта гасыр шәрекъ әдәбиятының XIV–XV йөзләр шигъри ядкярләре, төрки-татар телендәге дини-дидактик «Кисекбаш китабы»на нәзыйрә (охшату) рәвешендә язылган. Ул әсәр түбәндәгечә башланып китә:

Башлагали сүзи бисмилла илә,
Дурушалым төн вә көн Алла илә.
Үстүмездә Хакны хазир күрәлем,
Мостафаның җәмгатенә ирәлем.
Сүзләгәем бер хуб изгү дастан,
Кем күңелләр шады кыйлгай дустан.
Дөньяда бер хуб-хуб эшләр куп торур,
Һич муның тик бери тәкый юк торур.
Бер хикайәт кәлде телемгә арый,
Сүзләкәймен хак кыйлур ирсә ярый...

1 Печән базары – XVIII–XX гасырның 30 нчы еллары башында Казандагы сәүдә һәм иҗтимагый-мәдәни үзәк. Иске Татар бистәсендәге Шәрекъ базарына хас туры почмаклы озынча киң базар мәйданы, аның тирәли кибетләр, кунакханәләр, мунчалар комплексы тезелгән була.

2 Ат кәмите, Микитин җәмгате – Казанда 1890 елда бертуган рус цирк артистлары Петр Александрович (1846–1924) һәм Аким Александрович (1849–1917) Никитиннар тарафыннан оештырылган цирк. Татарлар циркны исә «ат кәмите» дип, Никитинны «Микитин» дип йөрткәннәр.

3 ...Мөселман пәһлеван – циркта французча көрәшеп йөргән Карәхмәт кушаматлы кеше. «Мөселман батыр»ның «кяфер батыр»лар белән көрәшүе Казандагы татарларны аеруча кызыксындырган. Цирк хуҗасы Никитин, үзенең керемен күбәйтү өчен, бу хәлдән

бик оста файдаланган. Печән базары татарлары күпләп-күпләп циркка йөри башлыйлар. Яңа чыга башлаган «Яшен» журналы бу вакыйганы сатира угы астына ала. Менә шундый чыгышлардан бер өзек: «Бу көннәрдә Казанга ат кәмитендә көрәшергә Карәхмәт исемле бер төрек килде. Буның килүе Казан халкының милли хисләрене ни дәрәҗәдә ирештергәнлегене тәүсыйф кыйлып бетерергә мөмкин түгел. Хәтта күп кешеләр намаз артыннан да буның өчен дога кыйлалар. Һәм тиз көндә догалыклар бастыра торган бер китап ширкәте үз матбагаларында «Карәхмәт догасы» дигән бер дога бастырачак, имеш. Хәзер Печән базарында, мәсҗедләрдә дә буның өчен дога кыйлуны муллалардан үтенү өчен бер кәгазьгә кул куйдырып йөриләр» («Яшен». 1908. 2 нче сан. 10 сентябрь) .

4 Зәркум, Салсал, Сәет-Баттал – Көнчыгыш халыкларында әкият батырлары.

5 ... «Көфер почмагы»на – көфер почмагы Печән базарында, хәзерге Мәскәү һәм Париж Коммунасы урамнары кисешкән урында салынган Юнысов мәчете (7 нче мәчет, «Ак мәчет» дип тә йөртелгән) белән янәшәдә булган.

6 Мәскәүски якка – бу урам берничә мәртәбә исемен алыштыра. Элекке исеме Владимирский, соңрак Московскийга әйләндерелә. СССР Үзәк Башкарма Комитетының С.М.Киров исемен Татарстан АССРда мәңгеләштерү буенча 1935 ел 25 июнь карары нигезендә Московский урамга Киров дип кушыла. Соңгы елларда Московский исеме кабат кайтарыла.

7 ... Хиҗаз сәхрасыни, Җиддәсен һәм Мәккәсен, Сангасыни – Согуд Гарәбстанындагы шәһәр һәм төбәк исемнәре.

8 Кич барыр ирдем «тәтәйләр рәте»нә – Тукай бу урында XX гасыр башында Казанда булган фәхешханәләрне истә тота.

9 Дию – бу образда үзләрен «божий фирка, божий полк» дип атап йөрткән сектаның берсе – «Вәисиләр хәрәкәте» башлыгы Гайнетдин (Гайнан) Баһаветдин улы Вәисев (1873–1918) күздә тотыла. Вәисләрнең төп таләпләре – Русия кануннарына һәм җирле хакимияткә буйсынмау, фәкать шәригать кушканча, Коръәнчә яшәү, көферләр армиясендә хезмәт итмәү, ике башлы каракошлы паспортны алмау, салым түләмәү һәм башкалар. Гайнан Вәисевнең бу елларда, хәтта мөритләренең хатыннарын никахлап алып калу очраклары да булган. Мәсәлән, «Бәянелхак» газетасының 1907 елгы 20 май санында «Т.З.» имзасы белән басылган хатта: «...Бәнем төшкән җирем камчатчы Гыйззәтуллада иде. Бу кеше, Вәисиләр мөриде, бәңа әйтә: «Хак өчен җиһад итүче хакгүйләр (туры сүз сөйләүче) бар. Барыйк, аннары күрик», – дип, без аның илә барып та кердек. Һәм Гайнан безне үзе чакыртып та алды. Бәнем илә хатыным да анларга барды. Ул Гайнан бәңа: «Хатының сәңа хәрам дип, ул гына да җитмәсә, талак, талак сүзләрен бер-ике тәкрарлаганнан, хатынымны үзенә алды да калды.

Бәнем хатыным кәнди хәләл иде. Бунда һич шөбһә юк. Әмма Гайнан әллә нинди аңлашмый шәригать сүзләре сөйләп, соңра: «Сәнең хатының сәңа бу сәгать хәләл түгел, хәрам», – дидектә эшне бетерде. Халәнки, хатыным берничә сәнәдән бирле бәнем тәхте никяхында иде. Шулай булса да, гомер иткән хатынымны аерып, бәне мәхрүм итеп бирүгә әлеге без шәргый дип йөрүчеләр җиркәнмәделәр...» – диелә. Бу вакыйга моның белән генә тәмамланмый, «Бәянелхак»ның шул ук санында: «...Шул Вәиси фиркасы Гайнан үзенең мөридләрендән Самара губернасының Зәйнулла угылы Тимергалинең хатыныны аерып аларак, аны гомер иткән җәмәгатендән аерганлыкны бәян иткән мәктүб, мәзкүр Тимергали

әфәнденең үз кулы илә язылмыш һәм Әхмәтҗан Сәйдәшевкә тапшырылмыш», – дигән юлларда Гайнанның бу гамәлләрне беренче генә эшләмәвен тагын бер кат дәлилли.

10 Садри Максуди (1878–1957) – II, III Дәүләт думалары депутаты, кадетлар партиясе члены, 1917 елгы Февраль инкыйлабыннан соң татар милли хәрәкәте лидерларыннан берсе – Милли Идарә рәисе. 1918 елдан мөһаҗирлеккә китә.

11 Камчылы ишан – Габдессаттар Хуҗаев, Казанда Яңа бистәдә яшәгән ишан. Ул авыруларны камчы белән сугып «дәвалый» торган булган. «Камчылы» кушаматы шуннан килә. Тукай аны үз күзе белән күргән. Бу хакта аның замандашы, «Әлислах» газетасының редакторы Вафа Бәхтияров түбәндәгеләрне яза: «Казанның Камчылы ишаны Фатих Әмирханнарга каршы гына тора иде. Фатих Әмирханга барганда, Тукай берничә тапкыр Камчылы ишанның мәчеттән чыгып килгәнен күрде. Моннан башка тагын 1907 елның ахырында җомга көнгә каршы кич белән Фатихларда булдык. Фатихта бераз утыргач кайтырга чыктык. Без чыкканда, капка төбендә байтак җигүле атлар тора иде. Башта, бу хәлне күргәч, бер туй мәҗлесе булырга кирәк дип уйланды. Сораштыргач, Камчылы ишанның мөритләре белән гыйбадәт мәҗлесе икәнен белдек. ...Без кергәндә, өйнең залында мөритләр идәндә түгәрәкләнеп утырганнар. Түгәрәк уртасында зур чалма кигән Камчылы ишан утыра. Шау килеп, «яһу!.. яһу!.. яһу!..» дип кычкырып, тавышланып утыралар иде. Шул кычкырып утыручылар арасыннан берничәсе, сикереп торып, шул түгәрәк эчендә сикереп-кычкырып йөри башладылар. Бу күренеш Тукайны шомландырды булырга кирәк: «Әйдә, чыгабыз», – диде. Без чыгып киттек». Шунда ук истәлек авторы Тукайның Камчылы ишан турында шигырь иҗат итүен яза. Шигырь түбәндәгечә:

Күзен йомган, муен бөккән, башында чалма чорналган;
Кибән чалма кибәк башта: ишан булган имеш, хайван!

(Тукай турында истәлекләр. – Казан, 1986 ел, 82 б.)

12 Зайкин, Пугач, Медведев – циркта рус көрәшчеләре.

13 Сулда – «Әлислах» идарәханәсе – атналык газетасы, «Әлислах» шул ук исемдәге оешма органы. Газета 1907 елның 3 октябреннән 1909 елның 22 июленә кадәр Казанда басыла. (Барлыгы 68 сан.) Хәзерге Тукай урамы буенча «Нәфис» берләшмәсенә таба барганда, «Әлислах» идарәсе бинасы сул якта булган (хәзер сүтелгән).

14 Зур завод Крестовниковны...– Казан һәм Мәскәү эшмәкәре Козьма Васильевич Крестовниковның уллары Александр, Василий, Иван Казанда 1855 елда Шәм-стеарин, сабын кайнату, гөлсирин җитештерү, химия заводы оештыралар. 1871 елдан ширкәтнең атамасы «Фабрично-торговое товарищество братьев Крестовниковых на паях» дип йөртелә башлый. Совет идарәсе елларында бу предприятие М.Вахитов исемендәге комбинат дип, хәзер исә «Нәфис» акционерлык җәмгыяте дип йөртелә.

15 Иштә бу алдыңдагы күлдер – Кабан – Кабан күле Тукай заманында да серле күл булып саналган. Моңа нигез дә бар: Иван Грозный Казанны басып алганда, шәһәрнең барлык байлыгы Кабанга ташланган, дигән легенда яши. Бу легенданың серләренә төшенүгә теләү бүген дә дәвам итә. Р.Мостафин «Кабан күле серләре» китабында шул серләрне ачарга тырышкан.

16 Су анасы – бик явыз, йөзе кара... – төрле халыкларның мифларында Су бабасы, Су иясе, Су анасы, Тукай язганча, явыз, табигатькә зарар китерүче зат итеп сурәтләнә.

Мәсәлән, «Татар халык иҗаты» (Казан, 2004) китабында: «Боларның ачуларын китерсәң, алар шушы үзләре торган суда каты дулкыннар ясыйлар. Шундый суда коенган кешеләрнең кайберләрен үзләренә тартып алалар...» – дигән аңлатма бирелә.

17 Күл буеның мәдрәсә талибләре...– Казан уртасындагы Кабан күле буенда урнашкан мәдрәсәсенә (Касыймия мәдрәсәсе) XVIII гасыр ахырында нигез салына. Башта Апанай мәчетендә, 1877 елдан Исхак Юнысов акчасына Кабан күле буендагы махсус бинага урнаша. 1898 елдан 2 нче җамигъ мәчетнең имамы һәм мәдрәсәнең мөдәррисе Касыйм хәзрәт (Мөхәмммәткасыйм Салихи) исеме белән атап йөртелә. Тукай бу урында шул мәдрәсәдә укучы шәкертләрне искә ала.

18 Кәчимеский Ибырай – бөтен малын эчеп, туздырып бетергән Ибраһим исемле (Касыйм шәһәреннән) сәүдәгәр. Шул заманда бу шәхес турында җыр да чыгарылган. Тукай «Халык әдәбияты» исемле язмасында «Касыймский Ибырай» көе турында түбәндәгечә яза: «Бу – Касыйм шәһәрендәге чамадан тыш мөсриф (мал, акча туздыручы) бер байга чыгарылган көй. Касыймский Ибырай гуләйт итә-итә дә актык тунын да сата. Ахыр гомерендә бик хосранлы (үкенечле) рәвештә вафат була. «Касимский Ибырай көе» шул сәбәптән чыга».

19 Бужи фирка – Вәисиләр үзләрен «Божий фирка наҗия» (коткаручы төркем) дип атап йөрткәннәр. Тукай «наҗия» сүзен «җинаятьче» мәгънәсендәге «җания» сүзе белән алмаштырган. Г.Вәисинең 1907 елда традицион дингә каршы килгән китабы басыла. Татар матбугатында әлеге хезмәтне тәнкыйтьләгән мәкаләләр шактый басыла. Мәсәлән, «Бәянелхак» газетасының 1907 елгы саннарында «Ни эшлибез?», «Идарәдән», «Вәисиләрә мөнәсәбәт», «Җәвәһире хөкүмәт», «Баһави китабы хакында» һәм башка мәкалә-язмаларда Вәисиләр хәрәкәте тәнкыйтьләнә.

20 Баһаветдин – Гайнан Вәисевнең атасы Баһаветдин Хәмзә улы Вәисев (1804–1893), Вәисиләр хәрәкәтен башлап җибәрүче, Идел буе һәм Себер, хәтта Урта Азия мөселманнары арасында изге булып танылган Хуҗа Баһаветдин. Үзенең дингә булган карашын «Хаҗилар юлы» («Тарикы хөҗҗәтин», 1874) исемле кульязмасында тасвирлап калдыра.

21 Әллә Ханның мәсҗеде җимрелдеме? – Тукай бу урында XVI гасырның беренче яртысында Казан Кремлендәге үзәк комплексның дини корылмасын күз уңында тота. Ул 3 манаралы, үзәк гөмбәзле җамигъ мәчет булган. XIX гасыр уртасында мәчет урынына «Сошествие Святого Духа» сарай чиркәве корыла.

284 бит.

«Кисекбаш»ка гыйлавә. «Әлислах»ның 1908 елгы 5 ноябрь (50 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «Ахыры бар» дип куелса да, ахыры күренмәде.

Текст «Әлислах»тан алынды.

285 бит.

Ата илә Бала. «Җуаныч» исемле җыентыкта («Сабах» көтепханәсе, И.Н.Харитонов матбагасы. «Мәктәп мөкяфәте»ннән беренче китап. Казан, 1908) басылган. Шигырь мәктәпләр өчен чыгарыла торган язу дәфтәре тышына басу өчен язылган, «Кара такта янында» дип куелган.

Текст шуннан алынды.

286 бит.

Яхшы хәбәрләр. «Җуаныч»та (1908) басылган. Текст шуннан алынды.

Әсәр шагыйрь А.Н.Плещеевнең (1823–1893) немец шагыйре һәм сәяси эшлеклесе Мориц Гартманнан (1821–1872) алып тәрҗемә иткән «Капля дождевая...» дип башланган шигыреннән иҗади файдаланып язылган. Шигырьнең русча тәрҗемәсе түбәндәгечә:

Капля дождевая
Говорит другим:
«Что мы здесь в окошко
Громко так стучим?»

Отвечают капли:
«Здесь бедняк живет,
Мы ему приносим
Весть, что хлеб растет».

288 бит.

Таз. «Җуаныч»та басылган. Әсәрнең исеме астына җәя эчендә «Бер авыл малае авызыннан» дип куелган.

Текст шуннан алынды.

1 ...Рәсемгә баксагыз. – бу шигырь беренче мәртәбә рәсем белән басылган.

290 бит.

Су анасы. «Җуаныч»та басылган. Әсәрнең исеме астына җәя эчендә «Бер авыл малае авызыннан» дип куелган.

Текст шуннан алынды.

Су бабасы, Су иясе, Су анасы турында риваятьләрнең барлыкка килүендә халыкның Табигать-Ананы илаһи зат итеп күрүдән, аның сихри көчләреннән курку, яисә хөрмәтләүдән туган ышанулардан гыйбарәт. Алар кабул ителгән дөньякүләм диннәрдәге инанулардан ерак тора. Шунысы ачык: бу образлар күп кенә халыкларның фольклорында яши, шул исәптән татар халык иҗатында да таралыш тапкан. Тукай тудырган әсәрдә Су анасы образ-сурәте классик дәрәҗәгә күтәрелә. XX гасыр башында, шагыйрь иҗат иткән «Су анасы»на кадәр дә, су анасы образын гәүдәләндергән шигъри әсәрләр бар. Мәсәлән, «Әлислах» газетасының 1908 елгы 3 апрель санында К.Исәнбаеваның «Су анасы» шигыре урнаштырылган. Ул әсәр түбәндәгечә:

I

Булды гаиб кичке якты тау артына,
Куе-куе чыршылыктан төште золмәт тау астына;
Чылтырый таш аралый суык чишмә,
Ялтырый алмаз кеби ерактан караңгыда.
Чиркандыра җылы тәнне төнге һава,
Куркындыра ярканатлар – очкан булып миңа таба;

Тавышсыз-тынсыз тау арасында
Чыгар төсле җиде башлы дәү аждаһа.
Бәрхетдәй ямь-яшел куе үләндән,
Борыныма һуш исләр сафлыгындан,
Һәммәсе җүешләнгән, чыланган күзләр кеби
Яңа төшкән алмаздай төнге чыкдан.
Кәһребаи (гәрәбәдәй) ай балкыды тау артындан;
Китмәде хәзер теге золмәт тау башындан,
Көмешдәй ялтырады түгәрәк күл –
Тирәсе чолганган таллык-камышлыкдан.

II

Балавыздай ап-ачык тәнле, тулы йөзле,
Зур күзле, урак кашлы, көлтә сачлы;
Шыпырдап чыкты күлдән бер матур хур,
Кап-кара толымнарын болгый-болгый.
Каерды айга карап зур күзләрен,
Күрсәтеп йөз, күкрәк һәм тәннәрен.
«Күрәмсең, мин матур бик» дигән кеби,
Җылмайтды чиядәй кып-кызыл иреннәрен.
Алтын тарак ялтырый хур кулында,
Нәфис сачын тарый ул күл буенда.
Әйтә ул: «Дәр күкрәгемә терәп,
Кем ятар мондый матур куйнында?
Кочар идем ул кешене бар көчемлә,
Үбәр идем нәзек кызыл ирнем илә.
Бирер идем алтын тәхет, алтын сарай
Һәм тукылган киемнәр энҗе илә».
Каһәр төшсен! Тау артыннан аучы чыкты,
Шәрә тәнле хури күргәч шып туктады.
«Этнең күзе юкка төшә» мәкаленчә,
Алтын тарак күрүбән күзе кызды!
Ач эт кеби сикерде хур өстенә.
Ләкин менгезмәде хур өстенә,
Чумды тирән күлгә, күз йомганчы,
Бер уч ком сибә-сибә «эт» күзенә.

Бу шигырьдә татар халык авыз иҗатына кергән риваятьне нигез итеп алган. Татар мифларында Су иясе азрак җүләрсымак һәм хатыныннан көнләшүче буларак сурәтләнә. Хатыны, яшь кыз булып су читенә, ай яктысына чыгып, алтын тарак белән озын чәчен тарый башласа, шунда Су иясенең бик нык көнчелеге кузгалып, судагы балыкларны куарга һәм су тегермәннәрен ерырга тотына. Ул, хатынымның йөзен ирләр күрә, дип бик курка, ди, коена торган ирләрдән бик көнләшә, ди. Нәкъ шул сюжет әлеге шигырьдә

өлешчә тасвирланган. Моңа охшаш детальләрне соңрак дөнья күргән «Егерменче гасыр кояшы. 5 нче дәфтәр. Мәшһүр рус шагыйрьләренең әсәрләрендән тәрҗемә иделмеш» исемле китапта да күрергә мөмкин. Анда да Су анасы турында ике шигырь урнаштырылып, су анасының җир кешесенә мәхәббәте сурәтләнә. Тукай шигыре исә, балаларга атап язылып, әхлакый тәрбия ягыннан үзгә әсәр, боларга охшамаган. Гомумән, югары дәрәҗәдә камил эшләнеп, тасвирый сурәтләргә бай әсәр булуы белән әһәмиятле.

293 бит.

Алтын әтәч. 1908 елда аерым китап итеп басылган (Казан, «Сабах» көтепханәсе, И.Н.Харитонов матбагасы. «Мәктәп мөкяфәте», икенче китап)*. Бу басма рәсемнәр белән чыккан. 1908 елгы басманың тышлыгында, искәрмә рәвешендә, «Пушкин хикәясеннән алынды», титул биттә (өстә) – «Пушкиннең хикәясеннән алынмыш» һәм беренче битнең астөшермәсендә: «Пушкиннең «Сказка о золотом Петушке» нам хикәясеннән алынмыш», – диелгән. Ике басмасында да сүз «Мәмәт атлы Һират** ханы» турында бара; 1918 елда чыккан «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре»ндә (Казан, «Мәгариф» көтепханәсе, 2 нче басма) «Гәрәй атлы Казан ханы» дип алынган, бүтән җыентыкларына да шулай кергән.

А.Пушкин бу әкиятне, америка язучысы В.Ирвингның (1783–1859) «Легенда об арабском звездочете» (1832) исемле новелласына нигезләнеп, 1834 елда язган, 1835 елда бастырган. Әкиятнең язылу тарихына бирелгән аңлатмада түбәндәге юллар бар: «...и представляет собой единственный случай у Пушкина, когда в основу сюжета русской народной сказки положен чисто литературный источник: шутливая новелла американского писателя В.Ирвинга «Легенда об арабском звездочете». Пушкин с удивительным мастерством заменил сложный, запутанный, обремененный посторонними деталями ход повествования Ирвинга простой, четкой, художественно выразительной композицией. А условно-литературные фантастические образы – образами русской народной поэзии». Бу фикерне Тукай тәрҗемәсенә дә әйтергә мөмкин. Беренчедән, Пушкинның әдәби әкиятендә төп герой Дадон белән башланса, Тукайда исә Һират ханы Мәмәт алына. Икенчедән, Пушкин үз әсәрендә традицион рус әкиятләренә хас:

Негде, в тридевятом царстве,
В тридесятом государстве,
Жил-был славный царь Дадон, –

дигән башламны да кулланган.

Тукай Пушкин әкиятен урта гасыр шәрекъ шигърияте нигезендә, татар мохитендә тәрбияләнгән укучыга яраклаштырып, татар халык әкиятләренә туры килгән детальләр белән баетып, иҗади тәрҗемә иткән. Әсәрдә борынгыдан килгән поэтик чараларның киң кулланылышта булуы да иҗади тәрҗемә икәнлеген күрсәтә.

Китапның икенче басмасына (1909) Г. Камал уңай бәяләмәсен язып чыга («Йолдыз». 9 март. № 373), анда «...Габдулла әфәнде бу әсәрен яшь балалар өчен язмыш вә китапның мәфһүмен Пушкинның «Золотой петушок» әсәреннән алмыштыр. Назымы гаять җиңел булу өстенә, тасвирлары да гаять шагыйранәдер...» – диелгән. (карагыз: Г.Камал. Әсәрләр: өч томда. – Казан, 2010. III т. – 171 б.).

Поэманың тексты икенче басмадан (1909) алынды.

301 бит.

Соңра. «Әлислах»ның 1908 елгы 24 ноябрь (52 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. «Лермонтовтан үзгәртелгән» дип куелган. «Габдулла Тукаев диваны»на (1908) кертелгән.

Текст «Диван»нан алынды.

Тукай бу әсәрне, М.Ю.Лермонтовның «Ответ» (1829) исемле шигыреннән иҗади тәрҗемә итеп, татар халкына хас милли бизәкләр белән баетып язган.

М.Ю.Лермонтовның шигыре түбәндәгечә:

Кто муки знал когда-нибудь
И чьи к любви закрылись вежды,
Того от страха и надежды
Вторично не забьется грудь.
Он любит мрак уединенья,
Он больше незнаком с слезой,
Пред ним исчезли упоенья
Мечты бесплодной и пустой.
Он чувств лишен: так пень лесной,
Постигнут молньей, догорает,
Погас – и скрылся жизни сок,
Он мертвых ветвей не питает, –
На нем печать оставил рок.

302 бит.

Нәрсәдән? «Яшен»нең 1908 елгы 5 декабрь (17 нче) санында «Кырмыска» имзасы белән басылган. Тукайның үзе исән чакта чыккан җыентыкларында юк. Беренче тапкыр Икетомлыкның 1 нче томына (1943) кертелгән.

Текст «Яшен»нән алынды.

1 ...әлбәт «Чүкеч» чыккан бүген – 369–371 нче битләрдәге искәрмәне карагыз.

2 ...нәфсе Байбурин нотык тоткан бүген.– Байбурин – Оренбургтан өч Дәүләт думасы депутатының берсе – Җиһангир Нургали улы Байбурин (1852–1915) турында сүз бара. Тукай аңардан күп тапкырлар көлә. «Яшен»нең 1908 елгы 10 сентябрь (2 нчы) саны тышлыгындагы бер рәсемдә Русия императоры эмблемасы сугылган трибуна артында, беләгенә башын салып, кара түбәтәйле берәү йоклый. Аска: «Депутат «Байбулыйм» Дума трибунасыннан нотык сөйләгәнен төшендә күрә», – дип язылган.

3 Бел ки, «Шура»га Бәшири борныны тыккан бүген. – 1908 елда «Шура» журналында З.Бәширинең «Картайган «кына» гөленә», «Сакла гыйффәтеңне, әй, гүзәл кыз!», «Ләззәтле хәят» исемле шигырьләре басыла.

4 Боснияне йотканда Австрия тончыккан бүген. – Босния – Балканда бер өлкә; элек Төркия кулында булып, 1907–1908 елларда Австрия-Венгрия кулына күчә, хәзер Босния һәм Герцеговина исемле конфедератив дәүләт составында. Шигырьнең шушы юлларына бәйләнештә «Яшен»нең бишенче саны тышлыгында «Сәясәт ашханәсе» дип исемләнгән рәсем бирелгән.

5 Хәзрәти шаһ, бел ки, биш-алты йәмин йоткан бүген .– Хәзрәти шаһ, дип Тукай Иран шаһы Мөхәммәдгалине атый. Шаһның йәмин йотуы – Ирандагы революцион хәрәкәт басымы астында конституция вәгъдә итүе. 1908 елда Мөхәммәдгали тәхеттән төшерелә.

«Яшен»нең өченче саны тышлыгында урнаштырылган рәсемдә кеше баш сөякләре тау-тау итеп өеп салынган. Астында: «Иран идарәи мәшрутасының нигезе», – дип язылган.

6 Нигә тулган... каткан бүген. – Мөлкәтле кешеләр үлгәч, сәдака алу өчен, муллалар, суфилар, шәкертләр, чалмалар киеп, зиратка җыела торган булганнар.

«Яшен»нең җиденче санындагы «Фидия козгыннары» дип исемләнгән рәсемдә гарәпчә язулар белән чуарланган кабер ташы тирәли чалма ураган кеше башлы, козгын гәүдә-аяклы «җанварлар» сурәтләнгән. Берсе мендәр өстендә утыра, ерактан тагын очып килгәннәре күренә. Бу – югарыдагы юлларга иллюстрация.

7 Бел: «Бәянелхак»ны бабай бер вагон саткан бүген. – Биредә халык арасында аз таралган һәм күп очракларда игъланнар бастыру белән чыгымнарын томалаган «Бәянелхак» газетасы турында сүз бара; бабай – аның нашире Ә.Сәйдәшев.

8 ...изге Корбан бәйрәме җиткән бүген – 1908 елда Корбан бәйрәме декабрьнең соңгы көннәренә туры килә.

304 бит.

Фәләннең фәләне. «Яшен»нең 1908 елгы 5 декабрь (17 нче) санында «Гөмберрт» имзасы белән «Нәрсәдән?» шигыреннән соң басылган. Тукай үзе исән вакытта дөнья күргән җыентыкларында юк. Бу әсәрне Ф.Ибраһимова «Мирас» журналының 1992 елгы 4 нче санында текстологик яктан әзерләп нәшер итә. Тукай томнарына беренче тапкыр кертелә.

Текст «Яшен»нән алынды.

1 Төрекнең тәмәкесе – ул чорда төрек тәмәкесе атаклы саналган. Татар байлары аны Истамбулдан махсус кайтартып тараткannар.

2 Испануляның үгезе – Испаниядә үгез белән сугышу тамашасы күздә тотылган булса кирәк.

3 «Болгар» – 1866 елда сәүдәгәр И.И.Апаков акчасына табыш йорты хисабына, И.И.Романов проекты буенча эклектика формасында төзелгән татар архитектура истәлеге. Г.Тукай бу кунакханәдә, кыска вакытлы күчешләрне исәпләмәгәндә, 1907–1912 елларда яши.

4 Тимершаһның «Чүкеч»е – «Чүкеч» журналының бу еллардагы нашире һәм мөхәррире Тимерша Соловьев турында сүз бара.

5 Кара гәзитәләрнең шуннан башканы язалмавы – 1905–1907 елгы инкыйлаб дулкынында дөньяга килгән татар матбугаты, татар иҗтимагый тормышына европа һәм рус мәдәнияте тәэсирендә үтеп кергән, заманы өчен прогрессив саналган идеяләрне яклаган яшь буын һәм борынгы милли-мәдәни традицияләрне югалтырга теләмәгән милләтнең күренекле зыялылары арасында каршылык туа. Бу фикер каршылыгы алар тарафыннан нәшер ителгән матбугат битләрендә дә күренә. Тукай монда шуңа ишарә итә.

6 Гурко-Литвалның бодае – 1906–1907 елларда Казан губернасында да икмәк уңмый. Күп кенә өязләрдә халык ачлыктан интегә. Хәйрия җәмгыятьләре ачларга ярдәм оештыралар. Әмма шул шартларда Эчке эшләр министры урынбасары Владимир Гурко (1863–1927) Лидваль-Ко фирмасының җитәкчесе һәм швед гражданы, Э.Лидваль,

крестьяннарны әлеге ачлыктан коткару өчен, хөкүмәт бүлеп биргән сигез йөз мең сумны үзләштерә. Шуның өчен Сенат карары белән В.Гурконы эшеннән алалар.

7 «Сабах» – 1908 елда Казанда «Болгар» номерларында ачылган китап бастырып тарату көтепханәсе. Аның хуҗалары Вәли Әхмәдуллин, Хәбибрахман Зәбири, Шиһап Әхмәровлар, китапчылыктан файда аз дип, сабын остасы алып, сабын кайнатып, сабынны көтепханәнең бер почмагында сату оештыралар. Тукай, моны күреп:

– Япуннар туп атмыйдыр, төтене җирдә ятмыйдыр.
Ялган сүзгә ышанмагыз. «Сабах» сабын сатмыйдыр, –

дип, юмор белән шигырь бастыра.

8 Йәмин – ант итү. Монда шаһның революцион хәрәкәт басымы астында халыкка конституция вәгъдә итүе турында сүз бара.

9 Печән базары – «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасына язылган искәрмәдән карагыз.

10 «Сарай» – хәзерге Париж Коммунасы урамында 9 нчы номерлы бинага урнашкан кунакханә.

305 бит.

Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә. «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) басылган.

Текст шуннан алынды.

1 Мөхәммәдзаһир – XIX йөз ахырында үзенең «Гөнаһе кәбаир», « Өлүф, яки гүзәл кыз Хәдичә», «Мавәраэннәһердә сәяхәт» исемле әсәрләре белән танылган татар язучысы, мәгърифәтче, публицист Заһир Бигиев (1870–1902) турында сүз бара.

306 бит.

Милләтчеләр. «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) басылган.

Текст шуннан алынды.

1 Көймә бата; йота торган балык өчен
Фида булган мөрәүвәтле бер җан кирәк.

Тукай монда Юныс пәйгамбәр турындагы риваятьне искә төшерә. Аллаһ Тәгаләнең Җәбраил галәйһиссәлам исемле фәрештәсе, Юныс пәйгамбәр янына килеп, Ниневи шәһәре халкын дингә өндәргә (христианнарда, Йона) чакыра. Юныс пәйгамбәр, халыкны тыңлата алмагач, өметсезлеккә төшеп, шәһәрне ташлап тауларга китә, аннары Иблис коткысы белән, Аллаһ сүзенә каршы барып, кабат шәһәргә юнәлә. Фәрештәләр аны бу адымыннан туктатырга теләсәләр дә, ул шәһәргә баруын дәвам итә. Гаиләсе белән бер диңгез янына җитәләр. Юныс пәйгамбәр бер көймә эзләп китә. Көймәгә утыргач, диңгездә көчле давыл чыга. Шунда ул үзенең Аллаһ Тәгаләдән качып баруын һәм зур гөнаһлы булуын әйтә. Шуңа карамастан юлларын дәвам итәләр. Юлчылар Юнысны, шобага салып, диңгезгә ташларга мәҗбүрләр. Аллаһ әмере белән Юныс пәйгамбәрне Зәлуха исемле балык йотып, үзендә кырык көн әсирлектә тота. Шул газаплардан соң гына, шәһәргә барып, халыкны туры юлга кертә ала.

308 бит.

Вак-төяк. «Әлислах»ның 1908 елгы 27 май (31 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Газетада «Шекспирдән («Китә рәхәт...»)» шигыре белән бергә бирелеп, бер имза астында нәшер ителгән. «Габдулла Тукаев диваны»на (1908) кертелгән.

Текст «Габдулла Тукаев диваны»ннан алынды.

Тукай А.С.Пушкинның «Евгений Онегин» шигъри романындагы

Врагов имеет в мире всяк,
Но от друзей спаси нас, боже! –

дигән ике юлны иҗади тәрҗемә иткән.

309 бит.

Төрекчәдән. («Кайсы тир кем...»). «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) басылган.

Текст шуннан алынды.

1 Сәлсәбил – дини мифология буенча, җәннәттәге татлы сулы чишмә.

310 бит.

*** («Сөю шигъре – агач аттыр...»). «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) басылган.

Текст шуннан алынды.

«Ялт-йолт» журналының 1911 елгы 27 сентябрь (11 нче) санында түбәндәге юллар бар: «Сөаль: – «Вакыт» ни өчен бу исемне сайлаган? – Җавап: «Бер вакытта бертөрле язып та, «Ни өчен болай?» дисәң, «Безнең гәзитәнең исеме дә «Вакыт» дияр өчен...» («Гәзитә вә журнал исемнәренә»). Шигырь һәм бу юллар «Вакыт»ның, җитди әсәрләр генә басабыз дисә дә, кайчак чиле-пешле шигырьләргә дә урын бирүенә ишарәли.

311 бит.

*** («Яшь бала ул нәрсә белсен...»). «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) басылган.

Текст шуннан алынды.

1 Шәһид-тәҗвид язып шөһрәт ала.– «Фәнел тәҗвид» язган Шәһид Гауни (Рәҗәпов) дигән кеше.

2 Тәҗвид – Коръәнне дөрес укырга өйрәтүче китап.

312 бит.

Булмаса. – «Габдулла Тукаев диваны»нда (1908) басылган. Текст шуннан алынды.

313 бит.

...гә (Ядкяр). «Габдулла Тукаев диваны»нда һәм «Әлислах»ның 1909 елгы 8 январь (56 нчы) санында басылган. Текст «Диван»нан алынды.

Тукайның замандашларыннан Каюм Мостакаевның (1883–1974) истәлегенә караганда, бу шигырь С.Рәмиевнең «Бәянелхак» газетасы хуҗалары Әхмәтҗан һәм Мөхәммәтҗан Сәйдәшевләргә хезмәткә керүе уңае белән язылган.

1 Зәмзәм чишмәсе – Мәккә шәһәрендә Кәгъбә янындагы кое исеме. Минераль матдәләргә бай бу суны хаҗга баручылар махсус савытларга тутырып алып кайталар, ул озак саклануы белән үзенчәлекле.

Кушымта

Тукайга нисбәт ителгән шигырьләр (1901–1907)

314 бит.

*** («Укыгыз, кызлар...»). Тукай үзе исән чагында басылмаган. Уральскида «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә Тукай белән бергә укыган Шәриф Каюмов, аның шигыре дип, үзенең истәлекләрендә китерә. (Бу истәлек Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында саклана. Шигырьнең язылу датасы мәгълүм түгел, шулай да аны 1901 ел ахыры яки 1902 ел башында (Ш.Каюмов «Мотыйгыя»гә 1902 елның көзендә килә) язылган өйрәнчек шигырьләренең берсе дип кабул итәргә мөмкин. Беренче тапкыр беренче дүрттомлыкның 1 нче томында (1955) «Искәрмәләр»гә керештә китерелгән. Аннары икенче дүрттомлыкның 1 нче томында (1975) « Өйрәнчек шигырьләр» бүлегенә урнаштырылган.

Текст Ш. Каюмов истәлекләреннән алынды.

«Бервакыт җәй көне, – дип яза Ш.Каюмов, – мәдрәсәгә Тукай янына Ярулла мөәззин килә. Мәдрәсәдә тактадан бүленгән бердәнбер бүлмәдә Тукай тора иде. Ярулла мөәззингә мин самавыр кайнатып өлгертәм. Чәй янында мөәззин Тукайга җырларга куша. Тукай, бер-ике җыр җырлагач, мулла кызларына карата болай җырлый башлый...» (Шуннан соң Ш.Каюмов «Укыгыз, кызлар, укыгыз!»ны китерә.) «Тукай Ярулла мөәззиннең буйга җиткән ике кызы барын белеп җырлый иде. Тукай кешенең күз алдында тәнкыйть итә, һич тайчанмый, оялмый, баш ими, тәрилкә тотмый; аңарда ирек сөючәнлек зур иде». («Тукай турында истәлекләр». – 65 б.).

315 бит.

*** («Мөгаллим Нурый...»). Тукай үзе исән чагында басылмаган. Ш.Каюмов истәлекләреннән алып, беренче дүрттомлыкның 1 нче томы «Искәрмәләр»енә керештә китерелгән. Язылу датасы куелмаган. «Тукайның 1905 елга чаклы ук язылган» шигырьләреннән берсе дип кенә күрсәтелгән. Икенче дүрттомлыкның 1 нче томында « Өйрәнчек шигырьләр» бүлегенә урнаштырылган. Замандашларының Тукай турындагы хатирәләреннән шигырьнең язылу вакыты 1902 ел ахыры яки 1903 ел башы булырга тиеш дигән нәтиҗә чыга. Мисырда укып, 1902 елда Уральскига кайткан һәм әтисе Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтуллин (1860–1920) урынына мәдрәсәдә «һәртөрле дәрес әйтә башлаган» Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин «Оренбург вилайәтеннән Нуриәхмәт исемле бер ысулы җәдидә мөгаллиме килгән» булуын әйтә. Мәдрәсә җитәкчелеге, дөресрәге, мәдрәсәнең почетлы караучысы сәүдәгәр-миллионер Мортаза Гобәйдуллин, башка мөгаллимнәрдән тартып алып, «барча кечкенә шәкертләрне» Нуриәхмәт хәлфәгә биргән. Шул сәбәпле элекке «хәлфәләр арасында байтак низаглар булып, мәдрәсәбездәге бик күп зур шәкертләр... үзләренчә забастовка ясап, мәдрәсәдән чыгып киткәннәр иде...» (Тукай турында истәлекләр. – 33 б.).

Кем соң ул Нуриәхмәт хәлфә (ягъни шигырьдәге мөгаллим Нурый)? Ул әлеге сәүдәгәр, «Мотыйгыя»нең попечителе Мортаза Гобәйдуллинның кияве икән. «Надан, әхлаксыз, аумакай-монафикъ табигатьле, солдаттан калу өчен, әллә нәрсәләр эчеп, үзен бозган, авызы кыйшаеп, күзе зәгыйфьләнеп калган абруйсыз бер зат. Мәдрәсә тормышының уртасында кайнаган уналты яшьлек Тукай киләчәктә иҗат ителәчәк сатирик әсәрләренә

үзенә күрә бертөрле аккорд булган бу «өйрәнчек» шигырен менә шушындый шартлар эчендә язган» (Р.Гайнанов).

Сәүдәгәр Мортаза Гобәйдуллин, К.Мотыйгыйдан типографиясе белән бергә «Әлгасрелҗәдид» журналын, «Фикер» газетасын сатып алгач, надан киявен – Тукайның шушындый үтергеч тәнкыйть-сыйфатлавына лаек булган Нурый хәлфәне – хәтта газета редакторы итеп куярга да тартынмый. Текст Ш.Каюмов истәлегеннән алып басылды.

316 бит.

*** («Туйга бардым...»). Тукай үзе исән чагында басылмаган. Ш.Каюмов истәлекләреннән алып, Беренче дүрттомлыкның 1 нче томы «Искәрмәләр»енә керештә китерелгән. Язылу датасы юк. «Тукайның 1905 елга чаклы ук язылган» шигырьләреннән берсе дип кенә күрсәтелгән. Икенче дүрттомлыкның 1 нче томында « Өйрәнчек шигырьләр» бүлегенә урнаштырылган.

Бу шигырь миллионер М. Гобәйдуллинның улы яшь сәүдәгәр Садыйк Гобәйдуллинның (1880–1929) туена барып кайткач язылган. Туй исә 1903 елның көз башында булган; димәк, шигырь дә шушы вакытта, вакыйганың «кайнар эзеннән» һәм экспромт буларак («Туйга бардым мин бүген...») язылган.

Ә бер елдан соң Тукай мондый юлларны яза: «Бай угылы Садыйк Гобәйдуллин яңа хатынын хәбестә саклайур, хәтта нә мәҗлесләргә алып чыксын, нә үзе мәҗлес җыйсын. Артык әсир төшерде вә кыйный да, имеш» (кулъязма «Әлгасрелҗәдид», 1904, 19 октябрь, 12 нче сан; Татарстан Республикасының Милли музеенда саклана).

Текст Ш. Каюмов истәлегеннән алып басылды.

317 бит.

*** («Сәнгә хезмәтдер мәрамем...»). Кулъязма «Әлгасрелҗәдид»нең 1904 елгы 14 октябрь (11 нче) санында журналның исеме астына, гриф куя торган урынга, укучыларга мөрәҗәгать рәвешендә имзасыз һәм исемсез урнаштырылган. «Фикер» гәзитәсенә генә махсус түгел», «Гәзитә мөрәттибләренә» шигырьләренең дә шул ук рәвешле басылуы, тел-стиле «Сәнгә хезмәттер мәрамем...»не Тукайныкы дип расларга мөмкинлек бирә. Беренче тапкыр Икенче дүрттомлыкның 2 нче томында (1976) «Тукайныкы булуы ихтимал шигырьләр» бүлегенә кертелгән.

Текст кулъязма журналдан алып басылды.

318 бит.

Мә, мә, мә! – Беренче тапкыр, Тукайның замандашы Каюм Мостакаев истәлегеннән алып, Беренче дүрттомлыкның 1 нче томында (1955) «Искәрмәләр»гә керештә китерелгән. Истәлектән күренүенчә, Тукай бу шигырен үзенең өстәл тартмасында гына саклаган, һәм К.Мостакаев, Тукайның рөхсәте белән, аны шуннан күчереп алган.

Текст истәлектән алынды.

319 бит.

*** («Безнең әти аягында...»). Кулъязма «Әлгасрелҗәдид»нең 1905 елгы 13 гыйнвар (3 нче) санында урнаштырылган. Җырлар өстендә түбәндәге юллар бар: «Дәһа бер мәгърифәтдин мәхрүм улан бай углына килән сылу кызлардан беренең ашагыйдагы язылмыш бәетләри нәркис күзләрендә яшь акызыб җырлаганы мәсмугымыз улыб, сынык

күңелемезгә пәк тәэсир әйләдекендин ичүн журналымызда дәрҗ әйләдек. Аягына таш бәйләп суга салу кеби, йөрәкләренең йимеши улан, җәннәт хуриләренә мөшабиһ сылу-сылу кызларыны белмәгән, сынамаган кияүгә биргәнләрең бичара кызларының күңелләрендә ушбу бәетләрнең мәзмуненә мөшабиһ яшерен утка ягучы пәк чукдыр. Манәхмә фида улан бәетләрең сурәте буйләдер» («Надан бер бай улына чыккан кызлардан берсенең түбәндә китерелгән җырларны матур күзләреннән яшь агызып җырлаганын ишетеп, сынык күңелебезгә бик нык тәэсир иткәнгә күрә, журналыбызда бирдек. Аягына таш бәйләп суга салу кебек, йөрәк җимеше булган, җәннәттәге хур кызларына тиң сылу-сылу кызларын белмәгән-сынамаган кияүгә биреп, бичара кызларын шушы җырларда чагылган яшерен утка салучылар бик күп. Без телгә алган җырлар түбәндәгечә»).

Беренче тапкыр Икенче дүрттомлыкның 2 нче томына (1976) кертелде. Текст кулъязма журналдан алынды.

320 бит.

*** («Әй җанашым, Гаделбану!). 1979 елда М.Сабирҗановадан (1891–1982) М.Әхмәтҗанов язып алган истәлектә* китерелгән. Истәлектән күренгәнчә, Тукай Уральскида Гаделбану исемле бер кызга гыйшык тотып йөргән, тик кыз Габдуллага карамаган. «Тукайның кызга әйткән сүзе бар», – ди дә истәлек авторы әлеге икеюллыкны китерә.

Текст истәлектән алынды.

321 бит.

Әйтәсем килә. «Уклар»ның 1906 елгы 1 июнь (1 нче) санында имзасыз басылган. «Уклар» журналының һәр санында зур урын алган темага – хатын-кызны азат итү, «чапан астыннан чыгару» темасына язылган бүтән шигырьләре, парчалары һәм мәкаләләре, теле-стиле, бохаралыларның кыргый гадәтләренә карата нәфрәтле сүзләре белән бу шигырь Тукайныкы икәнлегенә ышандыра. Ф.Сәйфи-Казанлы аны Өчтомлыкның 1 нче томында (1929) «Тукайга нисбәт ителгән шигырьләр» бүлегенә керткән.

Текст «Уклар»дан алынды.

322 бит.

Ахырзаман галәмәте. «Фикер»нең 1907 елгы 12 гыйнвар (2 нче) санында «Мөәррих» («Тарихчы») псевдонимы белән басылган.

Г.Тукай, «Бакырган китабы» дип йөртелгән шигъри җыентыктагы төрле шигырьләрнең стиленнән һәм формасыннан, ритм, рифмасыннан файдаланып, «Хатирәи «Бакырган», «Дөнья бу, йа!», «Тотса мәскәүләр якаң» һ.б. әсәрләрен яза. Бу «Ахырзаман галәмәте» шигыре дә шулар рәтеннән. Ул «Бакырган китабы»ндагы «Килең, дустлар, бу дөнья кичде – ахыр булдия» дип башланган шигырь калыбына салынган.

Текст «Фикер»дән алынды.

323 бит.

Кайгыру!.. «Фикер»нең 1907 елгы 22 февраль (8 нче) санында «Болгар» псевдонимы белән басылган. Тукайның мәгълүм «Государственная Думага» әсәре дөнья күргәннән («Фикер». – 1906. – 22 октябрь) төгәл дүрт ай соң басылып чыккан бу шигырь алдагысына

формасы (сорау куеп, аңа җавап бирү алымы), аерым сүзләре һәм гыйбарәләре («золым», «залимнәр», «залим башлыклар», «залим байлар», «фәкыйрь халык», «бичара ач халыклар», «ач-ялангач мужиклар» һ.б.) белән генә түгел, бәлки бөтен рухы, мәгънәсе белән бик якын тора, ике шигырь логик нык береккән. «Государственная думага»ны патша Дәүләт думасына караштa, мөнәсәбәттә – беренче этап, «Кайгыру»ны икенче этап дип карарга мөмкин. Беренче этапта Думага пассив кына булса да ышаныч бар, икенче этапта исә ышаныч сулларга гына.

«Кайгыру»да Тукайның бүтән шигырьләрендәге мотивларга, образ-гыйбарәләргә бик якын торган юллар да бар:

Каты золым качан чумар,
Чын иркенлек качан чыгар?

«Чын вә Ялган» (1908) шигыреннән:

Көчле кулы берлә Ялган Чынны бер суккан, ди дә,
Чын батып киткән, ди, чыкмаска җиһанга мәңгегә!

Яки «Кайгыру»дагы:

Үземез йокласак, дустлар,
Кемнәр безнең хәлне карар? –

дигән юлларны бу шигырьдән бер елдан артык алда язылып басылган «Иттифакъ хакында» (1905) әсәрендәге юллары янына куеп карыйк:

Җитәр, йокламыйк һаман...
Кайчанга чаклы татар
Ушбу уйкуда ятар, –

Шулай итеп, «Болгар» псевдонимы белән басылган «Кайгыру» шигыре Тукайныкы булуы ихтимал.

Текст «Фикер»дән алынды.

324 бит.

*** («Какма кеше капкасын...». «Фикер»нең 1907 елгы 22 февраль (8 нче) санында «Кешегә казыган чокырга үзең төшү» дигән имзасыз мәкалә ахырына урнаштырылган. Мәкаләдә, Нигъмәтулла Бәхтизин дигән кешене (Уральскида «Казан» кунакханәсен тотучы сәүдәгәрләрнең берсе) әшәке сүзләр белән хурлавы өчен, «Уральский Сәйдәшев» дип йөртелгән әхлаксыз миллионер-сәүдәгәр Хәйрулла Гаделшинне өч көнгә төрмәгә ябу яки 15 сум штрафка тартулары турында сөйләнә.

Текст «Фикер»дән алынды.

## Габдулла Тукайның кыскача тәрҗемәи хәле

Габдулла Тукай 1886 елның 26 апрелендә Казан өязенең Мәңгәр волосте (хәзерге Татарстан Республикасының Арча районы) Кушлавыч авылында указлы мулла Мөхәммәтгариф Мөхәммәтгалим улы һәм Бибимәмдүдә Зиннәтулла кызы гаиләсендә туа.

Габдуллага нибары дүрт ай ярым булганда, әтисе үлеп китә, һәм ул әнисе белән Өчиледәге бабасы Зиннәтулла йортына кайта. Бераздан Сасна авылы (хәзерге Балтач районы) мулласы Мөхәммәтшакир Фәйзуллинга кияүгә чыккан Мәмдүдә, декабрь аенда кечкенә Габдулланы, Кушлавычка алып барып, Шәрифә исемле карчыкка вакытлыча асрамага биреп калдыра. Бик тиздән, 1889 елның март – апрель айларында, аны үз янына ала. Әмма 1890 елның гыйнварында әнисе дә кинәт үлеп китә. Ятим калган баланы бабасы Зиннәтулла кире үзләренә алып кайта. Бу вакытларда Идел буенда каты ачлык хөкем сөрү сәбәпле, ишле гаиләнең дә тормышы гаять авыр була һәм, нәни Габдулланы бер авыл ямщигына утыртып, Казанга озаталар. Яңа бистә кешеләре – Мөхәммәтвәли белән Газизә – Габдулланы уллыкка алалар. Тик монда да аңа озак яшәргә туры килми, кинәттән авырып киткән әти-әниләре баланы бабасына кайтарталар. Берничә айдан Зиннәтулла Габдулланы Кырлай кешесе Сәгъдигә асрамага биреп җибәрә. Ул бу авылда ике еллап яши, башта абыстайга, аннары мәдрәсәгә йөреп укый. 1894 елның көзендә аны әтисенең бертуган апасы Газизә белән җизнәсе Галиәсгар Госманов үз яннарына – Уральскига алдыралар. Монда Г.Тукай унөч ел яши, «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укый, өч ел буе рус классына йөри. 1905 елгы вакыйгалар тәэсирендә шәһәрдә нәшер ителә башлаган «Фикер» газетасына, «Әлгасрелҗәдид», «Уклар» журналларына актив яза, лирик шагыйрь, ялкынлы публицист, сатирик һәм җәмагать эшлеклесе булып җитешә.

1907 елның октябрендә Тукай Казанга кайта, «Әлислах» газетасында, «Яшен» журналында эшли. Шул чорда ул татарның зур шагыйре булып таныла, бер-бер артлы китап-җыентыклары (барысы 33 исемдә) басылып чыга. «Ялт-йолт» журналын берүзе диярлек «тартып бара». 1911 елларда Габдулла Тукай авырый башлый, табибларга күренү дә, кымызга бару да ярдәм итми. Татарның бөек халык шагыйре дәрәҗәсенә ирешкән бер вакытта ул, том-том шигырьләрен, баллада һәм поэмаларын, балалар өчен язылган әсәрләрен, публицистик һәм сатирик мирасын замандашларына һәм киләчәк буынга мирас итеп калдырып, 1913 елның 15 апрелендә Казанның Клячкин хастаханәсендә үпкә авыруыннан вафат була.

Беренче томга кергән әсәрләрнең алфавит
тәртибендәге эчтәлеге

А


Авыл җырлары (беренче көлтә) ...................
Авыл җырлары (икенче көлтә) ....................
Авыл хатынының бала тирбәткәндә өмидләре............
Алдандым ................................
Алла гыйшкына ..............................
Алтын әтәч ................................
«Алтынга каршы» ............................
Ата илә Бала ................................
Ахырзаман галәмәте ...........................


Ә


Әдәбият ахшамы ясаучы яшьләремезгә ................

* * *(«Әй җанашым, Гаделбану!») ...................
Әйтәсем килә ...............................
«Әлгасрелҗәдид»ә маддәтән вә мәгънән иштиракь идәнләрең лисане хале нә диер? ...........................
* * * («Әхмәтсафа әфәнде...»).....................

Б

Байроннан .................................
Бәет ....................................
Бәйрәм бүген ...............................
Бәйрәм вә сабыйлык вакыты ......................
Безне урынсыз яманлыйлар ......................
* * *(«Безнең әти аягында...») .....................
Бер гәзитә идарәсе хәленнән ......................
Бер кайгы көнендә ............................
Бер манигы тәрәккъыйгә ........................
Бер рәсемгә ................................
Бер татар шагыйренең сүзләре .....................
Бер шәехнең мөнаҗате ..........................
Бишектәге бала ..............................
Борадәранә нәсыйхәт..........................
* * * («Бу көндә бер сарай ачды...»).................
Булмаса ..................................

В

Вак-төяк .................................
Вәгазь ...................................

Г

...га («И матур! иренмәче...») .....................
...га («Син дисең...») ..........................
...гә («Бай баласы бит...») .......................
...гә («Очраган юлда...») ........................
…гә (Ядкяр) ................................
Гәзитә мөрәттибләренә ..........................
* * * («Голүмең бакчасында...»)....................
Государственная думага ........................
Гыйлавә ..................................
Гыйшык бу, йа!.. .............................

Д

Дәрдемәнд дәгелмием? .........................
«Дөнья» көенә ...............................
Дөнья бу, йа! ................................

Дөньяда торыйммы? – дип киңәшләшкән дустыма..........
Дустларга бер сүз ............................

Е

Егет илә Кыз ................................

Җ

Җавап ...................................

И

И каләм!.. ................................
Ислахчыларга ...............................
Иттифакъ хакында ............................
Ифтиракъ соңында ............................
Ишек бавы................................

Й

Йокы ...................................

К

Кайгыру! .................................
* * * («Какма кеше капкасын...») .................
Кемнән ярдәм эзләргә? ..........................
Кемне сөяргә кирәк? ...........................
Кем ул? .................................
Кечкенә генә бер көйле хикәя .....................
Киңәш («Якын дустым...») .......................
«Кисекбаш»ка гыйлавә ..........................
Китмибез! ................................
Кичке азан ................................
Күз ....................................
Кулың ...................................
Күк сыер .................................
Күрдегезме? ................................
Кызык гыйшык ..............................
* * *(«Кыямәт якын килде – җир сораучы ярылды...») ......

Л

Ләззәт вә тәм нәрсәдә? ..........................

М

Мактанышу ................................
Матбага берлә уйнаган бер байга ..................

Мә, мә, мә! ..................................
* * * («Мәгатыйль кыйлды милләтне...») ..............
Мәддахе Истамбул шагыйрьләре ...................
Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр ..............
Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә ..................
Мәхбүс ..................................
Мәхәббәт .................................
Мәхвидәрмесән? .............................
Милләтә .................................
Милләтчеләр ...............................
* * *(«Мөгаллим Нурый...») ......................
Мөридләр каберстаныннан бер аваз .................
Мөтәшагыйрьгә ..............................
«Мөхәммәдия» көе ............................
«Мөхәммәдия»дән ............................
Мөхәрриргә («Китмәсен кәйфең...») .................
Мужик йокысы ..............................
Мулланың зары ..............................

Н

Нәрсәдән? ................................

О

Охшату ..................................

Ө

Өмид ...................................

П

Пар ат ...................................
Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш ..................
Пушкинә .................................
Пушкиннән ................................
Пыяла баш ................................

Р

Рәсемгә ишарә ...............................
* * * («Рөшде вар...») .........................
* * * («Руслар эш күрәләр...») .....................

С

Саташкан.................................
* * * («Сәгадәт юк...») ..........................
* * * («Сәнгә хезмәтдер мәрамем...») ................

Син булмасаң! ................................
Соңра ...................................
Сорыкортларга ..............................
Сөальләр ..................................
Сөеклемең кабер ташында ........................
Сөткә төшкән тычкан ...........................
* * * («Сөю шигъре – агач аттыр...») .................
Су анасы ..................................

Т

«Тавыш» хакында.............................
Таз .....................................
Тартар кошы сайрый...........................
Татар кызларына .............................
Тәәссер ...................................
«Тәрбиятел әтфаль»гә ..........................
Тәүлек ...................................
Театр ....................................
Теләнче ...................................
Тешләре ямьсез матурга ..........................
Тормыш ..................................
Тотса мәскәүләр якаң ...........................
Төлке һәм йөзем җимеше .........................
Төрекчәдән («Кайсы тир кем...») ...................
Төрекчәдән («Тән үстерсәң...») ....................
Туган җиремә ...............................
* * * («Тугъды, көн тугар кеби...») ..................
* * *(«Туйга бардым...») .........................

У

«Уклар» ..................................
«Уклар» журналында мөхбир уланлара тәнбиһ............
* * *(«Укыгыз, кызлар...») ........................
Улмы? – Ул... ..............................
Урланган мәгънә .............................
Утырышу ..................................

Ү

Үз-үземә ..................................
Үпкә .....................................

Ф

Фәләннең фәләне .............................
«Фикер» гәзитәсенә генә махсус түгел .................

Фөрьяд ...................................

Х

Хатирәи «Бакырган» ..........................
Хәзерге хәлемезә даир ..........................
Хөрриятә .................................
Хөррият хакында .............................
Хур кызына ................................

Ч

* * * («Чөнанча бездә...») .........................
Чын вә Ялган ...............................

Ш

Шагыйрь .................................
Шагыйрь вә Һатиф ............................
Шагыйрьгә ................................
Шатлык вә хәсрәт ............................
Шәйтанның муенына ..........................
Шәкерд, яхуд Бер тәсадеф .......................
Шекспирдән («Китә рәхәт...») ....................
Шигырь («Шималь яктан...») .....................
Шиллердән ................................
Шүрәле ..................................

Ы

Ысулы кадимче ..............................

Ю

Юаныч ..................................

Я

Яз («Тыныч торма...») .........................
Яз галәмәтләре ..............................
Янә ....................................
Японияне мөселман идәчәк голяма нәрдә? .............
Яхшы хәбәрләр ..............................
* * * («Яшь бала ул нәрсә белсен...») ................
«Яшен» журналы хакында .......................

Эчтәлек

Тукай: бөеклеге һәм фаҗигасе. Н.Ш.Хисамов ...................

Шагыйрьнең күптомлы басмалары. З.З.Рәмиев ..................

1904

* * * («Әхмәтсафа әфәнде...») ..............................
* * * («Тугъды, көн тугар кеби...») ............................

1905

* * * («Голүмең бакчасында...») ............................
* * * («Чөнанча бездә...») .................................
Мужик йокысы ......................................
Шигырь («Шималь яктан...») ..............................
* * * («Бу көндә бер сарай ачды...») ..........................
Хөррият хакында ....................................
Дустларга бер сүз ....................................
Иттифакъ хакында ....................................
Алла гыйшкына ......................................
Хәзерге хәлемезә даир ..................................

1906

* * * («Рөшде вар...») ..................................
* * * («Мәгатыйль кыйлды милләтне...») ........................
Шәкерд, яхуд бер тәсадеф ................................
Яз галәмәтләре ......................................
И каләм! ...........................................
Ифтиракъ соңында ....................................
Шагыйрь вә Һатиф ....................................
* * * («Сәгадәт юк...») .................................
«Фикер» гәзитәсенә генә махсус түгел ..........................
Мөридләр каберстаныннан бер аваз ...........................
Гыйшык бу, йа!.. .....................................
Пушкинә ...........................................
«Уклар» журналында мөхбир уланлара тәнбиһ ....................
Кечкенә генә бер көйле хикәя ..............................
Бәхре сани .........................................
Дәрдемәнд дәгелмием? ..................................
Гәзитә мөрәттибләренә ..................................
Японияне мөселман идәчәк голяма нәрәдә? .......................
Хатирәи «Бакырган» ...................................
Бәет .............................................
Сорыкортларга ......................................
Кемне сөяргә кирәк? ...................................
Татар кызларына ......................................
Мөхәрриргә («Китмәсен кәйфең...») ..........................
Мәхвидәрмесән? ......................................
Пушкиннән .........................................

Борадəранə нəсыйхəт ....................................
Хур кызына ..........................................
Пыяла баш .........................................
Рəсемгə ишарə .......................................
* * *(Кыямəт якын килде – җир сораучы ярылды...) .................
Көз .............................................
Государственная думага .................................
Миллəтə ............................................
Дөнья бу, йа! ........................................
«Мөхəммəдия» көе ....................................
Сөеклемең кабер ташында ................................
«Уклар» ..........................................
Үз-үземə ...........................................
Кичке азан ..........................................
Мактанышу .........................................
«Дөнья» көенə .......................................
Əдəбият ахшамы ясаучы яшьлəремезгə ..........................
«Əлгасрелҗəдид»ə маддəтəн вə мəгънəн иштиракь идəнлəрең лисане хале нə диер? .............................................

1907

Мəдрəсəдəн чыккан шəкертлəр ни дилəр ........................
Сөальлəр ...........................................
Шагыйрьгə ..........................................
Хөрриятə ..........................................
Тартар кошы сайрый ....................................
Телəнче ...........................................
Син булмасаң! .......................................
«Тəрбиятел əтфаль»гə ...................................
Күрдегезме? ........................................
Яз («Тыныч торма...») ..................................
Бишектəге бала ......................................
Шиллердəн .........................................
Мөтəшагыйрьгə ......................................
Пар ат ...........................................
«Тавыш» хакында .....................................
Лəззəт вə тəм нəрсəдə? ..................................
Кем ул? ...........................................
Дөньяда торыйммы? – дип киңəшлəшкəн дустыма .................
Юаныч ............................................
Бер манигы тəрəккыйгə .................................
Шүрəле ...........................................
Театр ............................................

«Алтынга каршы» .....................................
Бер татар шагыйренең сүзләре ..............................
Утырышу ..........................................
Сөткә төшкән тычкан ...................................
...га («И матур! иренмәче...») .............................
Авыл хатынының бала тирбәткәндә өмидләре ....................
Туган җиремә .......................................
Безне урынсыз яманлыйлар ...............................
Китмибез! ........................................
Матбага берлә уйнаган бер байга .............................
Мәхбүс ...........................................
Вәгазь ...........................................
Бер гәзитә идарәсе хәленнән ...............................
Ишек бавы ........................................
Байроннан .........................................
Гыйлавә ..........................................
Охшату ..........................................
Ислахчыларга .......................................
Фөрьяд ..........................................
Бәйрәм вә сабыйлык вакыты ..............................

1908

Бер шәехнең мөнаҗате ..................................
Төрекчәдән («Тән үстерсәң...») .............................
Янә .............................................
Тәәссер ..........................................
Урланган мәгънә .....................................
Егет илә Кыз ........................................
Шәйтанның муенына ..................................
Шагыйрь ..........................................
Чын вә Ялган .......................................
Тәүлек ...........................................
Бер кайгы көнендә ...................................
Саташкан ..........................................
Үпкә ............................................
Мәддахе Истамбул шагыйрьләре ............................
Шекспирдән («Китә рәхәт...») .............................
... га («Син дисең...») .................................
... гә («Бай баласы бит...») ...............................
... гә («Очраган юлда...») ................................
Алдандым ..........................................
Кызык гыйшык .....................................
Өмид ............................................
Тормыш ..........................................

Җавап ..........................................
Тешләре ямьсез матурга .................................
Кулың ...........................................
«Мөхәммәдия»дән ....................................
Күк сыер .........................................
«Яшен» журналы хакында ...............................
Тотса мәскәүләр якаң ..................................
Ысулы кадимче .....................................
* * * («Руслар эш күрәләр...») .............................
Кемнән ярдәм эзләргә? ..................................
Бер рәсемгә .......................................
Мулланың зары .....................................
Авыл җырлары (беренче көлтә) ............................
Авыл җырлары (икенче көлтә) ............................
Киңәш («Якын дустым...») ...............................
Шатлык вә хәсрәт ....................................
Улмы? – Ул... ......................................
Йокы ...........................................
Мәхәббәт .........................................
Төлке һәм йөзем җимеше ................................
Бәйрәм бүген .......................................
Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш ...........................
«Кисекбаш»ка гыйлавә ..................................
Ата илә Бала .......................................
Яхшы хәбәрләр .....................................
Таз ............................................
Су анасы .........................................
Алтын әтәч ........................................
Соңра ...........................................
Нәрсәдән? ........................................
Фәләннең фәләне ....................................
Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә ..........................
Милләтчеләр .......................................
Вак-төяк .........................................
Төрекчәдән («Кайсы тир кем...») ...........................
* * * («Сөю шигъре – агач аттыр...») ..........................
* * * («Яшь бала ул нәрсә белсен...») ..........................
Булмаса ..........................................
…гә (Ядкяр) .......................................

Тукайга нисбәт ителгән шигырьләр
(1901–1907)

* * *(«Укыгыз, кызлар...») ..............................

* * *(«Мөгаллим Нурый...») .............................
* * *(«Туйга бардым...») ................................
* * * («Сәнгә хезмәтдер мәрамем...») ........................
Мә, мә, мә! .........................................
* * *(«Безнең әти аягында...») .............................
* * *(«Әй җанашым, Гаделбану!..») ..........................
Әйтәсем килә .......................................
Ахырзаман галәмәте ..................................
Кайгыру!.. ........................................
* * * («Какма кеше капкасын...») ...........................

Искәрмә һәм аңлатмалар ................................
Габдулла Тукайның кыскача тәрҗемәи хәле ....................
Беренче томга кергән әсәрләрнең алфавит тәртибендәге эчтәлеге ......

*Табдул* – табды (тапты) ул.
*Затмыш* – зат имеш.
*Кәмаһи* – кәма һүә.

*Тәксир* – бу ике сүзнең берсе гарәп хәрефләрендә сакау «с» белән, шуңа рифмадаш икенчесе гади «с» белән бирелгән; беренчесе – «күбәйтик», икенчесе «сындырып ташлыйк» мәгънәсен бирә.

* «Шөһрәт казаныйк» мәгънәсендә.
*Буйсынучан – монда:* сүз уйнату.
*Гасрелҗәдид* – яңа гасыр.
*Бәхер – гарәп шигырендә*: үлчәү.
*Нәмер* – нә әмер.
* Исемнәре мәңге калды.
*Там* – тулы.
*Кярханә* – эш өе, мастерская, завод-фабрика.
*Зынҗырланган* – чылбырланган.
*Әләм* – ачыну.
*Мәмнүн булсын* – шатлансын.
* Теләкләрен тормышка ашыра.
*Мәзлум* – җәберләнгән (кеше).
*Гафил* – ваемсыз, пассив (кеше).
*Абразауный* (образованный) – укымышлы.
*Иттифакъ* – берләшү.
*Кәсрәт* – күплек.

*Хас вә гам* – өстен халык һәм гади халык; *бирелә*: «барыгыз да, барлык халык» мәгънәсендә.

*Нифакъ* – икейөзлелек.
*Алдале* – алда әле.
*Җәһел* – наданлык.
*Уйкуда* – йокыда.
«Кәгазьгә төшерелде, сүздән хәрефкә күчерелдеме?» мәгънәсендә.
«Аятьләр һәм сүрәләр җыйналып тәртипкә салындымы?» мәгънәсендә.
*Рәшид* – туры юлдагы, тугрылыклы, кыю, зирәк (кеше).
*Бака-бака* – (бага-бага) карый-карый.

*Мантыйк* – формаль логика.
*Саба җиле* – таң җиле.
*Гамькин* – кайгылы.
*Фазлың берлә* – рәхмәтең белән.
*Дәфгулынсын* – дәфгъ улынсын.
*Һатиф* – күктән иңгән тавыш, яшерен тавыш.
*Мөрит* – ишанга ияргән кеше.
*Сыртлан* – ерткыч хайван, шакал.
* Хәбәрче-язучы булганнарга кисәтү.
*Тәкъва* – изге.
*Әкъва* – өстен.
*Нам* – исемле.
*Хатының бер катыны* – хатынының бер гадәтен.
*Һәйбәтилә гайрәте* – курку сала торган гайрәтлелеге.
*Җәлеп итәрде хәйрәте* – хәйран итә иде.
*Бәгъзесен* – кайберсен.
*Кариэм* – укучым.
*Мөрид* – иярчен.
*Тәфгале һәп ма төрид* – (Фатыйма) ни теләсә, шуны эшли.
*Кәррә* – тапкыр.
*Һәмишә* – һаман.
*Сәнә* – ел.
*Хатының* – хатынның.
* Һәрвакыт булып тора торган хәл.
** Шул хәлдә алтынчы ел узып бара.
*Шәргый дә* – шәригатьне дә.
*Шәргың мәргы дә* – шәригать кошы да.
*Шәргың* – шәригатьнең.
*Якыша* – ярый
*Даимә* – дәвам итүче.
*Каимә һәм наимә* – уяу чакта да, йоклаганда да.
* Фәхеш белән байлык-муллык бергә сыешмас.
** Гарәпләрдә шигырьнең нинди үлчәүдә (шигъри иҗекләр саны – ритм буенча) язылганын күрсәтүче традицион алым (бетем).
*Рәнҗиерди* – рәнҗи иде.
*Тәнбиһ* – кисәтү.
*Чар-нәчар* – ирекле-ирексез.
*Бәхтияр* – бәхетле.
*Пишкадәм* – мәдрәсә курсын тәмамлап, шунда мөгаллимлек итүче яки хезмәт урыны көтеп ятучы.
*Бәхре сани* – икенче үлчәүдәге (шигырь).
*Ма гадә* – башка.
*Әксексез* – киметмичә, яшермичә, тулысынча.
* «Хәсрәт чигүче» мәгънәсендә.
*Мантыйк* – формаль логика, мәдрәсәләрдәге фәннәрдән берсе.
* Бар булдыклылыгын шуңа багышлый.
*Бильяр* – бильярд.
*«Дюшес»* – папирос исеме.
*Гасрый* – гасырны, чорны.
*Вәйран итү* – туздыру, бетерү.
*Кәррә* – кабат.

* Тарихи вә милли татар исемедер *(Г.Тукай искәрмәсе).*

*Икъбаль* – якты киләчәк.

*Мәгальурра вә билбанзай* – «ура», «банзай» дип кычкырып.

*Калан* – калган.

* Бу юл – алтын юл; котылуны теләсәң, шул юл белән бар.

*Мисле хәнҗәр* – хәнҗәр кебек.

*Мәсләк* – тоткан юл.

*Вастырок* (острог) – төрмә.
*Бең кәррә* – мең тапкыр.
*Салик* – тарафдар.
* Зур кайгың кемнәргә генә зур булып күренә соң?
*Мөшкил* – читен.
*Зәхмеңгә* – җәрәхәтеңә, авыруыңа.
*Җәһед* – тырышлык.
*Әхля* – татлырак.
*Тәмсилеңезне* – охшатылуыгызны.
*Садреңезне* – күкрәгегезне.
*Шәмсеңезме* – кояшыгызмы.
*Бәдреңезме* – тулган аегызмы.
*Биңзәр* – охшар, охшый торган.
*«Җим»еңез, «мим»еңез* – «җ» һәм «м» авазлары.
*Ань* – сулыш алырлык ара, мизгел.
* Һәм болай хокуксыз булырга сез хайваннар түгел, хокукка хаклы, хәтта бик хаклысыз.
*Җәһел* – наданлык.
*Саль* – ел.
*Шәһр* – ай.
*Бабын наданлык* – наданлык дигән бүлек.
*Әүляд* – балалар.
*Сабит* – нык.
*Әбәд* – мәңгелек.
*Санки* – гүяки, әйтерсең лә.
*Кортылмага* – котылырга.
*Пәнҗә* – тырнак.
*Эскәнҗә* – кыса, кыскыч.
*Хәүфитмә* – хәвеф итмә.
* Гүзәл кыз мәгънәсендә *(Г.Тукай искәрмәсе).*
*Фазлит* – фазыл ит.
*Зәүҗ* – ир.
*Вәли* – шулай да.
*Гаиб булу* – югалу, юкка чыгу.
*Бөйлә* – бу рәвештә.
*Шөйлә* – шулай.
*Хәүфитмә* – хәвеф итмә.
*Фәүтидәр* – фәвет итәр.
*Хәүфидеб* – хәвеф итеп.
*Әфсүн итәрсең* – «әфсен укып (сихерләп) үзеңә каратырсың» мәгънәсендә.
*Мисле пыяла* – пыяла кебек.

*Әдәп әһле* – әдәпле кешеләр.
*Мөртәсәм* – рәсемләнгән.
*Һиммәтең* – булдыклылыгың, яхшылыгың.
*Фөтүввәт* – егетлек.
*Җәһаләт* – наданлык.
*Сәфаләт* – түбәнлек.
*Гаян бит* – ачык күренеп тора бит.
*Мәҗаль* – көч.
*Мөхаль* – мөмкин түгел.
*Ычкынубән* – ычкыну белән.
*Сагымыз юк, сулымыз юк* – уңга да, сулга да китә алмыйбыз.
*Хәдденнән* – чигеннән.
*Фәрзәнде адәм* – адәм баласы (кеше).
*Хәятлар мәмат булды* – тереклек, тормыш бетте, тере җаннар үлеккә әйләнде.
*Мисале зәгъфыран* – зәгъфран кебек.
*Тәәссеф* – үкенеч.
*Золмәт* – караңгылык.
*Мисле куык* – куык кебек.
*Мазарыстанга* – каберлеккә.
*Бәһар* – яз.
*Нәһарең* – көндез.
* «Бумы» сүзе «Дума» белән рифмалаштыру өчен «бума» рәвешендә кулланылган.
*Бәхшәйлә* – бәхеш әйлә.
*Фәүтитмәсен* – фәвет итмәсен.
*Миллиятемне* – нинди милләттән булуымны.
* Дөнья бит бу!
** «Халыкка эчергән» дигән сүзләрдәге соңгы «а» һәм аның артыннан килгән «э» авазлары бер аваз булып, кушылып әйтелергә тиеш.
*Тәдавел ширбәте* – үзгәртә, бүтән халәткә алмаштыра торган эчемлек.
*Нам виреб* – исем биреп.
*Габде* – кол (габде милләт – милләт колы; габде корсак – корсак колы).
*Җәһдилә (җәһед илә)* – тырышлык белән.
*Мәсләк* – тоткан юл.
*Хәддин* – чиктән.
* *Кырылмасмы вавы* – сүз уйнату: «вәгъдәм» дигән сүзнең баштагы «в»сы кырылса, «юк» дигән мәгънәдәге «әгъдәм» сүзе килеп чыга. «Вәгъдә күп булса да, бар да бушка, юкка булмасмы?» дигән мәгънәдә.
*Инсане гали* – бөек кеше.
*Тәгали биттәвали* – туктаусыз югары күтәрелүне.
* Оригиналда шәһәрнең исеме русчалатып йомшак «к» («кяф») белән бирелә; сүз Касыйм каласы хакында.
*Хөлусән мөстәмәгъ* – ихлас белән тыңланган.
*Фи бәдьиһи вә бәгъдә* – башлангычында һәм дәвамында.
*Кәәннәһү тәсбихе рәгъд (рәгыд)* – бер-бер артлы күк күкрәгәндәй.
*Хизан* – кайгы.
*Нишан* – билге, эз.
*Гаҗиб* – искитәрлек.
*Ханәман* – ханәдан, династия.
*Әйләде тайран* – тузан кебек күккә очты.
*Галәлгомъя* – күз йомып, сукырлык белән.
*Өкешү (өкенешү)* – мактанышу.

*Шәк* – шик.

*Игътикяф* – уразадан соңгы ун көнне мәчеттә гыйбадәт кылып уздыру.

*Хуш-хой* – гүзәл холыклы.

*Әмма бәгъдә* – моннан соң.

*Галишан* – олы дәрәҗәле.

*Чалышан* – тырышкан.

*Нәхаклык* – хаксызлык.

*Нам* – исем.

*Садә «дал» да «лям»* – садә дил – беркатлы, тиз ышанучан (элекке орфографиядә күңел – «дил» сүзе ике генә хәреф – «д» һәм «л» белән генә язылган).

*Бәрбәр* – парикмахер.

*Галлямә* – бик белгеч.

*Зилләтләр* – түбәнлекләр, мәсхәрә ителүләр.

*Гыйлләттән* – авырудан.

*Ислах* – төзәтү, реформа.

*Җәһел* – наданлык.

*Зорлыкларга* – авырлыкларга.

*Шагыйль* – шөгыльләнүче.

*Тәнбиһ* – кисәтү.

*Һәрдәм* – һәрвакыт.

*Мөхәррир* – язучы.

*Бөһтаннар* – яла, нахак сүзләр.

*Хәсәдләр* – көнчелекләр.

*Сәдләр* – киртәләр, тоткарлыклар.

*Санәмнәр* – пот, идол, сыннар.

*Галиел-гальдән гали* – иң югарылардан да югары.

*Икъбаль* – якты киләчәк.

*Гыйльмә рәгъбәт сал* – гыйлемгә күңел сал.

*Гъәр* – гарьлек.

*Шәмс* – кояш.

*Мисле сәлеҗ Сангатар* – Сен-Готард тау үткелендәге (биеклеге – 2108 м) кар кебек (Альп таулары, Швейцария).

*Мәфтүн* – иярчен.

*Әфсүн* – серле дога.

* Робинсон рисаләсен укыганларга мәгълүмдер *(Г.Тукай искәрмәсе).*

*Әйа, и әһле ислам* – и мөселманнар.

*Мәнбәгъ* – чыга торган урын, чыганак, чишмә.

*Мөхәррир* – редактор.

*Җәһаләт* – наданлык.

*Кальгасендә* – шәһәрендә.

*Хәдәсханә* – бәдрәф.

*Санә Аллаһе ганилҗани* – бу җинаятьчедән Алла сакласын.

*Пишкадәм* – мәдрәсә программасын тәмам иткәч тә, аннан китмичә яшәүче карт шәкерт.

*Пишрәкме* – картракмы, искерәкме.

*Тәгаҗҗеб* – гаҗәп.

*Пис* – түбән, начар.

*Бар дорыр* – бар.

*Мөнәүвәр* – нурлы, якты.

*Әйләсен дил иһтизаз* – күңел дулкынлансын.

*Дөханы ахыр* – ахыры заманы – заман ахыры җитүен белдергән актыккы ут-төтен.
*Мәхшәр* – кыямәт (дөнья беткән) көндә яңадан терелгән кешеләрнең җыелу урыны һәм вакыты.
*Санки* – әйтерсең лә, гүя.
*Зәмһәрир* – суыклык.
*Хәрир* – ефәк.
*Халкы галәм* – дөнья халкы.
*Мәмат* – үлем.
*Хәят* – тормыш, тереклек, яшәү.
*Нарасыйдә* – яшь бала.
*Гыйрфан* – белем, культура.
*Эстәр исәң* – теләсәң.
*Мөтәшагыйрь* – шигырь язып маташучы.
*Сәнгать* – һөнәр, эш.
*Нафилә җиргә* – бушка, кирәксезгә.
*Вакты (вакыты) гаҗзеңне икърарга* – көчсезлегеңне, аптыравыңны үзең үк икърар итәргә.
*Тәшагырь итмә* – шагыйрь булган булып маташма.
* Нәрсәдә ләззәт? Чөнки азмыни ләззәтле нәрсәләр;
Ләкин аларның кайсында ләззәт тә кайсында тәм?
** Яки бер эшкә йә булмаса бер халыкка баш булмактамы?
*Әбелхәят* – тереклек суы.
*Мәст улып* – исереп.
*Аляме дөньядан* – дөнья газапларыннан.
*Каумә* – халыкка.
*Могътәбәр* – күренекле.
*Әтрафә* – тирә-юньгә.
*Нишан* – орден, медаль.
*Бәндә* – миндә.
*Бәнчә* – минемчә.
*Инсаннарга* – кешеләргә.
*Алгалмасаң* – алга алмасаң, үзеңне генә кайгыртсаң.
*Тәхриреӊ берлә* – язган әсәрең белән.
*Тәкъриреңдә* – телдән сөйләгәндә.
*Мәсләк, мәзһәб* – тоткан юл, юнәлеш.
*Хәзрәтендә* – каршысында.
*Истибдад* – деспотизм.
*Лязем* – кирәк.
*Мәрданә* – батырлык, егетлек.
*Нифакъ* – икейөзлелек.
*Касдың* – (чәнчергә) теләгең.
*Агар* – ак бул.
*Мөстәгар* – вакытлы куллану өчен генә алынган.
*Истигъдад* – булдыклылык.
*Мәзарестан* – каберлек.
* Саклан! «Тәмуг утында кыздырылган ташлар» да бар.
** Әлбәттә, бу чагыштырудан каршылык юк, и тыңлаучы.
*** Күкләр дуңгызга каршы ачулы.
*Ходадан* – котырту, аздыруга каршы.
*Манигы тәрәккыйгә* – прогресска каршы торучыга.
*Булды мәгъзуб та кыямәт* – мәңгелек газапка дучар булды.

*Тәмсилгә* – чагыштыруга.
*Тәгали ит* – югары күтәрел.
*Гонҗә* – ачылып җитмәгән чәчәк, бутон.
*Садаи хуш* – ягымлы тавыш.
*Намнары* – исемнәре.
*Сауләтләре* – батырлыклары.
*Сабрит* – сабыр ит.
*Кариэм* – укучым.
*Инсан* – кеше.
*Фөрьядларын* – зарланып елауларын.
*Асла* – һич тә.
*Дәрсе гыйбрәттер* – гыйбрәт дәреседер.
*Тәкмил итү* – камилләштерү.
*Тәхсил итү* – белем алу.
*Гали* – олы.
*Дарел-голүм* – белем йорты.
*Дарел-әдәп* – әдәп йорты.
*Һиммәт* – игелек.
*Мөддәте тулганда* – вакыты җитеп.
*Мәләк* – фәрештә.
*Дүзәх* – тәмуг, җәһәннәм.
*Җөмлә гасыйлар* – барлык гөнаһлы кешеләр.
*Чөн* – чөнки.
*Зөһед* – суфилык.
*Тәкъва* – яхшылык.
* Әгәр дә берәр укчы миңа тиешсезгә ук атса,
«Дус, бу атуың, һич ярамый» – дип әйтмим.
*Һәнүз* – һаман.
*Манигъ* – тоткар, киртә.
*Бәгъзан* – кайбер чакта.
*Хиссият* – тойгылар.
*Фәйзы* – рәхмәте.
*Фани* – бетә, үзгәрә торган.
*Ләфыз* – сүз.
*Фәләк* – күк.
*Гареш* – күк, күкнең түре.
*Галякасен* – бәйләнешен.
*Ит сөбат* – ныклык күрсәт.
*Икътибас* – файдалану.
*Фөрьядлары* – аһ ору, уфтанулары.
*Раһы гыйшкыңда* – гыйшкың юлында.
*Дәйтмичә* – дә әйтмичә.
*Бирса* – боерса.
*Иршатнамә* – таныклык.
*Гыйззәтем* – кадерлем, хөрмәтлем.
*Сайкалы* – яктыртучысы.
*Хиссеми* – тойгымны.
*Җисмеми* – гәүдәмне (үземне).
*Гаркъ итмәү* – батырмау.
*Харкъ итмәде* – яндырмау.

*Җөмләтән* – барчасы.
*Фосулы әрбәгъә* – елның дүрт вакыты.
*Сарикъ* – карак.
*Сәдакать* – турылык.
*Нифакъ выставкасы* – икейөзлелек күргәзмәсе.
*Нәзафәткә ригайәт* – арулыкка, пакьлеккә әһәмият бирү.
*Нә бөһтандыр!* – нинди яла бу!
*Гыйлем әһле* – зыялылар – укымышлылар, интеллигентлар.
*Сорганымыз* – сораганыбыз.
*Санагать* – промышленность.
*Табиблек* – врачлык.
*Мәризъ* – авыру.
*Мөһәндис* – инженер.
*Мөнкир* – инкяр итүче, танымаучы.
*Намендә* – исемендә.
*Җәсүр* – батыр.
* Гөруһе русияһ – кара йөз димәктер *(фарсыча). (Г.Тукай искәрмәсе).*
** Сезгә яхшырак булса, үзегез шунда рәхим итегез, әфәнделәр.
*Тәклиф итү* – катгый рәвештә тәкъдим итү.
*Сәкарь* – тәмуг.
*Әмсар* – шәһәрләр.
*Әгъсар* – гасырлар буенча үткән еллар.
*Гыйззе вә Җәл* – кодрәтле һәм шанлы.
*Матбага* – типография.
*Инсане гали* – бөек кеше.
*Хали* – буш.
*Һәнүз* – һаман.
*Лотфе Хактан* – Аллаһ рәхмәтеннән.
*Гари* – ялангач, шәрә.
*Гыйльмә нашир* – гыйлем таратучы.
*Нәйләем (нә әйләем)* – нишлим, ни хәл итим.
*Кабих* – кабахәт.
*Сәхи* – юмарт.
*Тәкмил итү* – төгәлләү, җитештерү.
*Гани* – бай.
*Гаүнәйләр (гавен әйләр)* – ярдәм итәр.
*Галишан* – олы дәрәҗәле.
*Каһре Хак* – Аллаһ каһәре.
*Золмәт* – караңгылык.
*Шәмс* – кояш.
*Залимең әмренә* – явызның боерыгына.
*Мәхбүс* – тоткын.
*Сада* – тавыш, аваз.
*Бөрадәр* – туган.
*Сәйритә (сәер итә)* – күчеп йөри.
*Ирексез әйләр* – ирексез итәр.
*Мәэюс* – өметсез.
*Мәхзүн* – кайгылы.
*Сәгадәт* – бәхет, уңыш.

*Нашир* – типография хуҗасы.

*Мөрәттиб* – хәреф җыючы, наборщик.
*Әзин җаниб* – кайсы яктан.
*Хәкыйрь* – хурлык.
*Мәшрубат* – эчемлек.

* Ихтар: Безнең Урал тарафында бер гадәт бар: кыз янына керәсе кияүне ишек төбендә балалар туктатып, акча сорыйлар. Балаларга акча бирмәсәләр, ишек ачылмыйдыр. Бәгъзе бер усал кияүләр балаларга, кәгазьгә төреп – бер тиенне күнә суына манып – 20 тиен сурәтендә бирәләр. Мин башка җирләрне белмим, безнең тарафларда шулай. (*Г.Тукай искәрмәсе*).

*Ризван* – оҗмах сакчысы.
*Вилдан, гыйльман* – оҗмахтагы хезмәтче егетләр.
*Ләгыль, якут, гәүһәр* – кыйммәтле ташлар.
*Ихтар* – искәртү.
*Гыйлавә* – кушымта, өстәмә.
*Җефет* – ир хатыны.
*Хөррә* – ирекле, хөр (хатын-кыз).
*Көррә* – түгәрәк, туп кебек.
*Ислах* – төзәтү, реформа (*монда:* мәктәпләрне).
*Мәтрүк, мәнси* – ташланган, онытылган.
*Тәрәкъкый* – прогресс.
*Гыйрфан җәзирәсен* – белем утравын.
*Матлуб* – теләнгән, тиешле.
*Йа Раб (Раббе)* – Йа Алла.
*Лязем булсын* – тиеш булсын.
*Зиммә* – йөкләмә, бурыч.
*Вәйран* – хәрабә хәленә килгән.
*Кәгъбә – монда:* күз токкан нәрсә мәгънәсендә.
*Фөрьяд* – аһ-зар.
*Һәнүз* – һаман.
*Ихтилялчы* – баш күтәрүче, фетнәче.
*Җасус* – шымчы.
*Жандар* – жандарм.
*Анчак* – тик, бары.
*Шул иманда* – шулай ышану яклы.
*Бәгъзан* – кайчакта.
*Рәфикъләрчә* – иптәшләрчә.
*Сәҗдә* – баш ию.
*Мәгъсум* – саф, бозылмаган.
*Мисал* – үрнәк.
*Нигъмәт* – бу урында «татлы нәрсә».
*Ля йөсьәл* – җавап бирергә мәҗбүр түгел.
*Сыйбъян* – балалар.
*Мәгъсуманә* – гөнаһсыз, пакь килеш.
*Инсан* – кеше.

*Шушы биш «къ»дан («казы», «кузый», «кыз», «каз», «кымыз» дигән сүзләрдәге «къ»лардан) аерма.

*Касдымыз* – теләгебез, максатыбыз.
*Зикремез* – һаман кабатлый торган теләгебез.
*Казы* – казылык.
*Кузый* – куй бәрәне.
*Әһлинсафлә (әһле инсаф лә)* – инсафлы кешеләр ич.

*Иштә* – менә.
*Афате нәфсә* – нәфес аздыруларына.
*Мөдавим кыйл* – дәвамлы кыл.
*Гали әйләсәң* – бөек итсәң.
* Мөнәҗҗимнәрнең (астрологларның. – *Төз.*) татарчасыдыр *(Г.Тукай искәрмәсе).*
*Оралар дәм дә хикмәттән* – тирән мәгънәле уйлар турында шапырыналар.
*Гафләт* – наданлык, аңгыралык.
*Тәәссер* – тәэсирләнү.
*Сәрләүхә* – исем.
*Тәкълид* – иярү.
*Дил* – күңел.
*Хәлас булу* – азат булу.
*Әкътагъ вә әбтәр* – кирәксез һәм яраксыз.
*Әшгаремдә* – шигырьләремдә.
*Бимәгънә* – мәгънәсезлек.
*Мәзлум* – җәбер күргән.
*Дәрхаль* – шунда ук, шул ук вакытта.
*Нәзым* – көйле әсәр.
*Мәҗалым* – көчем, тәкатем.
*Җәсәдемне* – тәнемне, гәүдәмне.
*Бәс* – димәк.
*Мәшрикъ* – көнчыгыш.
*Мәгърибкә* – көнбатышка.
*Парлаган* – яктырган.
*Ляземдер* – тиештер.
* «Все говорят» көенә җырлана иде *(Г.Тукай искәрмәсе).*
* *Та ашыйм* – ритм өчен «ташыйм» дип укылырга, әйтелергә тиеш.
*Мәҗнүн* – җүләр, шашкан.
*Сачтараш* – чәч алучы, парикмахер.
*Туратны* – туры атны.
*Җәридә* – газета.
*Мәддахе Истамбул шагыйрьләре* – Истанбулдагы мәдхияче, мактап кына язучы шагыйрьләр.
*И кашың һилал* – и яңа туган ай кебек кашлы.
*Хөснеңне* – күркәмлегеңне.
*Ядыңнан* – исеңнән, хәтереңнән.
*Мәдхияңи* – сине мактау сүзен.
*Ул синең васфеңдә: «Ля шәркыйя, ля гарбия», – ди!* – Ул, сине сыйфатлап: «Көнчыгышта да юк, көнбатышта да юк», – ди.
*Кәләмулла* – Коръән.
*Тәкълид* – иярү.
*Әмриткән (әмер иткән)* – боерган.
*Аяте Коръән* – Коръән җөмләсе.
*Тәләф* – әрәм.
*Гошшакъ* – гашыйклар.
*Җисменә* – тәненә, гәүдәсенә.
*Та кыямәт зикридәрди (зикер итәр иде)* – кыяməткә чаклы телгә алыр иде.
*Тәгъзимләү* – олылау.
*Кувәи шигъриями* – шигъри көчемне.
*Кич мине* – кичер мине.
*Вөҗүдемне* – барлыгымны.

*Бивафа* – үз сүзендә тормаучы, вәгъдәсез, вафасыз.
*Миследер* – охшаштыр.
*Шәһренә* – шәһәренә.
*Касдына* – теләгенә, ниятенә.
*Гыйсъян* – бунт, фетнә, баш күтәрү.
*Нәҗат* – котылу.
*Зәһр (зәһәр)* – агу.
*Фитъраттә гали* – яратылышында ук бөек.
*Иттифакый* – очраклы гына.
*Вәли* – шулай да.
*Ганимәт маллары* – сугышып алына торган маллар, трофей.
*Угърында* – юлында.
*Ләимнән* – саран, түбән җанлы кешедән.
*Һиммәте* – яхшылыгы, ярдәме.
*Миннәте* – мактанып сөйләве.
*Шикайәт әйләдең* – зарландың.
*Хикайәт әйләдең* – хикәяләдең, сөйләдең.
*Тәбәссем ит* – елмай.
*Гайне кодсият* – пакьлек һәм сафлык чишмәсе (яки: шуларның нәкъ үзе).
*Гыйффәт* – сафлык.
*Санки* – гүя, әйтерсең лә.
*Зәһрә тирьякътыр* – агуга дарудыр.
*Бәхренә* – диңгезенә.
*Гали* – бөек.
*Туба* – оҗмах агачы (дини мифология).
*Яңылдым юлый* – ялгыштым юлны.
*Хиҗаб каршысына* – хатын-кызның качып (битенә пәрдә ябып) йөрүенә каршы.
*Мөлхакларыңны* – иярүләреңне.
*Мәгъсыйәт уш* – шушы гөнаһны.
*Әлеңдәдер... насыйәт уш* – «шушы башым синең ихтыярыңда» дигән мәгънәдә.
*Сәтырларны* – (язмадагы) юлларны.
*Рәсүлнең* – пәйгамбәрнең.
*«Ляхәүлә»* – курыкканда укый торган дога.
*Как ты будешь отвечать там* – анда ничек җавап бирерсең.
*Сыгъмаз ирдең* – сыймас идең.
*Даже в тюрьму* – хәтта төрмәгә.
*Нет, князь, постой* – юк, князь, сабыр ит.
*Монафикъ* – икейөзле.
*Сирра* – яшерен генә.
*Фани җиһан* – бетәчәк дөнья.
*Торра* – барысы.
*Санки* – гүяки.
*Әһле фәтва* – соңгы сүзне, хәлиткеч фикерне әйтүче.
*Әүля вә әгъля* – яхшырак, уңайрак.
*Ширк вә заляләдән* – бозык уйлардан.
*Әтрафымда* – тирә-ягымда.
*Вилдан вә гыйльман* – оҗмахтагы хезмәтче егетләр.
*Бәүвабы җәннәт* – оҗмах ишеге сакчысы.
*Назы-нигъмәт* – сый-хөрмәт.
*Химайәт әйләдең* – сакладың.

* Барин, сездән егерме сум, тиз булыгыз, – тиздән сәгать бер тула.
** Акчамны... урлаганнар; этләр, урлаганнар да тайганнар.
*Час* – часть; «полиция участогы» мәгънәсендә.

* Яхшылыгын искә төшереп битәрләп тормый.
*Мәдәткә* – ярдәмгә.
*Иҗтиһад* – тырышу.
*Һәнүз* – һаман.
*Ихсанлы* – ярдәмле, кешелекле.
*Нани (нанны)* – икмәкне.
*Гайре мөмкин* – мөмкин түгел.

*Нәкъкашына* – художнигына, рәссамына.
*Игъвасына* – коткысына, вәсвәсәсенә.
*Мән* – кеше.
*Иярди* – ияр иде.
*Мәдхе сәнасында* – мактавында.

*Әһле исламда* – мөселманнарда.
*Итагать* – буйсыну.
*Тәфтиш* – тикшерү.
*Сохбәт* – сөйләшү, аңлашу.
*Мәгърифәт лязем* – аң-белем кирәк.
*Шәбаһәт* – охшау.
*Мәгъсум* – пакь, гөнаһсыз.
*Тәкфир* – «диннән чыктың, кяфер» дип әйтү.
*Җәһаләт* – наданлык.

*Самарау-кош* – сәмруг кош (мифик).
*Дарелфөнүн* – югары мәктәп, университет.
*Мөштәри* – алдан язылып газета алучы.

*Түзәйкән* – түзә икән.
*Фирисә (фирүзә)* – асылташ.
*Сахтыян (сафьян)* – яхшы сыйфатлы күн.
*Бәни* – мине.

*Анчак* – шулай.
*Шул ук хиндә* – шул ук арада.
*Илла* – фәкать, тик.
*Кемчәгнә* – кемчә генә.
*Шигъре* – шигырен.
*Гашыйкый* – гашыйкны.
*Анчак* – тик, бары.
*Барча әхраре мәхәббәт* – иң кайнар мәхәббәт ияләренең барысы.
*Зан итәм* – уйлыйм.

*Ниһаять* – «бик нык» мәгънәсендә.
*Ләгыль, якут* – кыйммәтле ташлар.

*Тәкый* – янә.
*Җиван* – таза егет.

*Шәһит ирер* – гаепсез үтерелгән.
* Көн дә бер тапкыр Корьәнне укып чыга идем.
*Тәваф итү* – әйләнеп йөрү.
*Гласныйлык* – шәһәр Думасы әгъзасы булу.
*Сәнә* – ел.
*Важиб* – тиеш.

*Яүме мәхшәр* – кыямәт көнендә.
*Җәмгулыб (җәмгъ улыб)* – җыелып.
*Итте... нида* – кычкырып җибәрде.

*Зур әйләде* – көч куеп карады.
*Тәгассыб* – фанатизм, искелекне яклау.
*Гыйнад* – тискәрелек.
*Җәһаләт* – наданлык.
*Хазирун* – шунда булучылар, тамашачылар.
* Алла ярдәм итсә.
*Газбилә (газыб илә)* – ачу белән.
*Гаһед* – сүз бирү, ант итү.
*Җөда булу* – аерылу.
*Әһле базар* – базар кешеләре.
*Сәма* – күк.
*Мәдәт* – ярдәм.

*Яльгабун* – уйнап.
*Нагяһан* – кинәттән.

*Иштә* – менә.
*Итәм бәян* – аңлатам, сөйлим.
*Гаян* – ачык.
*Карья* – авыл.
*Хәким* – белгеч, философ, галим.
*Бер дәфга* – берьюлы.
*Талиб* – шәкерт.

*Ләүхә* – язулы такта.
*Иштә* – менә.

*Сакин* – яшәүче, торучы.
*Җәлбитәрлек* – җәлеп итәрлек.
*Әнвәр әйләгән* – нурландырган.
*Кяр әйләгән* – йоккан.
*Хәлале* – хатыны.
*Болар һәп* – болар барысы да.
*Фөрьяд кыйлу* – ачынып елау.

*Ләгыйнь* – ләгънәт суккан.
*Биниһая* – чиксез.
*Мисле* – нәкъ.
*Гасый* – гөнаһлы, җинаятьче.
*Нәгъргә* – каты кычкыру.
*Нә рәсмә* – ни рәвешле.

*Гөрзи* – чукмар.
*Кариэм* – укучым.
*Хәмлитмәгә (хәмел итмәгә)* – сылтарга.
*Әһле ислам* – мөселманнар.
*Яхзәнүн* – кайгыда.
*Шул хәл* – шул мизгел.
*Әйләмәктә... интизар* – зарыгып көтәләр.

*Золмәт* – караңгылык.
*Җөмлә* – барысы.

*Шу рәсмә* – шул рәвешле.
*Аңсыздан* – кинәттән.

*Чөн* – кайчан.

*Тәкъва* – изге кеше.
*Җари кыйла* – агыза.
*Кәрамәт* – могҗиза.
*Күзилә* – күз белән.

*Гыйлавә* – өстәмә.
*Сәргаскяр* – гаскәр башы.
*Нәзмы* – көе.
*Мөкәммәл* – төгәл.
*Монтазам* – тәртипле.

*Эстәр* – эзләр.
*Мөмтаз* – аерылып тора торган.
*Гафитте* – гафу итте.
*Кыйсса* – хәл, вакыйга.
* Пушкинның «Сказка о золотом петушке» нам хикәясеннән алынмыш. *(Г.Тукай искәрмәсе).*
*Даный (даньне)* – ясакны.
*Фәган* – елау-сыктау.
*Мәшрикъ* – көнчыгыш.
*Мәгъриб* – көнбатыш.
*Мөнәҗҗим* – йолдызчы, астролог.
*Хәким* – философ, белдекле кеше, галим.
*Нам* – исемле.
*Мәснәви* – ике юллы шигырь.
*Тәвәкъкыфсез* – тоткарлыксыз.
*Дәрхаль* – шундук.

*Аманлык* – иминлек, тынычлык.
*Сарый* – якка.
*Рәван кыйлды* – җибәрде.
*Фирка* – төркем.
*Фазлит (фазыл ит)* – өстенлек бир.
*Асла* – һич тә.

*Бакый* – мәңгелек.
*Рәваннарым* – җаннарым.
*Исеркәп* – сизенеп.
*Хәҗәр* – таш.
*Шәҗәр* – агач.

*Абелхәят* – мәңгелек суы.
*Җиһат* – ян-як.
*Аңсыздан* – кинәттән.
*Тәгаҗҗеб берлә* – гаҗәпләнү белән.
*Фәкыйранә* – түбәнчелек белән.

*Хәдденңнән* – чигеңнән.
*Дәрхаль* – шунда ук.

*Шул хәл* – шул мизгел.
*Гаиб булу* – юк булу, юкка чыгу.

*Җөмлә* – бөтенесе, барысы.
*Гамь йимәс* – кайгы йотмас, кайгырмас.
*Золмәт* – караңгылык, караңгы урын.
*Газләт* – ялгызлык.

*Хиссият* – тойгылар.
*Мисле* – охшашы.
*Кәррә* – тапкыр.
*Нәфсе Байбурин* – Байбурин үзе.
*Йәмин йоту* – ант итү, ант эчү.
*Тәгассыб* – фанатизм.
*Сарт* – үзбәк.
*Бәтчә* – үзбәк баласы.
*Шадыман ул мәркадеңдә* – шат бул кабереңдә.
*Мәнси вә мәтрүк улмадың* – онытылмадың, ташланмадың.
*Газмеңдә* – ниятләгән эшеңдә.
*Манигъ түгелмен* – каршы түгелмен.
*Сәүкъ (сәвекъ) әйләр идең* – алга әйдәр идең.
*Гали* – бөек.
*Ашдыкча ашар* – ашкан саен һаман югары ашар.
*Мәхкүм* – хөкем ителгән.
*Мәсмүм* – агуланган.
*Лябед* – чарасыз.
*Хәтем* – Коръән уку.
*Фида булу* – корбан булу.
*Мөрәүвәтле* – үз-үзен кызганмаучы, башкаларга ярдәмле.
*Кәтем* – яшерү.
*Сәдакать* – турылыклы булу.
*Хәтем* – бөтен Коръәнне укып чыгу.
*Биһүдәдер* – буш, мәгънәсез эштер.
*Гыйлаҗ* – ярдәм, котылу.
*Гали* – бөек.
*Анчак вакытча* – тик вакытлы рәвештә генә.
*Мәхбүбә* – яратылган, сөелгән хатын-кыз.
* Бетмәс-төкәнмәс байлык – шагыйрьлек таҗы.
*Кодсиятең* – талантың, илһамың.
*Ләтыйф* – үтә күренә торган (гүзәл).
*Мәзахчы* – көлдерүче, шамакай.
*Анчак* – тик, бары.
*Бабына* – мәсьәләсенә, өлкәсенә.
*Михраб* – изге урын.
*Хәят* – тормыш.
*Мәгыйшәт* – тормыш-көнкүреш.
*Әдна* – бик түбән.
*Гыйззәт* – дәрәҗә.
*Хикмәт* – белем.
*Төштич* – төште ич.
* Ташла чапаныңны – хурлыкка үзеңне үзең салма, –
Бохарлылар чапаны ярый тик капларга атларга.
** Бохарлылар пылау пешерә һәм яшь егетләрне аулый.
*** Бохара бүләге ул схоластика ише авырулар;
Хатын-кызга һәм безгә дә киртә бу алга атларга.
*Мөсадиф улса* – очраса.
*Чөн* – чөнки.
*Гизмәли сәрбәст* – иркенләп йөр.
*Бәтчә зан итсен* – яшь егет, дип белсен.

*Зәүҗе* – ире.
*Бөйлә* – мондый.
*Әйләмә тәхкыйрь* – кимсетмә, хурлама.
*Угъратма* – дучар итмә.
*Тотың мәгъзур* – ихтыярсыздан шулай эшләгән, дип гафу итегез.
*Бу рәсмә бүлмәкләргә* – болай итеп аерып күрсәтеп бирүгә.
*Һәп дәм* – гел кан (канлы).
*Әм-әм* – ям-ям.
*Гыйлләт* – авыру, чир.

* Искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләгәндә, элекке елларда нәшер ителгән 3 томлык «Г.Тукай әсәрләре» (1929–1931; төзүчесе – Ф.Сэйфи-Казанлы), 2 томлык «Габдулла Тукай. Академик басма» (1943–1948; төзүчеләр – Х.Хисмәтуллин, Я.Агишев), 4 томлык «Габдулла Тукай. Әсәрләр» (1955–1956; төзүчеләр – Х.Хисмәтуллин, Я.Агишев), 4 томлык «Габдулла Тукай. Әсәрләр» (1975–1976; төзүчесе – Р.Гайнанов), 5 томлык «Габдулла Тукай. Әсәрләр»дә (1985–1986; төзүчесе – Р.Гайнанов) текстларга төзүчеләр тарафыннан язылган аңлатма һәм искәрмәләр файдаланылды.

*Нам* – исем.
*Мөндәриҗат* – эчтәлек.
*Фасих лисан үзрә* – матур тел белән.
*Хадим* – хезмәтче.
*Һәфтәлек* – атна.
*Хәмед улсын* – мактау булсын.
*Фазыйль* – галим, белемле.
*Хиддәт* – ачу.
*Шәэнени* – дәрәҗәсен.
*Сирәт* – тормыш рәвеше.
*Вәли* – ләкин.
*Сакын* – саклан.
*Тасхих* – төзәтү.
*Табгы ителгән* – басылган.

*Күңел җимешләре. Казан : «Сабах» көтепханәсе. И.Н.Харитонов матбагасы; 1911. 48 б. Моннан ары «Күңел җимешләре»ннән дип күрсәтеләчәк.

*Игътинаэ* – әһәмиять, игътибар бирү.
*Кавагыйде әдәбия* – әдәби кагыйдәләр.
*Гонваннар* – исемнәр.
*Тәхмин итәрмез* – чамаларбыз.

* Алга таба «Яшен ташлары» дип кенә күрсәтеләчәк.

*Тәгъкыйб итеп* – күзәтү ясап.
*Игътикад итә* – ышана, инана.
*Истибдадны химая өчен* – деспотизмны саклау, яклау өчен.
*Лөзүме бик бәдиһидер* – тиешлеге ап-ачык.
*Әбьят* – бәетләр; «шигырьләр» мәгънәсендә.
*Манигъ кыйлганлыкларын* – тыйганлыкларын.
*Тәрәкъкыятьтән* – прогресстан, алга китештән.
*Тәнәззелен* – артта калуын.
*Лязем булачактыр* – кирәк булачактыр.
*Угърашып* – чуалып, бәйләнешеп.
*Сахиб* – хуҗа.
*Тәхкыйрь* – хурлау, мыскыл итү. *«Габделхак» – «Бәянелхак»ны Тукай көлеп шулай атый. *Габделхак* – хаклык, дөреслек колы (хезмәтчесе) дигән сүз.

*Рәфикъ* – иптәш.
*Кифайәтләнү* – җитәр дип уйлау.
* Көннәрдән бер көн, язмыш кушуы буенча,
Кәлибүлидә яшерен генә утыра идем;
Бар халыктан кулымны селтәдем,
Телемдә – Алла исеме, күңелемдә хушлык иде.
Кәлибүлинең ул гашыйкларыннан
Берничәсе яныма килеп тезелде.
*Һәдия* – бүләк.
*Тәүсыйф кыйлып* – сыйфатлап, тасвирлап.
* «Теркәү дәфтәре»ндә китапның дөньяга чыгу вакыты 1908 ел, 14 ноябрь дип күрсәтелгән.
** *Һират* – Әфганстандагы шәһәр исеме (Герат).

Литературно-художественное издание

Тукай Габдулла
(Тукаев Габдулла Мухамметгарифович)

Сочинения

Академическое издание

В шести томах

Том 1

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Тукай Габдулла
(Тукаев Габдулла Мөхәммәтгариф улы)

Әсәрләр

Академик басма

Алты томда

1 том

Мөхәррирләре Т.Р.Шакирова, Ф.И.Фәтхетдинова, Р.Ә.Заһидуллина
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире Р.Х.Хәсәншин
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы Н.Н.Мусина
Корректорлары Г.Г.Мөхәммәтҗанова, С.З.Гыймалетдинова, Р.Ә.Фәйзуллина,

Г.Р.Ногманова, Т.Н.Сәгъдуллина, А.М.Закирова

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.04.2011. Форматы 60×90 1/16.
Басма табагы 25,5. Тиражы 3000 д. Заказ Р-490.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.